ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

6.2009



# САБАНТУЙ—ХАЛКЫМНЫҢ РУХЫНДА















# Казан утлары
# Qazan utları

2009

# 6
# (1040)

*ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:*
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

*НАШИРЕ:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru*
: **Факс**—*(843) 562-11-28.*
: **E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Марат ӘМИРХАНОВ. Гәүһәршад. *Тарихи бәян* ... 5
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Күңел сердәшләре. *Шигырьләр* ... 35
Әхсән БАЯН. Соңгы аккош җыры. *Шигырьләр* ... 54
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Үз хәлемне үзем беләм. *Хикәя* ... 58
Халисә ШИРМӘН. Кыргыйлык. *Хикәя* ... 64
Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА. Авыр тынлык. *Шигырьләр* ... 68
Рифат СӘЛАХ. Җәйсылуның яшел толымы. *Шигырьләр* ... 70

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Бәхет көлмәгә. *Тамаша* ... 40

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Илдус ИЛДАРХАНОВ. Ул бөек иде, ләкин... *(Көрәшче Шәзам Сафинның күтәрелү һәм төшү тарихы)* ... 74

**КАРДӘШ ӘДӘБИЯТЛАР**

Флера ТАРХАНОВА. Казакъның шигъри пәйгамбәре ... 93
Магҗан ҖУМАБАЕВ. Пәйгамбәр. *Шигырьләр* ... 94

**МИЛЛИ ГАМЬ**

Индус ТАҺИРОВ. Сөт калса, Ватан кайтыр ... 98

**ХӘТЕР**

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. Гумилев сабаклары ... 104
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Сагынмаска аны мөмкин түгел! ... 137
Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Ерактагы ак җилкәннәр. *Тарихи очерк* ... 140

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Төп геройлар – шәүләләр, кортлар... ... 117
Тәлгать НӘҖМИЕВ. Сабаның суында бар... ... 122

**СӘНГАТЬ**

Розалина ШАҺИЕВА. Мәңгелек белән тоташу *(Әхсән Фәтхетдиновка 70 яшь)* ... 128
Дания ГЫЙМРАНОВА. Сәхнә – илһам мәйданы ... 131
«Татар энциклопедиясе» битләреннән ... 157

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы ... 161

**ТАРИХ**

Альфред ХАЛИКОВ. Болгар-татар чыгышлы 500 рус фамилиясе ... 165

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Габдулла ГАЛИЕВ. Кәчтүм ... 167
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 186

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: историческая повесть М. АМИРХАНОВА «Гаухаршад»; рассказы Г. БАЙРАМОВОЙ, Х. ШИРМАН, Г. ГАЛИЕВА; стихи Г. ИДИЯТУЛЛИНА, А. БАЯНА, В. ХАЙРУЛЛИНОЙ, Р. САЛАХА.
«Драматургия»: пьеса Г. ГИЛЬМАНОВА «Рубашка счастья».
«Публицистика»: статья И. ТАГИРОВА «Как сохранить нацию?»; И. ИЛЬДАРХАНОВ. «Он был великим, но...» (история возвышения и падения борца Шезама Сафина).
«Братство литератур»: стихи казахского поэта М. ЖУМАБАЕВА в переводе и с предисловием Ф. Тархановой.
«Память»: статья М. ХАБИБУЛЛИНА «Уроки Гумилева»; исторический очерк Л. ХАМИДУЛЛИНА «Светлые паруса памяти»; статья Г. БАЙРАМОВОЙ об оперном певце Х. Бигичеве.
«Литературная критика»: статья Р. ШАРАФИЕВА «Тени и черви—главные герои?»; статья Т. НАЗМИЕВА о творчестве Рустема Зарипова.
«Искусство»: Р. ШАГИЕВА. «Воссоединение с вечностью» (к 70-летию А. Фатхутдинова); Д. ГИМРАНОВА. «Сцена—место вдохновения».
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение); А. ХАЛИКОВ. «500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения» (продолжение).
На наших обложках: Татарский Государственный театр оперы и балета им. М.Джалиля; писатель Зуфар ДАВЛИТОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: historical novel by M. AMIRHANOV «Gauharshad»; stories by G. BAYRAMOVA, H. SHIRMAN, G. GALIEV; verses by G. IDIYATULLINA, A. BAYAN, V. HAYRULLINA, R. SALAH.
«Dramaturgy»: piece by G. GILMANOV «Shirt of happiness».
«Journalism»: article by I. TAGIROV «How to save the nation?»; I. ILDARHANOV. «He was great, but ...» (History of rising and falling of fighter Shezam Safin).
«From creation of fraternal peoples»: poems by Kazakh poet M. ZHUMABAEV in translation and with foreword by F. Tarkhanova.
«Memory»: article by M. HABIBULLIN «Gumilyov's lessons»; history essay by L. HAMIDULLIN «Light sails of memory»; article by G. BAYRAMOVA about opera singer H. Bigichev.
«Literary Criticism»: article by R. SHARAFIEV «Shadows and worms are main characters?»; article by T. NAZMIEV about creativity of Rustem Zaripov.
«Art»: R. SHAGIEVA. «Reunification with eternity» (to 70th anniversary of A. Fathutdinov); D. GIMRANOVA. «Scene is place of inspiration».
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation); A. HALICOV. «500 Russian names of Bulgarian-Tatar origin» (continuation).
On our covers: Tatar State Opera and Ballet Theater named after M. Jalil; writer Zufar DAVLITOV.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 27.05.2009, график буенча 27.05.2009.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–732 Тираж 4510.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2009 ел.



Марат
Әмирханов

# ГӘҮҺӘРШАД

ТАРИХИ БӘЯН

Гәүһәршад көзгесен яман ачу белән идәнгә бәрде. Тик барыбер үз сурәтеннән арына алмады. Киресенчә, алар фәкать ишәйде генә. Дистәләгән көзге кыйпылчыкларының барысында да аның йөз чалымнары чагылып калган иде. Бикәнең зәһәре китте, үте-бәгыре кайнау кыяфәтенә үк бәреп чыкты. Үзен-үзе белешмичә көзге кисәкләрен аяклары белән изгәләргә керешә. Тузынды-тузынды да хәле китеп, кәнәфигә барып ауды. Аннан соң куркуыннан ишек чаршавы артына кереп поскан хадимә туташка:

—Нәрсә аңгыраеп торасың, тизрәк җыештырып ал бу чүпләрне,—дип кычкырды,—әйт анда, бүлмәдәге барча көзгеләрне дә кубарып ташласыннар!

Бикәнең көзге яратуы бөтен сарайга мәгълүм иде. Кайдан гына кайтартмады ул аларны? Бу исемлектә дистәләгән ил, дистәләгән кала: Кытай, Рум, Мәскәү, Мисыр, Таһран, Париж... Аеруча Кытай көзгеләрен үз итә иде. Күз аллары күк төтен булганчы үз-үзенә сокланып, хозурланып утырыр иде.

Чибәр иде Гәүһәршад. Йомырканың җөен табарсың, әмма дә ләкин яшь бикәнең кимчелеген таба алмассың. Шулай дип сөйлиләр иде сарайда. Йөзе мәмрәп пешкән алма кебек, бит очларына гүя чия тәлгәше орынып алган, алланып-алсуланып тора. Мондый ымсындыргыч сусыл иреннәр, томанлы ардан[1] күзләр берәүдә дә юк. Йомры иягеннән сыйпап алу өчен генә дә гомеренне бирерсен.

Хәер, бу матурлык кайбер кадими адәмнәрнең саруын да кайната иде. Мөселманнар арасында табак битле, юантык гәүдәле симез кыз-хатыннар күркәм санала. Ә бикәнең матурлыгы юләр матурлык—кара чәч, яшел күз. Нәкъ кыргый мәче инде...

Гәүһәршадның үзенә бу ошый иде. Чөнки ул—бердәнбер. Кияүнең дә

[1] Ардан—ягымлы

Марат ӘМИРХАНОВ (1933)—*прозаик, публицист; «Чулманның ак йолдызы», «Тәкъдир», «И кылган догам минем» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

яшьрәген, затлысын, ышанычлысын сайлады. Булат бәк иң мәртәбәле карачылардан санала. Ул аның өстеннән өйләнмәскә вәгъдә бирде. Дөресрәге, Гәүһәршад аңа шундый шарт куйды. Хан түгел түгелен, шулай да аннан да кулаерак егет солтанын, бар, эзләп кара, табарсыңмы? Ханнар да сүз куша иде, билгеле, тик Гәүһәршадның көндәшле гаиләгә төшәсе килмәде.

Әлегә барысы да көйле иде, әбе дә урынында, җәбе дә урынында. Булат бәк антын бозмады, акканда су, искәндә җил булды.

Ни кызганыч, хәзер бу хакта «иде», «булды» дип сөйләргә туры килә. Чөнки шымчысы яман хәбәр китерде. Имеш, Булат бәк төннәрен хадимә кыз катында үткәрә.

Гәүһәршад кызулыгы белән шымчысының яңагына чәпелдәтеп, изүеннән эләктереп алды. Тегесе карышмады, чәбәләнмәде, түзде, чөнки бикәнең тузынуы бер бүген генә түгел.

—Булат бәк турында мондый пычрак гайбәт таратырга ничек җөрьәт итәсең, кара йөрәк!

Бераз тынычлангач, Гәүһәршад мичкәдән ишетелгәндәй ниндидер ят, карлыккан тавыш белән сорап куйды:

—Хакмы?

—Хак,—диде шымчы.

—Коръән тотып ант итә аласыңмы?

—Бикәм, кимсетмә хезмәтчеңне...

—Ярар, ярар, беләм, син иң ышанычлы шымчым,—диде Гәүһәршад,—җан көйдергеч хәбәр бит бу, аңлыйсыңмы?

—Нишлим соң, вазифам шундый бит, бикәм.

Шымчы чыгып киткәч, бикә көзге каршына килеп басты. Үзен зәһәрле каенана рәхимсезлеге белән энә күзеннән үткәргәндәй үткәрде. Йөзендәге һәр үзгәрешне тәфсилләп тикшерде. Кай арада оялап өлгергән соң әле бу олыгаю галәмәтләре, нишләп моңа кадәр игътибар итмәде икән ул аларга? Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе—ботак тишеге ди. Хак икән. Карасана битенә, кабартма кебек кабарган лабаса. Икенче ияге дә шәйләнә түгелме? Җә, аллам, каш арасындагы бу буразна кайчан пәйда булган соң әле? Ире менә ни өчен читләргә күз ата икән. Моңа кичекмәстән чик куяр ул! Очынмасын әле. Теге себеркесенең авызын чиштерер, барысын да түкми-чәчми сөйләттерер. Берәмтекләп чәчен йолкыр ул әнчекнең. Ә аннан? Ә аннан нишләргә белер.

Гәүһәршад йомышчысын чакыртып алды.

—Ни боерасың, бикә?

—Минем янга Булат бәкнең яшь кәнизәген алып кил,—диде Гәүһәршад, тынычлыгын җуймаска тырышып. Әмма булдыра алмады.—Нәрсә карачкы булып каттың, тизрәк дим мин сиңа,—дип кычкырды.

Йомышчы артыннан ишек ябылгач, Гәүһәршад тәрәзә каршына килеп басты. Чалт аяз көн иде. Тирә-як ап-ак юрганга төренгән. Ак төс аның яраткан төсе иде. Ак төс—шат төс. Күңелләрне күтәрә торган төс. Ак төс илаһи нур сыман күңел төеннәрен чишеп җибәрә, ләззәт өсти, җиңеллек бирә. Гәүһәршадның йөрәк әрнүе дә басылгандай булды, каны суынды. Болай каударлану хан кызын бизәми, акыл алдан йөрергә тиеш, дип хәл итте. Җебеп төшәргә ярамый, тышаусыз тай түгел лә ул. Буласы булган, узган болытны әле берәүнең дә куып тота алган юк.

Үзе гаепле. Артык ышануы белән гаепле. Әһле вафа[2] юк ул җиһанда. Юк! Пәйман[3] бар, вафа юк. Ул исә гафләт йокысы белән йоклап йөргән. Ачык авыз!

[2] Әһле вафа—ышанычлы зат

[3] Пәйман—килешү

Гәүһәршад яралы бөркет хәлендә иде. Кирәк икән, кыядан түбәнгә атылачак, тик дошманына, кимсетүчесенә баш бирмәячәк. Шунын белән бергә, һәр эшнен үз жае бар.

—Чәй табыны әзерлә,—диде ул хадимәсенә,—йомышчыны туктатыгыз, кирәкми, чакырмасын, көзгеләргә дә тимәсеннәр.

Гәүһәршад ялгызы гына табын янында бик озак утырды.

Чынаягына кагылмады да диярлек, ара-тирә, оныткында бер генә, иреннәренә тигезеп куйгалады. Башы тулы уй иде. Ул уйлар калфагына да сыймый башлады бугай инде. Ниһаять, тәгаен бер нәтижәгә килде, ахры, иң якын күргән астөшермәсен дәштерде.

—Хәдичә, син бик дөрес юраучы күрәзәче бар дигән иден, жыен, шунда киттек,—диде.

—Сәеррәк ул, ошатырсын микән?—дип, хужабикәсен әлеге уеннан кире кайтарырга чамалап карады астөшермә,—тышта буран да кузгалып тора...

Гәүһәршадны чигендереп була димени, бер генә сүз әйтте:

—Сатулашма!

Бикә ат жиктермәде, өстенә дә астөшермәсенең иске киемнәрен киде. Кешеләргә сиздермичә генә аулак ишектән урамга чыктылар. Ә анда буран бар көченә котырына иде инде. Бу табигатьне дә анламассын, керәле дә чыгалыга әйләнеп бара. Әле иртән генә күктә кояш елмая иде, хәзер карлы зилзилә дуамаллана. Жилбикә тәмам чыгырыннан чыккан, үзен чын хужа итеп тоя, әле бездәй очлы кар бөртекләрен биткә китереп кадый, әле итәк астына кереп тәнне куыра, әле өермәсе белән юлынны бүлә, аяк атларга ирек бирми. Өй ышыкларында гына бераз хәлрәк. Урам бушап калган. Берән-сәрән генә ниндидер имгәкле адәмнәр очраштыргалый. Күрәсен, аларнын да якаларыннан бикәнеке шикелле бер-бер чарасызлык эләктереп алган иде.

—Еракмы әле?—дип, Гәүһәршад астөшермәсенең йөзенә салкын тынын өрде.

—Бар әле,—диде Хәдичә шәрехләмичә генә. Чөнки авызны ачар хәл юк, тамакка жил утыра.

Кирмән тавын төшеп, Ярминкә мәйданын үтүгә, бистә башлана. Монда төрледән-төрле һөнәрчелек белән шөгыльләнүче вак эшкуарлар яши. Шуңа күрә йорт-кураларынын да күбесе юктан бар итеп күтәрелгән корылмалардан гына гыйбарәт.

Астөшермә хатын алачык кадәрле генә бер хәрабә өй янында тукталып калды.

—Аллага шөкер, килеп життек,—диде ул бикәгә,—алдан үзем кереп күрешеп чыгыйм, дөнья хәлен белеп булмый...

—Минем кем икәнне сиздерәсе булма,—дип кисәтте аны Гәүһәршад,—керүен дә икәү бергә керәбез.

—Алайса, аллага тапшырдык.

Ишекне ачуга, алардан алда өйгә ыжгырып салкын һава ургылды, берара бүлмә эче буланып торды.

—Ару бәндә этен дә чыгармастай көндә кемнәр йөри анда?—дигән көр тавыш ишетелде.

—Без йомышчылар, Фагыйлә абыстай, үтенеч белән килгән идек, онытмаган булсан, Хәдичә мин...

—Йөзләгән кеше арасыннан каян мин синең исеменне хәтеремдә тотыйм,—дип бүлде аны күрәзәче.

—Менә бу юл ялы...—дип, астөшермә төенчеген сәкегә китереп куйды.

—Ничек киләсе иттегез, бәгъзе надан адәмнәр сихерче дип минем

данымны сата бит,—диде йорт хуҗасы. Ул үзе күренми, тавышы гына ишетелә.

—Кирәк тирәкне ега,—диде Хәдичә түземсезләнеп,—бүрәнә аша бүре кумыйк әле, Фагыйлә абыстай, безнең вакыт ягы чамалырак иде бит.

—Бәнем белән хан боерчысы сыман борын чөеп сөйләшмә, гадәмеңә хәсәнат[4],—диде күрәзәче төксе генә.

Гәүһәршад хезмәтчесенә карап куйды янәсе, сәвәтлерәк[5] тот үзеңне.

—Бик урынлы кисәтү ясадың, кәбәм, иярчеңә сәвәт житеп бетми,—диде күрәзәче.

Гәүһәршад өнсез калды.

Күрәзәче исә аның күңелендәгесен әйтте дә бирде! Бик хикмәтле күренә бит әле, тынлап карыйк, тагын ни-нәрсә белән шаккаттырыр икән.

Ниһаять, күрәзәче үзе дә пәйда булды. Һәм Гәүһәршад янә бер гаҗәпкә калды. Ул ике тамчы су кебек балачактагы тәрбиячесе Харрә тәтәгә охшаган иде: шундый ук базык гәүдәле, эре сөякле, тәкәббер йөзле. Киң итләч ияге тәртә башы сыман тырпаеп тора. Тумпак борыны, шешенке күз кабаклары—барысы да туры килә иде.

Ни хикмәт, ул аны нindидер эчке сиземләү белән нәкъ шушы кыяфәттә күз алдына китергән иде. Һәм мондый күзаллау тәүгесе генә түгел. Анасы Нурсолтанның сурәтен дә башта күңелендә тәгаенләде. Ә алар исә ана жиде яшь тулгач кына очраштылар.

—Синең колак артында миң бармы?—дип сорады ул аннан.

—Болай дорфа булырга ярамый,—диде анасы бу төпченүне ошатмыйча.

—Минем беләсем килә,—дип отыры киреләнде кызчык.

—Бар инде, бар,—диде Нурсолтан,—менә, авырттырмый гына сыйпап кара.

—Мин синең миңеңне төшемдә күрдем...

Күрәзәче кычкырып Әлхәм сүрәсен укып чыкты да:

—Инде йомышыгызны сөйләгез,—диде.

Астөшермә хатын урамга чыгып китте, хуҗабикәсенең жан серен белү ана лязим түгел.

Күрәзәче дөм сукыр иде. Тоташтан табышмак бу аздакы күвәндәсе[6], дип уйлап куйды Гәүһәршад.

—Ни йомыш?—дип ашыктырды карчык.

Гәүһәршад кыенсына-кыенсына гына монда килүенең сәбәбен анлатып бирде.

—Кара буранда абына-сөртенә шуның өчен килдеңме?—дип, карчык күрмәс күзләрен бикә ягына борды. Соравына үзе үк җавабын да бирде.

—Ир-ат атанның[7] атаны инде ул, кәбәм, көн таң атса, кыз-катын шул сөаль белән мөрәҗәгать итә.

Гәүһәршадның күрәзәче белән ир-ат турында тел кашырга бөртек тә теләге юк иде.

—Бу сафсатанны башкаларга калдыр, абыстай, иремне ничек бүтән туташларга күзе төшмәслек итәргә, шуны өйрәт син миңа,—диде.

Өйдә авыр тынлык урнашты. Күрәзәченең итәгендә карангалап утырган зур кара мәченең мырылдавы бу тынлыкка нindидер сихерле шом өсти иде.

—Һәр пәринең җене бар, бикәбез шуны да белми икән бит, пескәй,—диде

[4] Гәдәмеңә хәсәнәт—алдыңнан артың
[5] Сәвәт—зыялы
[6] Аздакы күвәндәсе—усал карчык
[7] Атан—ата дөя

күрәзәче мәчесенә мөрәҗәгать иткән атлы булып,—дорфалыкны каһәр итеп тә кайтара алабыз ич без синең белән, әйеме...

Күрәзәче кулларын алга сузды. Гәүһәршад үзеннән-үзе шул кулларга тартылды, алмаш-тилмәш үбеп чыкты.

—Бән сина сөйдерү бөтиләре өшкереп бирермен, кәбәм, аларны куллану серләренә дә өйрәтермен,—диде карчык тасма телләнеп,—иренә дога көче индерелгән сулар эчерерсен, күзенә генә карап торыр...

—Рәхмәт, абыстай...

—Шунысын да белеп тор, кәбәм,—дип юмалавын дәвам итте күрәзәче,—бу чараларның көче вакытлы гына. Ник дисәң, кыз-хатынның гыйффәти гомере күбәләк гомере кадәр генә. Син шул хафалы чиккә килеп терәлгәнсең...

—Минем яшемдә эшең булмасын,—дип, Гәүһәршад корт чаккандай ду кубып урыныннан торды да, ишеккә килеп орынды. Әмма ача алмады. Әллә тышкы яктан терәп куйганнар, әллә бозланып каткан, әллә...

—Бу йортның керер ишекләре киң булса да, чыгар ишекләре бик тар шул, кәбәм,—диде күрәзәче тыныч кына,—кабаланма, сина әйтер сүзем бар. Колагыңа киртләп куй: бән гүр иясе булганнан соңында барча вазифаларым да синарга күчәчәк. Көт, тәнәкә, ул көнгә дә ерак калмады.

Ишек кисәк кенә ачылып китте. Ниндидер көч Гәүһәршадны урамга суырып алды. Ә анда әле һаман буран котырына иде.

***

Гәүһәршад иң әүвәл Булат бәкнең мәгъшукасы белән араны өзде. Кызны елата-елата алтмыш яшьлек азгын мәздингә өч хатын өстенә кияүгә бирдертте. Аның артыннан хадимә туташларны ханымнарга алыштыртты. Шуннан соң чират үзенә җитте. Соңгы атнада йөз-кыяфәтен матурлау белән шөгыльләнде. Эшнең башы итеп, әле кырык көн узмаса да, эскәк ярдәмендә култык астындагы, җан җирдәге төкләрдән арынды. Бу авырттыргыч гамәлне ул һәрвакыт үзе башкара. Җиңгәсе, Мөхәммәдәмин ханның яшь кәләше Үрбәт ханбикә бизәнү мәктүбенең остасы иде. Алар кырык яшь узгач кына никахлаштылар. Ә бу яшьтә ирне янында тотуның ни-нәрсә икәнен үз башына төшкәч кенә аңлыйсың икән. Гәүһәршад та шул хәлдә хәзер. Бик күп тир түгәргә туры килә. Бүген, әнә, җиде тирен чыгарып, әйләндерә-әйләндерә мунчада чаптылар. Җиңгәсе үрнәгендә, тәненә калын итеп чәчәк балы да сылаттырды. Бал сеңеп беткәч, кәҗә сөте салынган зур кисмәккә кереп ятты.Үлән төнәтмәсе дә хәйран йомшартты. Тагын әллә ниләр кыландырып бетерделәр, чәчен генә дә ике-өч тапкыр тарап үрделәр.

Гәүһәршад ире белән төнге очрашуны зөфаф киченә әзерләнгән яшь кәләштәй ашкынып та, түземсезләнеп тә, куркыбрак та көтеп алды. Булат бәк ошатты.

—Һай, минем хәләлем хур кызларына биргесез бит ул,—дип кочаклап алды.

Гәүһәршад хатын-кызның наз сандыгында нинди сөю-сәгадәт хәзинәсе булса, барысын да чыгарап салды. Оялмады да, тартынмады да: үпте, кочты, ялады, сыйпады...

Булат бәк үзе дә бушны бушка бушатмады. Ә аның көче дә, гайрәте дә җитәрлек әле.

Ни кызганыч, арада ташкындай бөтереп алырлык янар хис юк иде инде. Шуңа күрә бу ясалма якынлык канәгатьлек китермәде, тамаша гына булып калды. Хәлбуки, аларны бербөтен итеп тота торган башка мәнфәгатьләр дә җитәрлек үзе. Булат бәк күптән инде шул хакта сөйләшеп аңлашырга җай эзли иде.

—Бикә, Мөхәммәдәмин хан вафатыннан соң дәүләт сәясәтенә карата битарафландын димме, һәрхәлдә, Олуг Мөхәммәд мирасын торгызу хакында янып-көеп йөрүдән туктап калдың,—диде ул хатынының чәчләреннән сыйпаштыра-сыйпаштыра.—Хәтерендәме, тәхеткә нинди генә хан утырса да, Барча Казан җире белән мин җитәкчелек итәргә тиеш,—дип аһ ора идең. Сизәсеңме, шул вакыт килеп җитте бит!

Яшьлеге үтсә дә, акылы мул иде Гәүһәршадның, әлеге тәкъдимне җәһәт кенә башында әйләндергәләп, нәтиҗәсен дә чыгарып куйды. Алай да төрттереп аласы итте.

—Димәк, әле миңа ясин укылмаган?

—Көрәш башлана гына, бикә. Һәм ул көрәшнең башында Олуг Мөхәммәд хан нәселенең бердәнбер дәвамчысы Гәүһәршад бикә торырга тиеш,—диде Булат бәк чын җитдилек белән.

—Сәгате сукты дисеңме?

—Сукты, бикә, сукты.

Бу кичне ир белән хатын ничек итеп ханлыкны кулга алу турында озаклап һәм тәфсилләп гәп кордылар, уртак түшәк хәлләре онытылды. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе дә юк, ник дисәң, сәяси уен шул ук гыйшык-мыйшык лабаса инде ул.

Шушы көннән мәхәббәттән дә ләззәтлерәк, әмма баш бетүгә тиң хәвефле яна тормыш башланды.

***

Көннәрдән бер көнне кичләтеп кенә Кече Гали Шириннәрнең капкасын какты.

—Исән-имин генә яшисезме, дәгъва-үтенечләрегез юкмы, тормышыгыздан риза-бәхилме?—дип, гадәттәгечә, ишектән керә-керешкә саескандай такылдарга керeште.

Бәкнең килеш-килбәте дә үз-үзен тотышына тәңгәл килә иде. Ярма ташыдай йомры итләч йөзе, әйтерсең лә, авыздан гына тора. Ә ул олы авыз һаман ерык булыр. Шамакайның шамакае.

—Дәгъва-үтенечләр белән кызыксынасың, ханга теркәүмән булып ялландыңмы әллә?—дип көлемсерәде Булат Ширин,—бездә алар хәдтин ашкан, кәгазь-каләмең җитәрлекме соң?

—Матавыкланма, бәк, олуг кенәз Василий Мәскәүдән бер олау язу-сызу әсбаплары җибәргән.

—Нәрсә, козгыннар үләксәгә кундылар да мыни инде?

Кече Галинең калын кашлары маңгаенда сыр ясап, дуга рәвешенә керде.

—Арт ягыңа су керсә, үләксәгә дә кунарсың.

—Ташла әле уен-муеныңны, тәфсилләбрәк аңлат,—диде Булат бәк, җитди кыяфәткә кереп.

Кунакның да иреннәре җыелды.

—Озын сүзнең кыскасы, фикерләшергә кирәк,—диде Кече Гали.—Миңа калса, җыенны ау төргәгенә төрү отышлы булыр сыман. Һәрхәлдә, сыналган алым. Ни кадәр йөгәнсезрәк кылансак, шул кадәр яхшырак. Хан шымчыларының күзенә төтен җибәрү, үзең беләсең, кыл басмада йөрүгә тиң.

Булат бәк ау белән әсәрләнгән кешеләр рәтендә йөрми иде. Ау ни, сунар ни—аңа барыбер. Тик нишлисең, карачы дәүләти дәрәҗәдәге чаралардан читтә кала алмый. Ә алар нәкъ шул өлгедә оештырылалар да. Дөрес, Мөхәммәдәмин хан вафатыннан соң тәхет тирәсендә башланган ыгы-зыгы аркасында мондый сафа сөрүләр күзгә күренеп кимеде. Сәхибгәрәй хан ул эшләргә маһир түгел иде, Сафагәрәй исә әлегә ныгып җитмәгән.

—Иргә дәүләт бетәрдә карга салса да каз алыр, ирдән дәүләт китәрдә лачын салса да аз алыр, диләрме әле,—диде Булат бәк үз белдеклелегенә үзе куангандай,—безләр ни-нәрсәгә өмет итәбез, ягъни дә ни-нәрсә аулаячакбыз?

—Үрдәк аулаячакбыз, бәк, үрдәк,—дип дустының аркасыннан сыйпаштырды Кече Гали.

—Ә мине күбрәк козгын кызыксындыра,—диде Булат Ширин кыяфәтен үзгәртмичә,—тел төбемне аңлыйсындыр, шәт.

—Борчылма, бәк, бик яхшы аңлыйм мин синең ураў сүзләреңне, тамашабыз итәк астыннан ут йөртү генә ләбаса. Баш аучыбыз—бикә! Ханлыкның язмышын үз кулына алырга батырчылык итәрме ул, кискен гамәлләргә фатихасын бирерме? Төп хикмәт менә шунда.

Ширин чынаягын кулына алды, чәе суынган иде, эчмәде, иреннәренә генә тигезеп куйды. Табынчы чәй ясаган арада әңгәмә өзелеп торды, сүз чыгудан шикләнәләр иде булса кирәк.

—Карт чыпчык кибәккә алданмас ди, бикәне өйрәтәсе юк,—диде Булат бәк.—Федор Карпов та төшеп калганнардан түгел анысы, мәгълүм илче, зур тәҗрибә иясе. Шаехгали вакытында калагай да булып торды. Әмма Сәхибгәрәй хан кәкре каенга терәде үзен.

—Хәзер шул җинелүнең үчен кайтармакчы исә... Ишетүемчә, Мәскәү Ибраһим бахшыны үз ягына аударган, имеш.

—Нәрсә, без хәзер шул буш куык белән бер җепкә теркәлдекме әллә?

Булат бәкнең ачуташ капкандай йөзе китте. Бахшы белән борчаклары пешми иде, күрәсең.

Анысы да хак. Ибраһим бахшы, яшь булуына да карамастан, арада акыл иясе зат иде. Язу-сызуга бик маһир. Искиткеч оста телмәр. Урысчаны су кебек эчә. Кирәксә, Иванның үзен дә сатып җибәрә алыр иде. Шуңа күрә иң дәрәҗәле илчеләрдән санала. Булат бәк үзе илчелеккә омтылмады, шулай да нигәдер илчеләрдән көнләшә иде.

Кече Гали дустының чытылуына игътибар итмәде, куен кесәсеннән төргәккә төрелгән ниндидер затлы кәгазь тартып чыгарды да, сүтеп укырга да кереште:

«Мөхтәрәм казанлылар!

Без гомер бакыена Мәскәү белән кулга-кул тотынышып яшәдек. Ачуланышкан чакларыбыз да, яу чапкан вакытларыбыз да булды. Әмма дә ләкин бервакытта да дошманлашмадык. Тузан кагу, танау канату туганнар арасында да була торган хәл. Аңа карап дуслык җуелмас. Һәммәбезгә мәгълүм, бөек ханыбыз Мөхәммәдәмин галиҗәнаплары бу дуслыкны рәсми килешү рәвешендә дә тәгаенләгән иде. Кырым килмешәкләрен Казаныбызга аяк бастырмады ул. Дан Мөхәммәдәмин ханга! Кырымлыларга Казанда урын юк. Сафагәрәйне куып җибәрегез!»

—Күр, бу безнең җырны җырлый түгелме соң?—дип гаҗәпкә калды Булат бәк.

—Шундый ук өндәмә белән Ибраһим бахшы Арча бәкләренә, чирмешләргә, чуашларга да мөрәҗәгать итә. Тик шулай да бахшы безнең җырны җырламый, ул Шаехгалине тәхеткә кайтарырга кодалый. Минем фикеремчә, башлангыч чорда безгә аның зыяны юк.

—Шаехгалинең хәсрәт капчыгы икәнен белә торып, һаман шуны төртергә тырыша бу Василий, аңламассың, казанлылар теш-тырнаклары белән каршы лабаса,—дип мыгырданды Ширин,—урысларның үзләренә дә күпме җик күрсәтте инде ул...

Хак. Әлегә Шаехгалинең Мәскәүгә әллә ни яхшылык китергәне булмады. Борын асты кибәргә генә өлгергән бу Касыйм ханың зур өметләр белән

Казан тәхетенә утырттылар. Шундый дәрәҗәле бүрек кигезгәннәр икән, халыкны үз ягына аударырдай эш майтарырга кирәк. Ә аның хәбәрендә дә юк, узган елгы әрекмән шикелле салынып төшкән колакларын шәлперәйтеп, күңел ачуын белә.

Түземлекләре төкәнгән казанлылар Кырымга чапкын җибәрергә мәҗбүр иделәр. Шул рәвешле Кырым ханы Мөхәммәдгәрәйнең ханның күктән көткәне җирдән килде. Энесе Сәхибгәрәйне, тәхетемә кул сузмасын дип, төрмәдә тота иде. Аннан котылуның моннан да җайлы, шул ук вакытта гаять мәртәбәле ысулы булырга мөмкинме соң? Һәм Сәхибгәрәй форсатны кулыннан ычкындырмады. Казанга яу чапты. Ихтимал, моны яу чабу дип тә булмыйдыр. Ник дисәң, гаскәре нибары өч йөз борыннан гыйбарәт иде.

Шәехгали, билгеле, урысларга аркалана. Чынлыкта хакимият Мәскәү илчесе Федор Андреевич Карпов кулында иде. 1505 елгы погром кабатланмасын дигән сылтау белән башкалага воевода Поджогин җитәкчелегендә тулы бер гарнизон кертелгән иде. Башта кырымлылар шуларны суеп ыргыттылар, тавышлары да чыкмады. Аннан ханның Касыймнан алып килгән шәхси сакчыларының башлары тәгәрәде.

Янә погром башланды. Ул бишенче елгысыннан күпкә канлырак иде. Шәехгали төнге күлмәк-ыштаннан гына тәхетен ташлап качарга мәҗбүр булды. Карпов белән Поджогин да үкчәләрен күтәрде.

Ут утыннан туймас, җир янгырдан туймас, ди, кырымлыларның да нәфесе зурдан иде. Сөңгеләр бу юлы Мәскәү тарафына борылды. Чөнки Мәскәүне тезләндерми торып Казанны кулда тотам димә.

Сәхибгәрәй агасы кушуы буенча тәхеткә утыруының икенче көнендә үк гаскәрен кузгатты. Бер яктан—казанлылар, икенче яктан—кырымлылар. Атна-ун көннән Коломнада очрашып, бер йодрык булып төйнәлделәр дә алтын гөмбәзле пай-калага ыргылдылар. Инде, әнә, алда Кремль манаралары да пәйда булды.

Василий куркуыннан чын мәгънәсендә астына җибәрде. Мәскәүдә кияве чукынчык Петр-Ходайколны калдырып, шәһәрдән үк чыгып сызды. Берничә көн печән кибәне астында яшеренеп ятты.

Мәмләкәт язмышын кибән астында гына хәл итеп булса икән? Мөхәммәдгәрәй хан Василийга ультиматум куйды: җә миңа, ягъни дә Кырым ханына мәңгегә баш бирәм дип ярлык язасың, җә Мәскәүегезне икенче Сарайга әйләндерәм, минем бабам Миңлегәрәй хан Алтын Урда булып Алтын Урданы туздырган, ә миңа калагызны җир белән тигезләү берни тормый, диде.

Василийга буйсынудан гайре юл калмады. Шуннан соң Мөхәммәдгәрәй һәр елны Мәскәүгә үзенең сын-сурәтен җибәрә иде. Василий исә шул сын-сурәткә табынырга тиеш. Ләкин Мәскәү барыбер Казанны тынычлыкта калдырмады, үч орышына хәстәрлек эшләрен башлап җибәрде. Күп тә үтми, Түбән Новгород янындагы Сура елгасы буенда сыргавыл каласына нигез салынды. Бу каланың бина ителгән урыны Казан йортына караган җирдә иде. Аңа олуг кенәз хөрмәтенә Василийград дигән исем бирелде.

Шул тирәләрдән урап кайтканның сонында Василий Сәхибгәрәйгә чапкын җибәрде. Ул ханга олуг кенәзнең ошбу сүзләрен җиткерде: «Үткән ел туганың белән, караклар һәм кеше үтерүчеләр сыман, искәртмәстән һөҗүм иттең. Менә мин, белекле сугышчы кебек, синең өстеңә йөргәнлегемнән хәбәр биреп, сиңа сугыш ачамын».

Василий сугыш ачты, теләгенә генә ирешә алмады.

...Әшнәләр әлеге вакыйгаларның эчендә кайнаган адәмнәр иде. Бу хакта фикер алышулары, хәтирәләрне янартулары да юкка гына түгел. Фетнә дилбегәсе инде алар кулына күчте. Ә сабак алыр нәрсә күп. Моңа кадәрге

фетнәчеләрнең башына, әлеге дә баягы, мал-милек, ваемсызлык житте. Сәясәттә исә вак нәрсә юк. Кем әйтмешли, энә дә бер, дөя дә бер. Энә генә дип йөргән гамәлнең мизгел эчендә дөягә әверелүе дә ихтимал.

—Федор Карпов үзе килгән дисең инде алайса,—дип, Булат бәк иреннәрен бүлтәйткән рәвештә ишекле-түрле йөрештерергә кереште.

—Илче сыйфатында түгел, шәхси йомыш белән, кача-поса гына,—диде Кече Гали,—Кырым һаман үзсүзләнә, күрәсең.

—Ә менә монысы шә-әп,—диде Булат бәк йөрүеннән туктап,—файдалана белсәң, әлбәттә...

***

Ауга мөнәсәбәтле кайбер гамәлләргә үзгәреш тә кертергә туры килде. Аеруча Чура морза тузынды:

—Гафил булмагыз, зинһар, хан ялмавызларына яшерен оешма әгъзаларын көтүе-ние белән бакмага куймакчы буласызмыни?—диде үзенә генә хас зәһәрлеккә төенеп.

Чура морза зирәк акыллы кеше булса да дуамаллыгы хәтдин ашкан иде. Шуңа күрә аның белән сүз көрәштерергә атлыгып торучы юк. Бу юлы да каршы төшүче булмады. Алай да Кече Гали чеметеп аласы итте:

—Көтү хәстәрендә, җәнабе гали,—диде ясалма бер басынкы тавыш белән,—кызганыч, беребез дә синең белән чагыша алмыйбыз.

«Пырх» итеп көлеп җибәрделәр. Чөнки көтүнең аерым мәгънәсе бар иде.

Чура морза үсмер вакытта көтү көтәргә алынган, имеш. Беркөнне үзенең яшьти кулдашларына әйтә бу: «Беребезне баш итәек»,—ди.

—Ничек,—дип белешә тегеләр.

—Кем дә кем бозау суеп ашатса, шул башлыгыбыз булыр,—ди Чура.

Үзе шунда ук эшкә керешә. Бер бозауны егып суя да иптәшләрен сыйлый. Һәм көтүбашка әйләнә.

—Көтүне авылга алып кайтканда, бозауларыгызга атланып, яулыкларыгызны таякка бәйләп байрак ясагыз да: «Чура морзаның гаскәрләремез дип кычкырыгыз»,—дип, әмерен дә бирә.

Хакмы, хак түгелме, әмма шундый гайбәт йөри. Ул үзе менә дигән сунарчы. Гәүдәгә пәһлүән булмаса да, искиткеч чырыш, тәвәккәл зат.

Гадәттә кошны кош белән аулыйлар. Чураның да ау лачыннары күп. Ләкин тигез урында мөгез чыгармаса, Чура булыр иде мени ул. Аның үз сөннәте: әгәр син үзеңне оста мәргән дип саныйсың икән, кошны һавада очкан халәтендә ук белән атып төшер. Менә булыр бу егетлек!

Морза әле дә ауга лачынсыз чыкты. Төп сунарчылар итеп Чура, Тагай, Кече Гали тәгаенләнде. Булат бәк белән Боерган сәедкә исә Гәүһәршад тәнәкәнең Мәскәүдән килгән яшерен илче Федор Карпов белән очрашып сөйләшүен оештыру вазифасы йөкләнде.

Яз киреләнсә, көздән яман ди. Иртәгә ауга чыгасы көнне генә һава бозылып китмәсенме. Югыйсә атна буе халык хозурлык кичергән иде: җылы, якты, матур, болын тутырып аллы-гөлле күбәләкләр оча... Җәй быел кабаланыбрак тәрәз кага дип зарлана да башлаганнар иде хәтта. Юк, табигать-ана барыбер үзенекен итә ул. Майда туның калдырма, дип бик дөрес әйткәннәр.

Җил котып ягына борылуга, көн дә суынды, кояш та сүрелде. Ничек сизенгәннәрдер, күбәләкләр ана кадәр үк каядыр китеп югалганнар иде инде.

Җиһан шыксыз җил уртасында калды. Нәкъ даладагы Самум җиле кебек, коры, чәнечкеле, йөгәнсез.

Ауны кичектерү мөмкин түгел иде. Бернәрсәгә карамый кичтән үк чыгып киттеләр. Каладан дүрт-биш чакрымда гына күлләр тезмәсе бар. Бик матур урын. Күтәрелеп карасаң, бүрек шуып төшәрлек биек вә төз чыршы агачлары арасыннан көмештәй ялтырап күренеп торалар. Кыска вакытлы ауга аксөякләр, гадәттә, шунда йөриләр. Аккош күле, Зәңгәр күл, Тирән күл—һәммәсендә кош-корт мыж булып ята.

Таң белән аучылар ярдәмчеләре алдан әзерләп куйган аулак урынга килеп урнаштылар. Аралары әллә ни ерак түгел. Чөнки үрдәк өере зур көтү белән йөри.

Чура морза ук сәмәкләрен тумпак борынлы итеп ясатты. Болай үрдәк җәрәхәт алмый, искәртмәс авырту вә куркудан гына йөзтүбән мәтәлә. Камыш арасында кечкенә каекларда яшеренгән кош җыючылар аларны айнып өлгергәнче җыеп алалар.

Озак та үтми, күлнең аргы башында кешеләр кычкырган, этләр өргән, таба каккан тавышлар ишетелде. Болар—өркетүчеләр. Әнә, болыт булып, үрдәк көтүе дә күтәрелде. Үрдәкләр бервакытта да үз күлләрен ташлап китми. Куркыткан-өркеткән очракта да урыннан-урынга гына очып куналар, бераздан кире әйләнеп кайталар.

Чура җәясен киереп, кошларның якынлашуын көтә башлады. Күп тапкырлар сынаганы бар, аның угы иң биек чыршыдан да югарырак очкан кошны куып җитә. Шуның белән мактана да. Мактанырлыгы бар, арада аңа житкән мәргәннәр юк. Бүре, төлке ише эрерәк ерткычларга да теше үтә морзаның. Аю эзенә дә төшкәли. Кош авы исә кулны җәядә тоту өчен бик файдалы.

Җил галәмәте булса кирәк, үрдәкләр ничектер кырын килеп очалар иде. Шуңа күрәме, утырырга чамалый башладылар.

—Бисмиллаһи рахман...

Чураның гәүдәсе шырпыдай тураеп катты, кулларына дулкын булып көч йөгерде, күзләре очланды...

Үрдәкләр баш очына җитүгә, җәя җебен үзенә таба тартып китерде дә, угын турылап, корбаны тарафына очырды. И һәм... Әмма түбәнгә мәтәлүче үрдәк күренмәде. Җилбикә мактанчык аучының борынына шалт берне! Атылган укны бөтереп алды да, бөтенләй башка юнәлешкә борып җибәрде. Шундук яшелле-зәңгәрле әче тавыш яңгырады.

—Ни булды анда, бар, белеп кил,—диде Чура toткавыл адәмгә. Тегесе чаптырып камыш арасына кереп китте.

—Габдулла җыючының күзенә ук тигән,—диде адәм урап килгәч.

—Чебен тимәс, чер итәр,—дип җиргә төкерде морза. Аның бушка очкан угы өчен кәефе кырылган иде.

—Күзе сытылып чыккан,—дип аңлатма бирде toткавыл адәм,—йөзе тулы кан...

—Алып китсеннәр, әйт, шыңшып үрдәкләрне куркыта,—диде морза,—шул гына җитмәгән?

Бу вакытта Гәүһәршад урыс илчесен кабул итәргә әзерләнә иде. Һич яшерен гамәл дип уйламассың, чын хөкемдарлар арасындагы рәсми аудиенциядән бер ким җире дә юк. Гәүһәршад ау йортының икенче катын хан сарае үрнәгендә җиһазлаттырды: идәнгә зиннәтле келәмнәр җәелде, йомшак кәнәфиләр урнаштырылды, өстәл, шкаф ише җиһаз да бик затлы иде.

Гәүһәршадның кием-салымга һәвәслеге турында бик күп имеш-мимешләр йөри. Бервакыт, тәнәкә Румнан тегүчеләр китерткән икән, дип шаулашкан иде югары даирәнең көнчел бикәләре. Утсыз төтен чыкмаган кебек, әлеге сүзләрдә дә хаклык бар иде, билгеле. Әйе, ул Рум осталарының күлмәкләрен яратып кия. Шул ук вакытта Кытайдан да, Мәскәүдән дә, Хәрәземнән дә тегүчеләр чакырта.

Әлеге очрашуга ул киенеп-ясанып килде. Өстендә үкчәгә кадәр төшеп торучы алсу төстәге өр-яңа күлмәк, ефәктән ука белән каймалап тегелгән озын яшел камзул. Аягында кызыл сәхиян күннән алтын җеп белән тегелгән искиткеч нәфис чүәк. Парча күкрәкчәсе дә бик килешле. Бизәнү әйберләре үзе бер тамаша. Әнә, алтынланган көмештән ясалган мәрҗән беләзекнең ахак, фирүзә ташлары ничек ялт-йолт килеп тора. Бармаклары саен кашлы йөзек. Энҗе, асылташ, алтын тәңкә белән бизәлгән хәситә кесәсендә вак хәрефләр белән язылган нәни генә Коръән. Ә очлы баш киеме аның ханнар нәселеннән булуына ишарә итә иде.

Гәүһәршад үзен һәрчак ханбикәләрчә тотты. Сарай даирәсе дә бу дәрәҗәне таный иде. Агасы Мөхәммәдәмин хан вафатыннан соң аксөякләр аны Казан тәхетенең хокукый варисы дип саный. Тәхеткә утырырга кыз-хатын булуы гына киртә куя иде. Ул моңа бик борчыла иде. Шушы борчулары аны көтепханәгә дә китерде. Беләсе килә: мөслимәләр идарә иткән мәмләкәтләр булганмы, андыйлар хәзер дә бармы?

Габбас хәзрәт озак кына көтепханә тузаны эчүдән борынгы китап төсенә кергән зәгъфрандәй сары йөзен, шушы ук сәбәптән коелган күсә сакалын сыпыргалап торды да:

—Мәрхүм Мөхәммәдәминнең яшь бичәсе Үрбәт ханәкә дә көтепханә сукмагына тузан кундырмый иде,—диде,—ифрат та укымышлы зат иде, башы гыйлемен күтәрә алмады, ахры, ярлыка Ходаем гөнаһлы бәндәнне...

—Җиңгәчәмне үзем дә бик ихтирам итә идем,—диде Гәүһәршад,—мин аннан күп нәрсәгә өйрәндем. Ә минем гозеремә карата ни әйтәсең, хәзрәт?

Көтепханәченең куллары янә сакалына ятты.

—Сиңа, тәнәкә, мәгълүмат кирәкме, әллә үзең укып белергә, эзләнергә телисеңме?—дип сорады.

—Хәзергә мәгълүмат та җитеп торыр, хәзрәт, аннары күз күрер.

Гәүһәршад беренче мәртәбә Мисыр патшабикәсе Кәлимә турында ишетте. Бик ошатты, менә кемнән үрнәк алырга кирәк дип күңеленә беркетеп куйды. Тәвәккәллегенә, зирәклегенә, хәйләкәрлегенә, үҗәтлегенә сокланып туймаслык. Кансыз да була белгән.

—Румлылар Кәлимәне дошман күргән, зәһәр еланга тиңләгәннәр, шуңа күрә аларның язмаларында патшабикә бик начар сыйфатта тасвир ителә,—дип кистереп куюны кирәк тапты көтепханәче.

—Моңа һич тә исең китмәсен, хәзрәт,—диде бикә,—үзең әйтеп торасың ич, Кәлимә патша Румның ике бөек җиһангир-илбашларын үз кубызына биеткән, дисең. Сизар үзе генә ни тора? Әнсәни дә шул калыптан булган дип уйлыйм. Һәр икесе гүзәл Кәлимәгә ярау өчен кулларына кылыч алган.

—Әйе, гүзәллектә, нәфислектә Кәлимәгә тиңнәр булмаган.

—Ә миңа Кәлимә бикәнең зирәклеге, хәйләкәрлеге күбрәк ошый,—диде Гәүһәршад,—үҗәтлеге, сүз иясе булуы. Сизар белән очрашу өчен ни-нәрсә уйлап таба бит? Сарайга үзен келәмгә төреп керттерә, ә токкавыллар авызларын ачып кала.

Шулай да Гәүһәршадның йөрәген җилкеткәне болар түгел иде. Хәтта унсигез яшьлек Кәлимәне ун яшьлек патшага ярәшү дә артык гаҗәпләндермәде, моны мин үзем дә булдырдым дип күңеленнән генә елмаеп куйды,—аның ире дә тугыз яшькә яшьрәк ич.

Хакимлеккә омтылу, хаким булу татар тәнәкәсе өчен дә кул җитмәс хыял түгел үзе. Үрдәкчедән күрмәкче, киекче дә килмәкче, ди. Кәлимәнең тәрҗемәи хәле аның өметенә ак канат куйды. Атае вафатыннан соң Кәлимә ил белән әүвәл, әлеге дә баягы, бәлигъ булмаган ун яшьлек ире, агасы белән берлектә идарә итә. Бу васыйлар[8] шурасы дип атала. Әлеге ысул

[8] Васый—регент

Казан-йортка карата да кулай күренә. Тәхеткә кануни дәгъваченең булмавы сәбәпле туган ыгы-зыгы бу мөмкинлекне күпкә арттыра. Казан тәхетенә дә шундый бәлигълык яше житмәгән хан утыртырга гына кирәк. Сафагәрәйгә каршы оештырылган фетнә менә шуны күздә тотырга тиеш тә инде. Тик аңа кадәр ул килмешәктән арынырга кирәк. Әлеге мәсләктә Гәүһәршад белән олуг кенәз Василийның карашлары тәңгәл килә иде.

***

Илче ишектән кереп, тәнәкәне күрүгә ирексездән идәнгә ауды. Аның каршында бүлмәне тутырып чын ханбикә утыра иде. Затлы, күркәм, тәкәббер.

Гәүһәршад илченең каушап калуын бик охшатты. Әлеге уенның максаты да Мәскәү вәкилен шаккатыру иде. Һәм ул максатына иреште. Илче, һичшиксез, әлеге тамаша турында олуг кенәзгә житкерәчәк. Ә бу бикәнең абруена өстәмә шакмаклар гына.

—Кәнәфигә рәхим ит, Федор Андреевич,—диде Гәүһәршад саф урыс телендә илченең каушап калуын күрмәмешкә салышып,—тәм-томнан авыз ит, дөрес булса, сине татар аш-суына мөкиббән диләр.

—Дөрес, бик дөрес,—дип жанланып китте Карпов,—бәлеш, тутырган тавык ише затлы ризыкларны пешереп, кунакларны да сыйлыйм әле мин.

Аш-су турындагы әңгәмә шушы урында өзелде, чөнки ишек уемында Булат Ширин белән Боерган сәед пәйда булды. Гәүһәршад каш астыннан гына аларга күз төшереп алды. Булат бәк беленер-беленмәс кенә башын иеп куйды. Бу, барысы да тәртиптә, барысы да алдан тәгаенләнгәнчә, дигәнне аңлата иде булса кирәк, тәнәкәнең йөзенә ышаныч кайтты.

—Аллага тапшырып, сөйләшүне башлыйк, җәмәгать,—диде ул,—иң элек мәнфәгатьләребезне ачыклыйк, Федор Андреевич, беренче сүз синеке.

Карпов авызын ачкалаганчы какча гәүдәсен кәнәфи читенәрәк авыштырып, аякларын тигезләгәндәй итте. Йөзе дә житдиләнде, хәтта бакыр төсендәге сакал-мыегы, җөнтәс кашлары да ничектер жыелып киткәндәй булды.

—Мәскәү хөкүмәте бүгенге көндә Казан тәхетен биләп алган кырымлы Сафагәрәйнең вәкаләтләрен танымый,—диде әңгәмәдәшләренә туп-туры карап,—без мөхтәрәм Мөхәммәдәмин галиҗәнаплары хакимлек иткән чор кануннарын төгәл үтибез, чөнки дә алар әле һаман үз көчендә. Шуңа күрә Казанның да бу килешүләргә турылыклы булуын та... әһе... әһе...

Илче тотлыгып калды. Чөнки «таләп» дигән сүз бу сөйләшүдә урынсыз иде. Ул ютәлләгән атлы булып, хатасын төзәтергә ашыкты.

—Әһе, әһе... турылыклы булуын үтенәбез. Үзегезгә дә мәгълүм, 1487 елгы әлеге килешү нигезендә, Казан тәхетенә дәгъвачене Мәскәү билгели.

—Килештерелә,—дип төзәтте аны Булат бәк.

—Килешүдә син әйткән бу сүз юк, кенәз,—диде Карпов.

—Безнең фирка да Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне яхшырту ягында,— диде Гәүһәршад, бәхәскә кызып китәргә ирек бирмичә.—Ә хөрмәтле урыс туганнар нигәдер һаман Казан арбасы тәгәрмәченә таяк тыккалап торалар, бу һич тә өлфәт гамәлләргә этәрми.

—Нинди дәлил китерә аласыз?

Гәүһәршад дәлилләрен китерергә ашыкмады. Әүвәл бармакларындагы йөзек-балдакларын берәмтекләп барлап чыкты, берочтан беләзек-чулпыларын да күзеннән үткәрде.

Тынлык озакка сузылган кебек тоелды. Чөнки фикерләрнең ургылып торган мәле ләбаса. Ә Гәүһәршад бүген генә күргәндәй асыл ташлары белән мәшгуль. Ул, әлбәттә, әңгәмәдәшенең эчендә ут кайнаганын бик яхшы белә. Очрашуга

да җентекләп әзерләнде. Әмма бу сөйләшүнең хуҗабикәсе ул, Гәүһәршад! Әйдә, урыс илчесе бераз уфтангалап, бимазаланып та алсын, укасы коелмас.

—Дәлилме?—диде ул, ниһаять, сүзләрен теш арасыннан гына сыгып,—дәлилләр бихисап, Федор Андреевич.

Гәүһәршад элмәкле карашын илче тарафына очырды.

—Ташаяк ярминкәсенә тышау салу нигә кирәк булды инде олуг кенәзгә? Бик күп урыс сәүдәгәрләрен баетып череткән ярминкә бит ул. Хәзер аларны тыйгансыз. Янәсе, әнә, Нижнийда үзебезнең ярминкәне ачтык, шунда сату итегез. Ә үзегез барысы да Мөхәммәдәмин хан чорындагыча булсын дип лаф орасыз. Моны ничек аңларга? Шушы да булдымы дуслык?

—Минем бу мәсьәлә буенча сөйләшү алып барырга вәкаләтем юк,—дип, туры җаваптан котылу юлын тапты Карпов.

—Хәйләкәр син, кенәз, мәкерле,—дип елмайгандай итте тәнәкә.—Алайса, илчене яшеренә-яшеренә Казанга китергән мәсьәләгә күчик. Син Мәскәү Сафагәрәйне хуп күрми дисән дә, күптән түгел генә олуг кенәз аны рәсми рәвештә хан итеп таныды лабаса. Сәбәбен дә әйтәм: Казан янында урыс гаскәре хурлыклы рәвештә җиңелде. Никадәр әсир бирдегез, никадәр корал югалттыгыз. Санаусыз. Үзегезнең кулдан килмәгәнне безгә йөкләмәкче хәзер. Сүз дә юк, Сафагәрәй ханны куып җибәрә алабыз без. Болай дип өздереп әйтергә ныклы нигез бар. Аксөякләр генә түгел, хәтта кара халык та гамәлләребезне яклый. Тик шуны белеп тор, кенәз, шартларыбыз тулысынча үтәлгән очракта гына алыначакбыз без бу эшкә. Ә шартыбызның иң мөһиме шул: Казан тәхетенә без тәкъдим иткән кеше утырырга тиеш!

—Олуг кенәзгә шартларыгыз турында барысын да бәйнә-бәйнә җиткерермен,—дип, илче башын иде.

—Рәхмәт,—диде Гәүһәршад,—хәерле юл.

—Без сине, тәнәкә, Мәскәүдә көтәбез, анагыз Нурсолтан ханбикәгә күрсәтелгән дәрәҗәдә хөрмәтләрбез,—дип, кенәз саубуллашырга ашыкты.

Нәкъ шушы вакытта тоткавыл керә, Булат бәкнең колагына нидер пышылдады. Тегесенең йөзе агарынып китте.

—Урман авызында хан җайдакларын күргәннәр, нишлибез?

Бүлмәгә бер мәлгә шик-шөбһә сөреме эленде, ыгы-зыгы кубып алды. Тәнәкә генә салкын канлылыгын җуймады.

—Ни-нәрсәгә колакларыгызны астыгыз әле, куян йөрәкләр, әллә оныттыгызмы, без ауда лабаса! Килгән кеше китә дә ул, ә хәзер кенәзне озатыгыз, минә аңа хан җайдаклары белән очрашырга ярамый.

Бераздан шау-гөр килеп аучылар кайтып төште. Мактанырлыклары бик үк күренмәсә дә, кәефләре шактый күтәренке иде. Җилбикәгә ачу итеп, кымыз дастарханы җәйдергәннәр иде. Хәзер әнә телләре телгә йокмый.

—Бар дөньяны су баскан, ә үрдәкләрнең гамендә дә юк,—дип ясмык иреннәрен җәеп көлде Чура морза,—ук артыннан ук атабыз, алар...

—Ук тимәсә, аткан белән кош үлмәс ди, морза, димәк ки, сөмәкләрегезне чарлап җиткермәгәнсез, фаразан,—дип чеметеп алды Давыт бахшы.—Кыек атып, туры тисә генә инде...

—Ул кадәр гарасатка, монысына рәхмәт әйтегез,—дип акланды кайсыдыр.

Кече Гали генә бахшының сүзенә ни мәгънә салганын аңлап бетермәде, күрәсең, шарык-шырык көләргә тотынды. Үзе көлә, үзе такмаклый:

> Безнең атай аючы,
> Эшләмичә баючы;
> Без үзебез төлкече,
> Булмыйк адәм көлкесе... ха-ха-ха...

Чура морза да күкәй салган тавык кебек кыткылдап кына тора, бер җавапка биш җавап, кымыз ару җибеткән тегене.

—Ышанмагыз, җәмәгать, шул кырык алдарның тетелдәвенә,—дип янә калкып чыкты,—коры куык бит ул, кеше кулы белән ут күрергә ясап куйган кебек. Тач мәзәктәге куян инде. Тыңлаң, сөйләп тә бирәм. Имеш, бервакыт ерткычлар безнең шикелле ауга чыкканнар. Талап-тешләп аюны урманнан куып чыгарганнар да, акланга төртеп екканнар моны. Шунда куян аюның колагыннан тотып: «Уф алла, көчкә тоттык», дигән. Шул сүзе өчен көлешеп, ерткычлар ит бүлгәндә мактанчык куянга да өлеш чыгарганнар, аюның колагын кисеп тоттырганнар. Кече Гали дә шул чут, күрегез, ничек башкалар рәтендә аучы сыман йөргән була. Югыйсә букчасында ник бер сыңар үрдәк булсын, ха-ха-ха...

Сунарчылар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә озак кына даулаштылар. Гәүһәршад башта елмаебрак кына тыңлап утырса да, мактанышу тешенә сылана башлагач, чырае үзгәрде, тавышын басып:

—Иснәнеп йөрүчеләр белән очраштыгызмы?—дип белеште.

Әлеге сорау аучыларны чынбарлыкка кайтарды.

—Нинди иснәнеп йөрүчеләр, тәнәкә?—дип кайтарып сорады Апай углан.

—Хан шымчылары.

—Сафагәрәй әнчекләренә генә биреш мәбез анысы,—диде Чура морза,—бу, тәнәкә, янә минем хаклыкны дәлилли. Сафагәрәй хан әҗәлен Казан каласында табарга тиеш. Чура морза аның Газраиле. Ул Казанга сукыр чебен урынына ябышты. Ник дигәндә, тәхет тәмен бик иртә татыды. Фәкать үлем генә коткарачак безне ул килмешәктән.

—Сезгә мәгълүм, җәмәгать, мин ханнарны үтерүне хупламыйм,—диде Булат бәк.—Бер мәртәбә авызым пеште инде, янә бу хатамны кабатлыйсым килми.

Сүзнең Мөхәммәдәмин ханга каршы оештырылып та, гамәлгә ашмаган фетнә турында барганын барысы да төшенде. Ләкин моны тәфсилләп тормадылар. Ханның бертуган сеңлесе Гәүһәршад алдында бу урынсыз иде.

—Син әле генә аю авы турында мәзәк сөйләдең, Чура морза, ошаттым,—дип сүзгә кушылды тәнәкә,—мәгънәле. Ерткычлар итне аюны үтергәч кенә бүлешкәннәр. Ә без исә әле иректә йөргән аюның тиресен өлешләргә кыҗрыйбыз. Иң әүвәл Сафагәрәйне тәхеттән береп төшерергә кирәк. Аннан соң нишләтергә икәнен уйлашырбыз. Без гамәлләребезне шулай әзерләргә тиешбез ки, бер чит җан иясе дә бу хакта белерлек булмасын. Югыйсә хан җәтмәсенә үзебезнең эләгүебез ихтимал. Андый тишек авызны үлем җәзасы көткәнен дә белдереп куям. Исегездә тотыгыз, безнең колаклар бүрәнә аша да ишетә.

—Тәүбә, тәүбә, әстәгъфирулла, тәнәкә...

—Шул Кырым килмешәген дөмектермәсәм, Карагир чаптарымны җир йотсын,—диде Чура үзсүзләнеп.

Бүлмәдәгеләр бер-берсенә карашып куйдылар. Аларны беренче чиратта Карагирга карата әйтелгән сүзләр гаҗәпләндерде. Чөнки морза тулпарын җаны кебек күрә, күз карасыдай саклый, тәрбия итә. Аты дөрестән дә Гали хәлифә качыры Дөлдөлдән ким түгел. Баскан урынында ут уйната, чабышта да һәрвакыт беренче, башкаларны җир буе калдырып килә. Гәүдәсе тоелмый да, гүя аяклардан гына тора. Озын, нәфис, көчле аяклар.

—Бусфал нәселеннән ул минем Карагирем,—дип мактана Чура.

Бусфал җиһангирларның җиһангиры Искәндәр каһарманның аргамагы. Гөл туфрагы шикелле чем-кара булган ул. Карагир дә корымдай кара.

Искәндәр жиһангир үрнәгендә Чура морза да бер авылына Карагир исеме бирергә җыена.

Атасы Филипп патша Бусфалны Искәндәргә унике яшендә бүләк итә. Дөрес, әүвәл ул бу үгез башлы чабышкыны үзе өчен сатып алмакчы була. Ләкин тегесе һич тә буйсынырга теләми: сикерenә, пошкырына, дулый. Шунда улы Искәндәр бу пырдымсызны өйрәтергә алына. Баксаң, җүләркәй үз күләгәсеннән өркә икән ич. Малай күләгә эченнән яшеренеп кенә килә дә, эләктереп тә ала.

Бусфал хуҗасының барча хәрби орышларында да катнаша. Әҗәлен утыз яшендә Һиндстанда таба. Искәндәр яраткан атына багышлап Бусфал исемле кала кордыра.

Чыңгыз ханның елгыры—сөттәй ак Сәтәр дә риваятьләргә күчкән. Һәрвакыт орышның үзәгендә кайнаса да, Сәтәр жиһангирны бер мәртәбә дә кыен хәлдә калдырмаган. Кай тарафка юнәлергә, кем өстенә ыргылырга—ул үзе хәл иткән. Чыңгыз атына тулысынча ышанган.

Чура морзаның Сафагәрәй ханны күрәлмавы шул кадәр көчле иде ки, кирәк булса, аны юк итү өчен хәтта толпарын да корбан итәргә әзер.

***

Сафагәрәй кызу канлы кеше иде. Якыннарына кулларын да уйнаткалый. Әле дә баш шымчысының якасыннан эләктереп алды:

—Кала дошмани бәндәләрдән кайнап тора, ә син кәеф-сафа корудан бушамыйсың,—дип буа ук башлады.

—Кү-ү-зә-ә-түләрне көн-төн а-а-лып бар-а-а-быз, х-а-а-н,—дип акланды шымчы этенә-төртенә.

—Миңа нәтиҗә кирәк, аңлыйсыңмы, нәтиҗә!

—Булат бәк белән Кече Гали оештырган үрдәк авын өч көн буе күзәттек.

—Шуннан?

—Ау карарга Гәүһәршад тәнәкә дә килгән иде. Алай шик уятырлык хәлләр булмады. Кемнедер урман эченнән генә озатып җибәрделәр җибәрүен. Киеменә караганда урыс кешесе. Ау буенча белгеч, киңәшкә чакырганнар иде булса кирәк.

—Әйттем бит, бөтен бәла-каза урыслардан килә, дидем. Дөрес тә бу!

Бу сүзләрне хан бер читтәрәк тыныч кына утырып торучы Шөгер аталыкка карап әйтте. Күрәсен, баш шымчыны кабул итәр алдыннан алар нәкъ шушы хакта фикер алышканнар иде.

Гали Шөгернең шымчы барында сүзгә керәсе килмәде, ахры, фәкать сакалын гына сыпыргалагандай итенде. Ә хан дәвам итте:

—Каладагы барча урысны зөлфәкар кылычы астыннан үткәрергә кирәк. Алар минем ханлыгыма турыдан-туры яныйлар икән, мин кул кушырып утырырга тиешме? Юк! Баш угланны чакыртыгыз. Тиз!

Сафагәрәй унөч яшендә тәхеткә утырды. Кабарынкы ирен өстендәге бала йоннары да беленеп кенә килә иде әле. Төмсә чырайлы, сирәк тешле, эченнән энә үтәрлек ябык. Әмма ут борчасы сыман хәрәкәтчән, тиктормас. Тәвәккәл, кыю. Еш кына Шөгер аталыктан узып, аның белән килештермичә, әмерләр дә биргәли иде.

Казан ханлыгының бик тә кыбырсыклы, тынгысыз һәм катлаулы чоры иде бу. Шуңа мөнәсәбәтле рәвештә, Сафагәрәйнең хакимлеге дә күңелсез вакыйгадан башланып китте. Аны Казанның олуглары Кунак атавы янында зурлап каршы алдылар.

—Хуш киләсен, мөхтәрәм хан галиҗанаплары, Аллаһы Тәгалә игелекле гамәлләр кылырга насыйп итсен. Сәгадәтле, гайрәтле вә данлыклы

падишаһыбыз булырга язсын, теләкләребезне кабул кыл,—дип сәламләде аны Борһан сәед.

Сафагәрәй алдан өйрәтелгәнчә, атыннан төште дә, түбәнчелек белән башын бөгеп, сәедненң кулын үпте.

Берничә көннән Борһан сәедненң чын йөзе ачылды. Баксаң, ул олуг кенәз Василийның ышанычлы бәндәсе икән. Яшь ханны Мәскәүгә тотып тапшырырга сүз биргән, хәзерлек эшләре дә алып барган, имеш. Кырымлыларның моңа бик ачуы чыкты, сәедне көпә-көндез урам уртасында буып үтерделәр.

Бу вакытта Казан тәхетенең төп дәгъвачесе Шәехгали хан белән җибәрелгән урыс гаскәре Нижнийга килеп җиткән иде инде. Сафагәрәй дә гаскәрен кырга алып чыкты. Тиздән Шәехгалидән язу китерделәр. Ул аңа яхшы чакта үзенең пайтәхете булган Казаннан китәргә боерган иде. Моңа каршы Сафагәрәй Шөгер аталык киңәше белән: «Әгәр дә син минем падишаһлыгымны алырга теләсең, без эшне корал ярдәмендә өзәргә тиешбез. Тәңре кемгә уңайлык бирсә, шул аны биләсен»,—дип җаваплады.

Орыш башланды. Казанда, урысларныкы кадәр үк булмаса да, туплар хәтсез иде, әмма тупчы берәү генә иде. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, ул да ядрә кыйпылчыгы тиеп, җан тәслим кылды. Тик барыбер Тәңре Сафагәрәй ханга хәерхаһ булды. Урыслар шәһәргә бәреп керәбез дип күтәрелгәндә генә кара болыт чыгып, каты яңгыр ява башлады. Койды гына, болытыние белән ишелеп кенә төште. Күк күкри, яшен яшьни. Мизгел эчендә тупларны, башка җиһазларны су басты. Гаскәриләр яңгырга чыдый алмыйча урыннарын ташлап китте. Казанлылар әлеге тупларны, барча коралны җыеп алдылар.

Сафагәрәй иртә җитлекте. Хәзер инде ул сөлектәй күркәм буй-сынлы ир-егет. Аңа икенче бичә итеп Мангыттан Мамай морзаның олы кызы Хәдичәне ярәштеләр. Хәдичә дә суырып йотарлык чибәр иде. Бик пар килгәннәр.

...Баш шымчы чыгып киткәч, Шөгер аталык, Сафагәрәйне каршысына утыртып, гадәттәге аңлату эшләренә кереште.

—Кабалану борча үтергәндә генә ярый,—дип сөйләп китте,—урысларга синң кадәр үк погромнар оештырганнар. Хәтта Мәскәү тәрбиясе алган Мөхәммәдәмин хан да тәмуг утында яндырган аларны. Ләкин нәтиҗәсе бервакытта да уңай булмаган. Хәзер хәл бигрәк тә катлаулы. Мәскәүнең гаскәре дә ишле, коралы да күп. Син аларның һөҗүменә каршы тора алмаячаксың. Сиңа казанлылар болай да: «Берәр куркыныч хәл генә килеп чыксын, Кырымнан килгән хан үз иленә сызачак, безне ташлап качачак»,—дигән гаеп ташлыйлар. Мәскәүне турыдан-туры яклаучылары да бихисап.

—Син Булат бәк ише сатлыкларны күз уңында тотасыңмы?—дип сорады хан.

—Дастархан түрендә Гәүһәршад тәнәкә утырганны хәтереннән чыгарма.

—Шуңа күрә дә ул еланнарның агуын өннәрендә костырырга кирәк тә инде, аталык.

—Кан гына коелмасын, бел, нахак канның бер хакимгә дә дан китергәне юк. Кан орышта гына лязим.

—Артык йомшак күңелле кеше син, аталык,—диде хан канәгатьсезлек белән.—Алар мине тәхетемнән мәхрүм итәргә җыенсыннар да, мин кан чыгарырга ярамый дип утырыйммы? Юк, аталык, тәхетем хакына мин теләсә-нинди корбаннарга барырга да әзер!

***

Фагыйлә күрәзәче бик изаланып үлде. Тәне суынды, аяклары агарынып катты, жаны гына чыгарга ашыкмады.

—Күзләрен сөзеп карый, нидер әйтергә тели бугай,—диде ясин чыгарга килгән туганнан туган энесе Хәсән мулла,—әллә таныды инде?

—Теле кисәк кенә бетте шул,—диде икенче хәрендәше,—бәхилләшә дә алмады, бәгырькәем.

—Ходай ярлыкасын инде, дөньялыкта гөнаһны күп жыйды, Аллаһы хуп күрмәгән шөгыльгә бирелде...

—Амин!

Күрәзәче әлеге сүзләр белән риза-бәхил түгеллеген белдергәндәй авызыннан өзек-өзек яшелле-зәңгәрле авазлар чыгарып алды.

Ясин да ибенә ятмады бугай. Мулла киткәч тә гасәбиләнүендә булды. Кайчак тавышы тынып, үтеп киткәндәй сыман да тоела. Саклаучылары догага керешүгә, янә әлеге килбәтсез яшелле-зәңгәрле авазларын сыга башлый. Чалшайган йөзе тагын да ямьсезәя, күзләре акая. Бераздан ничектер жиңеләеп тә китә шунда. Тик озакка түгел, янә үзәк өзгеч ухылдау башлана.

Күрәзәче әжәл белән тарткалашкан атнада Гәүһәршад тәнәкә дә бик тынгысыз хәвефле көннәр кичерде. Әллә ничек шунда, башы түнеп-түнеп китә дә кызышырга тотына. Моңа кадәр дә баш хастасы булгалый иде булгалавын, әмма тастымал белән кысып бәйләүгә, бетеп тә китә иде. Ә бу бөтенләй үзгә халәт. Башы гына түгел бит, тиктомалдан йөрәге кага башлый, берара бугазына килеп тыгыла да, тынын куырып ала. Шыбыр тиргә бата. Күңелен шик-шөбһә, курку хисе баса. Ниндидер фажигагә дучар булыр шикелле. Керфек тә какмыйча үткәргән шом тулы гасәби төннәре ешайды. Им-том да, дару-төнәтмәләр дә аның газапларын жиңеләйтмәде.

Сырхавына жиденче көн дигәндә күрәзәченең теле кайтты. Юк, теле кайтты дигәч тә, сөйләшер дәрәжәдә түгел иде. Шулай да авызыннан сүзгә охшаш ниндидер авазлар чыга башлады.

—Ни әйтергә телисең, Фагыйлә түтәм, әйт, эчеңдә калмасын,—дип туганы аның өстенә иелде.

Күрәзәченең жеп шикелле генә калган кысык күзләреннән ике бөртек яшь сытылып чыкты. Туган сеңлесе аптырап китте. Чөнки тәтәсенең күз яшен тәүге кат күрүе иде.

—Капылт егылдың шул, васыятеңне дә ирештерергә өлгермәдең, шуңа бик көябез...

—Ва-а-сы-я-ять... фа-а-л... төр-р-р-гә-әк... тә-ә-ә-нә-кә...

Туган сеңлесе фал китабын кулына алгач, барысын да аңлады, иясенә тапшырды. Аның эчендә: «Тәнәкә, аманәтемне кабул ит»,—дигән кыска гына язуы да бар иде.

—Нинди тузга язмаган нәмәстә бу, нигә теләсә-нинди тиле-миледән чүп-чар жыясыз,—дип гасәбәсен әрләп ташлады Гәүһәршад,—болай да үземне кая куярга белмим...

—Күрәзәче Фагыйлә абыстайның аманәте,—диде Хәдичә.

—Нинди күрәзәче, нинди аманәт?—дип тузынды бикә.

—Кышын барган идек бит инде, буранда...

—Ә-ә, теге аздакы күвәндәсеме? Ахмак ич ул, тинтәк. Ышандылар ди шул жүләр корткага. Бар, бу шакшы төргәкне чүплеккә чыгарып ташла!

Искәрмәстән генә Гәүһәршадның кулы фал китабына орынып куйды. Һәм ни хикмәт, аны чорнап алган кара пәрәвез жепләре дә чишелеп китте.

Шул төнне күрәзәче төшенә керде. Янә гозер белән аның янына килгән,

имеш. Мич арасыннан күз әфә акаеп баккан.

—Абыстай, нигә шулай күзеңне алартасын?—дип сорады Гәүһәршад, минем нинди гаебем бар?

—Гаебең зур,—диде күрәзәче кара янып,—син минем әманәтемне санга сукмадың. Бәхетеңә күрә гасәбәң гакыл иясе икән, фал китабымны чүплеккә атмады, кадерләп-хөрмәтләп урын-җиргә яшереп куйды. Соратып ал.

—Ярар, абыстай...

Шулвакыт сәке астыннан борыла-сарыла көтүче чыбыркысыдай озын кара елан чыкты да, авызыннан ут бөркеп, аңа таба шуышып килә башлады. Гәүһәршад чырылдый-чырылдый сәке өстенә өелгән урын-җир өстенә ыргылды.

—Коткарыгыз!

Күрәзәче аның үрсәләнүенә каршы:

—Сиңа, тәнәкә, хәзер ошбу хәшәрәтләр белән еш очрашырга туры килер,—диде.—Ай-кояш тотылу, җил-гарасат, яшен, йолдыз атылулар ише зилзиләләр дә моннан ары синең өчен аерым мәгънәгә ия булыр...

Кинәт кенә шалтыр-шолтыр итеп идән такталары чайкалып китте, әйтерсең лә, өйгә дию пәрие килеп бәрелде, хәтта бүлмәнең яртысын биләп торган биниһая зур мич тә кыйшайгандай булды. Багучы да юкка чыкты. Гәүһәршад кара елан белән икәүдән-икәү генә торып калды.

Елан өреп тутырган шикелле күзгә күренеп калынайды, зурайды, уты да көлтә-көлтә бөркелә, эссесенә чыдар хәл юк. Шунда янә бер могҗиза булып алды, еланга кеше башы үсеп чыкты. Баш Кырым чалмасына уралган иде, ә тажы—Казан тажы. Сафагәрәй ханның башы ич бу! Ботаклы-чатаклы шөкәтсез куллар да пәйда булды...

Күрәзәченең: «Ярдәмчеңне чакыр!»—дигән әмере яңгырады.

—Апай углан!

Идән астыннан Апай углан калкып чыкты да кылычы белән Сафагәрәй башлы еланга селтәнде. Баш барыбер урынында калды...

Гәүһәршад уянуга, таң беленеп кенә килүгә карамастан, Апай угланга кеше чаптырды. Чөнки фетнәнең язмышы кыл өстендә. Бу куркыныч төш шуңа ишарә иде.

Тәнәкәнең шик-шөбһәсе расланды. Апай углан килә-килешкә:

—Әллә хан сиңа да шымчылар куйдымы?—дип белеште.

—Нинди шымчылар, углан?

—Кичә кич безнең утар янында шымчылар йөреде...

Гәүһәршадның кашлары җыерылып төште. Димәк, хан фетнә турында белә. Белә! Ә нигә чара күрми? Ни көтә? Ошбу табышмакның төбендә ни ята? Бәлкем, ясавыллары инде ат өстендәдер? Хан юкка гына шымчылар куйдырмас.

—Углан! Хәзер үк набат сук, чирүеңне җый!—диде тәнәкә,—кизәнеп тә сукмый калсак, ояты бөтен ыру-кабиләбезгә төшәр.

—Чирүне җыясы юк, бикә, ул сарайда, казанлы хан эчкеләренең яртысыннан артыгы безнең якта,—диде углан,—сызгыруны гына көтәләр.

—Сызгыр, углан, таң суккан кеше генә җиңүгә өмет итә ала.

—Баш өсте, тәнәкә.

—Инде дога кылыйк, углан, Аллаһы безгә форсат бирсен.

—Әлхәмдү лилләәһи раббил гәәләмин...

***

Сарай тәрәзәләренә иркә нурларын бөркеп, Ослан таулары өстендә аллы-гөлле кояш пәйда булды. Әйе, кояш бүген аллы-гөлле булып туды, гүя ки чит-читләренә чәчәкле-чуклы челтәр элгәннәр. Үзе хозур, үзе мәрхәмәтле. Кояш нуры—шәфкать кулы дип әйткән ич бабаларыбыз да.

Шыксыз, жилле, салкын көннәр апрельнең үзе кебек артта калганга охшый. Бирсен ходай! Алдагысы җылы, йомшак көннәре белән кинәндерер, шәт.

Сафагәрәй күзенә төшкән шушы шифалы нурлардан уянып китте. Күптән инде кояшның болай якты көлтә булып бүлмәгә ингәне юк иде. Үзеннән-үзе дәрте кузгалды, янында мыш-мыш йоклап яткан хуш исле хатынына куллар сузылды.

Хәдичә, уяныр-уянмас килеш, песи баласыдай назланып, иренә сарылды...

Шул вакыт сак бүлмәсендә нindидер ыгы-зыгы купты. Кылычлар чыңлавы ишетелеп китте, кемнәрнеңдер үлем ачысы кергән куркыныч тавышлары колакны ярды. Ул да булмады, хан катына ясавыллар бәреп керде. Хан бер күз сирпүдә Апай угланны танып алды. Аһ, соңладым, дигән уй кисеп алды йөрәген. Ул торып басар хәлдә түгел иде, чөнки анадан тума килеш. Алай да үзенекенә ошамаган чәрелдек тавыш белән:

—Фарраш[9], мин Казан ханы Сафагәрәй, әмер бирәм, тотып бәйләгез бу фетнәчеләрне!—дип кычкырды.

Апайның кыска итеп кырылган сакал-мыегы эчендәге калын иреннәренә мыскыл кунды. Берара сөзеп карап торды да әйтте:

—Син хан түгел инде, юкка көчәнмә,—диде.

—Хакың юк...

—Менә нәрсә, Сафагәрәй,—диде углан дустанә бер кыяфәттә,—җәт кенә киен дә, сыз моннан, мин сиңа ирек бирәм.

—Хакың юк...

—Мине кире уйларга мәҗбүр итмә, Сафагәрәй.

Углан кылычын кынысына кертте дә, озын гәүдәсен турыга катырып, бүлмәдән чыгып китте.

Шушы ук вакытта Чура морза башкисәр яугирләре белән кирмән эчендә Кырым тоткавылларын пыран-заран китереп куып йөри иде. Тегеләре кая керергә тишек тапмый, ары сугылалар, бире сугылалар, кычкырышалар. Ишетүче генә юк. Чикләвек яргандай бер-бер артлы башлар оча, гүя йон бүксәләр...

—Сафагәрәй ялмавызга үлем, яшәсен хөррият!—дип, Чура әледән-әле оран салып, котыртып тора.

Өйлә тирәсендә морзаның карлыккан тавышы кала диварларында ишетелә иде инде. Иң беренче булып, Сафагәрәйнең аталыгы Гали Шөгер йортына бәреп керделәр. Сак каршылык күрсәтергә керешеп караган иде дә, кан исеннән ярсыган яугирләр аларны минут эчендә турап ташлады.

Аталык үзе өйлә намазын тәгаллап, зекергә тотынган, «Аятел көрси» догасын укый гына башлаган иде.

—Әллаһү лә иләһә һүәл хәййүл каййүм...

—Сиңа ясин чыгарга кирәк, тәкъсир,—дип ырылдады Чура морза.

Гали Шөгер, гадәтенчә, хәлне үгет-нәсыйхәт белән төзәтмәкче итте.

—Ходайдан куркыр идең, морза, атаң кебек кеше ләбаса мин, Коръән-кәрим өлкән яшьтәге тәкъвә адәмнәрне хөрмәт итәргә куша, хөсне ният белән яшәү фарыз, догалыкларга ешрак күз салырга кирәк...

—Телеңә салынма, мөселманча үлим дисәң, иман китер...

—Кырым тарафларында тәрбия алган бәндә ләбаса син, морза, нигә шулай үз кардәшләреңне күрәлмыйсың,—дип, Аталык һаман морзаны акылга китерергә чамалый иде.

—Беләсең килсә, шуңа күрәлмыйм мин Кырым әнчекләрен, алар мине илемнән аермакчы иткән.

[9] Фарраш—сакчы

—Кайсы ыру үчле—канны шул коя... Акылыңа ки-и...

Гали Шөгернең сүзе дә, гомере дә шушы мизгелдә өзелде.

Бер кизәнүдә Чураның кылычы чүмәләдәй олы гәүдәсен икегә ярып төште.

Ханның иң төп таянычыннан саналган Раст бәк яугирләрне әзерлекле каршы алды. Чөнки фетнә турындагы хәбәр таралып өлгергән иде инде. Капка янында кыска, әмма аяусыз бәрелеш булып алды. Морза да берничә яугирен югалтты. Бу хәл аны чик дәрәҗәдә чыгырыннан чыгарды.

—Этләргә эт үлеме, җебеп төшмәгез,—дип акырды.

Чын мәхшәр шунда башланды. Раст бәкнең дә җегәре бар, аның да бирешәсе килми. Җитез һәм төз гәүдәсе бөтерчек урынына бөтерелә. Ләкин хәле бик чамалы. Чурага ярдәм һаман өстәлеп тора. Инде, әнә, йорт ишеген дә каерып ташладылар. Ә анда бәкнең ишле гаиләсе. Аны бигрәк тә үсеп килүче алты улының язмышы борчый. Төпчеге әле имчәк бала. Ул шунда ыргылды. Бер кулында—нарасые, икенчесендә кылыч. Куркышып чаршау араларына кереп поскан хадимәләрдән, бала караучылардан ары янында беркем юк. Өстенә ябырылып килгән беренче яугирне ул бер селтәнүдә егып салды, икенчесеннән арына алмады, улын күкрәгенә кысkan хәлдә сыгылып төште. Башка улларының фаҗигасен ул инде күрмәде. Күрә калса, мөгаен, кылычтан түгел, йөрәге ярылудан үлгән булыр иде. Аларны ит турагандай турадылар.

Сафагәрәй Идел буйлап Нугай-мангыт якларына качты, җәмәгате Хәдичә бануның атае Мамай морза утарына барып егылды.

Чура морза Апай угланны мәми авызга чыгарды.

—Мин тәнәкәне алдан ук кисәттем, ханның башына җитмим дидем...

—Хиссият кара халыкка хас сыйфат, углан,—диде Чура морза,—хаким бәгырьле була алмый. Икенең берсе: җә син җиңәсең, җә дошманың өскә чыга. Ә дошман өскә чыкмасын өчен аны юк итәләр.

—Куегызчы, зинһар, бу кысыр хәсрәтләрегезне,—дип Булат бәк тә сүзгә кушылды,—безгә хәзер яңа хан мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Һәм кичекмәстән! Калганын ул җиренә җиткерергә тиеш.

***

Казан илчеләрен Мәскәү шау чәчәкле алмагачлары белән каршы алды. Шөкер, тоткарлыксыз гына килеп җиттеләр.

—Юлыбыз уңар шикелле,—диде Фәйрузат бәк,—күрегез, кала ничек чибәрләнгән.

—Башкача була да алмый,—диде Колчура морза.

Дөрестән дә, теге вакытта Казанга яшерен рәвештә генә килеп киткән урыс илчесе Федор Карпов очрашу мәсьәләләрен хәл итеп куйган иде. Олуг кенәз фетнә башында торучы Гәүһәршад тәнәкәгә, элеккеге хаталары өчен ачу тотмавын белдереп, ярлык та җибәргән иде.

—Тәнәкә гаһеднамәне[10] тулысы белән үткәрергә боерды бит, ә бу хәл, үзенә мәгълүм, морза, бик сирәк була,—диде Фәйрузат уйчан гына.

—Әйе, безнең бер карыш та чигенергә хакыбыз юк,—дип җөпләде аны Колчура,—тәнәкә галиҗәнаплары...

Ул җөмләсен төгәлли алмады, кисәк кенә аты абынып китте, чак җиргә очмады, ярый, куллары көчле, ияргә тотынып өлгерде.

—Менә бусы начар фал инде, морза,—диде Фәйрузат бәк уены-чыны белән бергә,—бәла аяк астында йөри ул.

Илчеләрне Кремль капкасы янында озак тоткарламадылар. Олуг кенәз

[10] Гаһеднамә—килешү

дә көттермәде, илчеләргә баштук шәраб тәкъдим итте. Гадәттә, ошбу юсык[11] сөйләшүләрнең ахырында гына була иде.

Василий үзе шәрабка кагылмады. Казан илчеләре дә кунакчыл хуҗаның күнеле булсын өченгә генә бәллүр касәгә иреннәрен тигезеп алдылар.

—Олуг кенәз, сина Казан хөкүмәте башлыгы Гәүһәршад тәнәкәдән күптин-күп сәламнәр, күптин-күп изге теләкләр алып килдек,—дип, түбәнчелек белән башын иде Фәйрузат илче,—Ходай озын сәламәт гомер, хәерле патшалык насыйп итсен.

—Туганым Гәүһәршад тәнәкәгә дә минем саф һәм эчкерсез теләкләремне житкерегез,—диде Василий.—Инде йомышыгызны әйтегез, тынлыйм.

Колчура баш илчегә хәстәрләп куелган кәгазьләрне тоттырды. Ә тегесе, гомер булмаганны, каушабрак калды, әллә нишләп теле тотлыкты.

—Ж-ж-жән...

—Шәрабеңне эчеп куй, бәк, җиңеләебрәк китәрсең,—дип, дустанә киңәшен бирде олуг кенәз.

Чынында да Фәйрузат илченең кыюлыгы кайтты, теле дә ачылды.

—Җәнәбе гали, без Казан хөкүмәте башлыгы Гәүһәршад тәнәкәнең ярлыгын алып килдек. Анда түбәндәгеләр язылган...

—Кирәкми, укып торма, бәк, без аны үзебез җентекләп өйрәнербез,—дип бүлде Василий илчене,—хансыз ханлык булмый, без кабат Шәехгали ханны тәгаенләп торабыз, туганым Гәүһәршад тәнәкә дә ризалашырдыр дип ышанам.

Василий каш астыннан гына илчеләргә сөзеп карап алды. Бу минутта ул үтә дә житди иде. Шушы житдилек аны картайтыбрак җибәрде. Ике каш арасындагы пар буразнасы тирәнәеп китте, иреннәре кысылып, бау шикелле генә булып калды.

Бу юлы Колчура морза җаваплады.

—Ярлыкта барысы да теркәлгән галиҗәнап, безнең вәкаләтләр шул кысаларда гына кануни көчкә ия,—диде.

Василийның йөзе янә кырысланды. Теш арасыннан гына:

—Минем карарны иртәгә җиткерерләр, хушыгыз,—диде. Шәраб тәкъдим итмәде.

Киңәшчеләре белән калгач, олуг кенәз Гәүһәршадның ярлыгын сүзен-сүзгә кычкырып укытты да уйга төште. Ярлык, кагыйдә буенча, дипломатик рухта язылган. Төче, мактау сүзләре күп. Шул сүзләр арасында игътибары бер җөмләгә төртелде. «Падишаһ Казанга хан итеп Шәехәүлияр солтанның углы Җангалине бирсә иде» дигән җөмлә иде бу. Һәм бу үтенеч аның ниятен астын өскә әйләндереп куя иде.

—Җә, ни әйтәсез?

Әлеге сорау күпчелек санда яңгыраса да, беренче чиратта Федор Карповка юнәлдерелгән иде. Чөнки Казандагы хәлләрне аннан да яхшырак белүче юк, күп еллар анда калагай вазифасын үтәде, чак кына башын да җуймады. Гәүһәршад фетнәсен әзерләүдә дә катнашы бар.

Кенәз җавапка керешкәнче тамагын кыргалап алды.

—Нәрсә, басурманныкы кебек синең дә тамагың корыдымы әллә?

Карпов олуг кенәзнең эчке сүз сөрешен шундук аңлап алды.

—Басурманнарга карата олуг кенәз мөнәсәбәте дә басурманнарча булырга тиеш,—диде.

—Ягъни-мәсәлән...

—Син, галиҗәнап Василий Иванович, атакаең олуг кенәз Иван IIIнең васыятен тулысынча үтәдең, Русьне Мәскәү канаты астында берләштерүне тәгәлләдең. Псков, Смоленск, Рязань шикелле төбәкләрнең киребеткән

[11] Юсык—йола

хөрриятпәрвәр кенәз аламаларын давыл еккан имәндәй сындырып ташладың. Русь зурайды, кинәйде, ныгыды. Аурупа да безнең белән чутлаша хәзер. Гомерлек көндәшебез бөек Литва да сырт йонын кабартудан фәтвә чыкмасын аңлады сыман. Мәскәү чын мәгънәсендә өченче Римга әверелде.

Залдагы боярлар әлеге сүзләрне хуплап гөрләшеп алдылар.

—Онытма, кенәз, сүзебез Казан ярлыгы турында,—диде тәхет хуҗасы. Шулай да бу багышлама аңа ошый иде.

Карпов, билгеле, патшаның тәгаен кинәш көткәнен бик яхшы белә, шул ук вакытта, форсаты чыкканда нигә үзеңне күрсәтеп алмаска? Бик оста телмәр һәм күренекле сәясәтче ич ул!

—Татарларда: «Кое төбеннән караучыга күк бәләкәй, энә тишегеннән караучыга дөнья бәләкәй» дигән мәгънәле әйтем бар,—диде.—Үзләренә бик туры килә. Ә без бөркет халык, хөр халык. Бу исә кылган гамәлләребезне Көнчыгышка, шул исәптән Казанга да, православиенең чикләрен киңәйтү мәнфәгатьләреннән чыгып карарга тулы нигез бирә. Русь тагын бик күп төбәкләрне үзенә сыйдыра ала әле.

Карпов каш астыннан гына олуг кенәзгә күз төшереп алды. Аның да канәгатьлеге йөзенә чыккан иде.

—Ләкин һәр эшнең үз вакыты бар,—дип дәвам итте илче,—миңа калса, тәнәкәнең шартларын тулысы белән кабул итү мәгъкуль булыр иде. Бикәнең җыры җырланган инде, ике-өч ел Русь өчен зур роль уйнамый дип саныйм.

—Шаехгали мәсьәләсендәме?—дип сорады олуг кенәз.

—Безнең өчен Җангали ни, Шаехгали ни, барыбер түгелмени? Икәве дә олуг кенәзгә җаны-тәне белән бирелгән затлар. Җангали балигъ булганчы тәнәкәнең ханлык дилбегәсен үз кулында тотасы килә. Бары шул гына. Үзенә күрә бер уен. Бирик туганыбызга әлеге мөмкинлекне, һич тә оттырмабыз. Казанны Кырым кулына тапшыру исә максатларыбызны күпкә ерагайтыр, хәлне күпкә катлауландырыр иде.

Шулай итеп, уйламаганда-көтмәгәндә унбиш яшьлек Касыйм шаһзадәсе Җангали, агасын узып, Казан тәхетенә утырды.

Ниһаять, Гәүһәршадның хыялы гамәлгә ашты, васый сыйфатында Барча Казан җиренең тулы хокуклы хакиме дәрәҗәсенә иреште, ханлык янә Олуг Мөхәммәд ыруына кайтты. Ул үзен Мисыр патшабикәсе Кәлимә кебек хис итә башлады.

***

Шаехгалигә бу яңалык Нижнийда килеп иреште. Ә монда ул хәбәр булу белән Казанга тизрәк барып житү, сәгате-минутында хакимиятне үз кулына алу максатында җибәрелгән иде. Олуг кенәз үзе чакыртып әйтте:

—Казан зур түнтәрелеш алдында тора, тәхеткә янә син утырачаксың, бүгеннән үк Нижнийга чыгып кит,—диде.

Шаехгали карт гашыйк кебек үзен-үзе белешмичә олуг кенәзнең башмагын, алтынлы-чуклы камзулының чабуын үбәргә тотынды.

—Рәхмәт, падишаһым, галиҗәнап атаем, ялгыш ышанычыңны аклый алмыйча йомшаклык күрсәтсәм, усал аюларыңның читлегенә ташла, анда да: «Яшәсен олуг кенәз, атакаем Василий Иванович!»—дип үләрмен.

—Беләм, беләм, син иң тугры этем, мин сиңа ышанам,—диде олуг кенәз.

Шаехгали шул көнне төнгә каршы дугаләмәт сәфәр чыгып китте. Хатыны, якын даирәсе җыенып калды. Алар берничә көннән кузгалырга тиеш иде.

Дәрәҗәне ярата иде Шаехгали. Ә Казан тәхете Мәскәү тәхетенә тиң

тәхет. Тәмен татып карады инде, белә. Әлеге бәхетне чагыштырыр нәрсә юк бу җиһанда. Хакимлек ләззәте, мөгаен, оҗмах ләззәте белән генә тиңләшә аладыр.

О-о, хаким! Бөекләрнең бөеге, зирәкләрнең зирәге, батырларның батыры. Син—әһле тәдбир[12]. Син—әһле өлфәт[13]!

Һәммә күзләр сина төбәлгән. Син буй җитмәс казый. Адәмне хөкем итү, янә дә ярлыкау өчен сүз әйтүеңнен дә хаҗәте юк, чәнти бармагыңны селкетү дә җитә. Чөнки син—хаким!

Меңнәр язмышын учыңда тотудан да олырак бәхетнең булуы мөмкинме соң?

Шушы хыяллар бәллүендә йокыга тала Шәехгали, шушы күркәм хыяллар кочагында күзләрен ача. Шөкер, бу хыяллар хыял булудан туктады, олуг кенәз Василий атакай ана үзенең фатихасын бирде. Иншаллаһ! Кырым черчетбашы[14] Сафагәрәйнең кояшы батачак, Аллаһы боерса. Ул аның бугазыннан буып ташлар иде. Теге вакытта тәхеттән шул маңка малай мәхрүм итте ич инде аны. Үчен кайтарачак әле, кайтарачак!

Ясавыл шаһзадәнең кылычын селтәнгәләп ишекле-түрле йөргән вакытына туры килде, бүлдерергә кыймыйча озак кына сәерсенү белән күзәтеп торды. Ләкин бүлдермичә дә ярамый, алгы бүлмәдә олуг кенәзнең әле генә Мәскәүдән килеп төшкән атчабары көтеп тора.

—Хан галиҗәнаплары, Мәскәүдән ашыгыч хәбәрнамә, атчабар кабул итүеңне үтенә,—диде ясавыл тавышын күтәрә төшеп.

Шәехгалине «Мәскәү» сүзе бик тиз айнытты.

—Нигә аны баштук әйтмәдең, имгәк,—дип кычкырды,—бар, чакыр олуг кенәзнең вәкилен, тизрәк керсен!

Ул бер-бер йомышчы кенәз яки санлы дәүләт илчесен көткән иде, ә ишек катында гап-гади урта кул хәрби атчабар пәйда булгач, йөрәгенең бер чите өзелеп төшкәндәй итте.

Атчабар, дөрестән дә, бик яман хәбәр язылган ярлык алып килгән икән. Казан тәхетенә Касыйм ханы, аның танау асты да кипмәгән туганы Җангали тәгаенләнгән, имеш. Ике җөмләдән гыйбарәт кечкенә хәбәр. Бернинди аңлатма да, күрсәтмә дә юк. Ни өчен бер гаепсез килеш аны шулай мыскыл итеп, таптап-изеп ташлаулары хакында ләм-мим. Тәхеткә ул утырырга тиеш иде бит. Шуның өчен олуг кенәз үзе Нижнийга чыгарып җибәрде, якындарак тор, хәбәр алуга кичекмәстән Казанга элдертерсең, диде.

Их, Василий Иванович, Василий Иванович, картаюың шушыдыр, мөгаен. Бер кулың нишләгәнне икенчесе белми, күрәсең. Шулай булмаса, казны каргага алыштырмас идең. Мин бит синең маэмаең идем, миндәй бирелгән колың, ай-һай, моннан соң булыр микән? Беләм, дошманнарым буа буарлык. Кенәзләрең, боярларың арасында да мине өнәмәүчеләр күп, беләм. Әмма дә ләкин Мәскәү өчен мин иң файдалы татар ханы лабаса! Моны исеңнән чыгарып бик нык ялгышасың, атакай. Башбирмәс киребеткән Казанны аркаңда тоту һәркемнең кулыннан килми. Җангали ише селәгәй малайны анда йомып кына алачаклар. Утырсын иде Касыймында, анда да хан бүреге иде ич башында.

Шәехгали энесе Җангалине әлегәчә үз күрә иде, киңәшләрен бирә, ярдәм итә, туганнарча әрләп тә ташлый. Кыскасы, һаман яхшылык кына итеп килде. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк, чөнки аралары шактый, унбер яшь. Агасына аркаланмый кемгә аркалансын ди малай кеше. Хәер, хәзер инде асау[15] айгыр кебек җитешеп килә. Зифа буй-сынлы, киң җилкәле, нык бәдәнле булырга охшый. Ат өстендә дә нык тора. Шәехгали үзе күркәмлек ягыннан мактана

[12] Әһле тәдбир—алдан күрүче
[13] Әһле өлфәт—матур дус
[14] Черчетбаш—өербаш
[15] Асау—кыргый

алмый. Карсак гәүдәле, муен-җилкәсе бербөтен булып укмашкан. Куллары маймылныкы шикелле озын, тубыгына кадәр төшкән. Анасы Шаһи-Солтан йөкле вакытта аттан егылган. Аңа шулай карында чакта ук зәгыйфьлек килгән, колагына кадәр рәвешен җуйган. Аның каравы, ходай көчне, житезлекне кызганмаган. Төрледән-төрле узышларда ул бервакытта да беренчелекне бирмәде. Орыш кырында да аның белән очрашырга язмасын.

Бүген менә кояшы сүнде. Кара хәбәр бөтен якты өметләрен, матур хыялларын чәлпәрәмә китереп ташлады.

Шәехгали кыйнап ташлаган сукбай кебек сыгылып төште, бармакларын селкетергә дә кыймый утыра. Йөзе качкан, бөтен килеш-килбәтеннән чарасызлык, гафиллек бөркелеп тора.

Бераздан бүлмәгә йомшак кына баскалап хәләл җефете Фатыйма-Солтан керде. Ул шулай көймәдәй йөзеп кенә йөри белә, янына килеп басканын абайламыйча да каласың. Шәехгали исә җәмәгатен исеннән сизә. Хатынының исен, иң яраткан «Аҗаган» кушаматлы атының исе кебек үк,ерактан тоя. Алар икесе дә аның өчен иң кадерле затлар.

Атын мангыт токымыннан колын килеш үзе тәрбияләп үстерде. Хатынын да сөеп-яратып үзе сайлап алды. Ул да мангыт кызы, би баласы. Үз ыруы да бик абруйлы. Атасы Шәехәүлияргә генә язмыш кырын караган. Кырым ханы Миңлегәрәй тарафыннан куып җибәрелгәннән соң, Иван III канаты астына килеп сыенырга мәҗбүр булган. Җәлил хан вафат булгач, олуг кенәз аны 1512 елда Касыйм тәхетенә утырткан. Хәзер менә ничә еллар инде урыс патшасына хезмәт итәләр.

Фатыйма чибәрне ул Нугайда күзенең бер чите белән генә күреп калган иде. Кызның йоп-йомры итчән гәүдәсе, түгәрәк йөзе, тырпаеп чыккан мул күкрәге шундук әсир итте.

Эшне озын-озакка сузмады, бу алма битле кара кашны шул ук елны килен итеп төшерде. Аллага шөкер, ике ярты бербөтен булып, бик матур яшәп яталар.

—Тут яфрагы сабырлык белән ефәк булыр ди, ул кадәр бетерешмә әле, хан,—диде Фатыйма-Солтан.

Шәехгали томырылып хатынына бакты, нидер әйтмәкче итте, әмма тавышы чыкмады, әйтергә теләгән сүзе тамагына утырып калды. Аннан үкси-үкси елый башлады.

—Фа-туш... Фату-у-уш... бәгърем...

***

Нугайларның сәер өстенлеге турында Гәүһәршад очраклы рәвештә генә белде. Баксаң, нугай-мангыт бәкләре Казаннан ел саен йөз батман бал, кырык мең сумлык алтын тәңкә алып барганнар икән. Һәм бу Идегәй морза заманнарыннан калган кануный бурыч, имеш.

Тәнәкәне бу хәл бик тә гаҗәпләндерде. Чөнки ханнар әлеге гамәлне ни өчендер җиренә житкереп үтәгәннәр, берсе дә аны гаделсезлек дип санамаган.

Озак кына баш ватканнан соң Гәүһәршад, ниһаять, бу гап-гади калым ич дигән нәтиҗәгә килде. Хак шулай. Әүвәл ул дәүләти дәрәҗәдәге калым булып йөргән. Ник дисәң, Казан ханнарының барысы да нугай бикәләрен ярәшкән. Ә хан дәүләт башлыгы, шуңа күрә калымны да дәүләт түләргә тиеш дип тапканнар, күрәсең. Бу әнә шулай буыннан-буынга сузылган. Инде моңа чик куярга вакыт.

Гәүһәршад тиз генә баш карачыны чакырып алды.

—Әвененә ут капмагандыр бит, бикә, нигә шул кадәр кабаланасың,—диде Булат Ширин керә-керешкә.

—Мич башы карты сыман сукранма әле, башта әйбәтләп тынла,—диде Гәүһәршад.

—Җә, тынлыйм.

Гәүһәршад әлеге мәсьәлә буенча үзенең карарын җиткерде, моннан ары нугайларга сукыр тиен дә тәтемәс, диде, чарасын күрергә кушты.

Булат Ширин сүз әйтергә ашыкмады, берни булмагандай бәллүр савыттан иң эре алманы сайлап алып, ашыкмыйча гына уртлап куйды. Тәнәкә аның бу кыланышын ошатмады, әлбәттә.

—Мин җавап көтәм!—диде коры гына.

—Ханыбызның буйдак икәнен исеннән чыгарма, бикә,—диде Булат Ширин соңгы кабымлыгын йотып җибәргән арада,—Нугайга яучылар юлларга туры килмәгәе. Араны бозарга ашыкмыйк.

—Өйләнәсе килгән егет кәҗә сатып өйләнә, калымны үз кесәсеннән түләсен.

—Әҗәтне калым белән бутама,—диде бәк җитди генә.—Хәтеренә төшер әле, Мөхәммәдәмин ханга урыс явында җиңү яуларга беренчеләрдән кем булышты? Нугайлар. Алгай морза егерме мең атлы гаскәр белән килде, шул орышта башын салды. Түләүләр шул югалтуларның әҗере генә.

Гәүһәршад төртелеп калды. Ә баш карачының теле, киресенчә, тегермәндәй тарттыра бирә.

—Беләсең килсә, тәнәкә, Мәскәү дә бүләк белән юмалый нугайның бәк-морзаларын. Алтын-көмеш, асыл таш, зиннәтле кием-салым, савыт-саба, затлы тун-толып, кадак кебек әйберләр далага Мәскәүдән китә.

—Ике сыерны имәләр икән,—диде Гәүһәршад сүрәнләнеп. Аның бик тә мөһим, ифрат та зарури булып тоелган ниятенең шулай бернинди эзсез тәмамлануына кәефе киткән иде. Шул ук вакытта бу вакыйга ханлыкның эчке тормышын җентекләбрәк өйрәнүгә этәргеч тә ясады. Казна хәлләре аны янә гаҗәпкә калдырды. Санап-чутлап карасаң, унөч төрле җыем гына бар икән: ясак, калан, хәреҗ, җир салымы, төтен салымы, кунак салымы, көләш, бәч... Шулар арасында әлеге дә баягы, йөз батман бал шикелләләре дә җитәрлек. Әйтик, калан салымының казнага бер файдасы да юк. Чөнки ул хан, аның җәмәгатьләре, аерым әмирләр мәнфәгате өчен генә җыела. Хан болай да казна исәбенә яши, ни хаҗәтемә бу өстәмә җыем? Ярый, хуш, монысына күз йомарга да була әле. Ханның чыгымнары күп, аны үз башыңа төшкәч кенә беләсең. Әмма салымнарның исәбе кул бармаклары саныннан артып китсә дә, керем нигәдер елдан-ел кими, казна саекканнан-саега бара икән. Җыем арта, керем кими.

—Сәбәп нәрсәдә, бахшы, аңлатып бир,—дип, Гәүһәршад баш салымчыга текәлеп бакты.

Бахшы күпне күргән, мунча ташыдай шомарган карт төлке иде. Эчтән умач уып, тыштан җәймә җәяргә дә бик маһир. Тик тәнәкәнең боз кебек салкын карашын күтәрә алмады, коелды да төште. Бу хәлдә хәйлә дә, татлы ялган да ярдәм итмәячәк. Дөресен сөйләү исә күрәләтә башыңны балта астына кую дигән сүз. Ә башны югалтасы килми. Шуңа күрә өзелмәгән җирдә тешләп булса да бу бәлале хәлдән котылу чарасын табарга кирәк.

—Мин тыңлыйм, бахшы,—диде Гәүһәршад.

Баш салымчы тәнәкәгә күз атып алды. Шул ук мәрхәмәтсез кырыс йөз, рәхим-шәфкать көтмәле түгел. Ышаныч фәкать үзендә генә.

Бахшы мизгел эчендә мескен кыяфәткә керде, хәтта күзләре дә яшьләнде.

—Әйтсәм әйтим инде, галиҗәнап тәнәкә,—диде җиң очы белән яшьләрен сөрткәли-сөрткәли,—казна тирәсендә Сафагәрәй ханның кәкре кулы уйнады... мин... мин... ни... каршы килә алмадым. Гаебем зур... мин аны акларммын... сүз бирәм...

Салымчы, ярлыкау өмет итеп, биленә кадәр башын иде. Өмете генә акланмады. Дөрес, Гәүһәршадның күнелендә кызгану хисе кузгалып алды. Ләкин эчке тавышы: «Ышанма бу адәмгә, күр, күзләре ничек уйнаклый»,—дип кисәтте.

—Бахшы, сине Идел буенда өч зур авыл сатып алган диләр, бу хакмы?—дип дәлил капчыгын чиште тәнәкә.

Каныкты тәки, ирдәүкә, дип эченнән генә сызланды тегесе. Таныргамыюкмы? Аны шул сорау борчый иде. Башорган башны кылыч чапмас ди, бәлкем, аягына егылып кичерүен үтенергәдер? Бүләкләр дә такъдим итә алыр иде. Әгәр уртак тел табып булмаса, ул чакта ни кötә? Бу бит кызхатын! Ерткыч хайван бер килер игә, яман хатынны күндерермен димә. Хатын-кызның акылы җил өргәнче җиде төрлегә әйләнә ди бит. Хатын-кыз да булдымы илбашы? Бәлагә инде бу, бәлагә. Әллә ятып калганчы атып калыргамы?

Салымчы мангаен идәнгә бәрә-бәрә акланырга тотынды:

—Җәнабе тәнәкә, зинһарлап сорыйм, кичер, хәраплар итмә, барысы да Иблис мәлгун котырыгы... буш итмәм...

—И, акүл, бирән!

—Җәнабе, тәнәкә...

—Алып китегез бу хәшәрәтне, базга ташлагыз!

***

Иртәнге намаз тәгәлләнеп, Идел артыннан кояш күренүгә, киереп ачылган хан сарае капкасыннан бер төркем мөнади-хәбәрмәннәр атылып чыкты. Су сипкәндәй шундук таралып та беттеләр. Тын һавада тавышлары гына эленеп калды.

—Һәр барчагызны җәза тамашасына чакырабыз!

—Колакларыгызны торгызыгыз, соныннан ишетмәдем димәгез: баш салымчы җавап тота.

—Угрыга гадел хөкем!

Күп тә үтми, каланың иң зур һәм иң кешеле Ярминкә мәйданы халык белән тулды, алма төшәр урын калмады. Шулай булмыйча, казый каршысына олы түрә басачак! Мөхәммәдәмин хан вакытында баш карачы Кәлимәтне шулай бөтен халык алдында җәзага тартканнар иде: башын кисеп, гәүдәсен ат койрыгына тагып, урам буйлатып йөргәннәр иде. Шуннан соң үз даирәсе адәмнәрен халык алдына чыгарганнары юк иде әле. Димәк ки, гаебе зур.

Кара халык шулай уйлый иде. Билгеле, кызык өчен килүчеләр дә шактый.

Читтәрәк, зур келәм өстендә, тын гына хөкүмәт әгъзалары, карачылар, бәкләр, морзалар басып тора. Болар, әлбәттә, үз ирекләре белән килмәгән, мәҗбүр иткәнгә генә кузгалганнар. Йөзләре төмсә, кашлары җыерулы. Чакма чаксаң бүрекләре дөрләп янып китәчәк. Чокынырга тотынсаңмы, һо-о, Аллам сакласын, баш салымчы телен йозактан гына ычкындыра күрмәсен.

Карагирын чаптырып Чура морза да килеп житте. Кәефе шәп күренә.

—Нигә болай пошаманга төштегез, аксакаллар?—дип оран салды. Аннан шаркылдап көлде дә, ярымжитди рәвештә дәвам итте.—Беләм, безгә дә чират житмәсә ярар иде дип кайгырышасыз инде сез. Дөресе дә шулай. Берәмберәм чүпләячәкбез, бигрәк тә Кырым әнчекләренә койрык болгаучыларның тез асларын чеметәчәкбез. Ха-ха-ха!

Болай да шыр жибәргән түрәләрнең йөрәгенә ук кадалды. Чура сибә генә:

—Акчаның башы гына аһ анын, сөекләләрем, соңы күп очракта чаһ[16] белән бетә,—дип авызын ерды.—Салымчы бик мөһим нәрсәне хәтереннән чыгарган—бер җирдә өстәлсә, икенче җирдә кими бит ул, менә хикмәт нәрсәдә. Шулай дигәннән, мәгълүм мәзәк искә төште. Бер тегүче авыл карчыгына кием тегәргә кергән. Кием кискәндә күргән-белгәннәреннән җыен юк-барны сөйләп кортканы мавыктыра да, киемлекне кисеп-кисеп алып, сәке ярыгыннан аска төшерә икән. «Тагын сөйлә дә, тагын сөйлә»,—дип үтенгәч, тегүче кискән киемлеккә карап, исәпләп торган да:

—Тагын берне сөйләсәм, бишмәтең бик кыскарыр шул, әби,—дип әйтеп куйган, имеш. Ха-ха-ха!

Чура морза көлеп туйганнан соң, бала башыдай олы йодрыгын төйнәп:

—Кем дә кем казнага кул суза икән, алдан ук дөнья белән саубуллашсын,—дип кычкырды.

Казый да эшкә тотынды. Дога кылып, Коръән өстендә гадел хөкем хакына ант эчкәннән соң, баш салымчыга сөален җиткерде:

—Үз гаепләреңне таныйсыңмы, бахшы?!—дип сорады.

Салымчы тезләренә ауды. Бик нык үзгәргән иде ул. Чырае көл төсенә кергән, тыгыз калын ияге сыер карынындай шәлперәеп төшкән, хәтта тышау җитмәс муены да юкарып киткәндәй күренә.

—Тәкъсыйр, үзенә мәгълүм, мин озак еллар буе тәхет иясе ханнарга ихлас күңелдән хезмәт итеп килдем. Мин угры түгел, зинһар, кулсыз калдырма, мине берәү дә тотмады... тәкъсыйр...

—Казый, капла шул нәмәхрәмнең авызын,—дип кылычын суырып чыгарды Чура.

—Сабыр, морза, хөкемне мин чыгарам,—диде казый вәкарьле кыяфәттә,—хөкемне хан үзе дә юкка чыгара алмый.

Күзе аларган морза бу сүзләрне әллә ишетте, әллә юк, йөгереп килде дә кылычын баш салымчының юан муенына батырды.

—Нәфесенә ияргән ахмактыр, җәһәннәм утын тапмактыр.

Түрәләр җиңел сулап куйды.

***

Җангали тәхеткә өч яшендә утырды. Ул аны хәтерләми дә инде. Хәер, белмәгәннең нәрсәсен хәтерлисең ди, сабыйлыктан чыккан чагы гына булган ич. Җәмгысы унөч ел Касыйм ханы вазифасын үтәде. Узган ел Казан ханы бүреген кигезделәр.

Иң гаҗәбе шул, шушы ундүрт ел эчендә бер мәртәбә дә мөстәкыйль карар кабул иткәне булмады. Касыймда агасы Шаехгали баш иде, монда хакимиятне Гәүһәршад тәнәкә үз кулында тота. Эт этлеген итмәсә, эче күгәрер ди. Тәнәкә дә шулай, һаман өреп кенә тора. Бөтен сарайның күзе аңарда: «Мөхтәрәм тәнәкә», «Җәнабе гали»... Төптәнрәк уйлап карасаң, бер ханлыкта ике галиҗәнап булмый ич инде. Чын галиҗәнап монда ул, Җангали!

Пакизә дә борынын җыерган була, юаш син, янәсе, йомшак, ә йомшак агачны корт баса...

—Юан юанайса, ишеккә сыймый, авызыңны үлчәп ач,—диде Җангали.

Туташ иртәнге чыктай саф, чиста тавышы белән, башын артка чөеп, челтер-челтер көлеп җибәрде.

Җангали мәгъшукасын кочагына кысты. Ошата иде ул Пакизәнең кыланчыкланып көлүен. Көлүе белән хан йөрәген эретте дә инде туташ.

[16] Чаһ – баз

Моңа кадәр асыл затларга битараф мөнәсәбәттә иде Җангали. Алай гынамы, җае килсә дә, килмәсә дә, кыз-кыркынны кимсетергә генә тора иде: чеметә, чәчләреннән тарта. Чөнки ул аларны булдыксызга, аңгырага саный иде. Кыз-хатынга эт тә өрми ич аңа. Билгеле, ана тәрбиясе күрмәү дә йогынты ясамый калмагандыр. Яшьли казый кулына бирделәр. «Ите синә, сөяге безгә»,—диде атасы. Усал, мәрхәмәтсез, кыя ташыдай каты күңелле кеше иде казый. Күп чыжлатты ул шаһзадәнең аркасына сыек чыбыкны. Үскәч, күкрәгенә хәнҗәр кадыйм мин моның дип күнеленә беркетеп куйганы да хәтерендә. Тик өлгерә алмады, казый ул буй житкергәләгәнче гүр иясе булды.

Җангали беркөнне ниндидер аңлаешсыз ләззәтле хисләнү белән уянып китте. Хәер, әлеге халәтне бөтенләй аңлаешсыз дип тә әйтеп булмый иде. Чөнки соңгы вакытта йөгерек тулпар өстендә җилдәй җилдергәндә дә шуңа охшаш татлы ләззәт кичерештерә башлады...

Җангали сеңерләре таш булып катканчы берничә тапкыр киерелеп-сузылып алды да, тәрәзәгә күз салды. Урамда күзләрне камаштырып кояш балкый иде, җиһан гөлт итеп тора: якты, киң, матур. Яз галәмәте. Әнә, өй кыекларыннан тамчылар йөгерешә. Юлларда инде күгәрчен тәпиен күмәрлек күлдәвекләр хасыйл булган.

Күр, чыпчыклар ничек чыркылдаша: куанышалар, шатланышалар, яратышалар...

Бу тамашадан егетебезнең тамагына татлы төер килеп сыланды, үзеннән-үзе тәнендәге барча күзәнәкләре тулышты... Кеше-фәлән юкмы дип, җәт-җәт як-ягына да каранып алды. Шөкер, бүлмәдә үзе генә икән. Аны йоклый дип уйлыйлар иде, күрәсең. Түшәкче дә, киемче дә керергә базмый, ашчыга әле иртәрәк.

Әнә шулай, сиздермичә, капылт кына Җангалинең тәрәзәсенә бәлигълык җиле килеп кагылды. Моңарчы оят тоелган гамәлләр оят түгел иде инде.

Киенеп-ясанып ат утарына барышлый колагына кемнеңдер яңгыравыклы көлгән тавышы ишетелде. Ул аны тәүге тапкыр гына ишетми. Ләкин әлегәчә игътибарын җәлеп итми иде. Көләме—көлә, нәрсәсе бар инде аның? Кызлар койма ярыгыннан да көлә ди бит.

Бу юлы көлү тавышы ниндидер күңелле, җинел җыр сыман яңгырады, йөрәген ашкындырып узды. Бүгенге яз кояшы кебек якты, җылы, пакь вә нурлы тавышның иясе кем икән?

Җангали бүлмә ишеген ачып эчкә узды. Анда бер хадимә туташ йомгактай кечкенә генә мәче баласын уйната иде. Пескәйнең койрыгына кызыл тукыма кисәге бәйләгән. Тегесе шуны авызы белән эләктереп алмакчы итә. Әле бер якка бөтерелә, әле икенче якка. Авып-тәгәрәп тә алгалый.

Кыз дөньясын онытткан, көлепме-көлә. Мавыгуы шул кадәр көчле иде ки, хәтта ишек ачылганын да, янына Җангалинең килеп басканын да сизмәде.

Җангали малайлык гадәте белән кызны чеметеп алмакчы итсә дә, кулы йомшак кына чибәркәйнең билен капшап узды. Тегесе кыр кәҗәсе җитезлеге белән читкә ыргылды.

—Оятсыз, нишләвең бу?

Күрәсең, тирәсендә чуалучылар җитәрлек иде. Әмма артына борылып карагач, каушавыннан чөгендер төягәндәй кызарып чыкты.

—Хан!—диде ул артына чигенә-чигенә,—мин... мин... күрмәдем...

Җангалинең кызыксынуы арта гына барды.

—Нәмә, күлмәгең эченә кош керттеңме әллә,—дип бармагы белән, кызның күкрәгенә төртеп күрсәтте.

Ул арада аягына песи баласы килеп сарылды: мияу-мияу...

—Перс,—дип кычкырды кыз озын куллы егеттән арынырга җай чыгуына

куанып,—аннан тиз генә пескәйне кулына алып, күкрәгенә кысты.

—Син ни атлы?—дип сорады Җангали.

—Пакизә...

—Ә мин Җангали...

—Беләм,—диде кыз керфекләрен сирпеп,—бөтен кеше белә...

Җангали белән алар яшьтәшләр иде. Әмма табигать шулай көйләнгән ки, кызлар ир-егетләргә караганда иртәрәк өлгерә. Шул сәбәпле, Пакизә дә инде житкән кыз рәвешенә кергән иде. Шуңа күрә ул яшь егетнең үзенә күзе төшүен, күнеленең вәсвәсәләнүен бик тиз сизеп-тоеп алды.

—Син ничек шулай матур итеп көләргә өйрәндең?—дип сорады Җангали.

—Белмим...—диде Пакизә күз очлары белән генә көлемсерәп,—ул хакта уйлаганым юк...

—Мин синең янга тагын керәм әле,—диде Җангали.

***

Пакизә үзе дә наз-сөешүләр өченгә ясап куйган кебек иде. Тик бүген егетенең кочагында элеккечә эреп китмәде. Җангалинең сизгер йөрәге моны бик тиз тоеп алды.

—Нишләвең бу?—дип авызын турсайтты.

—Нигәдер күңелем болганып тора,—диде кыз.

—Хәзер дәвалыйм мин сине,—диде Җангали...

Мәхәббәт киртәләрне белми шул ул, гашыйкларга көн дә яз, төн дә яз.

***

Булат бәктән Мәскәүгә аның никахына ризалык алу өчен илчеләр китәсен ишеткәч, Җангали коелып төште.

—Ю-ю-к, мин өйләнмим,—дип мыгырданды.

Булат бәк моның сәбәбен төпченеп тормады, «Барысы да хәл ителгән инде,—дип кенә куйды. Шулай да бераз ачыклык кертергә уйлады, ахры, әйтте:—Мин синең урынында булсам, Гәүһәршад тәнәкәнең аягына егылыр идем, ул сине тәхеткә утыртты, инде башлы-күзле итә...»

Ишек уемында якын кардәше, чүмәләдәй зур гәүдәле Касыйм кенәзе Котлыгъ-Булат күренгәч, Җангали шатлыгыннан үрле-кырлы сикерә язды.

—Әссәламегаләйкүм, Барча Казан җиренең бөек ханы,—дип сәламләде аны кенәз. Калын вә көчле тавышыннан тәрәзә пыялалары да чынлап киткәндәй булды. Киң күңелле, ачык чырайлы агасы телмәрнең телмәре, аның хакында, сүзе белән еланны да өненнән чыгара, дип сөйлиләр иде.

—Бик кирәк идең син миңа агаем, нинди җилләр ташлады монда?

Җангали кунакны кочаклап алды.

—Җил генәме, хан, өермә кубарылды, өермә! Күрмисеңмени, ыштанымның бер балагы кәвеш өстенә чыккан,—дип гөрелдәде Котлыгъ-Булат,—баш кода мин хәзер, баш кода! Иртәгә Мәскәүгә чыгып китәбез. Аллаһы боерып, Ходай кушса, олуг кенәз Василийның фатихасын да алып кайтырбыз. Гөрләтеп туй ясарбыз. Беләм-беләм, үземнең дә башымнан үтте, синең тизрәк кәләшеңнең кайнар кочагында эреп китәсең килә инде. И-х! Борчылма, энем, ул көннәр дә килеп житәр, күбенә түзгәнне, азына гына ничек тә түзәрсең...

—Агаем, миңе кемгә өйләндермәкче соң сез?—дип сорады Җангали.

Кенәзнең калын иреннәре буаз биянекедәй салынып төште, күзләре киерелеп ачылды.

—Нәмә, әйтмәделәрмени әле?

—Жу-ук...

—Ихтимал, алар хаклыдыр да,—диде кенәз бераз уйланып торганнан соң,—ашыккан ашка пешкән, сабыр иткән морадына җиткән ди. Әмма дә ләкин, энем-бәгърем, агаеңа ышана аласың, серне ачам мин сиңа. Шуны алдан ук әйтеп куям, Ходай бәхетне өеп биргән икән, атлылар атыннан төшеп, җәяүлеләр ятып карарлык сылукай куены көтә үзеңне. Белдеңме? Нугай бие Йосыф морзаның төпчек кызы. Бик сайланган, имеш. Сөенбикә атлы икән. Сөелешеп кенә яшәрсез, Аллаһы боерса...

—Утырган кызмыни?

—Утырган дип, яшьтәшең... Ансына исең китмәсен, бал черемәс, кыз картаймас ди.

—Минем сылукайга барыбер җитә алмас ул морза кызыгыз.

Котлыгъ-Булатның йөзе янә нурланып китте, авызы колагына җитәрдәй булып ерылды. Күзләренә генә түгел, каш арасындагы ике тирән сырына кадәр елмаю кунды.

—Мактыйм, энекәем, мактыйм, сөбханалла, тик ятмыйсың икән, Казан туташларының күңелләрен күрәсең икән. Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын, егет булып җебегән булса, бар булганчы юк булсын ди. Афәрин хан!

—Мин аны ташламыйм,—диде Җангали.

—Ташлама, кем сиңа ташларга куша, энем-бәгърем, җариясез ир-егет канатсыз кошка бәрабәр ул, белдеңме? Аннан болай, башлы-күзле булу бәлигълык билгесе. Ә бу—Гәүһәршад тәнәкәнең васыйлык камытын салып ташлау дигән сүз. Хак, ул читкә китмәс анысы, тик кануни яктан синең өстән берәү дә тормаячак, үзең хуҗа. Тәхет хакына, энекәем, адәмнәр өйләнү генәме, башларын сала. Ә сиңа нугай бие кызын ярәшергә тора. Бел, Казан ханлыгының дәрәҗәсе әнә шулай бик югары бәяләнә. Бәхетең тулып ашкан, олуг кенәз Василий атакайның артын яларлык.

—Монда Гәүһәршад тәнәкәгә бурычлы син дип тукыйлар...

—Олуг кенәз фатиха бирмәсә, салам да селкенми. Моны бервакытта да исеңнән чыгарма. Берүк казанлылар коткысына бирелеп, хилаф гамәл кылып ташлый күрмә, энем-бәгърем. Шәехгали туганыбыз хәленә төшәргә язмасын.

—Шәехгали хан сине тәхеттән бәреп төшереп, үзе утырмакчы иткән дип сөйләгән иде Булат бәк,—диде Җангали уйчан гына,—ышанырга да, ышанмаска да белмәдем...

—Үз авызыннан ишетмәгәч, кистереп кенә әйтеп тә булмый инде аны, энем-бәгърем, мәгәр Шәехгали олуг кенәзнең бик нык ачуын чыгарган булырга тиеш,—диде Котлыгъ-Булат пышылдауга күчеп,—урыс яугирләре Шәехгали ханның оясын туздырып бетергәннәр, бәкләрен, морзаларын, угланнарын бала-чагалары, хатыннары белән бергә кулга алып, Тверь, Псков, Новгород, Орешек, Карев өтермәләренә илтеп япканнар. Миңа сер итеп кенә сөйләделәр, Псков өтерменендә җитмеш татарны бугазлап ташлаганнар. Шулар арасында тугыз бала да булган. Бер Хәсән атлы морзага гына тимәгәннәр. Чөнки дә ул мөртәт динен саткан, православиегә күчкән. Исләр китмәле бит, җә, Ходай, дошманыңа күрсәтмәсен. Ә кыз-хатынны, бала-чаганы бераздан иреккә чыгарганнар чыгаруын, ләкин дә архиепископ Макарий кушуы буенча чыгарылган берсен көчләп чукындырганнар. Һәм дә урысларга кияүгә биргәннәр. Шәехгалинең барысы ике йөз кешесен җәзалап үтергәннәр.

—Шушы кадәр кансызлыкка тиң нинди гаебе булды икән соң?

*Ахыры киләсе санда*



Рим
Идиятуллин

# КҮҢЕЛ СЕРДӘШЛӘРЕ

## Ахирәттәге Әнкәмә ачык хат

**Әнкәм!**
**Кояш җегәрле һаман,—калка батса да,**
**Кышлар уза таш өйдә, җәйләр—бакчада;**
**И яратып тыңлыйм кәккүк тавышларын,**
**Бик күзләмим хәзер кояш баешларын.**

**Төшендем шул,—озын гомер бәхет түгел,—**
**Кемгә ләззәт эчү чүпле шешә төбен?!**
**Яши бәндә «төсле тартма» эчләрендә,**
**Чын тормышны күрәм бары тик төшләрдә.**

**Әнкәй!**
**Үрчи халык, Җирдә кысан була бара,**
**Адәмнәрнең исә ерагая ара;**
**Басты күңел басуларын кара билчән,—**
**Керсәң ут та бирмәс күршең, әгәр белсәң.**

**Ваклансам да, язып үтим әләк янә:**
**Ахырзаман!—бай кызлары йөри шәрә;**
**(Музеемны бизәр, шагыйрьлектә уңсам,**
**Сабый чактан син саклаган тишек ыштан).**

**Күктә йолдыз сирәк, җирдә «йолдыз» күбрәк,**
**Этләнә авыл—көтүгә кеше кирәк;**
**Күрсәң кайтып, аш та үтмәс тамагыңа:**
**Ана бала бакмый хәзер, таба гына.**

**Әнкәм!**
**Кемдер үчле киң дөньяның тарлыгына:**
**Яшь-яшь җаннар янып калды Кафтауларда;**
**Ә Аналар ташкын кадәр яшьләр түкте,**
**Төште каргыш: Арал диңгез уптым кипте.**

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940)—*Уфада яшәүче татар шагыйре; «Хәерле иртә», «Хәерле көн», «Хәерле кич» һ. б. китаплар авторы.*

Авыл картая, Әнкәй, зират яшәрә:
Сиңа китергән сукмак әнә шап-шәрә.
Һич кирәкмидер монда шарлатан Чумак:
Тәки дә илгә чиннәр баш булыр сымак.

Үрчеде буржуй,—акылдан алда корсак,
Туган туганны таныргга чыкты форсат;
Акча бездә бер букча, намуска кытлык,—
Тук җанда озон тишеге күк бушлык.

Әнкәй!
Хәлбуки да хак мөселман күрде бәхет:
Авыл саен манарасын чөйгән мәчет;
Дисбе тартып кемне көтә имам-хатыйп?! —
Вак мөселман эчә ятып... казын сатып.

...Шулаерак бүгеннәрдә безнең эшләр;
Эт ишәйде,—иртәгәсен кемне тешләр?!
Сугыш та юк, гел үтереш,—шунсы яман,
Үлеп китеп булса инде исән-аман.

P. S. Әнкәм!
Исән әле Гөлсем, оныта да яшен,
Хушбуй сибеп, үреп куя сирәк чәчен;
Күрше Хәбир мәхрүм калды сау аяктан,
Сәеррәк: киенеп ята гелән актан.

Гафу итче! Язалмадым базар хакын;
Кичерерләр, сүгәлмәдем түрә халкын.
«Оҗмахларга почта йөрми», дигәч хатын,
Тәмам иттем ошбу төштә әләк хатым...

## Аллаһыга ялвару

Галәм хакында уйламыйм,
Адәм хакында уйлыйм,
Шуңа теләк-үтенечем
Туп-туры Күккә юллыйм.

Җирдә үзгәреш җилләре,—
Шашты тәмам Адәмең,
Хак юлларга кайтарырга
Тапчы берәр әмәлең!

Яраткансың, рәхмәт, безне
Бар яктан камил итеп,
Тик ошбу тәкъдимнәремне
Алсаңчы кабул итеп!

Гайбәт чәйнәп тук булабыз,—
Кыскарт телнең яртысын!
Сүз белән сабан сөргәннәр
Җиргә кирәк батырсын!

Томыр бер күзне түмәргә,
Берсе дә күп безләргә;
Без болай да бик остардык
Күрмәгәнне сөйләргә.

Йә, ике колак—хатынның
Әрен тыңларга микән?
Берәү җиткән, анысы да
Саңгырау булса икән!

Ни хаҗәтемә ике кул
Өләшкәнсең кешегә!—
Җык җилкәләр икесен дә
Тыгып йөри кесәгә.

Без хайванга ике аяк!—
Бу һич сыймый башыма,
Хәзер маңка малайда да
Дүрт сыйраклы машина.

Баш дигәннән... берне генә
Бирүеңә, һай, рәхмәт!—
Башлы бәндә гел кайгыда,
Башсызлар яши рәхәт.

Ходайкаем, никләр безне
Әвәләдең балчыктан?!
Вакыт узды, балчык тузды,—
Аермасы юк инсанның
Көтүдәге сарыктан...

Син яраткан Адәм затны
Бик ярактканга күрә,
Аңга сыймас гамәлләре
Күңелемне нык кыра.

Ошбу-ошбу уйга килдем
Чиксез күп гомер итеп:
Ярат безне яңабаштан,—
Шакыр туң тумәр итеп!..

## Чынбарлыкны күзаллап

Кара болыт купты, шомлы тоем:
Таш гөрелте күкне кубарыр,
Кубарыр да ашкын ут көлтәсе,
Угын атып, миндә тукталыр...

Җирнең җиде катын дер селкетеп,
Күкне тулгак тоткан мәлләрдә,
Аяк аста, менә, кинәт кенә
Җир ярылып китсә әгәр дә,
Йә Ходаем, коткарырга кемне
Упкыннарга ыргыр идемме?!.
Тәнне суык өтте...Бит моңарчы
Кыю санап йөрдем үземне.

...Булмый калды көткән гарасат.
Әйттем:
И дивана! Сабантуйга кадәр
Батыр булып йөрү, һай, рәхәт!..

***

Байкыйм Күктән күңел сердәшләрен:
Кай йолдызым балкый яктырак?
«Син ул!» диеп,
Җилеп кенә барып әйтер идем,—
Аралар шул, ай-һай, бик ерак.

Барлыйм Җирдә күңел кардәшләрен:
Кайсысында шәфкать күбрәк?
«Син ул!» диеп,
Очып кына кереп әйтер идем,—
Аралар шул якын бигрәк...

***

Бөек Пушкин шушы боек көзне
Ник яраткан?!—изә моңсулык;
«Хуш!» диясем килә дөньясына,
Яуган яфракларга кушылып.

Әле кайчан кояш нурын эчкән
Яшел яфрак, сутлы үләнгә
Тиң идек бит, күрче, охшап калдык
Көя кискән төссез келәмгә.

Тик картлыкка нигә зар еларга!—
Сәфәр кыласым юк еракка;

Ачы җилгә һаман бирешмичә,
Тома ятим калган яфрак та,
Җиңүченең тузган байрагыдай,
Җилфердәргә тели иртәсен;
Филдәй җанда, кечтек бөҗәктә дә
Өмет яши, ни хәл итәсең!..

Табигатьнең хөкемнәре кырыс,—
Кичектерер чара табылмый;
...Иртәгәсен шәрә шул ботакта
Тантаналап карга каркылдый.

...Их,
Яратыр да идем көзне, безне
Кемнәр сөрсен рәхәт сөргенгә?!
Көнләшепләр куям, көзен үлеп,
Язын тереләчәк чебенгә...

## Авыл ихатасында

1

Хәтер хәтәр әле бабайның:
«Перцовка»ны онытмаган хәтта;
Күзен җиргә терәп карый да
Күзлек элгән оныгына төртә:
«Күрче, яшь кырмыска карт ташның
Җыерчыклар ярган йөзен сөртә...»

2

—Адәм гомере кыска дисеңме!
Мин, мисалга, олы яшьтәмен,—
Сиксән еллап тирле эштәмен,
Җитмеш кан-кардәшне җирләдем,
Бер миллиард сом салым түләдем,
Мәрфугамны кошка тиңләдем,
Чынын әйтсәм, яшәп җиләдем,
Йөртә һаман Ходай, юньсезне!..

3

—Яшәүләрен телим балаларның,
Бер-берләрен гелән туган итеп,
Шуңар күрә мирас калдырмыймын,
Зур байлыгым—тузмас хром итек,—
Сакласыннар иде төсем итеп!

4

Пәрәвезләр баскан дөм келәттән
Үпкә чирле гыж-гыж гармунын
Капшап тапты да ул кавыштырды
Үзе тезгән сүзгә үз моңын:
«Илдә күрдем күпме кешеләрне,
Чит-ятлар да кардәш кебекләр,
Әйтерсең лә алар моң үрчеткән
Моңсу гармундагы күрекләр.

**Күрдем җирдә күпме чибәрләрне,**
**Чибәрләрне сөеп кем уңган?!»**
**...Бу елый дип уйламагыз берүк!—**
**Аһ, ачы ла булды бу суган...**
**Их–ма!**

## Күрше ихатада

**Бигрәк сәер парлар иделәр:**
**Әби–бабай, көнгә чыксалар,**
**Култыклашып түгел, кулларын**
**Бер яулыкка бәйләп йөрделәр;**

**«Акыл качкан, ахры, боларның...»—**
**Сүз җилгәреп торган карчыклар**
**Артларыннан шулай өрделәр.**

**Булса булыр икән могҗиза!—**
**Икәве дә вафат бер көндә;**
**...Шәригатьчә узган җеназа;**

**«Хас куш йөрәк сыман иделәр,**
**Кабат тумас мондый гашыйклар»,—**
**Озатканда яшь тә койдылар**
**Гайбәт эрләп талган карчыклар...**

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Гөлчәчәк
Галиева

**ГАЗЗӘБАНУ**

РОМАН

«Тулгак», «Өзелгән өмет» кебек популяр әсәрләр авторының бу яңа романында тасвирланган хәлләр 1921 елгы ачлык вакытында бара. Әсәрнең үзәгендә — өзелеп яраткан иренең яшь хатынына көндәш булып яшәргә дучар ителгән, реаль тормыштан алынган татар хатынының (автор аның хәтта исемен дә үзгәртмәгән) тетрәндергеч язмышы. Тагын бүтән катлаулы язмышлар белән уралып-чорналып, ул гаҗәеп бер вакыйгалар йомгагын хасил итә.



Галимҗан
Гыйльманов

# БӘХЕТ КҮЛМӘГЕ

ӨЧ КҮРЕНЕШТӘН ТОРГАН ТАМАША

**Катнашалар:**
Я у ы ш  х а н — ил башы
В ә з и р — ханның киңәшчесе
А й б и к ә — ханның җиткән кызы
Ә б ү г а л и с и н а — мәшһүр табиб
М ө х ә м м ә т җ а н — сукачы егет
Б и ю  к о л л е к т и в ы.

## Пролог

*Пәрдә алды. Тын гына көнчыгыш көе яңгырый. Шулвакыт ян-яктан (залдан) сәхнәгә бер юлчы карт (мәшһүр галим, табиб Әбүгалисина) керә. Тирә-ягына каранып торганнан соң, ул сәхнә читендәге калкулык җиргә җиләнен җәя, таягын алдына куеп, аякларын бөкләп утыра. Дога кыла. Аннары букчасыннан «Тыйб» («Медицина») китабын чыгарып, укый башлый. Ул арада сәхнәнең икенче башында җанлылык. Егет тавышы: «Һай, малкай, әйдә! Бураз-на!.. Буразна!..» Бераздан сәхнәгә читек-чалбардан, күлмәксез генә биленә ак билбау бәйләгән егет килеп керә. Кулында камчы, инсәсендә—су салынган тире янчык. Ул шул янчыктан су алып эчә. Ләкин кинәт, нидер сизенеп, үрелеп карый-карый кемнедер күзәтә башлый. Сәхнәгә йөгереп-уйнап бер житү кыз килеп керә. Ләкин шундук, егет белән күзгә-күз очрашуга, каушап, туктап кала. Каушавыннан кулындагы чигелеп бетмәгән ак күлмәкне җиргә төшереп җибәрә. Егет аны иелеп ала, яңагына куеп, хисләнеп тора, аннары үз тәненә куеп, таманлыгын карый...*

Е г е т. Чибәр кыз, бу күлмәк миңамы?

К ы з *(яулык чите белән йөзен капларга тырышып).* Энәдән төшеп житмәгән күлмәкне кию языклыкны белмәсәң, кем...

Е г е т *(шаярулы аһәң белән).* Сөю—языкмыни, чибәр кыз?

К ы з. Без бит таныш та түгел, ә син сөю хакында сөйлисең...

Е г е т. Ә без күптән инде таныш. Син—Яуыш хан кызы, шулаймы?

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957)—*язучы һәм әдәбият галиме; «Заман сүз сорый», «Албастылар», «Тозлы яңгыр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

*(Хисләнеп.)* Айбикә...

Кыз. Мин дә сине беләм. Син шушы басуда сарай халкы өчен иген игәсең, икмәк үстерәсең...

Егет *(чаяланып).* Шулай булгач? Танышлар булып чыгабыз ласа... Димәк, килештек?

Кыз Нәрсә килештек?

Егет. Тегеп бетерүгә, күлмәк— минеке! Ә мин—синеке!.. *(Көлә.)*

Кыз *(шулай ук чаяланып, егет башлаган уенга керешеп).* Мин риза. Тик бер шарт бар.

Егет. Нинди шарт тагы?

Кыз. Син бу күлмәкне ничек тә үз тәненә кияргә тиеш. Ничек—анысы синең зирәклек. Күлмәкне өстеңдә күргән көнне үк мин—синеке. Ризамы? Ә хәзергә кире бир! *(Егеткә сынап карый.)* Кара аны, сүзеңдә тор! Юкса... Күлмәк тә, хан кызы да тәтемәс...*(Рәхәтләнеп көлә дә күлмәкне егет кулыннан тартып алып, чыгып йөгерә.)*

*Береаздан һушын җыеп өлгергән Егет тә Кыз артыннан ашыгып чыгып китә. Иң ахырдан боларның барысын да күзәтеп утырган юлчы карт кузгала. Ул, башын чайкый-чайкый чыгып барганда, кинәт тукталып, залга мөрәҗәгать итә.*

Карт *(залга эндәшеп).* Бәхеткә дәлил кирәк түгел шул, бәхеткә язмыш кирәк... *(Чыгып китә.)*

## Беренче күренеш

*Хан сарае. Диварлар сөңгеләр, калканнар белән бизәлгән. Бер якта зур, биек тәрәзә. Урталыкта затлы тәхет тора. Ул буш. Бер читтәрәк—атлас-бәрхетләр җәелгән түшәк. Анда башын сөлге белән бәйләгән Яуыш хан ята.*

*Салмак Көнчыгыш көе яңгырап тора..*

Хан *(яткан түшәгендә әйләнгәләп, ыңгыраша-ыңгыраша).* Ай! Ай-ай-ай!.. Әй... Әй дим... Кем бар анда? Кая китеп олактыгыз барыгыз да? Ай-ай-ай? Ханнары үлеп ята, кереп хәлен белүче дә юк... Кая бара бу дөнья, ә? Ай-ай-ай!..

*Пауза. Көй дәвам итә.*

Хан *(ыңгырашып).* Ыһ!.. Ай-ай-ай! Уф-уф-уф!.. Әй!.. Кем анда? Керегез тизрәк!.. Ярдәм итегез!.. Үләм бит, үләм!..

*Йөгереп Айбикә килеп керә.*

Айбикә *(куркынып).* Әтием, ханым! Ни булды сиңа, нәрсә булды? *(Әтисе янына барып, кочып ала.)* Һаман авырыйсыңмы, әтием? Ничек кенә ярдәм итим соң, бер дәва да килешми бит үзеңә... Аптырап беттек инде. Әтием, бүген кай җирең авырта инде?

Хан. Бар җирем дә авырта, кызым, менә аяк очларыннан башлап чәч бөртегенә кадәр авырта... Ай, авырта!.. Ай-ай-ай!.. Бөтен тәнем сызлый, хәтта җаным сызлый... Ай-ай-ай...

Айбикә. Әтием, тагын мәтрүшкә чәе эчеп карыйсыңмы әллә?

Хан. Юк-юк, юк-юк!.. Якын да китермә! Ай-ай-ай,сызлый!..

Айбикә. Әтием, бөтнек суы кайнатып биримме әллә?

Хан. Юк-юк, юк-юк... Күземә дә күрсәтмә! Ай! Ай-ай-ай, сызлый! *(Башын тотып, түшәк-мендәр өстендә бәргәләнә.)*

Айбикә *(гаҗизләнеп).* Әтием... Былбыл кош йомыркасы кабып карыйсыңмы әллә? Дәвасы бар диләр бит...

Хан. Юк-юк, юк-юк...

Айбикә. Алма кагы?

Хан. Юк-юк, юк-юк...

Айбикә. Умарта балы?

Хан. Юк-юк, юк-юк...

Айбикә. Кәккүк төкерege?

Хан. Юк-юк... Юк дигәч, юк! Ай-ай, авырта... Ай, сызлый!.. Бар, Вәзирне чакырып китер, ул берәр чарасын йә берәр дәвасын тапмады микән?

Айбикә. Хәзер, әтием... Тик син болай нык бетеренмә инде, яме... Хәзергә сау бул, әтием, ханым... *(Әтисен тагын бераз кочып торганнан соң, хан түшәге каршында башын иеп артка чигә, аннары йөгереп чыгып китә.)*

Хан. Ай-ай-ай!.. Уф-уф-уф!..

*Ашыгып Вәзир килеп керә.*

Вәзир *(хан каршында башын иеп).* Сез мине чакырдыгызмы, ханым? Кәе-

фегез ничек, ханым?

Хан *(вәзиренә мендәр ыргыта).* Әй гөнаһы шомлыгы! Сорап торган була бит әле... Ничек булсын, менә бит—үләм, үләм!..

Вәзир. Кай җирегез авырта, ханым?

Хан. Бөтен җирем дә авырта, бөтен җирем дә сызлый!.. Ай-ай-ай!.. *(Түшәгендә бәргәләнеп изалана.)* Мин шундый бәхетсез!..

Вәзир *(нишләргә дә белмичә).* Ханым-солтаным, Сезне зарларыгыздан бүлдерергә рөхсәт итегезче! *(Башын иеп тора.)*

Хан *(усалланып).* Тагын нәрсә? Мине бу чиремнән коткарырдай берәр чара беләсеңме әллә?

Вәзир. Бар андый чара.

Хан *(җанланып).* Бар? Нинди чара ул? Нигә аны башта ук әйтмисең? Йә, үртәмә җанымны, әйт!..

Вәзир. Мин бүген сарайга патшалыкның иң оста кылычдарларын чакырдым... Алар Сезгә тамаша күрсәтәчәк... Бу тамашадан соң бөтен борчуларыгыз да онытылачак, ханым...

Хан *(тагын да җанлана төшеп).* Йәйә!.. Тизрәк чакыр!.. Ник торасың инде, бар! *(Тагын мендәр ыргыта.)*

*Вәзир кулындагы таягы белән идәнгә бәрә. Таяк башындагы кыңгырау чыңлап китә. Көнчыгыш көе уйнала башлый. Кылыч тоткан егетләр бию башкаралар. Бу вакытта Вәзир тәхет янында басып тора.*

*Хан, бию башлануга, дәртләнеп, бөтен авыруларын онытып, түшәгендә торып утыра. Биюче егетләргә кушылып, кулларын өскә болгый-болгый, бию тактына хәрәкәтләнә. Ләкин бераздан тагын кәефе китә, бию тәмамланганда ул башын мендәрләр астына куеп ята.*

Хан *(инрәп-ыңгырашып).* Ой-ойой!.. Әй-әй-әй!..

Вәзир *(йөгереп хан янына килә).* Ханым-солтаным! Тагын ни булды? Тагын кәефегез киттеме? *(Биюләрен тәмамлап, сәхнә уртасында баш иеп басып торучы кылычдарларга ишарәләп, чыгып китәргә боера.)*

*Кылычдарлар ансамбле хан каршында баш ия-ия чыгып китә.*

Хан. Әй-әй-әй!.. Нинди бәхетсез мин?!. Мин нинди бәхетсез?!.

Вәзир. Ханым! Тынычланыгыз инде, бу кадәр бетеренмәгез... Мин Сезгә тагын бер тамаша әзерләдем. Ул Сезнең күңелегезгә хуш киләчәк. Бу юлы Сез үзегезне бәхетле итеп тоячаксыз...

Хан *(мендәр ыргыта).* Юк! Миңа бернәрсә дә, беркем дә кирәкми!.. Минем яшисем килми, мин шундый бәхетсез!..

Вәзир. Ханым! Соңгы мәртәбә үтенеп-ялварып сорыйм: зинһар, тыңлагыз мине—сылу кызлар биюен карагыз... Бу биюне карасагыз, Сезнең йөрәгегезгә—дәрт, тәнегезгә—дәрман, күзегезгә—нур, күңелегезгә җыр тулачак...

*Хан, ярар алайса, син дигәнчә булсын, дигән кебек, кул белән ишарәләп, ризалык бирә. Вәзир тылсымлы таягын идәнгә ора, кыңгырау чыңлап китүгә, көй башлана, сәхнәгә Көнчыгыш киемнәренә киенгән кызлар бию ансамбле чыга. Бию вакытында Хан тагын җанланып китә. Яныннан үтеп киткәндә кызларны тотып—чеметеп алмакчы була. Утырган түшәгендә сикергәләп ала. Тамаша ахырында ханның кәефе китә, ул тагын борчыла, тынгысызлана башлый. Вәзир, ишарәләп, кызларга чыгып китәргә куша, үзе хан ятагы алдына килеп тезләнә һәм, башын иеп, тынып кала.*

Хан *(бераз түшәгендә аунаганнан соң).* Әй, син кайда? Вәзир!

Вәзир *(сикереп тора).* Ханым! Мин монда!..

Хан. Син миңа хәзер үк Әбүгалисинаны табып китер! Аның табиблык даны еракларга киткән. Минем бәхетсезлегемә берәр чара тапсын! Ишетәсеңме, Вәзир?

Вәзир. Баш өсте, ханым! Ул... Ул монда инде. Әбүгалисинаны әйтәм...

Хан. Нишләп керми соң ул, алайса?

Вәзир. Ул... Ул, ханым, бу авырудан дәва юк, ди... Дәвалый алмыйм, ди...

Хан *(усалланып).* Ә? Син нәрсә? Минем үлемемне телисеңме әле? Мине үтермәкче буласыңмы? Хәзер үк Әбүгалисинаны чакыр! Үзем сөйләшәм!..

Вәзир. Баш өсте, ханым... *(Чыгып китә.)*

Хан *(үзалдына).* У-у-у!.. Дәва юк, дигәнме?!. *(Сәхнә буйлап йөренә, тәрәзәгә барып карана.)* Дәваламый кая барасың... Дәваларсың... Башыннан колак кагасың килмәсә... *(Йөргән чакта йә башын, йә эчен, йә күкрәген тотып, ухылдап ала.)* Ой-ой!.. Ай-ай!.. Уй-уй!..

*Ул арада ишек катында Вәзир күренә, аның артында Әбүгалисина пәйда була. Мәшһүр табибның кулында «Тыйб» («Медицина») китабының махсус зурайтып эшләнгән макеты. Түшендә— үпкәне, йөрәкне тыңлый торган көпшә... Хан, Вәзир белән Әбүгалисинаны күргә, йөгереп барып, түшәгенә ята, тагын да ныграк ыңгыраша башлый.*

Вәзир *(баш иеп).* Ханым!.. Без килдек.

Хан *(түшәктән башын калкытып).* Кем ул—без?

Вәзир. Без—Әбүгалисина хәзрәтләре... *(Табиб ягына ишарәли.)*

Хан *(Әбүгалисинага).* Синме инде ул мәшһүр табиб?

Әбүгалисина *(бераз вакыт башын иеп, уң кулын күкрәк өстенә куеп торгач).* «Мәшһүре» кемдер—белмим. Табибы мин булам... «Әбүгалисина хәзрәтләре» дип йөртәләр мине, олуг хан...

Хан. Әһә! Нәкъ син кирәк тә инде миңа!

Әбүгалисина. Баш өсте, ханым...

Хан. Синең хакта, барлык авырулардан да шифа белә, дип сөйлиләр. Дөресме бу?

Әбүгалисина. Нинди авыру, нинди бәндә бит...

Хан. Менә мине дәвалый аласыңмы? *(Аягын салындырып, торып утыра).* Менә мине—ханнынны?!

Әбүгалисина. Хан булсаң да, син дә Адәм галәйһиассәлам әһеле, ягъни мәсәлән, инсандыр, кешедер бит? Әллә?.. Кеше түгелме?

Хан. Кеше!

Вәзир *(Ханны җөпләп).* Кеше, кеше!

Әбүгалисина. Шулай булгач... Нишләп дәваламаска, дәвалыйбыз! Йәле, кай җирең авырта? *(Йөрәк тибешен, үпкә сулышын тыңлый торган көпшәне тотып, хан каршына ук килә.)* Әһә... Әһә... *(Үзе тыңлый, үзе сөйләнә.)* Күзләреңне ач, авызыңны ач, теләнне күрсәт... Күлмәгеңне күтәр... *(Үзе бертуктаусыз сораша. Ара-тирә китабын кулына алып, актарына, күңелендә туган шикләргә җавап эзли.)* Бу җирең авыртамы? Ә бу җирең? Бу төшең?

Хан. Юк, юк, юк... Һи-һи-һи... Кытык килә...

Әбүгалисина *(Тыңлап, тикшереп чыккач, уйланып тора, шулай уйлана-уйлана шактый йөренә).* Шула-ай... *(Залдагы халыкка карап, Хан ягына ишарәли, иреннәрен җыерып, кулбашын сикертеп ала. «Берни дә аңламыйм», янәсе...)*

Хан *(үтә дә борчылып).* Әйт, табиб, өмет бармы?

Вәзир. Бармы?

Әбүгалисина. Бар, нишләп булмасын... Әмма...

Хан *(куркынып).* Нәрсә—«әмма»?

Вәзир. Нәрсә?

Әбүгалисина. Бер нәрсә дә юк та... Тик...

Хан. Нәрсә—«тик»?

Вәзир. Нәрсә?

Әбүгалисина. Нәрсә дип... *(Ханга карап.)* Тәнең сау-сәламәт синең. Тик җаның бик борчылган. Җаныңнан тынгылык киткән. Бәхет ташлап киткән сине, ханым... Күңел борчуларыңа сәбәп шул... Шуңа күрә дә мин сине дәвалый алмыйм. Сиңа бүтән дәва кирәк... Сиңа бәхет кирәк... *(Бераз арткарак чигеп, Хан каршында башын иеп басып тора.)*

Хан. Бәхет? Нинди бәхет ул тагын? Алтыннан да, асыл ташлардан да кыйммәт әйберме? *(Уйланып.)* Ә ул «бәхет» дигәннәре күпме тора соң? Йә әйт бәясен, табиб!..

Әбүгалисина. Нинди дип... Иң гади кеше бәхете... Адәми затларда гына була торган, кеше-инсанның тәненә сихәт, җанына тынычлык бирә торган әйбер ул—бәхет... Бәхетле кеше бөтен нәрсәдән дә өстен—җир байлыкларыннан да, борчу-хәсрәттән дә, хәтта байлыктан, алтын-көмештән дә!..

Хан. Ханлыктан, патшалыктан да өстенме?

Әбүгалисина. Әйе, ханлыктан да, патшалыктан да өстен...

Хан *(түземсезләнеп).* Кайда соң ул бәхет дигәннәре? Аны каян табып була?

Каян сатып алып була? Әйт тизрәк, Хода бәндәсе!

Әбүгалисина. Белмим, ханым...

Хан. Нәрсә-ә-ә? Белмисең?

Әбүгалисина. Белмим... Шуны гына әйтә алам: бәхетле булу өчен кеше бәхет күлмәге киярга тиеш.

Хан. Бәхет күлмәге?

Вәзир *(тәмам аптырап)*. Бәхет?.. Күлмәге?..

Әбүгалисина. Әйе, Адәм галәйһиәссәлам заманындагы борынгы китапларда язылган: «Инсани зат, тәненә дә, җанына да изге-илаһи тынычлык, бәлзәми шифа һәм имани шәфкать аласы килсә, бәхет күлмәге кисен»,—диелгән...

Хан *(залга карап, хәйләкәр елмая)*. Әһә, менә хәзер аңлашылды... *(Әбүгалисинага.)* Ә син, табиб, бар, үз юлыңда бул. *(Кинәт.)* Тукта! Ишетсен колагың—«Бәхет күлмәге» хакында беркемгә дә авыз ачасы булма. Бу хакта әйткәнеңне ишетеп кенә калыйм—шундук башыңны юк итәм, аңладыңмы?

Вәзир *(Ханга куштанланып)*. Аңладыңмы?

Әбүгалисина. Аңладым... *(Үзалдына ирония белән.)* Аңламаган кая ул... Аңладым, ханым... Солтаным... Баш өсте...

*Әбүгалисина, арты белән барып, баш ия-ия чыгып китә. Аның артыннан Вәзир дә чыга. Сәхнә артында тавышлар: «Мәшһүр Әбүгалисина килгән!» «Барлык сырхауларны дәвалый, ди...» «Гарипләрне аякка бастыра, күзсезне —күзле, аяксызны аяклы итә, ди...» «Ашыгыгыз, кояш баеганчы дәва алып калыгыз...» «Әбүгалисинага дан, дан, дан!...»*

Хан *(уйчан кыяфәттә тәхетенә барып утыра)*. Нәрсә ди? Күлмәк диме? *(Уйлана.)* Бәхет күлмәге... *(Масаеп.)* Аннан гына торса, табарга була... *(Торып йөренә. Тагын тәхетенә утыра, тагын йөренә...)* Алтын-көмешкә бөтен нәрсәне алырга була... Нәрсә ул күлмәк?!. Чүпрәк кисәге!.. Чүпрәк тә булдымы мал?! *(Тәкәбберләнеп.)* Теләсәм, көмештән тукылганын, алтыннан тегелгәнен китерәчәкләр, билләһи газыйм!.. Яшибез әле рәхәттә типтереп!.. Бәхетле булып... И-и-и-их!.. *(Җырлый.)*

Бу дөньяда һәр кешенең
Үз исеме, аты бар.
Үз тормышы, үз язмышы,
Үз бәясе, хакы бар...
Һәр нәрсәнең үз базары,
Үз колы, үз иясе!
Һәрбер җанның үз бизмәне,
Бәхетнең—үз бәясе!..

Гомерләр белән түләнә
Инсаннарның бәхете.
Бер нәрсәгә дә сатылмый
Тик ханнарның тәхете...

Алтын миндә—капчык-капчык,
Көмеш—чүлмәге белән.
Рәхәт яшисе бар әле
Бәхет күлмәге белән!

*Хан җыр җырлап, биеп йөргәндә аңа биючеләр ансамбле кушыла. Гомуми биюгә, сәхнә артыннан чыгып, Хан кызы Айбикә белән Вәзир дә катнашып китә. Бию башкарылган мәлдә сәхнә ябыла.*

*Пәрдә.*

## Икенче күренеш

*Беренче күренештәге сәхнә. Аерма шунда гына—диварларның һәр җирендә күлмәкләр, күлмәкләр... Алар арасында төрлеләр бар—алтынсу, көмешсу төстәгеләр, энҗе-мәрҗәннәр белән бизәлгәннәр, чигелгәннәр, атластан, бәрхеттән тегелгәннәр, чигүле якалылар, билбаулылар, чачаклы-чуклылар... Сәхнә ачылганда арган-талган, кәефе киткән Хан үз тәхетендә йокымсырап утыра. Тәхетнең ике ягында ике гүзәл кыз (ансамбль кызлары). Вәзир чыгып кычкырганда Хан дертләп китә һәм сискәнеп торып утыра.*

Вәзир *(кулындагы бөкләүле кәгазьдән укып игълан итә)*. Мең дә беренче күлмәк. Яшел бәрхеткә алтын белән чигелгән! Дингез аръягыннан китерелгән. Тукымасына үләннәр шифасы сеңгән, алтынына кояш нурлары иңгән. *(Кулындагы таягын идәнгә ора, кыңгырау чыңлый.)*

*Ике гүзәл зат (шулай ук ансамбль*

*кызлары) икесе ике яктан яшькелт-алтынсу күлмәкне тотып сәхнә әйләнәләр—жинелчә генә биилэр. Сәхнәне берничә тапкыр әйләнгәч, күлмәкне тәхет янында басып торган Вәзир кулына тапшыралар. Вәзир аны тәхетнең ике ягында торган гүзәл кызлар кулына бирә, үзе кулындагы таягын идәнгә ора. Таяк башындагы кыңгырау чыңлап китүгә фонограммада көй уйнала башлый. Шул көй астында кызлар күлмәкне Ханга кидерәләр...*

Хан *(киеп бетергәнче ук, ах-ух килеп).* Ай-ай-ай!.. Монысы бөтен тәнемне кыса... Жанымны, йөрәгемне кыса... Сулышымны буа... Ай-ай-ай!.. Кире алыгыз!.. Салдырыгыз!..

*Кызлар күлмәкне кире салдыралар. Ул арада Вәзир тагын кәгазеннән игълан укый.*

Вәзир. Мең дә икенче күлмәк! Шәмәхә күккә көмеш йөгертелгән тылсымлы күлмәк! Аны Тулган Ай нурлары белән бизәп, гүзәл Зөһрә кыз тоткән!.. Рәхим итеп ал, ханым-солтаным!..

*Ике кыз, игълан ителгән күлмәкне алып чыгып, салмак бию башкаралар. Аннары Вәзир кулына тапшыралар. Вәзир күлмәкне тәхет янындагы кызларга бирә дә таягын идәнгә ора. Кызлар моңлы көй астында Ханга күлмәк кидерәләр.*

Хан *(баштарак канәгать булса да, соңрак кәефсезләнә).* Вәзир... Тагын бирәр күлмәк юкмы анда? Ә?

Вәзир. Ханым, бу күлмәк тә ошамыймыни?

Хан. Ошый... Матур... Ипле... Тик... нигәдер күңелемә сагыш керә, моң керә, шом керә... Бәхет бөтенләй башка нәрсә бит ул, Вәзир... Их!..

Вәзир. Тагын бер күлмәк бар барын... Аны мәшһүр Гали акын үзенә дип теккән булган...

Хан. Шуны китерегез...

Вәзир. Баш өсте, ханым. *(Кулындагы кәгазьдән укып игълан итә.)* Игътибар! Мең дә өченче күлмәкне китерегез! Ул күлмәк йолдызлардан төшкән якты балкыштан тукылган булсын! Жиде таңның сихри чыгында юылган булсын! Сайрар кошлар канаты белән сыйпалган булсын!..

*Ишек катында торучы кызлар игълан ителгән күлмәкне алып керәләр. Аны ике яктан тотып бию әйләнәләр. Соңыннан Вәзир кулына тапшыралар. Вәзир күлмәкне тәхетнең ике ягында торучы кызлар кулына китереп сала. Таягын идәнгә орып, кыңгырау чыңлата. Дәртле көй астында кызлар күлмәкне Ханга кидерәләр. Ханга күлмәк ошый, ул сәхнә буйлап биеп китә...*

Хан *(такмаклап):*

Мин яшәдем бу дөньяда
Киң тәхетле хан булып.
Яшим хәзер шушы илдә
Иң бәхетле жан булып!..

Кемдер мина әйтсә әйтсен,
«Алтын чүлмәге», диеп.
Мин тагын да байыйм әле,
Бәхет күлмәге киеп!..

*Шулвакыт ханның сулышы буыла, тыны кысыла башлый. Ул, хәлсезләнеп егылган чакта, чак-чак кына тәхетенә таянып кала. Вәзир аңа тәхеткә менеп ятарга булыша, бертуктаусыз учларын жилпеп тора.*

Вәзир *(Хан тирәсендә бөтерелеп).* Ай-һай харап булдык, ай харап булдык... Шушы күлмәк галәмәте генә бу, күлмәк сихере генә... *(Кызларга ишарәләп, күлмәкне Хан өстеннән салдырырга куша.)*

*Кызлар Хан өстеннән күлмәкне салдыралар. Хан ах-ух килеп утыра. Шулвакыт сәхнәгә Ханның кызы Айбикә килеп керә. Кулында—гап-гади тукымадан тегелгән, күкрәкчәсенә кызыл чәчәкләр чигелгән ак күлмәк.*

Айбикә *(әтисенең хәлен күреп, тәхет катына йөгереп бара).* Әтием! Тагын нәрсә булды, әтием?.. Ханым?.. *(Әтисе дәшмәгәч, кулындагы күлмәкне күрсәтеп, күңелен күрмәкче була.)* Менә мин сина нинди матур күлмәк тегеп алып килдем. Ул сине бәхетле итәчәк, мин моны беләм!.. *(Сөенечен яшерә алмыйча, күккә багып.)* Син бәхетле булачаксың, әтием! Син бәхетле булсаң, мин дә бәхетле булачакмын...

Хан. И кызым, мин инде бәхетле булмамдыр... Нинди генә күлмәк киеп карамадым бит... Җиде диңгез артыннан да алып килделәр, Кояш, Ай нурларыннан тукылганын да китерделәр, үзенә урман-сулар шифасын сеңдергәнен дә бүләк иттеләр... Әмма аларның берсе дә мине бәхетле итә алмады... Ы-ы-ы-ы...*(Елый.)*

Айбикә *(әтисенең башыннан сыйпап).* Ә менә мин теккән күлмәк сине бәхетле итәчәк... Йә инде, әтием, киеп кара, ә?

Хан. Кимим... Ы-ы-ы... *(Үкереп елый.)*

Айбикә *(юатып).* Әтием, кеше көлдермә инде, йә, тукта елавыңнан... Бала чага кебек... Әнә күпме кеше карап тора... Бу бик серле күлмәк, әтием. Аны мин күңел хисләремне, җан җылымны кушып тектем... *(Кулындагы күлмәген, бармак очлары белән генә тотып, әйләнгәләп, җырлап, биеп китә.)*

Бу дөньяга һәрбер кеше
Бәхетле булып туа.
Тик нигә күпләр йөзләрен
Күз яшьләрендә юа?

Ап-ак, ак-бүз күлмәк киеп,
Җаннарыбызны аклыйк.
Ходай безгә бүләк иткән
Бәхетебезне саклыйк!

*Җырлап бетеругә, Айбикә кулындагы күлмәкне әтисенә илтеп кидерә, соңыннан аны кочып, үбеп ала. Бу вакытта күңелле көй уйнап тора. Хан, күлмәкне киюгә, күз яшьләрен сөрткәләп ала. Кызын кочып, баш түбәсеннән үбә.*

Хан. Рәхмәт, кызым...

Айбикә. Әллә елыйсың инде, әтием?

Хан. Әниең искә төшеп китте, кызым... Сине күрсә, нишләр иде икән ул хәзер? Сөенер иде, мөгаен... Их, гомерләре генә кыска булды...

Айбикә. Әйт әле, әтием, нинди иде ул? Чибәрме? Мин аңа охшаганмы?

Хан. Охшаган, охшмаган кая ул!.. Шундый ук сылу, шундый ук зирәк, уңган...

Айбикә. Ничек үлде ул, әтием?

Хан *(уйчанланып).* Сине якты дөньяга китерде дә шундук җан тәслим кылды. «Кызымны бәхетле итү өчен барысын эшлә!»—дип кенә әйтергә өлгерде. Мин аның җеназасы каршында сине бәхетле итәргә ант бирдем. Бик күп байлык туплыдым, тәхеткә ирештем... Боларның барысы да синең өчен бит... Бәхетемне генә кайтарып ала алмадым... Ә син... син бәхетлеме, кызым?

Айбикә *(ямансулап).* Белмим, әтием... Бәхет... нәрсә соң ул? Беләсеңме?

Хан. Беләм, кызым. Әниең—ханбикәм исән чакта мин бик бәхетле кеше идем... Бәхетле чагымда минем аягым җиргә тими иде, кулым белән очар кошны тота ала идем, хыялымның иге-чиге юк иде... Аннары... Бәхетле чагымда мин кара җирнең исен тоя идем... Тир катыш орлык исе сеңгән туфракка маңгаемны терәп, Ходабызга дога кылган чакларым бар иде минем... Әниең үлгәч, бәхетемне дә, шул туфрак исен дә югалттым... *(Бераз паузадан соң.)* Юк, кызым, синең бу матур күлмәгең генә бәхетле итә алмый инде мине... Ләкин барыбер рәхмәт... *(Кызын кочып үбә дә, башын тәхет култыксасына куеп, мыштым гына елый. Ул шулай тыныч кына оеп-йоклап китә.)*

*Айбикә бераз вакыт әтисе янында утыра да, сак кына торып, тирә-юньдәгеләргә: «Тс-с!»—дип, чыгып китә. Тәхет янында басып торган Вәзир, диварларда эленеп торган, идәндә чәчелеп яткан затлы күлмәкләрне берәм-берәм үз буйсынына куеп карап, куенына тутыра бара. Бер-икесен киеп тә куя. Куенына сыймаганнарны кочагына җыеп, чыга башлый. Шулвакыт Ханның зәһәр тавышы ишетелә.*

Хан *(башын күтәрә төшеп).* Ту-у-у-кта! Вәзи-и-ир! Кая барасың? Кая алып киттең минем күлмәкләрне, ә?

Вәзир *(туктап катып кала, аннары баскан урынында артына борыла).* Мин ни... Ни... Чыга идем әле... Ә... боларнымы? Боларны казна келәтенә илтә идем... Ханым-солтаным...

Хан. Миннән әмер шул: бу күлмәкләрне хәзер үк халыкка өләшеп чык!.. Кемнең күлмәге юк, шуларга бир, ишеттеңме?

Вәзир. Ишеттем, ханым. Кемнең күлмәге юк,—шуларга бирергә.

Хан *(бармагы белән чакырып).* Кил әле монда. *(Вәзир өстендәге күлмәклəр-*

*не салдырып.)* Кара аны! Бер күлмәкне генә үзеңә алсаң да, мәрхәмәт көтмә!

Вәзир *(өстендә үз күлмәге генә торып калгач, Хан каршына тезләнеп).* Ханым! Зинһар өчен, үз күлмәгемне калдыр... Кеше көләр бит... *(Ялварулы тавыш белән.)* Ханым...

Хан. Нәрсә, шәрә йөрүдән куркасынмы? Ә бит бездән күптән көләләр инде. Өстебездә ун кат күлмәк булса да, күнелләр, жаннар шәрә безнен... Их, Вәзир, Вәзир... *(Кискен генә укталып.)* Бар! Торма монда күз көеге булып!..Чык, тиз бул! Тукта! Әбүгалисинаны чакыр, минем янга керсен!

Вәзир. Баш өсте, ханым. *(Тәнен күлмәкләр белән капларга тырышып, гаурәтен яшерә-яшерә чыгып китә.)*

*Ишек катында Әбүгалисина күренә.*

Әбүгалисина. Чакырдыгызмы, Хан галиҗанәбләре?

Хан. Чакырдым шул. Кайда йөрисен бу кадәр вакыт?

Әбүгалисина. Халык арасында авырулар күбәйгән. Моның сәбәбе бер генә—аның тормышы җайсызланган, хезмәте авырайган...

Хан. Халыкның тормышы—минем борчу, минем кайгы, анысына тыгылма. Менә син әйт: Ханның саулыгы, Ханның язмышы, аның бәхете сине кызыксындырамы-юкмы? Вәгъдәң кая? «Бәхет күлмәге» хакындагы вәгъдәң кая? Ә? Ник дәшмисен?

Әбүгалисина *(кулбашын сикертеп).* Вәгъдә—минем өчен иман. Күлмәк хакындагы сүзем хак. Таптыңмы, кия алдыңмы соң син ул «бәхет күлмәген»? Әллә... тапмадыңмы?

Хан *(кәефсезәнеп).* Таптым... Үземә борчу таптым...

Әбүгалисина. Тагын нәрсә булды, ханым? Кай җирең авырта?

Хан. Бер җирем дә авыртмый минем! Күпме әйтергә була инде... Бәхетем генә юк минем, бәхетем генә... Ишетәсенме—бә-хе-тем юк! *(Эчтән изаланып, хәтта еламсырап.)* Күлмәге дә юк...

Әбүгалисина *(Хан өстендәге ак күлмәккә күзе төшеп).* Ә бу күлмәк каян? *(Җиңнәреннән тотып-тотып карый.)* Калеб кебек саф, һава кебек йомшак булса да булыр икән...

Хан. Кызымның бүләге ул. Кызымның «бәхет күлмәге».

Әбүгалисина. Синең кызың да бармы? Ә үзең... бәхетем юк, дип зарланасың...

Хан *(тынгысызланып йөренә).* Мин бит каршы түгел. Кызым белән үземчә бәхетле мин... Тик күнел тыныч түгел, күнел авырта, җан сызлый, җан сыкрый... Менә бит нидә хикмәт, табиб!..

Әбүгалисина *(уйчанланып).* Ә бит күнел авырта икән, җан сызлый икән, димәк ки, бу адәмнең инсани асылы исән дигән сүз!.. Ул күнелдә, җанда иман белән вөҗдан яши дигән сүз!.. Син әйткән хикмәт әнә шунда, ханым...

Хан. Сүзең матур, Әбүгалисина. Тик син һаман әйтеп бетермисең: җан тынгысызлыгы белән бәхет берничек тә килешә алмыймыни? Аларны килештерергә берәр чара юкмыни? Син әйткән «бәхет күлмәге»—бер ялган, уйдырма гынамы?!. *(Пауза.)* Ә мин ышандым. Шул буш сүздән яшәү мәгънәсе эзләргә керештем... Хан башым белән көлкегә калдым...

Әбүгалисина *(кискен генә).* Бар ул күлмәк. Минем сүзләремдә һич кенә дә ялган түгел. Уйдырма яисә хорафат та, сихер галәмәте дә юк... *(Бераз паузадан соң.)* Үзең гаепле. Син бит миннән ул күлмәкне каян алырга, дип сорамадың. Шундук алтын-көмеш һәм затлы асылташлар белән бизәлгән күлмәкләргә ябыштың... Бәхет байлыкта гына түгел шул...

Хан. Алайса, әйт: кайда соң ул—«бәхет күлмәге»? *(Табиб каршына тезләнә.)* Каршыңда инанып әйтәм, мәшһүр Әбүгалисина, ул күлмәкне таба алсам, аны тәнемә киеп, бәхеткә ирешә алсам, ярты патшалыгымнан ваз кичәргә дә риза булыр идем! *(Әбүгалисинаның җилән чабуыннан, җиңнәреннән тарткалап.)* Алыр идеңме минем ярты патшалыгымны? Ә? Ханның беренче вәзире булырга теләр идеңме?

Әбүгалисина. Тор, ханым. Сиңа тезләнү килешми. Син бит беркем каршында да гаепле түгел. Мескен дә түгел. Синең күнелең, җаның тынычлыгын, гомерең асыл мәгънәсен югалткан, шул гына. Син... халкыңнан аерылгансың, кара җирдән, туфрактан аерылгансың, хезмәттән аерылгансың... Ә бу—гаеп тә,

гөнаһ та түгел, бу—бары тик язмыш, кеше язмышы...

Хан *(тора).* Шулай дисеңме? *(Уйланып йөри.)* Ә бит чынлап та шулай. Минем инде күптән кара туфракка, яшел чирәмгә аяк басканым юк, кешеләр белән сөйләшкәнем юк... *(Әбүгалисина ягына кискен борылып.)* Аңладым, барысын да аңладым, табиб... Миңа яшәргә кирәк, тормышка кайтырга кирәк... *(Тагын уйланып йөри.)* Ә беләсеңме, миңа хәзер ул «бәхет күлмәге» кирәк тә түгел. Мин болай да ничек яшәргә кирәген төшендем. Рәхмәт сиңа...

Әбүгалисина. Ашыкма, ханым. «Бәхет күлмәге»ннән баш тартырга ашыкма. Син бит аңа лаек, бәхеткә лаек... Ә бәхеттән алай тиз генә баш тартмыйлар... *(Пауза. Әбүгалисина тәрәзә янына килә. Бераз вакыт тышка карап тора.)* Хәтерлисеңме, җиде кат таш кальга белән уратып алынган шушы мәһабәт сарай артында кыр-басулар җәелеп ята? Әллә хәтерләмисеңме? Алтынга төрелгән, әмма тынчып беткән сарай эчендә хәтер йомгагың тәмам чуалып беттеме? Ә бит бу кырлар, басулар сине, синең комагай вәзирләреңне, йөзәрләгән куштан хезмәтчеләреңне еллар, гасырлар буе икмәк белән туендырып торды. Менә шул басуга һәр таңда, кояш белән ярышып, бер игенче егет җир сөрергә чыга...

Хан *(түземсезләнеп).* Кем ул, нинди егет? Нинди катнашы бар ул ярлы-ябагайның минем язмышыма?

Әбүгалисина *(каты гына).* Тагын ашыгасың, ханым... Тагын ялгышасың... Үз-үзеңне тыңлый белмәсәң дә, башкаларны тыңларга өйрән... ханым! «Бәхет күлмәге» әнә шул егеттә—көн саен якты таң белән җир сөрергә чыккан сукачы егет өстендә!..

Хан. Ә? Шуңардамы?.. Шул... ачы тиргә, балчык-тузанга катып беткән кара халыктамы? Һы-һы!.. *(Ачуыннан нишләргә дә белмичә сәхнә буйлап йөренә.)*

Әбүгалисина. Әйе, бәхет әнә шунда яши, шул игенче алачыгында. Без бәхетне сайлый алмыйбыз шул, бәхет безне сайлый... Телисең икән—барып күр. Телисең икән—шул бәхет күлмәген өстенә киеп кара... Сорап кара—бәлки ул игенче егет сиңа ул күлмәкне бүләк итәр? Ләкин бик нык итеп, ышандырып сорарга туры киләчәк...

Хан. Телим икән—мин ул ярлы сукачыны хәзер үк каршыма китереп бастырачакмын! Өстендәге «бәхет күлмәге»н сыдырып алачакмын!

Әбүгалисина. Юк, ханым, ул күлмәк, сарай эченә килеп керү белән юкка чыгачак. Күңеленә салып куй: син аны үзең барып алырга тиеш буласың... Бәхет бервакытта да үзе килми, аны барып, үзенә ышандырып, инандырып кына алырга мөмкин. *(Пауза.)* Йә ярый, миңа китәргә кирәк. Әнә шундый бер игенче бәндәнең яңа туган баласы авырый, шуны дәваларга барасы бар... Ул баланың киярге күлмәге түгел, төренергә сөләмә чүпрәге дә юк... *(Хан каршында баш ия дә китәргә кузгала.)*

Хан. Табиб!

Әбүгалисина. Нәрсә, ханым? *(Кабат борыла.)*

Хан *(Тәхет өстенә ябылган җәймәне сыдырып ала).* Мә, ал, бир шул балага. Бәхет китермәсә дә, җылы ул...

Әбүгалисина. Баш өсте, ханым. *(Җәймәне ала да ашыгып чыгып китә.)*

*Сәхнәдә Хан ялгызы кала. Моңлы, салмак көй яңгырый башлый. Хан, тәхетеннән төшеп, арлы-бирле йөренә, аннары тәрәзә янына килә.*

Хан *(тәрәзәдән карап, моңсу җыр җырлый).*

Офыкта ажаган уйный,—
Таңнарның балкышымы?
Тәхете бар, бәхете юк,—
Бу—ханнар язмышымы?

Шәфәкъләрнең генә түгел
Таңнарның да моңы бар.
Сукбайларның гына түгел,
Ханнарның да җаны бар!..

Эх! *(Дәррәү кузгалып тәхете янына бара, өстендәге затлы киемнәрне салып, тәхет кәнәфиенә өя башлый. Бераздан ул, чишенеп бетеп, кызы бүләк иткән күлмәктән генә кала. Залга карап.)* Их!.. Бәхетле булам әле мин, булам! *(Ашыгып китә башлый.)*

*Хан чыгып барганда аның каршысына Вәзир белән Айбикә очрыйлар.*

Айбикә. Әтием?..
Вәзир. Ханым?..

Хан *(Вәзир белән Айбикәне ике яктан култыклап ала да сәхнә алдына килә.)* Сезнең бәхетле кешене күргәнегез бармы? *(Айбикәгә.)* Юк? *(Вәзиргә.)* Юк? *(Залга карап.)* Күрмәсәгез—күрерсез! *(Йөгереп чыгып китә.)*

*Вәзир белән Айбикә баскан урыннарында катып калалар, бераздан, айнып, бер-берсенә карашалар да Хан артыннан чыгып йөгерәләр.*

Вәзир. Ханым!..

Айбикә. Әтием!..

*Пәрдә.*

## Өченче күренеш

*Сәхнә артында табигать манзарасы. Уң кулда—еракта күренеп торган Хан сараена илтүче юл. Сул кулда—кырлар, басулар җәйрәп ята. Еракта урман күренә. Сәхнәнең бер як читендә юан агач. Фонограммада ат кешнәгән тавышлар. Сукачы тавышы: «На-а, малкай! Бураз-на-а!.. Бураз-на-а!.. Бураз-на-а!..» Бераздан шул ук тавыш дәртле җыр башлый:*

Бәхетемнән вазлар кичмим,
Йөрәк дөрләп янса да.
Язмышыма башны имим,
Кара тирләр тамса да...

*«На, малкай, на-а! Бураз-на-а!.. Бураз-на-а!.. Бураз-на-а!.. Тпр-р-ру!» Ат кешнәгән тавыш. Сәхнәгә маңгаендагы тирен сөртә-сөртә сукачы егет Мөхәммәтҗан килеп керә. Өстендә күлмәге юк, тир белән юылган тәне кояш нурларында балкып тора. Башында салам эшләпә, кулында камчы, инсәсендә—су салынган тире янчык. Ул керә дә ашлык орлыгы тутырылган юкә тыраслар тезелгән калкулыкка барып утыра. Рәхәтләнеп, тәмләп су эчә...*

Мөхәммәтҗан *(җырлый).*

Сөю кошым урын сайлый
Үзенә куныр өчен.
Ярату гына җитми шул?
Бәхетле булыр өчен...

*Шулвакыт якындагы агач артында Хан пәйда була. Гади киемнәрдән. Өстендә кызы Айбикә бүләк иткән чигүле ак күлмәк. Ул агач артында качып, сукачы егетнең җырын тыңлый. Үзе дә моңсуланып, хисләнеп тора.*

Хан *(үзалдына).* Әбүгалисина шушы егет хакында әйтте микәнни? Ә? *(Залга карап.)* Шулайдыр... Алай дисәң, өстендә, бәхет күлмәге түгел, кылка күлмәге дә юк бит моның!.. *(Паузадан соң.)* Кияр күлмәге булмаса да, ничек моңлы итеп җырлый тагы үзе... Ай-һай үзәкләрне өзә... *(Иләсләнеп тора.)* Бәгырьләрне актара бу, билләһи!..

Мөхәммәтҗан *(җырлый).*

Син Сак кебек, мин Сок кебек,—
Икебез ике якта.
Кошлар гына сайрар инде,
Ишетеп безнең хакта.

Их!.. *(Башын иеп, авыр сулый.)* Дөньясы да дөньясы... *(Бераз паузадан соң, кискен торып баса, кулларын баш очына күтәреп, күккә карап, кычкырып җибәрә.)* Мин барыбер бәхетле, бәхетле-е-е-е! Мин яратам, ярата-а-ам!

*Агач артында посып карап торган Хан бу хәлдән кинәт сискәнеп китә һәм агач янәшәсендәге чирәм калкулыкка егыла. Аны шундук Мөхәммәтҗан күреп кала.*

Син кем?.. Шайтанмы-җенме? Әллә фәрештәме?.. *(Якынрак килә. Хан өстендәге күлмәкне тотып-тотып карый.)* Бу нинди күлмәк? Кем күлмәге? Каян алдың? Кемнән урладың? Йә әйт тизрәк! Юкса... *(Кизәнә)*

Хан *(каушап калган Хан, ниһаять, исен җыеп, торып баса, мәгърур тавыш белән).* Хан мин, хан! Синең ханың! Ә менә син кем?

Мөхәммәтҗан *(көлемсерәп).* Һи, ышанды ди!.. Хан тикле хан агач төбендә аунап ята димени?!

Хан. Ышанмыйсыңмы? Ышан-

масаң, миңа ханлык билгесе! *(Кулын сузып, бармагындагы алтын балдакны күрсәтә.)*

Мөхәммәтҗан *(баш иеп).* Баш өсте, ханым... Ни боерасыз?

Хан *(йомшап).* Тс-с-с!.. *(Ишарәләп, егетне үз янына чакыра. Бертуктаусыз тирә-ягына карана.)* Ни... Минем монда икәнне беркем дә белми... Шулай кирәк... Син үзең кем соң?

Мөхәммәтҗан. Мин—игенче. «Сукачы Мөхәммәтҗан» диләр мине. Мөнә шушы басуда җир сөрәм.

Хан. Алайса, син минем хезмәтчем буласың? Бу басу минеке бит.

Мөхәммәтҗан. Ялгышасың, ханым. Бу җир, бу басу—Ходай Тәгаләнеке, Тәңренеке. Анда игелгән икмәк кенә синеке... Шуңа күрә дә җир синнән олырак...

Хан. Ә син кемнән олырак? Син үзең кем буласың соң? Синең бәяң нинди? Асылың нинди? Бәхетең нинди? Син... Син... *(Әйтергә икеләнебрәк тора.)* Син бәхетлеме?

Мөхәммәтҗан *(бераз паузадан соң).* Бәхет турында кычкырып сөйләшмиләр. Бәхетле булалар гына, йә... булмыйлар.

Хан *(Мөхәммәтҗанга якын ук килеп, як-ягына карана-карана, пышылдап кына сораша).* Әй, син, сукачы... Мөхәммәтҗан... Синдә «бәхет күлмәге» бар диләр, дөресме?

Мөхәммәтҗан *(аптырабрак).* Нинди-нинди?

Хан. «Бәхет күлмәге» дим. Ярыйярый, белмәмешкә салынма... Барысын да беләбез... Йә, бармы?

Мөхәммәтҗан *(хәйләкәр чырай белән).* Булса нәрсә әйтерсең? Нәрсә бирерсең?

Хан *(Мөхәммәтҗанның алдына тезләнеп).* Нәрсә телисең, шуны бирәм... Әйт кенә.

Мөхәммәтҗан *(хәйләкәр елмаеп).* Ханлыгыңны бирәсеңме?

Хан. Ханлыкнымы? *(Кискен торып баса, читкәрәк китеп уйлана.)* Юк, бирә алмыйм. Ә менә яртысын бирәм. Ризамы шуңа? Йә, тизрәк чыгар инде теге «бәхет күлмәген»! Кул сугышабыз да килешәбез!

Мөхәммәтҗан. Юк, кирәк түгел миңа ханлыгың. *(Уйланып тора.)* Ике шартым гына бар: бердән, син миңа өстеңдәге күлмәгеңне бирәсең, икенчедән, менә шушы басуны сукалап чыгасың. *(Кулын сузып, якындагы басуларга күрсәтә).* Минем шартларга риза булсаң, карарбыз...

Хан *(тагын тезләнә).* Риза, риза, Мөхәммәтҗан!.. Өстәвенә мин сине әле вәзир итеп тә алачакмын...

Мөхәммәтҗан. Анысы кирәк түгел. Анысы үзеңә булсын...

Хан *(торып, кулларын сыпыргалый).* Килештек алайса?..

Мөхәммәтҗан *(залга карап хәйләкәр елмая).* Килештек! *(Кул сугышалар.)*

Хан *(өстендәге күлмәген Мөхәммәтҗанга салып бирә, шәрә кала, мескен кыяфәттә, гаҗиз булып басып тора).* Хәзер нәрсә эшләргә?

Мөхәммәтҗан *(вәкарь белән басу ягына ымлый).* Хәзер—сукага! *(Камчысын тоттыра, су янчыгын бирә, үзе Хан биргән күлмәкне кия.)* Хуш иттек!

Хан. Хуш иттек! *(Китәм дигәндә генә кабат борылып.)* Кара аны, «бәхет күлмәге»н алып качасы булма!

Мөхәммәтҗан. Әй ханым, юкка борчыласың, мин инде үз язмышыма төшкән күлмәкне таптым. *(Үзалдына.)* Ә син, ханым, үз бәхетеңне үзең кара...

*Хан чыгып китә, Мөхәммәтҗан озак кына аның артыннан карап тора. Бераздан фонограммада Ханның: «На, малкай! На! Бураз-на! Бураз-на!»—дигән тавышы ишетелә башлый. Мөхәммәтҗан калкулыкка утыра, өстендәге күлмәген сыйпый-сыйпый, баягы җырны җырлый:*

Бәхетемнән вазлар кичмим,
Йөрәк дөрләп янса да.
Язмышыма башны имим,
Кара тирем тамса да...

*Ашыга-ашыга Вәзир керә. Хәле бетеп, ах-ух килеп, Мөхәммәтҗан янәшәсенә килеп утыра. Аякларын уа, битендәге тирен сөртә. Янәшәсендәге Мөхәммәтҗанны бераздан соң гына күреп ала. Баштарак, шаккатып, берберсенә карашып торалар.*

Вәзир *(торып баса).* Син кем?

Мөхәммәтҗан Ә син кем?

Вәзир. Мин—Ханның беренче

вәзире, баш министры. *(Як-ягына карапып.)* Үзе монда күренмәдеме?

Мөхәммәтҗан. Кем?

Вәзир. Ханыбыз-солтаныбыз.

Мөхәммәтҗан. Ә... Күренде... Әнә ул—җир сөреп йөри.

Вәзир *(башын тотып).* Ай-вай-вай... Нишләттең син безнең ханны?.. Кара халык хәленә төшергәнсең бит, хөрәсән! У-у!.. *(Кулындагы таягы белән яный.)* Моның өчен күрмәгәнеңне күрәчәксең әле син! *(Кыр ягына карап кычкыра.)* Ханым! Ханым!..

Мөхәммәтҗан. Туктале, Вәзир, җир ертып кычкырмале. Бөтен киекне куркытып бетерәсең бит... *(Кинәт исенә төшеп.)* Әй, карале, Вәзир, нинди «бәхет күлмәге» эзләп йөри ул? Миннән таптырып, җанны ала язды...

Вәзир. Ә син нәрсә диден?

Мөхәммәтҗан. Нәрсә диим? «Юк» дип булмый бит инде... Бар, дидем... Хәзер, әнә, шул күлмәк өчен җир сөреп йөри ханыбыз...

Вәзир. Ә бармы соң андый күлмәк?

Мөхәммәтҗан. Каян белим? Минем «бәхет күлмәге» хакында уйларга вакытым юк, әнә никадәр басу-кыр сөрәсем бар әле...

Вәзир. И-и, тинтәк! Булдыргансың икән!.. Ханым! Ханым!... *(Кычкыра-кычкыра чыгып китә.)*

Мөхәммәтҗан. Бар, бар. Сиңа да эш җитәрлек анда.

*Сәхнә бераз тын тора. Мөхәммәтҗан, берникадәр вакыт Вәзир артыннан карап торганнан соң, сәхнә алдына килеп, халыкка карап сөйли.*

Мөхәммәтҗан. Җәмәгать! Нинди дер серле күлмәк хакында шау-шу бара монда... Сез белмисезме, нинди күлмәк ул—«бәхет күлмәге»? Юк? *(Йөрени. Кинәт залга карап.)* Ә мин беләм! Беләм ул «бәхет күлмәге»н! Айбикә теккән шушы күлмәк бит ул... *(Хыялланып, хисләнеп тора. Бая җыр көенә җырлый.)*

Сөю-мәхәббәт утыннан
Йөрәгем бетте көеп.
Их!..
Бәхетле булам әле мин,
Бәхет күлмәге киеп...

*Мөхәммәтҗан җырлаганда сәхнәгә Айбикә керә, агач ышыгындарак егетнең җырын йотлыгып тыңлап тора. Җырын җырлап бетергәндә генә аны Мөхәммәтҗан күреп ала.*

Мөхәммәтҗан *(дулкынланып).* Айбикә?..

Айбикә *(хисләнеп).* Мөхәммәтҗан!..

Мөхәммәтҗан. Си-и-н?

Айбикә. С-и-ин?

Мөхәммәтҗан. Син каян, Айбикә?..

Айбикә. Мин... әтиемне эзләп йөрим. «Бәхет күлмәге» дип хыялланып йөргән чагы... Бер-бер хәл булмасын димен.. Син дә шул хакта җырлыйсын... Нинди «бәхет күлмәге» ул, Мөхәммәтҗан? *(Мөхәммәтҗан өстендәге күлмәккә күзе төшә. Якын ук килеп, тотып, сыйпап карый.)* Ә бу күлмәк каян?

Мөхәммәтҗан *(ихлас елмаеп).* «Бәхет күлмәге» шушы була инде, Айбикә... Таныйсыңмы—бу бит син теккән, син чиккән күлмәк. *(Җитдиләнеп.)* Ә хәтерлисеңме теге вакыттагы сөйләшүебезне? Менә—сүземдә тордым. Күлмәк—минеке!

Айбикә. Каян алдың син аны, Мөхәммәтҗан? Урлап чыктыңмы? Берәрсеннән талап алдыңмы?

Мөхәммәтҗан. Мина аны атаң бүләк итте. Шушы басуда җир сөрү бәрабәренә...

Айбикә. Ничек? Әтием җир сөрәме? Хан-солтан башы беләнме? Кайда ул?

Мөхәммәтҗан Ә-ә-ә-н-ә, күрәсеңме? Ничек ипле итеп тота ул суканы. Гомер буе җир сөреп яшәгән диярсең...

Айбикә. Ул кадәр мыскыл итмәсәң дә була иде ханыңны...

Мөхәммәтҗан. Нәрсәсе бар аның. Икмәк игү кайчаннан мыскылга әйләнде әле? Иң изге, игелекле эшләрнең берсе ул, беләсең килсә...

*Фонограммада Ханның тавышы: «На, малкай! На! Бураз-н-а-а! (Такмаклый.) «Кара җир, кара җир—орлыкка бишек булсын! Ипикәй, ипикәй—бәхеткә ишек булсын! На, малкай, н-а-а!.. Бураз-на-а!.. Бураз-на-а-а!..» Айбикә гаҗәпкә калып тыңлап тора...*

Мөхәммәтҗан. Хәзер нишлибез

инде, ә? Күлмәк миндә бит, Айбикә?

Айбикә. Мин сүземдә тора беләм... Мөхәммәтҗан... (*Хисләнеп, Мөхәммәтҗанга омтыла.*)

Мөхәммәтҗан (*дулкынланып, кызга каршы бара*). Мин... Мин... сине шундый көттем!.. (*Барып кочаклап алдым дигәндә генә, тайпылып, читкә китә.*) Әгәр теләмәсәң—көчләмим. Яратмыйсың икән—вәгъдә бозу гөнаһ түгел... Күлмәк дип кенә...

Айбикә (*тагын да ныграк хисләнеп, егеткә омтыла*). Мөхәммәтҗан!.. Сөйгәнем минем!.. Күлмәктәмени эш!.. Мин бит сине чынлап та яратам, күптән яратам!.. Сарай тәрәзәсеннән син эшләгән кыр-басуларга карап күзләремне, күзләремне генә түгел, йөрәгемне талдырып бетердем инде мин... (*Мөхәммәтҗанның күкрәгенә башын сала.*)

Мөхәммәтҗан (*Айбикәне күкрәгенә кысып*). Сөеклем... Җаным... Ә мин шушы сукмактан үткәненне көтеп зар була идем...

Айбикә. Мөхәммәтҗан...

Мөхәммәтҗан. Айбикә...

*Егет белән кыз бер-берсенә сыенышалар, шулай тынып калалар. Моңлы көй уйнала. Фонограммада Вәзир тавышы: «Ханым! Ташлагыз бу кара эшне! Сараегызга, тәхетегезгә кайтыгыз! Басу туфрагына буялып йөрү ханнар эше түгел.!» Хан тавышы: «Ханнар эше хакында ни беләсең син, Вәзир?! Ә?! Син бит вәзир генә. Мә, сиңа да зыян итмәс сука эше. Тот! Тот диләр сиңа!.. Шушы басуны сукалап бетермичә күземә күренәсе булма! Икмәкнең каян килгәнен белеп калырсың, ичмасам!..»*

*Ул арада сәхнәгә Әбүгалисина керә, юлчы киеменнән аркасына биштәр аскан, кулына таяк тоткан. Ул яшьләрнең сыенышып торганын күрә дә агач ышыгынарак барып баса, аннары, агач кәүсәсенә аркасын терәп, җиргә чүгәли.*

*Пауза. Көй уйнап ала.*

*Сәхнәгә ах-ух килеп, тирләп-пешеп, Хан килеп керә. Тәненнән, йөз-битеннән җемелдәп тир ага. Керә дә агач кәүсәсенең икенче ягына аркасын терәп утыра.*

Хан (*киерелеп тән яза*). У-у-һ!. Р-р-рәхә-ә-ә-т!.. Бу кадәр дә рәхәт арганым булмагандыр... Үлән өзәрлек тә хәлем юк, ә үзем... шундый бәхетле!.. (*Залга карап.*) Ишетәсезме, бә-хет-ле!.. (*Кулларын өскә күтәрә.*) Яшисе килү, бәхеткә тару шушы була икән... (*Хисләнеп елмая. Аннары кинәт сикереп тора.*) Ә бит миңа кемдер «бәхет күлмәге» вәгъдә иткән иде... Кая ул адәм баласы? (*Эзләнә.*) Әллә алдап качканмы? (*Мөхәммәтҗан белән Айбикәне күреп ала.*) Һайт, имансызлар! Нишләп торасыз монда көпә-көндез?! (*Мөхәммәтҗанга.*) Әле бу синме? Хәзер арт сабагыңны укытам мин синең! (*Уктала.*) Кая вәгъдә иткән күлмәгең? «Бәхет күлмәге» кайда? Кайда минем күлмәк?

Айбикә (*Мөхәммәтҗанның кочагыннан чыкмыйча гына*). Әтием... Сиңа нигә ул күлмәк? Син болай да бәхетле бит инде...

Хан. Ә вәгъдә, ә иман? (*Мөхәммәтҗанга кабат уктала.*) Йә, егеткәй, җавап тот. Мин синең ике шартыңны да үтәдем. Кайда син вәгъдә иткән «бәхет күлмәге»? Ә? Кайда?

*Мөхәммәтҗан каушап кала. Шулвакыт агач төбендә утырган Әбүгалисина кузгала башлый, салмак кына хәрәкәтләр белән торып баса.*

Әбүгалисина. Син аны киден инде, Хан...

*Барысы да сискәнеп читкә тайпылалар, шикләнеп, шомланып калалар, аннары тавыш килгән якка төбәләләр.*

Айбикә. Ай! Абау!

Хан. Әй, син кем? (*Якынрак бара.*) Әбүгалисина?

Мөхәммәтҗан. Табиб хәзрәт?

Әбүгалисина (*Ханга карап баш ия*). Мин бу, ханым. Әйе, син «бәхет күлмәге»н кидең инде...

Хан (*тәмам гаҗәпләнеп, хәтта гаҗизләнеп*). Ничек кидем? Кая ул күлмәк? Мин бит тиле түгел!

Әбүгалисина. «Бәхет күлмәге» сине өстеңдә, ханым. Тәнең буйлап аккан хәләл тирең—шул бәхет күлмәге була да инде... Икмәк игеп агызган тир—икеләтә изге, саваплы. Үзең дә инандың ласа—бүген синең дөньяң бөтенәйде, күңелең көрәйде, саулыгың артты, рухың чыныкты, иң мөһиме, бәхетең артты...

Бәхетенә тагын бер бәхет өстәлде: кызын үзенең парын, ярын тапты... Аларны тормышка бәхилләп, син тагын бер мәртәбә бәхетле булачаксың...

Айбикә *(Хан каршына тезләнә).* Әтием, фатиханны бирсәнә!

Мөхәммәт *(Айбикә янәшәсенә тезләнә).* Ханым, фатиханны бир!.. Мин синең йөзенә кызыллык китермәм!.. Кызынны соңгы сулышыма кадәр сөярмен, үзенә тугры ул, теләсәң, кол булырмын... Бу фатихаң өчен гомерем буе кара җир сукаларлмын, халкыбызны тук, дәүләтебезне имин итәрмен!.. *(Башын ия.)*

Хан *(башта йөзен чытып тора аннары «әй!» дип кул селти дә яшьләрнең баш түбәсенә учларын куя).* Бәхетле булыгыз, тигез гомер кичерегез. Олы тормышка бәхиллим, балалар. Фатихамны да бирәм, вакыты житкәч, ханлыгымны да тапшырырмын... Мин инде яшен яшәгән, эшен эшләгән, явын яулаган... Мина дөнья куарга түгел, бәхетле булырга гына кирәк... *(Уйчан кыяфәттә.)* Ә бит сез хаклы. Юк ул бәхет көлмәге. Бәхет—кешенең тәнендә түгел, ул аның асылында, рухында, җанында... Бүген минем рухым ирекка чыкты, жаным уянды... Тәнем буйлап аккан кара тир белән бөтен усал ниятләрем, шикшөбһәләрем агып бетте... Хәзер әйтә дә алмыйм: мин—Ханмы, әллә инде Хан түгелме? Чөнки минем бары тик жырлыйсым гына килә... *(Салмак кына жыр башлый.)*

Бу дөньяда һәр кешенең
Үз исеме, аты бар.
Үз тормышы, үз язмышы,
Үз бәясе, хакы бар...

*Кушымта:*
Әй күлмәк, күлмәк, күлмәк,—
Затлысы да аклысы!
Яулап алган бәхетләрне
Ничек кенә саклыйсы?

*Фонограммада Вәзир тавышы: «На, малкай! Бураз-н-а-а!.. Бураз-н-а-а!.. Бураз-н-а-а!..» Жыр дәвам итә. Ханга башкалар (Айбикә, Мөхәммәтжан, Әбугалисина) кушыла. Сәхнәгә бию ансамбле чыга. Күмәк бию—«Күлмәк биюе» башкарыла. Бию вакытында Ханга бер-бер артлы биюче кызлар тотып чыккан күлмәкләрне кидерәләр. Ул шулай жырлый-жырлый, бии-бии, алты-жиде күлмәк киеп өлгерә.*

Бәхет өчен житми икән
Ханнарның да тәхете.
Үз кулында, үз иркендә
Инсаннарның бәхете!

Кушымта:
Әй күлмәк, күлмәк, күлмәк,—
Затлысы да аклысы.
Язмышка тигән бәхетне
Ничек кенә саклыйсы?!

*Шулай жырлый-жырлый, бии-бии чыгып китәләр. Чыгып барганда Әбугалисина кире борылып керә. Залга карап сөйли.*

Әбугалисина *(эчке вәкарь белән).* Йә, жәмәгать, мина да кузгалырга вакыт. Ашыгырга кирәк. Бәхет юлы озын, айһай озын... Сез дә үз бәхетегезне табыгыз. Тапкач, югалтмагыз... «Тәхет» белән «бәхет» шигырь юлларында гына ул... Ә сез бу серле сүзләргә үз кафия—рифмаларыгызны табыгыз, яна мәгънәләр бирегез... *(Залга карап торганнан сон.)* Бәхетле булыгыз, кешеләр! *(Чыгып китә.)*

*Сәхнә артында баягы жырның соңгы куплеты кабат яңгырый. Шул жырны жырлый-жырлый, артистлар зал каршына баш иярга чыгалар.*

Бәхет өчен житми икән
Ханнарның да тәхете.
Үз кулында, үз иркендә
Инсаннарның бәхете.

*Кушымта:*
Әй күлмәк, күлмәк, күлмәк,—
Затлысы да аклысы.
Өлешкә тигән бәхетне
Безгә мәңге саклыйсы!

*Пәрдә.*



Әхсән
Баян

# СОҢГЫ АККОШ ҖЫРЫ

## Чәчәк

Малай чакта чегән кызы
Уч төбемдә фал ачты.
Юраганы онытылмады
Шушы көннәргә чаклы:
«Сине көтә озын юллар,
—Урау-урау, бормалы.
Утлар аша чыгасың бар,
Кичәсе күп суларны.
Морадыңа ирешерсең,
Барсаң дөрес, әкертен.
Су өстендә гөл шикелле
Чәчкә атар бәхетең.

Шау-гөр килеп уйнап үстек
Су буенда—яшьтәшләр.
Тегермәнле, тын дәрьяда
Ымсындырды чәчәкләр.

Пәрәвезләрдәй чолганып
Үскән гөл сабаклары.
... Мин әле йөзә дә белмим
Бик бәләкәй чакларым.
Бакчадагы түтәл төсле
Үскән гөлләр җыелып,
Аклы-күкле алсу чәчәк
Таныш төсле тоелып.

Туп-туры киттем янына
Йөзмичә—җәяү атлап.
Шулай күпме барылгандыр,
Барып җиткәнмен чак-чак.
Кире чыгуны уйлама,
Белмә син чигенүне!
Җиткәч барып, чорнап алган
Гөлләрнең пәрәвезе:
Хыялландың гомер буе,
Хәзер менә түз инде!..

Берзаман килсәм һушыма,
Ятам елга ярында.
Ятам ярда, охшап элек
Тоткан балыкларыма.
Инде батты дигәннәр дә,
Коткарган иптәшләрем.
Авыр хәлләргә таргаңда
Шуны уйлап яшәдем.
Күпме генә яшәлсә дә,
Искә һаман төшәчәк:
Кулыма кысып тотканмын
Исән-сау алсу чәчәк!

Аклы-зәңгәрле чәчәк.
Мин барда шиңмәячәк!..

*Әхсән БАЯН (1927)—Татарстанның халык шагыйре; прозаик, драматург, публицист. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Күпсанлы китаплар, шул исәптән 5 томлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Казанда яши.*

## Аксыргак

Туган җирем ак каенлык,
Көн дә кайтыр җаем юк.
Юл юк диеп уйламыйм да,
Кайтамын уйларымда.
Туган җирдә булам көн дә—
Чишмәле тауда уйлар.
Иманнәр, каеннар,таллар
Танып, сөенеп карыйлар,
Яфрак төсле канатларын
Җилпеп карый аксыргак.
Үз урыным—шушы болыным,
Ят түгел мин ди сымак.
Җилпенеп-җилпенеп куя
Очрашуга шат гүя.
Гөлләргә карап онтылсам,
Бераз кимсенеп куя.
Яфракларын салмак җилпеп,
Үпкәли шунда бераз:
«Онытма, якташ, сиңа да
Янап тора инкыйраз».
Безне никме яратмыйлар?—
Маллар ашый алмыйлар.
Чәйнәп-чәйнәп карыйлар да
Йотып җибәралмыйлар».
Мин бит бераз агулырак,
Бал кортлары тапмый бал.
Сөймәсәң бик аптырамам,
Бик теләсәң йолкып ал.
Тик онытма, үзеңнән дә
Яшиләр дошман ясап.
Син татар—минем мисалда
Син дә бераз аксыргак.
Кешелек тугайларында
Җитми урын, тар кайчак.
Сине дә бик зурламыйлар
Булмаган өчен ашап.
Шушы хәлдә яшәп торсак,
Булуыбызга—бул шат!

***

Буйсынганмын ялган матурлыкка,
Ышанганмын ялган карашка.
Хыянәтле йортның яме кача,
Бәхет югын белә,
Белә кош та:
Оя кормый корыган агачта.
Андый йортка шайтан ияләшә.
Елмаюын оныта сөйгән яр.
Адым саен аның сыйрагына
Чорналырга тора еланнар.

***

Күзгә чебеннәр шикелле,
Кырылды дошманнарың.
Син алардан үч алмадың,
Кырын күз дә салмадың.

Җиңел генә узмыйдыр шул
Хөсетлекләр, этлекләр.
Көчләр—зая, хәлдән тая
Өрә-өрә көчекләр.

Безне юк итмәк иделәр,
Ләкин без исән әле.
Аларсыз кызыксыз да бит...
Яшәргә исәп әле.

***

Күп китерден ак бәхетләр миңа,
Караларын бәлки—артыграк.
Газапларың булган саен күбрәк.
Күрешүләр булды татлырак.

Кичләремдә син балкыдың чынлап,
Болыт буйлап йөзгән ай сымак.
Озын төннәр узгач сине уйлап,
Иртәләрем булды яктырак.

Ал кичләрем, алтын иртәләрем
Инде сүнгән, калган, әй, ерак!

Син калдырган хисләр-яраларны
Дәвалыймын сыйпап, кадерләп.

Чуар күңелеңдә минем артык
Ышанучан холкым чагылган.
Алданганым өчен тиргим сине,
Тирги-тирги, өзелеп сагынам.

***

Китәсең лә, җаный, әй, китәсең,
Яшьләр юмый күзең карасын.
Таңнарымнан киткән идең, хәзер
Кичләремнән китеп барасың.

Таңнарымнан, кичләремнән киттең,
Хисләремнән китеп барасың.
Тик белеп кит, йөрәгемә яңа
Яралар син ясый алмассың.

Юлларыбыз инде очраштырмас.
Уйларымнан китеп барасың.
Хуш инде, хуш, синең йөрәгеңдә
Төзәлмәслек яра калмасын.

***

Җырлыйсың да моңаясың,
Моңнарың миңа күчә.
Элекке хисләр аларга
Иярә, сүрелмичә.

Тоеп туелмаган бәхет
Яңарып төшә искә.
Очрашуга килә ярым,
Вакытка бирешмичә.

Таңнан тирән коңгырт күзләр
Сирпиләр серләр кичкә.

Үзе төсле, таллар—нечкә,
Иелеп исәнләшә.

Чәчләрен тарап, җил исә,
Өстә болыт шул төстә.
Җилпенеп җитез яфраклар
Дәшәләр сөенечкә.

Син төшермәсәң дә искә,
Сагынып өзеләм бит.
Инде бераз онытырга,
Моңаймаска ярдәм ит.

***

Минем алда, зинһар, еламагыз,
Авыр булса да бик кайгыгыз.
Күз яшьләре күрсәм, мин дә елыйм,
Зинһар, шуны искә алыгыз.

Ярдәм итәр идең, килми кулдан,
Аяклардан мине шул ега.
Булмас кебек моңардан да авыр,
Моңардан да ачы фаҗига.

## Сихерле гыйшык

Бәйләнчек уй көн-төн минем
Талый бәгырьне.
Ачы мәхәббәт ярасы—
Татлы, кадерле.

Фәрештә дип, күккә ашар
Көч алган идем.
Үземнән дә изгерәк дип,
Ышанган идем.

Ышанычны кичәләрдә
Сыный ул, бик тә:
Бәйрәм итсә, шайтаннарга
Ияреп китә.

Азгын җанлы дип уйламас
Һичкем һич аны.
Күпвакыт әдәп-шәфкатьнең
Тере мисалы.

Качып йөреп, ят кочактан
Чыккан чакта да,
Гөнаһсыздай сыена синә,
Сөя, шат кала.

Сизми калам, тылсымыннан
Бетә ихтыяр.
Уйлар кала, уйда һаман—
Чибәр, көчле яр.

...Хыялыйлар булсам әгәр,
Белерсез, дуслар,
Мин әле дә шул сихерле
Гыйшыкка дучар.

## Аккош мәхәббәте

Гомер буе аккош мәхәббәтен
Бөек максат диеп сакладым.
Ә ул калды җырда, моңнарымда,
Ә тормышта үзем тапмадым.

Ә тормышта аккош тавышлары
Һава ярып, кайчан яңгырар?
Кайларгадыр китеп адаштылар
Кайтмаскамы китеп бардылар?

Соңгы аккош җыры туар әле,
Гомер хакы торган яр булса.
Биек ярдан ташка ташланырлык
Мәхәббәтнең тиңе табылса.

***

Төнозын яуган яңгырдан
Агачлар баш иделәр.
Яңгырдан түгел, ләззәттән
Арып калган иделәр.

***

Китте бикләп туган-үскән йортын,
Кесәсенә салды ачкычын.
Югалтмады озак, бик озак.
Китмәс өчен кайтты еллар урап.
Ачкыч кулда! Ләкин юк йозак...

*2007—2009*



Гөлзадә
Бәйрәмова

# ҮЗ ХӘЛЕМНЕ ҮЗЕМ БЕЛӘМ

ХИКӘЯ

Һажирә карчык йокысыннан уянганда сызылып кына таң атып килә иде инде. Көтүгә куасы малы, эшкә озатып җибәрәсе кешесе булмаганлыктан уянуга ук торасы да итмәде. Урынында уйланып ятарга бүгенге күргән төше дә сәбәпче иде, ахрысы...

...Бай, мул тормышта гомер кичерде дип әйтә алмас иде Һажирә үзен. Бәхет, мал, бәрәкәт—әллә ничек кенә шунда, өй тирәсендә йөргән кебек итте дә, эчкәрәк үтеп, тармакланып китә алмады. Әллә ул килен булып төшкән йортның нигезе шундый иде, әллә үзенең аягы җиңел булмады.

Уртача матурлыкта, уртача уңганлыкта, кешеләр белән ачуланышмас, чыкы-мыкы килеп йөрмәс, кияүгә чыгар яше җитеп, узыбрак барса да утырып калудан да курыкмас, үзенчә, үз көенчә генә яшәп ятучы, кешенекенә тимәс, үзенекен бирмәс бер кыз иде ул. Бөтен эше-шөгыле—фермада сыер саву да, кышларын кичке якта әнисе белән бергәләшеп шәл бәйләү булыр иде. Алай да, кирәсе ризык тешенне сындырып булса да керер дигәндәй, Һажирәгә дә кияү куенын күрергә язган булып чыкты. Күрше авылга кино карарга баргач, эскәмия читендә генә утырган кызны Харис кинодан соң яшьләр җыелып килгән машинада озата төште. Бер төште, ике, ахырда арый башлады, сөйләшергә сүз таба алмый интекте. «Әнигә килен булыр, мина күнелле булыр»,—дигән сымак кына өйләнде дә куйды. Чынлыкта Харис әбисе белән генә үсеп, кыш житсә башкорт якларына итек басарга, җәйләрен бригадир әйткәндә колхоз эшенә барып, әйтмәгәндә бармый калып, ялгызы гына гомер кичереп ятучы буйдак егет иде.

—Ирдән аерылу илдә була торган хәл. Чыкмый калу күңелсез. Ялгыз хатын-кызны басымчак итүчән булалар. Җәйнең җылы җиле дә салкын тоела башлый бервакыт,—диде әнисе, аны мең дә беренче тапкыр үгетләп, кызының башка кызлар кебек кияүгә чыгарга атлыгып тормавына аптырап.

Хатын-кызның кайда яшәсә дә үз шөгыле, үз эше, юасы-пешерәсе, өйне тәртиптә тотасы дигәндәй Харисның әбисеннән калган кечерәк кенә өен җыештырып чыгару әллә ни күп вакыт алмый, Һажирә килен булып төшкән авылында да фермага урнашты, иң беренчеләрдән булып килер, иң соңгылардан булып китәр иде. Ана карап кына алдынгылар рәтенә дә чыкмады

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА–*шагыйрә; «Әле кайчан гына...» исемле китап авторы. Казанда яши.*

үзе. Вакытны күбрәк эштә уздырырга теләвенең сәбәбе тирәндәрәк иде.

Эш—эш белән, хатын-кызның тагын бер вазифасын—ир хатыны булуны бик үк үз итеп бетерә алмады ул. Бер юган табак-савытын кабаттан юып, кул эшен тәгаллисе барын сылтау итеп иренең йоклап китүен көтеп йөри йөрер иде. Һаҗирә үз сыерларын савып бетереп, үзе белән бер елны кияүгә чыккан яшь кыз Гөлүсәнекеләргә керешкәндә тегесе килеп кереп:

—Һаҗирә апа, җаныкаем, яхшылыгыңны мәңге онытмам, таң атып килгәндә генә йоклап киткәнбез,—дип сөйләнүе аның өчен ят иде.

Тапмады ул ир кочагының тәмен. Тоя алмады... Әллә Ходай Тәгалә ярату-мәхәббәт дигән хисне өләшеп йөргәндә Һаҗирәне онытып калдырган инде... Харис белән җәйләрен урманга мунча пинлеге әзерләргә баргач, ире аланлыкта бераз утырып ял итеп алыйк, дип әйтә башласа да, курка калып: «Без монда аунап ятарга килмәдек»,—дип эшләвен дәвам итәр иде.

Һаман да шул Гөлүсә инде. Бер көнне Һаҗирә:

—Нишләп теге аксыл-матур күлмәгеңне бер дә кимисең?—дип сораган иде.

—Әй, Һаҗирә апа, аның киярлеге калмады инде, Азат белән җиләккә барган идек...—дип үзенең чираттагы мәхәббәт маҗарасын сөйләп китте теге, ник сүз башлаганына үкенде Һаҗирә, оялып бетте.

И бу хәзерге яшьләр... Яратуның ни-нәрсә икәнен белмәве, белергә теләмәве аркасында иренең күңелендә дә үзенә карата мәхәббәт уята алмады Һаҗирә. Бергә утырып ашый-эчәләр, дөнья көтәләр, тик көндезләрен бер-берсенең кайтуын тәрәзәдән үк күреп сөенеп каршы алулар, төннәрен бер-берендә эреп, таралып ратышулар гына була алмады.

Алай да, сез бер-берегезне яратасызмы, юкмы дип сорап тормый, туасы җан дөньяга туа. Кияүгә чыгып ике елдан соң уллары Фәрит туды. Читтән караганда үзләренә күрә тулы гына гаилә барлыкка килде.

Кош-корт, каз-үрдәк асрасалар да, нишләптер, олы мал үрчетеп җибәрәселәре итмәделәр. Бәлки моңа Харисның инде итеккә чыгып йөрүдән туктап, җәйләрен күрше-тирә авылларга мич чыгарырга йөрүләре, кунатөнә эшләүләре дә сәбәп булгандыр. «Харис кебек миччеләр тирә-якта бармак белән генә санарлык, ул чыгарган мичнең җылысы әле икенче көнне дә суынмаган була»,—дип сөйләрләр иде аның турында. Акча кайтып торганга ит-сөтне сатып та алалар, тик менә Сабира карчыктан калган өй генә кечерәеп, заманы өчен яраксызга әйләнеп, искереп бара иде. Үзе өйгә сирәгрәк—бакча эшләрен эшләп, йә акча кайтарып китәргә генә кайткангамы, өйне зурайтырга кирәк, малай да үсеп килә дип Харис сүз кузгатмады. Күңелендә булмаган җылылык—балага, балага булмаган җылылык өйгә күчә алмады.

Бер көнне Һаҗирә эштән кайтып кергәндә ишек алларында ят бер аваз ишетеп туктап калды. Капканы ачып эчкә үткәндә улы Фәритнең йоп-йомры, бөдрә йонлы бәрәнгә шешәдән сөт эчереп, аның белән мәш килгәнен күреп, баскыч төбендә утыручы иренә сораулы күзләрен төбәде.

—Менә, Фәриткә иптәш алып кайттым әле,—диде Харис аптырап калган хатынына.—Сарык малы үрчетеп җибәргәндә дә начар булмас,—дип абзарга юнәлде.

Әнә шул кайтуында әйтте дә инде Харис Һаҗирәгә теге сүзне. Хатынының урын җәергә йөргәнен күреп, кисәк кенә әйтте дә куйды:

—Бүтән бергә ятмыйк инде, яме, Һаҗирә...

Ормады, сукмады, арада киртә генә иде, инде койма ук корып куйды.

***

Алар авылында көтү чираты өй буенча килә. Кемдә ничә сарык малы, ничә сыер—шуңа карап. Ике сарык—бер чират. Авыл халкы көздән чиратны үзендә калдырмаска тырыша, нинди генә кар катыш яңгырлы көн булса да чиратны уздырып җибәрү ягын карый. Көтүнең беренче көне—бәла көне булырга мөмкин. Бу көнне малай-шалай кәрт сугып, хатын-кыз кыштан

бәйләнеп бетмичә калган оекбашын бәйләп утыра алмый инде. Бу көн—кыш буе абзарда ябылуда яткан мал-туарга узган еллардан татып калган иреккнең кире кайтуы, яна танышулар, кавышулар көне.

—Сыерыгыз шул тирәләрдә бозаулаячак,—дип, көтүченең кайтып әйтүе хуҗаларга сөенеч. Хуҗа көтүче әйткән көнне урындык астына яки өстәл кырыена язып куяр да, вакыты җиткәч шул айларда малга игътибарны арттырыр. Ел буе күз текәп, өметләнеп нәрсәдер төзергә, янартырга исәп тотып көтеп алынган мал бит. Сыерның кысыр калуы—хатынынның кысыр булуыннан бер дә ким түгел авыл кешесе өчен. Андый малны гадәттә озак тотмыйлар, иткә озаталар, хатынны исә аералар. Харис алып кайткан кара иярке дә хикмәтле булып чыкты. Бер ел көттеләр, ике, өч... Тик бәрәнләмәде. Көтүгә чыккач, Һаҗирә үзе дә аптырап карап торыр иде, бахыр, көтү уртасына да кермәс, гел кырыйда, читтә йөрер. Аптырагач, Һаҗирә үзләреннән өч-дүрт өй аша гына яшәүче ахирәте Минниса белән сөйләшеп, ирләре ерак урманга печән чабарга киткәч төнгелеккә алар абзарына ябып калдырырга булдылар. Ябуын алар япты, ачып чыгару Миннисаның ире Мулланурга насыйп булган икән. Сөйләшеп киткән машиналары килмәгәч, таң алдыннан гына авылга икенче машина белешергә кайткан Мулланур өенә кереп хатынын уятып тормый, лапас тирәсендә тегесен-монысын караштырып йөргәннән соң көтү куар вакыт җиткәч абзарның ишеген ачып җибәрүе була, алагаем ыргылып, әсәрләнгән кара нәрсә Мулланурның баш өстеннән очып чыгып китүе була. Калган сарык маллары да Мулланурны изеп-таптап алга ыргылалар. Өеннән чыгып килгән Миңниса исә бу хәлне күреп өнсез кала.

—Мулланур, җаным, кем белгән болай буласын! Һаҗирә бик үтенеп сораганга гына тыңлаган идем, дус бит, күршеләр бит,—ди иренә хикмәтнең нәрсәдә икәнен аңлата башлый.

—Мал иясенә охшамаса харам булыр, ди. Әйткән иде аны Харис...— ди Мулланур күбеп чыккан маңгаен уа-уа урыныннан кузгалып. Миңниса исә Харисның нәрсә әйткәне белән кызыксынып тормыйча, тизрәк маллары артыннан йөгерде. Бу минутларда аңа Харисның сүзе түгел, кызу холыклы иренең тавыш чыгармавы хәерлерәк иде.

—Бүтән бергә япмыйк инде, яме, Һаҗирә,—диде көтү куып кайтышлый Миңниса ахирәте янында тукталып. Теге вакытта Харис әйткән сүз белән никадәр охшаш иде бу сүзләр!

***

—Башка тояклы мал алмыйбыз, унсак шушысыннан уңабыз,—диде Харис, печәннән кайтып бераз вакыт узгач. Күрәсең, Мулланур аңа барып сөйләгән иде.—Нигезе шундый анын. Сабира карчыктан ук килә бу,—диде. Серен, сәбәбен белсә дә, Һаҗирәгә сөйләп торасы итмәде.

Адәм балалары да гел йә бик әйбәт, йә бик начар гына булып бетмәгән кебек, кара бәрәннең дә өстен ягы бар иде: ифрат та матур, затлы-йомшак, бөдрәләнеп, елкылдап торган йонлы иде ул. Авылларында инде төрле яклап сөйләнә торган бу җан иясенең йонына кешеләр яз-көз алдан ук әйтеп куярлар иде. Аеруча кыз-кыркын бияләй-шарф бәйләр өчен үз итә иде.

Бергә яши башлауларына дистә елдан артып китсә дә, бөтен байлыклары уллары Фәрит тә, каз-үрдәк һәм кара бәрән иде. Әле шулай булса да яраган икән. Фәрит инде кул арасына керә, әтисе белән чыккалый башлаган иде. Ире белән урам буйлап җитәкләшеп йөрмәсәләр дә, сугышып урамга да чыкмадылар. Баласы ата баласы, үзе ир хатыны булып, ире күләгәсендә, ире ышыгында яшәде. Кунакта урыннары янәшә булды. Сабантуйларга парлап бардылар, парлап кайттылар. Капканың эчке ягындагы тормышта ике генә нәрсә аерым иде—бергә мунча кермәделәр, бергә ятып йокламадылар. Анысы төн эше. Төннең исә күзе сукыр була...

...Харис һөнәрләренен—ни итек басуынын, ни мич чыгаруынын кирәге көннән-көн кими бара. Ара-тирә, юк-юкта—кемгәдер мунча мичe

чыгарырга кирәк булганда гына чыгып керер иде. Соңгы чыгуының берсендә хәлсезләнеп, авырып кайтты Харис. Район хастаханәсеннән Казанга ук җибәрделәр, Казаннан исә ай тулыр-тулмас үле гәүдәсен алып кайттып җирләделәр.

***

Әтисе үлгәндә мәктәптә соңгы елын укып йөргән Фәритнең мәктәпне тәмамлап армиягә китәр вакыты да җитте. Күзгә алынасы булгач, җәй китәсен көтеп үтте, эш, һөнәр дип йөрмәделәр.

Әллә бәхеткә, әллә бәхетсезлеккә—Һаҗирә нәрсәгә юрарга да белмәде, күздән язга калдырдылар, язын исә «ак билет» ук тоттырып кайтардылар. «Аю табаны»ның иң катысы, имеш. Алар үзләре үскән вакытта армиягә алынмау хурлык саналганга, бераз күңелен нидер кимереп куйса да, инде халык арасында йөргән төрле сүзләрне ишетеп, алынмавына сөенгән сымак та булды әле.

Мәктәптә укыганда ук трактор йөртергә таныклык алып чыгуы ярап куйды Фәриткә, ватык булса да бер трактор бирделәр үзенә. Әле колхоз рәисе:

—Харис малае икәнлегенне күрсәт әле, энем, сәгать кебек келтерәп кенә йөри торган ит үзен,—дип үсендереп тә җибәрде. Тик Фәрит җәй буе кара майга батып ятса да «менә кабына, менә кабына»,—дигән өмете генә акланмады, тракторын кабызып, эшләтеп җибәрә алмады. Ахырда тәмам күңеле кайтып, тимерләрен букчасы-ние белән трактор идәненә томырды да әнисе каршына кереп утырды.

—Китәм!—диде катгый итеп.—Шәһәргә китәм! Анда бер-ике ел заводта эшләсәң бүлмә дә бирәләр икән. Өй дә салып интекмәбез, сине дә кайтып алырмын,—дип өстәде ахырда.

... Болай да артык ачылып сөйләшми торган Һаҗирә Фәрите киткәч бермәлгә бөтенләй үз эченә бикләнде. Үткән тормышының бердәнбер тере шаһиты булып калган кара сарыкны ишек алдына җибәрер иде дә сәгатьләр буе аның белән сөйләшер, эчен бушатыр иде. Теге бичара исә, үзем дә синең хәлдә бит, дигән сымак күзләрен мөлдерәтеп карап торыр иде. Кайчандыр, ире алып кайткач яратып бетермәгән, инде тәмам картаеп, арт аякларын өстерәп йөрер хәлгә калган бу җан иясе Һаҗирә өчен хәзер бердәнбер юаныч иде...

***

Шәһәр кешене үзенә йота дип әйтүләре хак, ахры, Фәрит тә китте дә югалды. Авылдашлары артыннан бер-ике тапкыр җибәргән хатын санамаганда артык хәбәре булмады, үзе кайтып йөрмәде.

Китүенә ел тулганда бер кайтты, әмма берәгәйле кайтты...

Ишек алларында вак-төяк эшләрен караштырып йөргән Һаҗирә машина килеп туктаганын ишетеп капкага юнәлде. Машинадан исә улы Фәрит, аның артыннан яшь кенә кыз бала чыкты. Чүт кенә соңарып, кулына машина ачкычы тоткан ир, теләр-теләмәс кенә төшүче хатын-кыз күренде.

—Менә, әни, өйләндем, таныш бул...—Фәритнең исәнләшүеннән дә алдан әйтелгән бу сүзгә Һаҗирә башына сугып миңгерәйтелгән кеше сымак катып калды. Башлап кемгә кул бирергә, нәрсә дип әйтергә белмичә аптырап торды.

Ир кеше дөнья күргәнгә охшап тора, хатынның каушап калганын сизеп алды:

—Яшьләр шулай инде, сюрприз ясарга ярaталар,—дип куйды шаярткан булып.

Бу көннең кайчан да булса бер килерен Һаҗирә белә иде, тик бүген дип уйламаган иде. «Шулай, әйтмичә, киңәшләшмичә, и бала, бала...» Һаҗирә күңеленнән улын шелтәләп алса да, кунакларны өйгә дәшмичә булмый, йөгерә-атлый өйгә әйдәде. «Кунак килсә ит пешә, ит пешмәсә—бит пешә»—коры өстәл артында кара-каршы озак утыра алмыйсың, Һаҗирә

юк йомышын бар итеп чоланга чыгып керергә кузгалды да, шул хут белән Мулланурларга йөгерде.

—Мулланур, җаным, малай өйләнеп кайткан. Гомергә бер килә торган көн. Кода-кодагыйлар бик кәттә күренә. Суй теге кара сарыкны. Булды, түзмәдем түгел, түздем...—Һаҗирә ишектән керә-керешкә үк башлаган сүзен тәмамламыйча ярты юлда туктап калды.

—Булмый, Һаҗирә, ачуланма,—диде Мулланур эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алгач,—Хариска биргән сүзем бар, Һаҗирә бик ялынып сораса да тимә, үз үлеме белән үлсен,—диде.

Мулланурның холкын белгән Һаҗирә вакыт уздырып ялынып утырасы итмәде, авылның бөтен ирләренә әйтеп бетермәгәндер әле дип урамның теге ягында яшәүче Хәмиткә барырга уйлады. Тик урамга чыккач үз өйләре турысындагы машина тирәсендә әллә нинди, сәер генә кайнашучы кунакларны күреп кире борыласы итте. Кодагый тиешле кеше инде машинага кереп үк утырган, Һаҗирәне күргәч чыгып торуны кирәк санамады, кызның әтисе исә:

—Монда Фәритнең эшләре бик күп икән, бераз тәртипкә салсын әле,—дип машинасын кабызырга үрелде. Бер читтә кыйшайган капка баганасына сөялгән Фәрит, әтисенең ачулы карашыннан ни әйтергә белмичә ике арада калган кыз бала басып тора иде. Инде зәңгәр төтеннәрен чыгара башлаган машинаның ишегенә үрелгәндә, әй, каерылып-каерылып карады да соң бахыр. Һаҗирәгә аның бил тирәләре калыная башлаган сымак тоелды...

...Икенче көнне Фәрит төнлә җан биргән кара сарыкны кул арбасына салып үләт базына илтеп ташлады...

***

...Менә шул кара сарыгы бүген төшенә керде Һаҗирәнең. Күпме вакытлар, күпме еллар үткәч диген син! Үзе кебек үк бөдрә йонлы, йоп-йомры бәрән ияртеп кайткан. И гаҗәпләнде дә соң Һаҗирә. Кертмәскә итә. Кертмәде дә. «Соң, нишлим мин хәзер сезнең белән, баштарак, абзар тутырып мал асрыйсы килгәндә алып кайталар аны, күпме көттем бит»,—ди икән...

Урыныннан торып ишек алдына чыкканда Һаҗирә чоланның чаршау белән бүленгән ягында йоклап ятучы, күп эчүдән йөзләре саргаеп калган улына күз салды. И бала, бала... Инде гомерең уртасына җитеп киләсең...

...Теге вакытта әтисе кызын алып киткәч, әй, кимсенде дә инде, бахыр, айлар буе беркая чыкмыйча ятагында аунар, әнисе ишек алдына чыгып киткәндә генә аз-маз капкалап алыр, җылау катыш җырлау белән гел бер җырны сыктар иде:

Үз хәлемне үзем беләм,
Барыбер саргаеп үләм.

Һаҗирәнең колагында җырның соңгы сүзләре генә яңгырап торды: үләм, үләм, үләм. «Шулай үләсе килерлек дәрәҗәдә яратып була микәнни? Кемгә охшап шундый булды икән?»

Әле җырлавы яраган... җырлый, күңеленә ятышлы җыр сүзләре таба ала икән, димәк кеше уйлана, яши. Берзаман чаршау артыннан җыр ишетелми башлады. Җырны аракы алыштырды. Әллә заманы җайсыз туры килде, әллә үзләре сансыз булды, тора-бара Фәрит кебекләр авылда ишәя төште. Беркөнне кибеткә ипи китергәннәрен көтеп торганда хатыннар санап чыгарды, аларның кырык-илле йортлык авылларында ике өйгә бер өйләнмәгән, яисә гаиләләрен шәһәрдә калдырып авылга кайткан ир-егет бар икән. Илнең көе китте. Илнең көе юк икән—ирләргә кыен, ирнең көе булмаса—гаиләгә. Шәһәрдә көне буе базарда басып торып сату иткән хатыннарга ирләренең аз гына гаебе дә күп булып, кайчандыр күп тоелган акчасы аз булып күренә башлады. Хатын-кызның

өйдә: «Мин»,—дигән сүзе ешрак ишетелә башласа, белеп тор, димәк, бу өйдә хатын-кыз хакимлек итә.

Түбән очнын Шакир абзый малае Рәшит турында көлеп тә, җәлләп тә сөйләгәннәр иде бервакыт. «Әти, унбиш көнлеккә утырып арыдым, авылда көтү булса да көтәр идем, зинһар, килеп ал»,—дип этисенә хат язган икән. Моны укыгач Шакир карт агач аягы белән идәнгә китереп типкән дә:

—Сугыш кирәк аларга!—дип кычкырган.

—Әстәгъфирулла, карт, үзең сугыш күргән кеше, ничек шул сүзне әйтә аласың?—ди икән карчыгы Галимәттәй куркынып.

—Күргәнгә күрә әйтәм дә. Сугышта санитарлар тәнендә аз гына җаны калган ир-атны да бер гаилә булса да ятим булмасын дип сыртларына салып әллә ничәшәр чакрым кыр буйлап өстерәп алып чыгарлар иде. Ә болар? Ире ир була белми, хатыны—хатын...

...Тик анага сыймый кайда сыйсын инде бала? Баланың гарибе дә, гаебе дә анага гына сыя шул...

***

Язмыш кабатлана икән. Улы Фәрит үсеп җитеп, өстәвенә, тормышының башында ук каршылыкка очрап күңеле төшкәч, әйтерсең лә Һаҗирәнең язмыш китабының икенче битен генә ачып куйдылар. Шул ук салкынлык, шул ук аңлаша алмаучанлык... Әтисе белән икесе арасында ир белән хатын арасында булырга тиешле хистән бигрәк туганлык хисе кебегрәк хис булса, улы белән Һаҗирә арасында хәтта анысы да юк сымак иде. Галимәттәй әйткәндәй, «Ир кайгысы—итәктә, баланыкы—йөрәктә»... Дөрес, вакыт-вакыт ачылып та куйгалый үзе, кечкенә вакытларын, әтисенең кара бәрәнне алып кайткан чакларын искә төшереп сөйләшеп тә утырырлар иде. Тагын да шундый сөйләшүләргә өметләнеп сүз башласа, Һаҗирә икенче юлы улының: «Баш катырма», «Үзем белермен», кебек каты-каты җавапларына юлыккач эндәшмәс булыр иде.

...Һаҗирә Фәритләр кичтән караңгы төшкәндә генә эшкәртеп бетергән, кайсы ауган, кайсы күмелеп калган бәрәңгеләрне рәтләштереп йөргәндә дә иртәнге уйларыннан арына алмады. Әллә нинди бүген көне дә... Гел уйларга гына этәрә. Эш, уй белән Һаҗирә капкага какканнарын да ишетмәде. Кагу көчәя төште.

—Кайсы хәерсезе икән инде? Тагын кемгә нәрсә эшлиселәре бар икән...—Һаҗирә кулындагы чүп үләннәрен читкә атып капкага юнәлде. Фәрит уянмасын, кемдер килеп алып чыгып китеп, тагын эчеп кайтмасын дип келәне төшереп үк куйган иде.

—Исәнмесез... Миңа Фәрит... исемле кеше кирәк иде...

Пөхтә киенгән, һич кенә дә авыл тирәсе кешеләренә охшамаган матур гына яшүсмер басып тора иде.

—Юк бит, Фәрит, өйдә юк, китте,—диде Һаҗирә каушый-тотлыга, ярым пышылдап, үзенә дә чак ишетелерлек итеп.

—Кайчан кайтыр икән?

—Кайтмас шул, тиз генә кайтмас, бәлки, башка бер дә кайтмас,—Һаҗирә ни дип җавап биргәнен дә аңышмыйча теленә килгән сүзләрне кабатлавында булды.

—Кызганыч. Бик күрәсем килгән иде. Хушыгыз...—Егет кәефе төшеп, акрын гына машинасына юнәлде. Машинасының ишеген ачканда тагын бер кат саубуллашырга теләпме борылып карыйсы итте. Әнә шул каерылып каравы белән кемнедер хәтерләтте ул Һаҗирәгә...

—Хуш, улым, бәхил бул...—Һаҗирә капка келәсен төшереп, хәле китеп баскыч төбенә килеп утырды.

Бу минутларда улы Фәрит чоланның чаршау белән бүленеп алынган сәкесендә соңгы сулышларын ала иде...



Халисә
Ширмән

# КЫРГЫЙЛЫК

ХИКӘЯ

...Ниһаять, Гәүһәр яңа фатирга күченде. Үз фатирына! Егерме елдан артык тулай торакта яшәгән хатынның шатлыгы сөйләп бетергесез иде. Шулай булмыйча соң! Казансу елгасы ярында төзелгән яңа йорттан бер бүлмәле фатирны ярты бәясенә генә алып кара әле син! Төрле сүзләр йөрде: имеш, Гәүһәр Ирхановның сөяркәсе икән. Ирханов кул куймаган булса, Гәүһәр бу фатирны төшендә дә күрәсе түгел икән. Житмәсә, Гәүһәр Мәскәүдән килгән комиссия вәкилен дә үзенә караткан ди. Мәскәү вәкиле хатынның тулай торакта яшәвен белгәч, Ирхановка әйткән имеш: «Мин Казанга еш киләм, икенче килүемдә Гәүһәр Сафуановна мине үз өендә каршыласын, тулай торакта түгел!»

Мондый сүзләр йөрисен йөреп, тыңланып, колакларны ялыктырып бетергәч кенә Гәүһәрнең үзенә дә килеп ирешә. Хатын башта кычкырып көлмәкче иде, тик «Нәрсә әйтер икән бу?» дип үзенә текәлгән Гөлиягә карап, берара аптырып калды. Күпләр кебек үк, якын дусты Гөлия дә хәлнең нәкъ шулай булганына чын күңелдән ышанган иде, ахрысы. Тавышында бераз үпкәләү дә бар, янәсе, ана әйтми генә Гәүһәр сөяркә булып куйган. «Ничек инде ул? Мин икесенең дә сөяркәсе булып чыгаммыни?» Ни генә әйтеп акланса да, Гәүһәр инде кеше сүзен кире кага алмаганлыгын аңлады. Хәер, мондый сүзләрне беренче тапкыр гына ишетми лә. Чибәр хатын ул, үзе дә белә. Премия-фәлән ала калса, «Карале, син бит иртәдән-кичкә кадәр ат кебек эшлисең», димиләр, «Бу юлы кемгә елмайдың?» дип ятлар кылларын тарта. Җыелышта берәр ир-ат белән янәшә утырса, иртәгәсен ирләр тәмәке тарткан арада әлеге «бәхетле»не «чеметкәлиләр». Янәсе, ничек анда, эш пешәме?

Их, гомер... Яше кырыкка якынлашып килсә дә, Гәүһәргә гаилә бәхете насыйп булмаган, күрәсең. Берәм-берәм дус кызлары кияүгә китә торды, балалары үсте, инде балаларын да кияүле-киләшле итә башладылар, ә Гәүһәрнең үз тинен тапканы юк. Юк иде... Нурланга кадәр. Нурлан. Казакъ исемен алган, Казакъстан далаларында ат уйнаткан бу ирне Гәүһәр күрсә дә күрде, күрмәсә дә күрде.

Халисә ШИРМӘН *(Халисә Хатыйп кызы Кузьмина)–КДУның татар теле тарихы һәм гомуми тел белеме кафедрасы доценты; бернича повесть һәм хикәяләр авторы. Казанда яши.*

Республика көнен чамалап, энесенең хатыны кунакка килгән иде. Гәүһәр ерак авылдан Казанга беренче тапкыр килгән туганына башкала күрсәтәм дип бик өзгәләнде: Кремль, Сөембикә манарасы, метро—барысы-барысы турында да белгәннәрен сөйләп, кунакның кәефен табарга тырышты. Хәер, авылдан тиенләп җыйган акча белән килгән кунак «метро» дип тә, «Кремль» дип тә җан атмады, икенче көнне иртәсен: «Гәүһәр, витнам базары син торган җирдән еракмы ул? Күршеләр ун сумнан гына оекбаш алып кайтканнар, шул витнам базарыннан, диләр. Бездә бигрәк кыйммәт бит. Малайга да кышкылыкка өстенә бирәр нәрсә табып булмасмы»,—дип, Гәүһәрне бик тиз күктән җиргә тартып төшерде.

Шулай да бәйрәм көнендә ат чабышы карарга бардылар. Гәүһәр чабыш карарга яратмый иде. Кунакның теләгенә каршы килеп булмый бит инде. «Карале, мәйтәм,—диде кунак.—Президентны якыннанрак күреп булмас микән? Телевизордан барыбер икенче төрлерәк күренә бит инде ул. Тормыштагыча түгел». Гәүһәр көлемсерәде генә. Менә шул чакта Нурлан белән таныштылар да инде алар. Үзенә текәлеп карап торганын күргәч, берәр иске танышыммы әллә дип үзе дә күз салган иде хатын. Сүзләрен дә тынлап торган икән бу ир. «Теләсәгез, мин сезне янәшәдәге трибунага үткәрә алам. Әйдәгез!» Ил башлыкларын якыннан күреп, Казан кунагы бик канәгать калды, байлыгы булганнарның тормыш мажараларыннан гыйбрәт алгач, вьетнам искесе белән шыплап тулган авыр сумкасын күтәрде дә, икенче көнне үк туганнарын сөендерергә кире авылга кайтып китте. Ә Нурлан калды. Ипподромда ат тәрбияләүче булып эшли икән. Атлар турында бик күп белә. Кайчакта, кызып китеп, Гәүһәр белән бәхәсләшә дә. Гәүһәр исә атларның күзенә карый алмаганын сөйли. Дөнья яралганнан бирле нинди хәсрәт булса, шуларның барысы да ат күзенә җыелгандыр кебек тоела аңа. Бер елны ул җәйге каникул вакытында авыл ашханәсендә пешекче булып эшләде. Каравыл атын суеп, итен ашханәгә китергәннәр иде. Ярабби, әле дә күз алдында тора Гәүһәрнең: яңа туналган ябык кына түшкә өстендә камчы белән сугудан буй-буй кан сауган эзләр иде... Аякларын тышаулап, кайберләренең авызлыкларын да алмый ул (янәсе, бер-ике сәгатьтән җигәсе бар!) утларга җибәрелгән малкайларны күреп йөрәге өзгәләнә иде кызның... Авызлык кидерү өчен казык тешләрен сугып сындырулар... Тагын кайсы хайванны кеше шулкадәр рәнҗетә? Сыерныммы, сарыкнымы? Йә, Ходай, кешегә каргыш төшсә, ат каргышы төшәдер... Ә Нурлан атлар турында иләсләнеп сөйли. Янәсе, ат—ирнең юлдашы. Хатын-кыз моны аңлыймы соң?! Шулай да хатын-кыз белән ат арасында уртаклык бар имеш. Яхшы ат, гүзәл хатын-кыз кебек, нечкә билле, озын торыклы, нык бәкәлле булырга тиеш. Шундый атлар гына чабыш аты була ала. Калганнары—йөк атлары. Тагы кымыз атлары—бияләр бар. Йорт хатын-кызлары кебек. «Ә мин, мин нинди ат булам инде?» Нурлан, беркадәр сынап, Гәүһәргә текәлә. Авызын ачтырып, тешләрен санар шикелле тоела башлый Гәүһәргә. «Синме? Яшьлегеңдә син чабыш аты булгансыңдыр. Ә хәзер кыргыйлангансың. Кыргый ат син». Гәүһәр көлә. Ярый инде, йорт аты, бия, димәде. Шунысына да канәгать хатын. Ә Нурланның назлары... Беркайчан да Гәүһәрнең «ир» дип болай җүләрләнгәне юк иде. Баксаң, ир назларының төмен белмәгән дә икән ул. Тыгыз тәнле дала ире үзе кыргый атка әверелә. Их, гайбәтчеләр! Ирханов, имеш... Ирхановкамы соң Нурлан белән тиңләшергә!..

Нурланга зур өметләр баглады Гәүһәр. Менә инде яз да узып китте, күптән көтелгән җылы яңгырлар яудырып, җир өстенә июнь ае ятты. Яңа фатирда беренче язы, беренче җәе Гәүһәрнең. Йорт яңа булганга, әле күршеләре дә юк диярлек, берничә гаилә генә күзгә чалына. Нурланны

да фатирына дәшкәне юк әле. Ничектер, тантаналы һәм бик җылы итеп каршылыйсы килә аны. Ә ничек—күз алдына да китерә алмый. Гадәттәгечә, табын әзерләр инде, Нурланның яраткан ризыкларын куяр. Яңа фатирны котлап, шампан шәрабы ачарлар. Шуннан соң... сихри төн килер. Тик болар барысы да бик гади, бик зәвыксыз, хәтта вульгар булып тоела Гәүһәргә. Нурланның боларга исе китмәс. Ярый әле быел подъезд төбендә роза гөлләре үстерде. Яңа йортка ямь өстиләр. Гөлләрне бик ярата шул Гәүһәр. Тулай торакта яшәгәндә дә берничә ел рәттән ишек алды ягына түтәл ясап, затлы роза гөлләре утырткан иде, һәркөн сулар сибеп, тәрбияләп үстерде. Шул роза гөлләре иртәнге таңда кызыл шаһинә таҗларын ачып, көне буе кешеләрнең күңелләрен күтәрсә, икенче көнне гүзәл чәчәкләрнең бары сынган сабаклары гына утырып кала иде. Кемнәр өзә, кемнәр шундый сихри матурлыкка кул күтәрә—Гәүһәр белми. Бик рәнҗи кызның күңеле. Өзелгән чәчәкнең нинди матурлыгы булсын? Чәчәкнең җәсәде ич ул, ничек кешеләр шуны аңламыйлар?! Кем үлгән кошның, үлгән мәченең гәүдәсен бүләк итеп икенче бер кешегә бирсен инде! Башка килмәслек күренеш! Ә чәчәкләрнең үлгән гәүдәләрен бүләк итеп бирү—гадәти хәл, хәтта зыялылык билгесе, имеш! Аннан шул чәчәк җәсәдләрен чүплеккә чыгарып аталар. Их, кешеләр...

...Гәүһәр тулай торак янына гадирәк чәчәкләр—ромашкалар, канәфер чәчәкләре, күккүзләр утырта башлады. Өзсәләр дә, күп булып шытып чыккач, алай сизелерлек кимемәде чәчәкләр. Еллар буе һәр җәйне тулай торакның соры диварына ямь биреп, аңлаганнарның күңелләрен назлап, аңламаганнарның күзләрен кызыктырып, Гәүһәрнең чәчәкләре күкрәп үсте. Әһә! Менә! Уйлап тапты! Нурлан килүгә, өен гөлчәчәкләр белән бизиячәк ул! Ярый әле, хәзер кибетләрдән чәчәк аткан гөлләрне теләгән кадәр алып була, акчасын кызганмас...

...Подъезд янына утырткан сары, кызыл, алсу роза гөлләре быел, ничектер, көттереп кенә чәчәк атарга уйладылар, ахры. Әллә комлы туфрак килешмәдеме? Гәүһәр исә, гөлләренең чәчәк атуына туры китереп, кибеттән дә бары чәчәкле гөлләрне генә сатып алды. Зәвык белән бизәлгән өстәл өстенә, тәрәзә төпләренә, телевизор, диван, кәнәфи—кайда урын бар, шунда гөлләр тезеп чыкты. Ишектән залга кадәр арага ике яклап гөлләрдән сукмак салды. Шәмнәр утыртты. Соңыннан бу кадәр гөлләрне кая куясын да уйламады Гәүһәр—табар әле урынын, дусларына, күршеләренә өләшер. Бары Нурлан өчен... Киләчәге өчен. Бәхете шушы гөлләр кебек гүзәл булсын, көтеп алган бәхете бит ул аның!

...Ишектәге кыңгырау да, Гәүһәрнең холкына килештереп, назлы гына чылтырый. Тәрәзәдә кичке шәфәкъ чагыла—вакыт соң инде. Нурланның эштән кайтып, юынып, чистарынып, Гәүһәргә беренче тапкыр өй котларга кунакка килүе. Гәүһәр тиз генә шәмнәрне кабызып чыкты. Кичке эңгер-меңгер яктысына утның сихри нурлары кушылып, йокымсыраган гөлләрне уятты. Кичке балкыш Гәүһәр өстендәге озын алсу ефәк күлмәкне шаһзадә киеме итеп күрсәтә иде. Биленә кадәр таралып төшкән кара чәчләрен төзәткәндәй итте, дулкынланып, көзгегә карап алды. Йә, Ходай, әйтерсең, беренче тапкыр очраша Нурлан белән! Тынычлан! Ниһаять, ашыкмый гына, серле елмаюын ирен читләренә яшереп, Гәүһәр ишекне ачты. Бусагада аның Нурланы—аның сөеклесе басып тора иде. Гәүһәрне күреп, елмая, дала кешеләренә хас нурлы күзләреннән соклану бөркелә.

—Нурлан... Нурым минем! Шундый көттем сине!

Гәүһәр иренең көчле иннәренә сарыла, ир бер кулы белән Гәүһәрне кочып ала, иреннәренә үрелә, артка яшерелгән икенче кулын хатынга суза...

—Аһ!..

Гәүһәр үзе үстергән роза гөлләрен шунда ук таныды. Әнә, иң беренче булып ачылган зур бөреле кызыл шаһинә розаның таҗлары тымызык кына яуган сәер янгырдан соң саргаебрак калдылар. Башкаларына ул янгыр тимәде. Ә менә сары розалар көннәр салкынаеп киткәндә бөреләнделәр, шуна бераз гына соңрак ачылдылар, таҗларының очы да, кырау тигәндәй, каралыбрак тора... Шулар инде, Гәүһәрнең гөлләре... Жил тидермичә, сулар сибеп, карап-саклап үстергән гөлләре... Хатын авызыннан чыккан аһылдауны ир үзенчә аңлады, тагы да киңрәк елмаеп, чәчәкләрне хатынга суза төште.

—Котлыйм, кадерлем!

...Гәүһәр, чәчәкләрне кочаклап, подъезд төбенә атылды. Күңеле ышанмый иде әле, Нурлан ич ул, аның нурлысы, аның Нурланы болай эшли алмас!!!

Нурлан исә шәмнәр янып торган гөлләр патшалыгын ачык ишек аша бераз тамаша кылып торды да, аптырап, Гәүһәр артыннан чыкты. Ярамаган эш эшләгәнен аңлап, күңеле сулкылдап куйды. Гәүһәр, өзелгән чәчәкләрне кочаклаган да, бала тибрәткәндәй, алга-артка чайкалып, түтәл каршындагы утыргычта утырып тора. Юк, еламаган. Нурланның чыкканын да тыныч кына каршы алды.

—Мә, тотып тор әле,—кочагындагы чәчәкләрне сак кына Нурланга сузды.—Мин хәзер.

Җыештыручы бүлмәсеннән көрәк алып чыкты, сүзсез генә чокыр казыды. Чәчәкләрне шул чокырга салып, туфрак белән күмеп куйды.

—Менә, булды да.

Көрәкне урынына кертеп куйгач, Гәүһәр ни әйтергә белми аптырап басып торган Нурлан янына килде.

—Нурлан, әйт әле, чабышта аяклары җәрәхәтләнгән атларны соңыннан нишләтәләр? Суялармы?

Көтелмәгән сораудан ирнең башы әйләнеп китте. Нигәдер күз алдында далага чыгып чапкан кыргый ат гәүдәләнде. Томырылып, артка борылмый каядыр офыкка таба чаба иде ул ат... Җавап көтеп үзенә текәлгән күзләргә чумгандай булды. Туктале, мондый күзләрне күп күрде түгелме соң ул? Дөнья яралганнан бирле нинди хәсрәт булса, шулар җыелганмы әллә бу күзләргә?

—Барысын да түгел инде. Шунда ук тартышып үлсә, чүплеккә чыгаралар. Җәрәхәтләрен дәвалап булганнарын хуҗалыкларга озаталар. Кайберләрен суялар.

Озын кара керфекләр тетрәнеп куйды, тамчылар яңаклар буйлап аска тәгәрәде.

—Хуш, сау бул, Нурлан. Бәхетле яшә.

* * *

... Дала буйлап кыргый ат чаба. Тузгыган ялларын, авызлыкның нәрсә икәнен белмәгән горур башын, төз муенын, киселмәгән озын койрыгын җил хөкеменә тапшырып, дала буйлап томырылып ат чаба. Бу—аның даласы, бу—аның тормышы, бу—аның бәхете...

...Гәүһәр төшендәге дала, кайда син?!



Вәсимә Хәйруллина

## Авыр тынлык

**Шундый авыр тынлык җирдә,
Потлап салган йөгән иңгә:
Көннән-көн тирән батыра
Каракош тырнагын илгә.**

**Үз кулыбыз, үз көчебез
Белән телне өзеп бара.
«Канун» атлы тышаулары:
Каршы барып йөзеп кара.**

**Тыныч ил-көн, имин, шөкер.
Тик тынлыгы шундый авыр.
Бакыйлык тынлыгы кебек,
Чумып бара шуңа авыл.**

**Кычкырсаң да син каравыл,
Авыл белән милләт бата...
Ә каракош: «Ирек»—диеп,
Мөнбәрләрдән ялган сата.**

**Татар акылы төштән соң,
Терсәк һаман ераклаша.
Без сайлаган бөекләр дә
Каракошка яраклаша.**

**Зыңлап тынлык өзелерме,
Киселгәннәр ялганырмы?
Халык берчак аерырмы
Чынлык белән ялганнарны?**

## Намус

**Намусыңны яшьтән сакла,—диләр,
Намус нәрсә? Кайдан башлана?
Кульяулыктай кесәләрдә йөрсә,
Бөтен нәрсә бик тиз таплана.**

Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА—*шагыйрә; балалар өчен язылган берничә китап авторы. Сарман районының Чураш авылында яши.*

Йөрәктәме намус, башыңдамы.
Желектәме, әллә кандамы?
«Намуслар»—дип бездә сөйләмиләр,
Юкка гына берлек сандамы?

Намус нәрсә? Әллә рентгенмы ул?
Барсын күрә, барсын белә ул.
Үзе тешсез, әмма шулай тешли—
Тәнне түгел, җанны телә ул.

Ачындыра, үкендерә намус,
Күз яшьләре белән чылата.
Жиңел заман әле булганы юк,
Намусыңны һәр көн сыната.

Вөҗдан газаплары жиңел түгел,
Иң күтәрми, жаның күтәрә.
Намусыңа таплар тия калса,
Ай-һай авыр дөнья көтәргә.

Намус каршысында җавап тоту—
Сират кичү кебек халәттер.
Туры карар өчен намусыңа
Кесәләрдә йөртмәү кирәктер.

Намус нәрсә? Нәфес йөгәнеме?
Керсез хисләребез сагымы?
Авырлыклар безне сынаганда
Агызмасмы тормыш агымы?

Намус кайда?
Җанда, җилегеңдә,
Йөрәгеңдә, күңел түреңдә...
Намусыңны яшьләй сакла,—диләр,—
Тыныч ятар өчен гүреңдә.

## Кышка керәм

Шундый матур эре ак кар ява,
Жиргә ята зрер-эремәс.
Кышка керәм, гомер язы үткән,
Хис йөгәнле, күренер-күренмәс.

Матур чәчәк булып кар коела,
Каплап килә минем эземне...
Көннәр, еллар капламаслык итеп
Әйтә алсам иде сүземне.

## Бәхетем

Уч төбендә бәхетем,
Күзләр тия күрмәсен.
Язмыш аны күпсенеп:
—Артык—дия күрмәсен.

Уч төбендә бәхетем,
Очып китә күрмәсен.
Читләр, ятлар, усаллар
Өлешемә кермәсен.

Уч төбемдә бәхетем.
Сыймый мыскал үлчәмгә
Йомдым ныклап учымны—
Ычкындырмам үлсәм дә.



Рифат
Сәлах

## ҖӘЙСЫЛУНЫҢ ЯШЕЛ ТОЛЫМЫ

***

**Җәйсылуны кочагыма алам,**
**Юкка чыксын язгы туңуым.**
**Бөтен күңелемне биреп назлыйм**
**Җәйсылуның яшел толымын.**

**Язлар алып китте сагышымны—**
**Гел мәхәббәт белән тулымын.**
**Акылымны җуеп иркәлим мин**
**Җәйсылуның яшел толымын.**

**Җәй җылы ла—үз сөюем җитәр,**
**Синсез генә яшәп торырмын.**
**Чәчләреңнән сыйпаган күк назлыйм**
**Җәйсылуның яшел толымын.**

**Безне янә үз янына дәшәр**
**Безне табыштырган бу болын.**
**Гөлчәчәкләр белән тарап үрәм**
**Җәйсылуның яшел толымын.**

## Болгарым!

**Тәүге күргән сыман каршылыйсың,**
**Бар иде лә монда булганым.**
**Меңъеллыклар, гасыр, чорлар аша**
**Сиңа кайтып барам, Болгарым!**

**Дәва эзләп синең җиргә киләм**
**Сыкрый калса җанда иманым,**
**Һәр ташыңны, һәр сулышың тоеп**
**Сиңа кайтып барам, Болгарым!**

**Күңелемә төрәм аклыкларын**
**Идел өстен күмгән томанның.**
**Томаннарны, дулкыннарны ерып**
**Сиңа кайтып барам, Болгарым!**

Рифат СӘЛАХ (1987) — *яшь шагыйрь, «Күңел бөртекләре» исемле китап авторы. Казанда яши.*

Милли кояш сүнгән чакларда да,
Болгар җиле, рәхмәт, тынмадың.
Милләтемнең җантибешен тоеп
Сиңа кайтып киләм, Болгарым!

## Гает

Бу җирдә динилек булганын
Оныттык без, әллә белмәдек.
Мөэминнәр яхшыга юрасын
Хәерле булсын дип бу гает.

Мәчеттә урын юк—шау халык,
Мәҗбүрмен урамга чыгарга.
Гаеттә мәчеттән чыксам да,
Йә, Раббым, иманнан чыгарма!

Хаталы укысак намазны,
Ходаем, гафу ит, син, кичер.
Казасыз калмабыз,
Газаптан коткарчы
Иманга сусаган җан өчен.

Исламның яңадан калкуы,
Юл да юк—шау халык урамда.
Елына ике кат булса да
Кайтабыз икән бит иманга.

Бу җирнең иманлы буласын
Белмәдек бугай шул, белмәдек.
Болытлар яхшыга юрасын,
Үткәч тә, сүнмәсен бу гает.

Мәчеттән чыгабыз, һәркемнең
Күзләре яңгырга чылана...
Гаеттән чыксак та,
Йә, Раббым,
Күңелдән иманны чыгарма!

## Гыйбадәт

Аллаһ исме белән башлыйм әле!—
Изге эшләр шулай башлана
Һәм күкләргә багып дога кылам:
«Йә, Ходаем, үзең ташлама!»

Һәм диварга килеп башны куям,
Кулны куям дивар өстенә.
Бер үрмәкүч пәрәвезен үргән—
Язып куйган сыман: «бисмиллаһ».

Маңгаемны җир өстенә куям
Һәм ялварып сорыйм, тезләнәм.
Мин булмасам иде язмышымның
Бәхет-сынавына түзмәгән.

Һәм күкләргә багып дога кылам,
Йә, Ходаем, үзең ташлама!
...Гаҗәпләнәм, әле шуннан соң да
Бәгыремдә күпме таш кала...

## Исхакый!

«Милләтебез!»—диеп, янып-көеп,
Без яшәргә тиеш, без—бакый!
Дөрес юлны күрсәткәнең өчен,
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Исхакый!

Инкыйразга ике гасыр алдан
Кисәткәнсең ярый...
Без—исән!
Башны ию кирәк микән илгә—
Ватаныңда үзең изелсәң!

Син киткәч тә, милләтебез күге
Бер каралды, әле аязды.
Казан урамнары истә тота
Яуширмәдән килгән Гаязны.

Казан йортларына сеңеп калган
Синең аваз булып: «Азатлык!»
Инкыйразга барса туган халкың,
Яшәвең дә җирдә газап бит.

Ләкин яшәү күпкә ләззәтлерәк,
Көтеп яту түгел казасын...
Чит илләрдә торып әле һаман
Милләтеңә хатлар язасың.

Без атларга тиеш ялгышмыйча,
Туры юлда синең эз балкый!
Син яшәсәң, яшәр милләтебез,
Ышан безгә, ышан, Исхакый!

## Йолдыз кыйпылчыгы

*(диптих)*

1

Карашларың—йолдыз кыйпылчыгы...
Кулларыңнан төште алсу алма.
Таң кызының толымнары аша
Сиңа бага кемдер, соңга калма.

Уйларымны кабул итәр микән
Йолдызлардан төшкән алтын нурлар.
Керфегеңә кунган йолдыз-чыклар
Тыныч кына җиргә атылырлар.

2

Күңелеңнән йолдыз-хыялларың
Атылырлар...
Ә мин китәрмен.

Йолдызыма илткән гөлләремне
Тылсым белән әрем итәрмен.

Чыклар кибәр беркөн,
Офыгында
Югалырлар йолдыз-эзләр дә...
Таң кызының толымнары аша
Сөеп багам яшел күзләргә.

## Постмодерн

Гаскәр булып Үткән килә,—
Кулларында—айбалта.
Тәрәзәләр яна күктә,
Әрнеп кенә ай бата.

Гаскәр булып килә бүген
Сызып ташланган Тарих.
Таң кызының толымнарын
Төн егетләре тарый.

Гаскәр булып Үткән килә,
Бүгенге тора карап...
Җирдә ята Таңсылуның
Толымы белән тарак.

## Видагъ

Кинәт кенә туктап калган дөнья...
Кошлар ишетелми. Инеш—тын.
Кыш-сылукай килә салмак атлап—
Иңнәренә салган көмеш тун.

Кыш-сылукай килә ак сукмактан,
Бураннары акбүз ат сыман.
Юл читенә гөлчәчәкләр тезгән
Сөйгән ярлар язган хат сыман.

Тынып калган дөнья куенында
Торып калган икән кар-буран.
...Кыш-сылукай өчен түгел, Сиңа
Йөрәк-йөрәк Сөю калдырам.

## Саубуллашу

Хатирәләр төяп киткән чакта,
(Хатирәләр ике «КамАЗ»лык.!)
Истәлеккә диеп гарәп дустым
Бүләк иткән иде намазлык.

Намазлыкка сыеп беткән бугай
Бөтен дуслык, бөтен туганлык.
Без бу илдә туган җиребездә
Иркен сулар өчен тын алдык.

Гарәпме ул, башка милләттәнме,
Иң беренче туган, дус кеше!
Истәлеккә диеп гарәп дуска
Бүләк иттем Казан сөлгесе.



Илдус
Илдарханов

# УЛ БӨЕК ИДЕ, ЛӘКИН...

## КӨРӘШЧЕ ШӘЗАМ САФИННЫҢ КҮТӘРЕЛҮ ҺӘМ ТӨШҮ ТАРИХЫ

*Монда тасвирлана торган хәлләр узган гасырның урталарына туры килә. Башлануы исә–тарих мең дә тугыз йөз дә утыз икенче елда, Нижгар якларында, Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Кучкай Пожары авылында.*

**Рамил КУРАМШИН,** *Татарстанның халык артисты, баянчы:*

—Бу—безнең авыл. Аның биш гасырдан арткан тарихы бар. Артист булып ярты дөньяны әйләнгәндә мин нинди генә матур җирләрдә булмадым да, кайларда гына йөрмәдем, әмма беркайда да үзебезнең авылдагы кебек гүзәллекләргә тап була алмадым. Без мишәрнең бөек улы Такташчарак итеп әйтсәк: «Беркайда юк... андагыдай челтерәп аккан чишмәләр, яшел хәтфәгә төренгән болыннар, таулар, бормаланып-бормаланып аккан Пияна елгасы...»

Казаннан Мәскәүгә бара торган поездан Сергач стансысында төшеп каласың да, болын аркылы ярты сәгать атлауга су буена җәелеп утырган туган авылыбызга килеп җитәсең. Аңа нигезне Кучкай бабай салган, авыл да шуның исемен алып, Кучкай Пожары булып киткән дип сөйлиләр. Заманалар үзгәргәч, татар дөньясыннан читтәрәк калган авылны урыслаштырырга омтылып, халыкның хәтереннән аның тарихын сызып ташларга тырышып Кучкайны Кочкига әйләндергәннәр. Авылда яшәгән халык мин белә-белгәннән бирле ике якка сәфәр чыкты—алыш-биреш итәргә, сәүдә белән шөгыльләнергә маһирлар Мәскәүгә йөрде, белемгә омтылганнар, милли мәдәният, тарих белән кызыксынганнар Казанга юл тотты, шунда төпләнеп калырга тырышты. Узган гасырның егерменче-утызынчы елларында илдә социализм төзү, ил башкаласы Мәскәүне заманга яраклы итеп үзгәртүләр башланып киткәч, аеруча беренчеләре күбәя. Тора-бара авыл бөтенләй мәскәүләште. Бәрәңгеләр алынып, көннәр суыта башлауга ил башкаласына барып төпләнгәннәр әти-әниләрен, әби-бабаларын кышларга дип үзләре янына алып китә башладылар, көннәр язга борылуга алар оныкларын алып, Мәскәү тормышы рухын ияртеп яңадан туган туфракларына әйләнеп кайттылар.

Илдус ИЛДАРХАНОВ (1944) – *журналист; Татарстанның спорт журналистлары федерациясе (1974 – 84), Татарча көрәш федерациясе (1989 – 91) җитәкчесе; «Олимп тавына ничек менәргә», «Халык һәм спорт уеннары», «Без көрәшле халык» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Утызынчы-кырыгынчы елларда туган, инде илленең-алтмышның өсте ягына чыккан олылар яшәешләрен әле яшьлекләрендәгечә дәвам итәргә тырышсалар да, урысча укучы, урысча яшәүче яшь буын Кучкай Пожарына яңа сулыш өрде. Авыл Кучкай бабайны бөтенләй онытып, Кочки Пожаркига әйләнеп бетте...

**Роза ҖИҺАНШИНА (Зарипова):**

—Шушы авылда яшәгән Зариф атлы кешенең икенче улы Сафа, безнең булачак әтиебез, Мәскәүгә 1929 елда барып урнаша. Ул бик тырыш, эшчән, әйбәт кеше иде. Белеме булмаса да, нәрсәгә алынса шуны җиренә җиткереп башкарды. Баштарак ул хәленнән килгән эш—әйбер алып сату белән яши, аннары, торыр җир бирәселәрен белгәч, мич ягучы булып урнаша. Йөри-йөри безнең булачак әниебезне—Әстерхан якларында туып-үскән, Тула өлкәсендә яшәгән Рәхиләне очрата. Алар 1931 елда өйләнешеп, 1951дә әти үлгәнчегә кадәр тату-матур яшәделәр. Шул гаиләдә 1932 елның 7 апрелендә беренче бала дөньяга килә. Аңа Шәзам дип исем кушалар. Әни аны табарга әтинең туган авылына кайткан була, шуңа да документларына ун көннән соң гына «Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районындагы Кочки-Пожарки авылында туган» дип языла. Тагын өч елдан дөньяга мин килгәнмен...



Без баштарак Мәскәүнең Трудовая урамындагы йортларның берсендә тордык. Шундый зур илнең башкаласында яшәсәк тә, татарлар әти-бабайлардан килгән гадәтләрне тотарга тырышты. Кибеттә ит өзелеп тормаса да, көзләрен әти барча туганнарын, дус-ишләрен чакырып мал суя иде. Егетләр армиягә китә башласа, аларны авылдагыча барча якташлар бергә җыелып, ашап-эчеп, гармуннар белән җырлап-биеп, күңел ачып озаттылар. Җәй җитүгә әти белән әни безне тимер юлдан Сергачка кадәр алып кайтып, аннан тәпи-тәпи авылга алып китеп, әби белән бабай кулына тапшыра торганнар иде. Абыйга әле бер ел күрше урыс авылындагы мәктәптә дә укырга туры килде. Без абыйны бик яраттык. Ул бик көчле иде, берәүдән дә курыкмады, үскән чакта безнең барыбызга да терәк булды. Дуслары күп иде, берәүгә дә беребезне дә рәнҗетергә ирек куймады. Унбиш яшьләренә җиткәч, Мәскәүдәге һөнәр училищесына укырга керде, шуннан көрәш түгәрәгенә йөри башлады.

**Лев ШИРШАКОВ,** *көрәш буенча халыкара спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры:*

—Безнең малай чак авыр сугыш елларына туры килде. Ачлы-туклы яшәүдән әтиләр, абыйлар дошманны җиңеп кайткач кына арына башладык. Бу вакытта ил хәлсезләнгән, ирләр аз иде, шуңа да дәүләт үсеп килүче яшь буынны таза, бар эшне дә булдыра алырлык кешеләр итеп тәрбияләүгә зур игътибар бирде. Мәктәпләрдә, училищеларда укучыларны спорт секцияләренә тартып, алардан көчле, таза, нык ихтыярлы кешеләр тәрбияләүгә зур тырышлык куелды. Сугыш яраларын төзәтү белән бер үк вакытта илдәге көчле спортчылар халыкара ярышларда катнаша башладылар. Алардан җиңү яулап кайтучыларны, дошманны тар-мар иткән илнең дәрәҗәсен тыныч тормышта да дөньяда югары тоталар дип, бик зурладылар. 1947 елда беренче мәртәбә Европа чемпионатында көрәшеп, Чехословакия башкаласы Прагадан алтын медальләр алып кайткан Николай Белов, Константин Коберидзе, Иоханнес Коткасны ил җәмәгатьчелеге сугыштан җиңү яулап кайткан батырларыдай каршылады. Бу хәл илдә спорт, бигрәк тә көрәш белән кызыксынуны тагын да арттырып җибәрде. Шул елның көзендә мин дә, мәктәптә бергә укыган иптәш малайларыма ияреп, «Хезмәт резервлары» спорт җәмгыятенең Бакунин урамындагы спорт залына йөри башладым. Ул чакта без андагы барысы да бер төсле киенеп, фронттан кайткан әтиләрнең, абыйларның күкрәкләрендәге орден-медальләр кебек значоклар тагып йөрүчеләргә бик кызыгып карадык. Әле дә хәтердә, икенче катка урнашкан залда безне галифе чалбарлы, аягына күн итек кисә дә майкадан гына йөрүче, чандыррак гәүдәле бер абый каршы алды. Ул мине Саша Сафин, Юлий Лебедев, Володя Яковлев, Юрий

Майоров кебек берничә елдан бик зур көрәшчеләр булып житешәчәк егетләр янына куйды да, «Мә, Юлик, бу егетне сиңа тапшырам. Дөнья чемпионы булгач, бәлки безне дә җылы сүзе белән искә алыр»,—дип шаяртып, Юлий Лебедевка беркетте. Аның белән келәмдә бәтерелгән, аунаган арада башкаларга да күз төшергәләдем. Игътибарым түгәрәк йөзле, зур матур күзле, барысы да «Саша, Сашко, Санек» дип йөрткән көрәшчегә тукталды. Шунда мин аның татар малае булуын, шул тирәдәге йортларның берсендә яшәвен, физкультура техникумында укуын белдем. Сафин белән без шулай таныштык. Миңа аның бигрәк тә көндәшен келәмгә аркасы аша тәгәрәтеп җибәрүе ошый иде. Бу алымны ул башкаларга караганда төгәлрәк, җиренә җиткереп, йомшак һәм матур итеп, екканда бер дә авырттырмыйча башкара торган иде. Ул бик ярдәмчел булды, үзе белгәннәрне бик теләп уртаклашты. Күп балалы гаиләдән икән. Энесе, сеңелләре абыйларының көрәшкәнен карарга ярышларга да килгәләделәр.

Андрей Антонович безнең беребезне дә игътибарыннан читтә калдырмыйча, һәркайсыбызны дикъкать белән күзәтте. Теге яки бу алымны өйрәнгәндә ясаган хаталарыбызны шундук күрсәтеп барды. Аз гына булса да алга китеш күрсә, безне юатырлык, үсендереп җибәрерлек сүзләрен кызганмады. Оста көрәшче булуы өстенә ул бик яхшы тәрбияче, педагог, остаз да иде. Күнегүләрдән соң юынып, өсләребезне алышып, «Бауманское» метросына кадәр бергә барабыз да, аннары Мәскәүнең төрле ягына таралышабыз. Безнең һәр көнебез диярлек әнә шулай узды. Гордиенко янына күнегүләргә йөрү безне дуслаштырды, бер төрле-омтылышлар белән яшәргә гадәтләндерде. Безнең бу дус командадан Владимир Яковлев, Юрий Лебедев, Виталий Белоглазов, Евгений Исаев, Анатолий Парфенов, Виктор Антошин, Фәтхулла Хәмидуллин кебек зур көрәшчеләр үсеп чыкты.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ,** *көрәш буенча СССРның спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры:*

—Сашка арабыздагы иң талантлы малайларның берсе иде. Нәрсә генә эшли башламасын, ул гел беренче булырга омтылды. Җиңел атлетикадан, гимнастикада, ату буенча ярышабызмы, ул барыбызны да уза торган иде. Бу төрләрнең һәркайсыннан спорт разряды нормасын үтәде. Һәм ул моңа артык көч түкмичә, җиңел генә ирешә иде кебек. «Хезмәт резервлары»нда ул чакта ике бильярд өстәле бар иде. Күнегүләргә кадәр дә, кайчакларда калып та без еш кына шунда шар суга торган идек. Сафинга анда да тиңнәр табылмады. Аннан соң инде күпме гомер узган, ә шулай да Сашканың бер сугуда ике шарны ике тишеккә кертеп ясаган «штаннары» әле дә күз алдымда тора...

**Виталий БЕЛОГЛАЗОВ,** *көрәш буенча СССРның спорт остасы, цирк артисты, рәссам, Россиянең художество фонды әгъзасы:*

—Бакунин урамындагы залга мин соңрак, 1949 елда барып эләктем. Бу вакытта Андрей Антонович янына йөреп шөгыльләнүчеләр арасында ил чемпионнары Леонид Егоров, Николай Белов, Александр Колмановский кебек танылган батырлар да бар иде. Шулар белән янәшә яшьрәкләр, Андрей Антонович сүзләре белән әйтсәк, «биеклеккә һәм бөеклеккә күтәреләчәк малайлар» да шөгыльләнде. Кеше күплектән кайчакларда келәмдә урын да җитеп бетмәде. Ләкин беребез дә тренерыбызның игътибарыннан читтә калмадык.

«Көрәшче,—дип өйрәтте безне Андрей Антонович,—көндәшен тәне, мускуллары белән тоярга, «күрергә» тиеш. Шул чакта гына ул аның нинди алым кулланасын алдан ук сизеп торачак. Шул чакта гына ул аңа каршы тору юлларын таба алачак...» Бу яктан ул безнең барыбызга да Сафинны үрнәк итеп куйды. Андрей Антонович аның белән чын күңелдән, вакытын да, көчен дә кызганмыйча шөгыльләнде. Мондый тырышлык үзенең җимешләрен дә бирде. Сафин аңа кадәр бер генә көрәшче дә кулланмаган алымнарга кадәр өйрәнде. Белгечләр тарафыннан җиңүгә иң туры юл дип саналганын—көндәшен арка аркылы ыргыту, ул чакта әйтелгәнчә, «бросок через бедро со скрещиванием» дигән алымны да ул беренче булып куллана башлады. Аннары ул «подсадка» дигән алымны бик ныклап үзләштерде, аны җиренә җиткереп башкарырга өйрәнде.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Андрей Антонович көрәш алымнарын әйбәт белүче, кай ягы беләндер бөек педагог Макаренкога охшаганрак кеше иде. Ул безне көрәшне яратырга, аның

бөтен серләренә өйрәтергә тырышты, һәр көнегү кызык, мавыктыргыч булып үткәнлектән, без алдагы көнне көтеп ала торган идек...

Без ач идек. Ярышларга әзерләнгәндә, көрәшкән көннәрдә ашарга талоннар биреп, безнең тамагыбызны туйдырдылар. Командаларга кергәч, әр-яңа спорт киемнәре бирделәр, шуның белән өс-башыбыз рәтләнде. Башка якларга барып йөрү, андагы тормыш белән танышу дөньяга карашыбызны киңәйтте. Һәм без андый тормыштан бик тә разый идек. Хәтеремдә, 1950 елда Ленинградта ярышып, «Хезмәт резервлары» беренчелегендә җиңеп чыккач, Сафинны да, мине дә катыргы чемодан белән бүләкләделәр. Ярышта яулаган значок-жетоннарыбызны күкрәкләребезгә тагып вокзалдагы перронга килеп төшкәндә без үзебезне сугыштан җиңү яулап кайткан фронтовиклар кебек хис иттек. Миңа ул чакта бөтен Мәскәү безгә карап торгандай тоелды.

**Лев ШИРШАКОВ:**

—1950 елның августында Сафин ил күләмендә яшүсмерләр арасында оештырылган ярышларда җиңеп чыкты. Бу уңышын аннан соңгы елда да кабатлады.1951нең февраль ахырында 17-18 яшьлекләр арасында «Хезмәт резервлары» спорт җәмгыяте беренчелегенә оештырылган бәйгедә 67 килограммга кадәрге урта үлчәүдә мәйдан тотты. 1952дә Мәскәү беренчелегендә ярымурта үлчәүдә зурлар арасында җиңде.

**Виталий БЕЛОГЛАЗОВ:**

—Келәмдә ул үзен сәхнәдәге артист кебек тотты. Аның белән көрәшергә чыкканда нинди алым кулланырга җыенуын белеп булмый иде. Менә ул тычкан белән уйнаган песи кебек кулын салмак кына итеп өстән көндәшенең муенына, иңбашларына сала, аның нишләргә теләвен сиземләргә теләп әкрен генә йөри. Тегенең аз гына вакытка сизгерлеген җуюы була, Сафин көтелмәгән җитез алым кулланып, көндәшен кочагына ала. Һәм ул моны шулкадәр тиз, җитез башкара ки, көндәше нинди алымга эләгүен сизми дә кала. Каршы торырга омтылып карый, ләкин, бер яки ике алымны яхшы үзләштергән кайбер оста көрәшчеләрдән аермалы буларак, Сафинның алымнары шулкадәр күп, ул аларны шулкадәр гади һәм тиз башкара ки, көндәшенә келәмгә тәгәрәүдән яки гел сакланып йөрүдән башка чара калмый. Шулай бер алымын төгәлләп өлгергәнче үк башкасына күчүе, һәр хәрәкәтен бик тиз башкаруы белән ул күпләрне, хәтта танылган батырларны да бик кыен хәлдә калдыргалады. Мондый көрәш тамашачыларга бик тә охшый иде һәм күпләр алдагы ярышларны көтеп ала, Сафинның көрәшкәнен карарга дип махсус рәвештә йөри башладылар.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Чибә-ә-әр иде... Кояштай балкып торган йөзендә тирә-якка нур чәчкәндәй ике күз яна. Зифа буй-сын, кыска аяклар—көрәшер өчен туган диярсең... Очарга талпынган бөркетмени—кулларын көндәшенең иңнәренә ерактан китереп сала (ул чагында өстән тотып көрәшә идек)... Келәмгә ул һәрчак чиста киенеп,чәчләренә кадәр ясатып чыкты... Унтугыз яшендә дөньяның булачак чемпионы Шатворянны егуы белән ул бөтен Мәскәүне шаккатырды.

**Рамил КУРАМШИН:**

—Мин моны бер дә кинәт кенә булгандыр димәс идем. Әнинең абыйсы Исхак абый сөйли торган иде. Шәзамның бабасы Зариф абзый Фәхретдиновның биш улы була: Хөсәен, Сафа, Абделхак, Абдулвәли, Абдулла... Барысы да тазалар, чибәрләр... Зифа буйлылар, горурлар... Карлар эреп, җир кибә башлауга кеше күзеннән аулаграк урынны сайлап, шунда көрәшә, бил алыша башлый болар. Сабан туйлары җиткәч тә мәйданда шулар хакимлек итә. Көрәшкә башлап биш туганның иң кечесе Абдулла чыга. Аны ексалар, мәргә өлкәнрәге Абдулвәли керә. Шулай бер-берсен алыштыра-алыштыра көрәшеп, чират иң өлкәннәре Хөсәенгә җитә. Һәм гадәттә җиңүче булып ул кала торган була. Мәрдән (Сабан туе көрәше барган түгәрәкне бездә шулай дип йөртәләр) аны зурлап күтәреп алып чыгалар. Ә инде алай-болай малайларын читтән килгән берәр батыр ега калса, ул чакта көрәшкә әтиләре Зариф чыга һәм җиңү барыбер Фәхретдиннекеләрдә кала торган була...

**Фәймә АБДУЛЛА кызы:**

—Минем әти белән әни дә шул авылдан иделәр. Шуңа да Сафиннар гаиләсе белән еш аралаштылар. Икебезнең дә әтиләребез бер елда—1951дә дөнья куйды. 1952 ел башларында минем абый хәрби хезмәткә киткәндә аны озатышырга Шәзам да килде. Чибәр иде, кара-кучкыл тәнле, карашыннан нур сибелә. Бер-беребездән күзне ала алмадык. Шунда ул: «Син үзеңнең минем өчен үскәнеңне беләсеңме?»—дип бәйләнде генә бит... Ул чакта мин унбиштә генә идем әле. Алай да, туганнар җыелып сөйләшкәч, уртак телне тапканнар. Аерым очракларда унбиштә дә кияүгә чыгарга ярый дип белешмәләр, рөхсәт кәгазьләре җыя-җыя, без шул елда ир белән хатын булып яши башладык..

**Виталий БЕЛОГЛАЗОВ:**

—Ул арада безнең дә кайберләребезгә хәрби хезмәткә чакырылыр чак җитте. Бу кадәр күп яхшы көрәшчене гомер буе «Хезмәт резервлары»нда саклап утырып булмаячагын яхшы аңлаган тренерыбыз Сафинны Владимир Росин, Виктор Антошин, Геннадий Лебедев белән бергә Армия үзәк спорт клубы ЦСКАның штаттагы командасына илтеп урнаштырды, үзе исә безнең калганнарыбызны ияртеп «Динамо»га күчте..

**Георгий ЗВЯГИНЦЕВ,** *көрәш буенча СССРның спорт остасы, СССРның атказанган тренеры:*

—Шәзамның ЦСКАга барып урнашуында хатынының да роле аз булмаганлыгын әйтеп үтәргә кирәк. Аның әтисе Абдулла абый ул чакта бик зур кешенең (үзара сөйләшкәндә без аны Оборона министры Булганин дип тә йөрдек) шоферы булып хезмәт итте. Хәрби хезмәткә Мәскәүгә беркетү белән бер үк вакытта рядовой Сафинга 3 мең сум стипендия дә түләп тордылар. Ә ул елларда бу аз акча түгел иде...

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Хәзерге заман Олимпия уеннарының аңа кадәр ярты гасырлык тарихы булса да, Советлар иле спортчыларының аларда катнашканы юк иде әле. Чөнки баштарак безнең илне халыкара мәйданнарда танырга теләмәделәр. Икенче бөтендөнья сугышында фашизмны җиңеп чыккач кына аңа карата мөнәсәбәт уңай якка үзгәрде. Бу вакытларда инде илдә олимпия хәрәкәте белән кызыксыну туган, анда Советлар иле спортчыларының да катнашу мөмкинлеге өйрәнелә башлаган иде. Безнең илнең Уеннарда 1948 елда ук катнашу мөмкинлеге булган. Тик ул чакта Сталин: «Мин сезне Лондонга ярышырга җибәрсәм, ничәнче урынны алып кайтырсыз?»—дип сораган. «Мөгаен, өченче урынны ала алырбыз»,—дигәннәр аңа. «Юк... Без дөньядагы бөек держава. Иң көчле дошманны җиңгән ил. Без беренче булырга тиеш. Шунсыз барып йөрисе дә юк...»,—дигән юлбашчы. Шуңа да 1952 елда Финляндиядәге Хельсинки каласында узачак 15нче җәйге Олимпия уеннарында беренчелекне алырга дип бөтен ил әзерләнде...

**Виталий БЕЛОГЛАЗОВ:**

—Ул чакта Сафин көрәшкән үлчәү авырлыгында илдә Леонид Егоров хакимлек итте. Советлар Союзы чемпионатларында 1934 елдан көрәшә башлаган, классик көрәштә ун тапкыр беренче, алты мәртәбә икенче булган, алай гына да түгел, ирекле көрәштә дә чыгыш ясап бер әр тапкыр алтын, көмеш һәм бронза медаль яулаган бу бөек шәхес—кырыкнын өсте ягына чыгуына да карамастан, Олимпиадага бару турында хыялланып яшәде. 1951 елнын җәендә ил беренчелегенә Одессада узган ярышта Егоров янә беренчелекне яулады, шунын белән алда торган Олимпия уеннарында катнашырга хыяллануын күрсәтте. Сафин исә бу бәйгене Григорий Гамарниктан да калышып, өченче урында гына төгәлләде. Алай да белгечләрдә әйбәт тәэсир калдырды. Олимпия командасына кемне алырга дип сүз чыккач, тренер Гордиенко Сафинның яшьрәк булуын, әлегә тәҗрибәсе генә җитеп бетмәвен әйтеп, аны тагын да сынап карауларын сорый. Егоров белән көрәштә яшь егет аз гына да югалып калмый, яхшы әзерлекле булуын күрсәтә. Аңа шикләнеп карау чылар исә, башка ил көрәшчеләре белән очрашканы юк дип, һаман каршы килә бирәләр.

**Владимир БЕЛОВ,** *көрәш буенча СССРның спорт остасы, СССРның атказанган тренеры:*

—Уеннарга дүрт ай кала Софиядә Болгария, ГДР, Венгрия, Румыния, Чехословакия, Советлар Союзы вәкилләре катнашында халыкара бәйге узарга тиеш иде. Безнең илдән аңа ике команда җибәрергә булдылар. Җиңел үлчәүдә беренче командага—Егоров, икенчесенә Сафин кертелде...

Халыкара бәйгенең җиңүчесен билгеләр чак житкәч исә беренчелек өчен безнең ике команда очрашырга тиеш булды. Шәзамга шул чакта төп көндәше Леонид Егоров белән көрәшергә туры килде. Икесе дә бер үк остазның шәкертләре. Шушында җиңгәненең олимпия командасына керәсен икесе дә яхшы белделәр. Шуңа да көрәш бик кискен барды һәм әзерлек дәрәҗәсе белән дә, осталыгы, җиңүгә омтылышы белән дә яшь егетнең өстенрәк икәнлеге, аның алда торган иң зур бурычларны да үтәргә өлгереп җиткән оста булуы күренде. Уеннарда кайсысы катнашачак дигән мәсьәлә дә шуның белән хәл ителде. Димәк, Хельсинкига спорт остасы исеме дә булмаган (ул чакта мондый исемне алыр өчен ил чемпионатында беренче-икенче булырга яисә өч ел дәвамында ике тапкыр өченче урынны яуларга кирәк иде) егерме яшьлек Сафин барачак...

**Лев ШИРШАКОВ:**

—Финляндиягә классиклардан Борис Гуревичны, Артем Терянны, Яков Пункинны, Шәзам Сафинны, Семен Марушкинны, Николай Беловны, Шалва Чихладзены, Иоганес Коткасны алдылар.

**Александр МАЗУР,** *грек-рим көрәше буенча дөньяның авыр үлчәүдәге 1955 елгы чемпионы, СССРның атказанган спорт остасы, СССРның атказанган тренеры, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре:*

—Сафинны мин аңа кадәр ишетеп һәм ярышларда күреп белсәм дә, якыннанрак ул Олимпия уеннарына әзерләнүче командага килеп кушылгач таныштым. Егерме яше дә тулмаган, ил чемпионы булырга да өлгермәгән япь-яшь егетнең дөньядагы иң зур спорт ярышына—Олимпия уеннарына әзерләнүче командага алынуы ул чакта күпләрне, шул исәптән минем үземне дә баштарак аптырашта калдырды. Әмма әзерлек чорында аның келәмдәге житезлеген, көндәшләрен бик яхшы тоя белүен, көрәштәге алымнарны яхшы үзләштергән булуын күргәч, аның яхшы көрәш мәктәбен үткәнлеген һәм гомумән көрәшер өчен туган кеше икәнен аңладым. Аның тәнендәге мускуллары бик сизгер иде... Келәмгә чыккач, ул көндәше көтмәгән алымнарны бик оста башкарды. Көндәшләре нинди дә булса бер алымга бара башлауны ул алдан ук ниндидер бер тән сиземләве белән тоеп алып, аларны узып эш итте. Бик катлаулы алымнарны да искиткеч бер җиңеллек белән башкарды.

**Сергей ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ,** *СССРның атказанган тренеры:*

—Совет олимпиячеләре катнаша башлау Уеннар тарихында яңа чорны ачып җибәрде. Ике лагерьга бүленгән дөнья кайсысының көчлерәк икәнлеген ачыклауны тыныч шартларда, спорт мәйданнарындагы көч сынашларында дәвам итте. Совет олимпиячеләреннән иң беренче алтын медальгә 1952 елның 20 июлендә диск ыргытучы Нина Ромашкова (Пономарева) ия булды. Бу төрдә ярышкан кызлардан Елизавета Багрянцева белән Нина Думбадзе көмеш һәм бронза медальләр яуладылар.

**Александр МАЗУР:**

—Классик көрәш осталары «Мессухалли» спорт сараендагы залга җәелгән келәмнәргә 26 июльдә чыктылар. Сигез мең тамашачыга исәпләнгән залда бер генә буш урын да юк. Һәркем үзенең яраткан көрәшчесенә көч өстәргә теләп кычкыра, кулларын бутап ниндидер киңәшләрен бирергә тырыша. 67 килограммга кадәрге җиңел үлчәүдәгеләрдән игътибар үзәгендә, билгеле инде, дүрт ел элек Лондонда узган Уеннарда алтын һәм көмеш медальләр яулаган швед Фрей белән норвегияле Эриксон тордылар. Фрей бу юлы да келәмдә үзен хуҗаларча тотты. Кемгә генә каршы чыкмасын, аны аркандай нык куллары белән кочып алып, ничәмә-ничә еллар буена күнегелгән гадәте буенча үзе аркылы әйләндереп сала барды. Көндәшләре аның бу алымны кулланасын алдан ук белсәләр дә, каршы тору өчен бөтен көчләрен куйсалар да, швед иртәме-соңмы барыбер үзенекенә

иреште, икесен келәмгә чыгуга ук аркаларына салды, өченчесеннән баллар белән өстен булды.

Сафинга беренче көндәшкә төрек пәһлеваны Акбулат туры килде. Шәзам җир йөзендәге иң зур бәйгегә чыга. Югалып калмасмы? Безнең тренерларның, спорт оешмалары җитәкчеләренең бөтен игътибары аңа юнәлгән. Менә ул, зифа буйлы, сылу гәүдәле, беләкләре, кул, аяк, бил мускуллары уйнап торган чибәр егет, келәмгә атлый. Мондый матурлыкка битараф булып кала алмаган тамашачы да аны сокланып күзәтә. Егет исә ашыкмый, беренче минутта ук өстенлеген күрсәтергә теләп көндәшенә ташланмый, аңа һөҗүм итәргә ирек куя. Ә теге, безнең көрәшченең үзенә юл куюыннан канатланып китеп, алга омтыла. Сафинга шул гына кирәк тә, ул көндәшен җайлап кына кочаклап ала да күкрәге аша келәмгә ыргыта. Акбулатның сикереп торып яңадан килеп ябышуы була, янә келәм өстенә барып төшә. Ул да түгел, безнең көрәшче көндәшен аркасы белән келәмгә кыса. Ул кыса, ә тегенең бирешәсе килми, «күперчек»кә яткан да борылып торырга маташа... Мондый хәл шактый озак, берничә минут дәвам итә. Алай да төрек егете астан чыгуның җаен таба. Әмма Сафин моның белән генә тынычланмый, һөҗүм арты һөҗүм оештыра, Акбулатның аягында басып торырлык та хәлен калдырмый. Ул арада очрашуның вакыты бетүне белдереп судья сыбызгысын сызгырта. Келәм белән янәшәдә очколар буенча безнең спортчының җиңүен белдереп кызыл төстәге ут кабына.

Икенче әйләнештә безнең көрәшчегә тагын да көчлерәк көндәш—дүрт ел элек Лондондагы Олимпия уеннарында көмеш медаль алган норвегияле Оге Эриксон туры килде. Сафинның бу юлы башкачарак юлны сайлаганлыгы күренде. Келәмгә чыгуга ук ул дәһшәтле көндәшенә үзен өйрәнеп торырга да ирек бирмичә, аны күтәреп алып аркасына тәгәрәтте. Моны чиста җиңү дип тә бәяли алган булырлар иде, ләкин нindидер бер билгесез татарның дөньядагы иң көчле көрәшчеләрнең берсе булган атлетны болай тиз аркасына салуын танырга теләмәделәрме, судьялар никтер күрмәмешкә салышты. Шәзам исә мондый хәлдә аз гына да югалып калмады, һаман һөҗүм итүендә булды. Көрәшә башлауларына өч минут та үтмәде, көндәшен ул бирәү дә бәхәсләшә алмаслык итеп келәмгә сылап куйды.

**Сергей ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ:**

—Сафинга чын-чынлап менә шул чакта гына игътибар иттеләр бугай. Безнең көрәшче очрашудан-очрашуга ныграк ачыла барып, тамашачыларның гына түгел, көрәш белгечләренең, башка командалар көрәшчеләренең, тренерларының да игътибарын җәлеп итте. Әгәр моңа кадәр залда аңа көч өстәргә теләп кырык-илле татар шаулап, сызгырып, кычкырып утырган булса, инде барысының да игътибары шушы чибәр егеткә күчте.

**Александр МАЗУР:**

—Бу көнне әле Сафинга тагын бер көндәше—данияле Патерсон белән дә очрашырга туры килде. Яңадан да шул ук тактиканы кулланып, көндәшенә сулышын яңартырга да ирек бирмичә, һөҗүм арты һөҗүм оештырып, ул исәпне җиде: нольгә җиткерде.

Аңа кадәр җиңелү ачысын татымаган чех Микулас Атанасов та Сафинга өч кенә минут каршы тора алды. Шуның белән безнең көрәшче финалда көрәшү хокукына ия булды. Анда да җиңгән очракта ул—чемпион, җиңелсә дә үкенерлек түгел, көмеш медаль алачак. Күпләребез ул чакта шулай дип уйлады. Чөнки безнең спортчыга үтә көчле, бик тә тәҗрибәле, дүрт ел элек Лондонда үткән Уеннарда шушы үлчәү авырлыгында җиңгән Густав Фрей белән көрәшергә кирәк иде.

Классик көрәш осталарының финалдагы очрашулары 27 июльгә билгеләнде. Шул ук «Мессухалли» залын тутырган сигез мең тамашачы тарихта моңа кадәр күрелмәгән көрәш карарга әзерләнде. Судьялар башта келәмнәргә иң җиңел, җиңелчә һәм ярымҗиңел үлчәүләрдәге пәһлеваннарны—безнең Борис Гуревич белән италияле Игнацио Фабраны, Яков Пункин белән венгр Имре Поякны, ливанлы Зәкәрия Цихаб белән венгр Имре Ходошны чыгардылар. Бу очрашулар Гуревич белән Пункинга алтын медальләр китерде. Артем Терянның бронза медаль яулавы да уңыш дип бәяләнде.. Алардан соң алып баручы судья чираттагы парны дәште.

—Сафьин Шазам... Совьет Юнион...

Келәмнең кызыл төскә буялган почмагына яшь кенә, әмма таза гәүдәле, зифа буйлы егет чыгып басты.

—Фрей Густав... Шведен...

Яшел төс белән билгеләнгән каршы якта какча гәүдәле, тәнендә бер чеметем дә мае чалымланмаган, гүяки сеңгерләрдән генә торган, келәмдә тәгәри-тәгәри борыннары яньчелеп беткән ир уртасы кеше пәйда булды. Бу үлчәү авырлыгындагы иң көчле көрәшче, «Тимер кеше», «Карт төлке» кушаматлары алган данлыклы Густав Фрей...

Соңрак безнең газеталар, журналлар бу мизгел турында болай дип язарлар: «Көрәш келәменең ике ягында ике батыр—үзләрен һәм физик, һәм рухи яктан тәрбияләгән ике җәмгыять вәкилләре басып тора... Яшел төс белән билгеләнгән якта—швед, капиталистик ил вәкиле... Аңа каршы—кызыл төс белән билгеләнгән якта кызыл флаглы илдән, җир йөзендә яңа җәмгыять корырга алынган Советлар Союзыннан килгән комсомолец егет... Кайсысы җиңә, шул чемпион була, алтын медаль ала, Олимпия педьесталының иң югары басмасына күтәрелә, бөтен дөньяга танылa... алтын медальгә ия була. Шуның белән үз илен, үзен тәрбияләгән халыкны, аның хөкүмәтен, үзе яшәгән мохитне данлый.»

**Александр МАЗУР:**

—Менә аларны уртага чакырдылар. Көрәшчеләр бер-берсен сәламләп һәм хәрәмләшмәскә сүз куешкандай кул биреп күрешәләр... Советлар иле дигән, сугыш хәрабәләреннән арынып кына килүче СССР спортта аларга әле бик үк таныш түгел, Ә Фрейны инде күптәннән ишетеп тә, күреп тә беләләр. Ул алар өчен—җиңелмәс батыр, «Корыч кеше», «Карт төлке»... Менә ул безнең көрәшчене биленнән кочып алып, ике кулы белән «йозакка бикли» дә, янбашы аша әйләндереп сала ... дигәндә ... келәмгә үзе барып төшә. Моңа тамашачылар гына түгел, судьялар да ышанырга теләми. Ләкин телисеңме-теләмисеңме, алым ясалган, ул тиешенчә бәяләнергә тиеш. Сафинга бер балл языла. Көрәшне дәвам итәргә боерып судьяның сыбызгысы яңадан яңгырауга, Фрей көндәшен яңадан да кочагына алырга омтылды. Сафин бу юлы да аның «бросок с прогибом» алымына әзерләнүен тоеп, аңа тагын да якынгарак килде. Һәм көндәше бу юлы да, аны әйләндереп салам дип кискен хәрәкәт ясауга, аякларының ничек келәмнән аерылганын, ничек очып киткәнен сизми дә калды. Безнең көрәшче шведның яраткан алымын әкренрәк ясавыннан файдаланып, аның кулларын һәм гәүдәсен кысып тоткан хәлдә «прогиб» белән аның үзен әйләндереп җибәрде. Башка берәү булса, болай ыргытудан аркасына ук барып төшкән булыр иде. Тәҗрибәсе, осталыгы гына Фрейга һавада очып барган җиреннән бөтерелеп аякларына төшәргә булышты, ул «күперчек»тә калды. Сафин исә яшен тизлеге белән аның өстенә сикерде, торгызмыйча тотып торырга, аркасын келәмгә тидерергә тырышты. Швед мондый кыен хәлдән чыгуның җаен тапса да, ике минут дигәндә ике балл оттырып баруны күз алдына да китерә алмый иде. Һәм ул яңадан да һөҗүмгә ташланды. Ләкин «корыч кеше» ничек кенә тырышмасын, яшь көрәшчегә ачкыч таба алмады. Ул Сафинның көрәшү серенә төшенә алмады... Фрей, атаклы Фрей нинди дә булса алым кулланасы килеп хәрәкәтен башларга да өлгерми, көндәше аның нишләргә теләвен шундук аңлап алып, каршы алым кулланды. Ул да түгел, Сафин яшен тизлеге белән алга ыргылып, көндәшен келәм читенә бәреп чыгарды. Моның өчен тагын бер балл алды. Алты минут узып, партерда көрәшү өчен шобага салгач, беренче ике минутны өстә торырга Фрейга чыкты. Ул инде оттырып баруын сизә иде, шуңа да бөтен тәҗрибәсен файдаланып исәпне үз файдасына үзгәртергә теләде. Ашыга, кабалана башлады. Тик көндәше аның һәр омтылышын алдан ук сизеп, һәрьюлы каршы алым куйды. Алай гына да түгел, аста яткан хәленнән шуып чыгып, шведны келәмгә әйләндереп салды. Шуның белән өстенлеген тагын да ныгытты. Аннары инде үзенә дә көндәше өстенә ятып көрәшергә чират җитте. «Корыч кеше», җиңелеп барганын аңлап, мондый хәлдән чыгу өчен нинди дә булса этлек уйлап чыгарырга маташты. Ул безнең көрәшченең бармакларын кысып тотып, аларны сындырырга, шуның белән көндәшенә җәрәхәт ясап, аны ярыштан чыгарга мәҗбүр итмәкче булды. Келәмдәге судья исә аның мондый әшәкелеген әллә күрмәде, әллә күрмәмешкә салышты, кисәтү ясарга ашыкмады. Сафин аста яткан көндәшен биленнән кочып келәмнән аермакчы була, ләкин теге һаман аның бармагын каера, «йозакка бикләнү»дән чыгуның җаен эзли. Бармак

сеңгеренең үзелергә җитеп шартлаган тавышын, ниһаять, судья да ишетә, ул көрәшне туктатып, шведка кисәтү ясый...

Очрашу тәгәлләнергә өч минут калгач, көрәшчеләрнең икесен дә уртага чакырып, бер-берсенә каршы бастырып куйдылар. Шунда Фрейның бик тә арыганлыгы, көндәше башлаган алымнарга каршы торырлык хәле калмаганлыгы күренде. Ә яшь егет, әйтерсең, келәмгә әле генә чыккан, тукталырга, сулыш яңартырга исәбендә дә юк. Менә ул яшен тизлеге белән алга ыргылып, көндәшен тагын келәм читенә бәреп чыгарды. Моның өчен тагын бер балл алды. Бер минут та үтәргә өлгермәде, шундый ук җитезлек белән тагын һөҗүм итте.

Аннан соңгы минут тынычрак узса да, швед тиз генә аңына килә алмады, Сафин исә, берничә баллга алда барам дип, артык ашыкмады да. Очрашу тәгәлләнеп килгәндә, оттырып баруын сизгән швед янә активлашты. Ул да түгел, тагын нәрсәдер буласын көтеп торгандай, тынлык урнашты. Шуны гына көтеп утыргандай, кемдер бөтен залга ишетелерлек итеп татарча кычкырып җибәрде: «Са-а-л, әйдә!..» Шәзам янә алга омтылды. Ул яңадан да көндәшен кысып кочаклады, аны бөтереп ыргытырга теләде. Бу юлы алым (бросок с прогибом) тагын да кискенрәк ясалды һәм Сафин үзе дә көндәшеннән аерыла алмыйча келәм читенә үк йөгереп чыкты. «Карт төлке» келәмгә тәгәрәде, ә үзе күтәрелергә базмыйча гына яткан җиреннән сөзеп судьяларны күзләде. Тегеләрнең икешәр бармакларын күтәрүләрен күрү аны бөтенләй бетерде. Димәк, совет спортчысы тагын ике балл алган дигән сүз. Шуннан соң ул: «Күпме кеше белән көрәшергә туры килде, әмма Сафин кебек остасын күргәнем булмады», дигән.



**Сергей ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ:**

—Шулай итеп, Сафин белән көрәшүчеләрнең икесе генә аңа унбиш минут буена каршы тора алдылар, калганнарын ул берничә минут эчендә үк биреләрде. Олимпия бәйгесенең финал өлешенә кадәр җиңелүсез килгән чех Атанасов та Сафинга өч кенә минут каршылык күрсәтә алды. Һәм менә ул, яшь, чибәр, бик тә сөйкемле егет, бу залга гына түгел, бөтен Җир шарына диярсең, елмаеп басып тора. Ул—Олимпия уеннары чемпионы, Гомерлек батыр. Аның җиңүе хөрмәтенә залдагы барча кешене аягүрә басарга мәҗбүр итеп күккә кызыл төстәге флаг күтәрелә, барысын да тыңларга мәҗбүр итеп Советлар иле гимны яңгырый...

**Александр МАЗУР:**

—Бу көнне безнекеләрдән 52 килограммга кадәрле иң җиңел үлчәү авырлыгында көрәшкән Борис Гуревич, 62 килограммга кадәрге ярымҗиңел үлчәүдәге Яков Пункин, авыр үлчәүдәге Иоганс Коткас та алтын медальләр яулады. Тагын ике көрәшчебез—87 килограммга кадәрге ярымавыр үлчәүдәге Шалва Чихладзе—көмеш, 79 килограммга кадәрле урта үлчәүдәге Николай Белов бронза медаль алдылар, рәсми булмаган зачетта команда белән дә беренчелекне яуларга зур өлеш керттеләр.

**Сергей ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ:**

—Безнең ил спортчылары, Олимпия уеннарында беренче тапкыр гына катнашуларына да карамастан, Хельсинкидагы ярышларда 22 алтын, 30 көмеш, 19 бронза медаль яулады, командалар арасындагы рәсми булмаган зачетта американлылар кебек үк 494 очко туплап, алар белән беренче-икенче

урыннарны бүлеште. 16шар алтын һәм бронза, 10 көмеш медаль белән өченче урынга чыккан Венгрия командасы алардан 134,5 очкога калышты. Ул чакта һәр медальнең, һәр уңышлы чыгышның илдәге халыкта, милли җанлы кешеләрдә нинди зур шатлык хисләре тудырганлыгын күз алдына китерү кыен түгелдер.

**Александр МАЗУР:**

—«Мессухалли» залындагы келәмдә Сафин җиңеп чыккач, безнең кебек үк нык сөенүчеләр Финляндиядә яшәүче татарлар булды. Аларның ниләр кыланганнарын күз алдына китерсәгез икән. Сашаны алар «Безнең Шәзам, безнең Шәзам!..» дип кулларыннан төшермәделәр.

СССР Министрлар Советы каршындагы физкультура һәм спорт комитетының 1952 ел 28 июльдәге 781нче приказы белән Шәзам Сафа улы Сафинга «СССРның атказанган спорт остасы» исеме бирелде. Журналистлар үзләренең язмаларында аны «Көрәш келәмендәге рыцарь» дип атадылар.

Ил үзенең геройларын олылап каршылады. Олимпия чемпионнарын халыкка күрсәтергә дип хәрби частьларга, завод-фабрикаларга, югары уку йортларына, мәктәпләргә йөрттеләр.

**Рамил КУРАМШИН:**

—Олимпиададан соң, июль азакларында, Шәзам абый Кучкай Пожарына да кайта. Авыл халкы һәм педагогия училищесында укучылар аны Сергач тимер юл вокзалына барып, бик зурлап, тынлы оркестр белән каршылыйлар, училищеда оештырылган очрашуга алып китәләр. Шәзам абый анда үзенең Уеннарга ничек әзерләнүе, Хельсинкида ничек көрәшүе турында тәфсилләп сөйли, сорауларга җавап бирә. Очрашудан соң болын буйлап борыла-борыла аккан Пиана елгасы буена төшәләр.Шунда кыюрак егетләр Олимпия чемпионының җегәрен сынап, аның белән көрәшеп карарга булалар. Әмма Шәзам абый аларны капчык кебек кенә ыргыта бара. Училищеда укытучы бер спорт остасы да көрәшергә чыга. Чемпион аны да бик тиз тәгәрәтә. Шәзам абый үзенең осталыгы белән егетләрне шулкадәр сокландыра ки, каникулдан килгәч, училищеда укучы егетләр көрәш түгәрәге оештырып, шунда шөгыльләнә башлыйлар.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ,** *СССРның спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры:*

—Безнең ил спортчыларының Олимпия уеннарында катнаша башлавы, Хельсинкида яуланган җиңүләр, ирешкән уңышлар халыкта спорт белән кызыксынуны тагын да арттырып җибәрде. Чемпионнарга охшарга тырышып бик күпләр балаларын физкультура-спортка бирде. Мин дә Мәскәүдәге классик көрәш секцияләренең берсенә йөри башладым. Атаклы чемпион белән танышуым да шул елларга туры килә.

Сафин безнең барыбыз өчен дә бик зур кеше, спорт күгендәге иң якты йолдызларның берсе иде. Соңрак физкультура институтында укып, белгечлек үзләштергән елларда мин барлык Олимпия уеннарындагы, дөнья чемпионатларындагы көрәшләрне өйрәндем. Шул чакта узган гасырның илленче елларында Шәзам Сафин кебек матур көрәшүче булмаган икән дигән фикергә килдем. Чынлап та, даһи көрәшче иде ул. Яшь аермабыз җиде генә ел булуга да карамастан, ул минем өчен бөек шәхес булып торды. Бу вакытта әле мин үсмерләр арасында Мәскәү беренчелегендә җиңеп чыккан 14 яшьлек бер малай булсам да, әллә икебез дә татар, алай гына да түгел, әтиләребез чыгышлары белән бер районнан булганга, әллә Трубный мәйданы тирәсендә күршеләр булып яшәгәнгә күрәме, ул миңа бик җылы карады.

**Александр МАЗУР:**

—Ил үзенең геройларын һәрчак зурлап каршылый. Хельсинки геройлары белән дә очрашулар иң югары кимәлдә узды. Андый очрашуларның һәркайсы диярлек табын янында тәгәлләнде...

Уеннардан кайткач, бу көрәшченең моңа кадәр без белми, күрми, сизми йөргән бер йомшак ягы да ачылды.Ул ара-тирә күнегүләрдән читләшеп, салгалый башлады. Мине җыелма командага тренер итеп билгеләгәч, аны бу афәттән коткарырга теләп әнисе, туганнары белән дә очрашкаладым. Алай да әчүдән

туктата алмагач, аны хастаханәгә дәваланырга салырга туры килгән чаклар да булды.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Мин үзем Шәзамны бу тайгак юлга Финляндиядә яшәүче татарлар алып кереп китте дип саныйм. Олимпиадага кадәр без аның кайда да булса, кем белән дә булса эчеп йөргәнен күрмәдек. Ә Хельсинкида җиңеп чыккач, андагы татарларның шул хөрмәткә бөтен дөньяны шаккатырырлык мәҗлес оештырганлыкларын сөйләделәр. Андагы бу начар гадәтне, бигрәк тә спортчыга хас булмаган гадәтне, без Шәзам Олимпия чемпионы булып кайткач сизә башладык. Аңа илнең милли герое итеп карадылар. Аның белән очрашуны, аралашуны, чәй табыны артында бергә сыйланып утыруны һәркем зур дәрәҗәгә санады. Шундый зур игътибар булганда башың әйләнмичә йөреп кара әле. Аның да башы күкләргә тиде. Үзен милли герой, бу дөньядагы иң кадерле кунак итеп тойды ул... Егерме яшьлек егеткә ялгыш юлга кереп китәр өчен күп кирәкмени... Жыелма командада да «Бу тизрәк эчүчелеккә салышсын, командада безгә урын бушар»,—дип уйлаучылар да булмагандыр дип әйтә алмыйм.

**Георгий ЗВЯГИНЦЕВ:**

—Андый кеше хакында табиблар: «Эчәргә ярамый, югыйсә акылын җуя»,—диләр. Сафин аз гына исерткеч капса да бик ярсу кешегә әйләнә иде. Мәскәү хәрби округында бергә хезмәт иткәндә миңа аның белән бергә өйләрендә дә булырга туры килгәләде. Әниләренә бер керүебездә әйбәт кенә ашап-эчеп утырдык та, Шәзам исерде, тавышлана башлады. Энесе Таһир, шундый ук таза, зифа буйлы егет аны җиңел генә күтәреп алып, урынга илтеп салып тынычландырмаган булса, бу очрашу ни белән беткән булыр иде икән...

Акылын җуймаса, берничә елдан соң, урамда сыра эчеп торган җирдә юктан гына бәхәскә кереп китеп, бер отставкадагы полковникның маңгаена сыра кружкасы белән җибәргән, моның өчен хөкемгә тартылган, мактаулы исемнәреннән, ирегеннән мәхрүм ителгән булыр идемени ул...

**Фәймә Абдулла кызы:**

—Кияүгә чыгып, бергә яши башлагач та мин Шәзам әнисенең гаилә мәсьәләсендә үз планнары булганлыгын, улын үзенең ахирәте кызына өйләндерергә хыялланганлыгын белдем. Шәзам бер тапкыр аларга килгәч, әнисе: «Мин сине хатының янына башка җибәрмим»,—дип, ишекләрен бикләп куйган да, улын тәрбияләргә керешкән. Шәзам аннан гөл савыты белән пыяланы бәреп ватып, тәрәзәдән чыгып кына котылган... Аны үз-үзен белештермичә кемгәдер суккан өчен хөкемгә дә тарттылар. Мин ике бала белән берүзем калдым. Тик ирем озак утырмады, амнистиягә эләкте.

Алай да мин аны дуамал кеше булды димәс идем. Ул шаяртырга яратты, тик аны бар кеше дә аңлый алмады...

**Лев ШИРШАКОВ:**

—1952нең октябрь аенда, мәскәүләр Хельсинки геройларының көрәшен карарга дип Ленинград шоссесындагы «Крылья Советов» спорт залына—классик көрәш осталарының башкала беренчелегенә җыелдылар. Күркәм буй-сынлы, чибәр, хатын-кыз булсаң, ике дә уйлап тормыйча гашыйк булырлык ир-ат... Җитмәсә инде дөньяда тиңе юк көрәшче. Үзен дәрәҗәсен бик белеп кенә тота... Шуңа да Шәзамның келәмгә чыгуын алкышлап каршыладылар. Ул чакта аңа үзе белән бергә үскән Афиногенов туры килде. Тамашачы кызык бит ул, әгәр син зур батыр икәнсең, көндәшеңне келәмгә чыгуга ук күтәреп аркасына салырга тиешсең дип уйлый. Шуңа да Олимпия чемпионының Кораллы Көчләр чемпионын очколар буенча гына ота алуыннан бик үк канәгать калмадылар...

**Юрий ДЕННИКОВ,** *халыкара спорт остасы, Советлар Союзының күп тапкырлар чемпионы:*

—Ноябрь аенда Ереванда ил беренчелегенә узган бәйгедә дә шул ук хәл: Сафин анда 67 килограммга кадәрге үлчәү авырлыгында көрәшеп, өч әйләнештә ике штраф баллы җыеп, Леонид Егоров белән Александр Соловьевтан калышып,

чемпионатны өченче урында гына тәгәлләде. Көрәш белгечләре һәм тамашачы Олимпия чемпионыннан, билгеле, инде бу юлы да беренче булуны көткән иде. Тик күпләр, шул исәптән без дә, аның тормышында бик үк матур булмаган үзгәрешләр баруын тойдык. Алай да сайлап алу ярышларында алгы урыннарга чыгуы Сафинга һаман да ил җыелма командасында калырга булышты.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ:**

—Татарның беренче Олимпия чемпионы Яшьләрнең һәм студентларның 1953 елда Бухарестта үткән беренче фестивалендә дә катнашты. Үзенең көчле, яхшы әзерләнеп килгән булуы белән барлык көндәшләрен дә диярлек хәлдән тайдыра-тайдыра тамашачылар арасына озатты. Финалда күптәнге танышы Кук белән очрашты. Ярышларның Румыниядә узуын истә тотсак, бу ил көрәшчесенең үз өендә беренчелекне алып, андагы милли геройга әйләнәсе килүен аңларга була иде. Ул баштарак саклангандай кыланып, җай чыккан саен кинәттән көндәшенә ташланды. Аның мондый активлыгы көрәш карарга җыелган күп санлы румын тамашачылары хуплап алкышладылар. Әмма келәмдәге бәхәсне партерга ятып дәвам итә башлагач, Кукның инде каршы торырлык хәле калмаганлыгы күренде. Ул һәрьюлы тизрәк келәм читенә үрмәләде...

**Лев ШИРШАКОВ:**

—Шул елда «Хезмәт резервлары» спорт җәмгыяте беренчелегенә әзерләнергә дип Днепропетровскига баргач, без зур югалту кичердек. Сафин бу вакытта инде Кораллы Көчләр командасында исәпләнсә дә, тренеры Гордиенкодан аерылмады, аңа булышырмын, үземә дә әйбәт күнегү булыр дип безнең янга килде. Көн бик кызу иде. Күнегүләрдән соң барыбыз да җиңелчә генә арыганлык сиздек. Ә Андрей Антонович, ничектер җайсызрак сикергәч, бөере авыртуга да зарланып алды. Аның хәле торган саен начарлана барды. Безгә тренерыбызны тиз генә Мәскәүгә озатырга туры килде. Ә өч көннән аның вафаты турында хәбәр алдык... Ул безгә алыштыргысыз остаз, әтиебез кебек кеше иде. Илдә аның дәрәҗәсе бик зур булды. Аның белән башка тренерлар да, спорт оешмалары җитәкчеләре дә бик исәпләште. Шәкертләреннән кайсын да булса берәр зур ярышка җибәрү аңа бер дә кыен булмады. һәм менә без һәркайсыбыз үз көнен үзе күрергә тиеш булып калдык.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Бөтенсоюз спорт комитетында ул чакта көрәш белән Вячеслав Петрович Кожарский җитәкчелек итте. Үзе дә келәмдә күп тир түккән спортчы —илнең ике тапкыр чемпионы, Европа чемпионатында бронза медаль яулаган кеше, Шәзам кебек үк атказанган спорт остасы (соңрак—алтмышынчы елларда ил җыелма командасын житәкләп, СССРның атказанган тренеры исемен дә алды) булса да, ул никтер Сафинны яратып бетермәде, җай килгән саен аны җыелма командадан чыгару ягын гына карады. Гордиенко вафат булгач, Шәзамны яклап сүз катучы табылмады.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ:**

—Соңрак мин, моның сәбәпләренә төшенергә теләп, Сафинны да, Кожарскийны да яхшы белгән байтак кешеләр белән очрашып сөйләшкәләдем һәм үземчә мондыйрак нәтиҗә ясадым. Югарыда утыручылар ул чакта да, әле хәзер дә ул ара-тирә сизелгәли, халыкка, шул исәптән спортчыларга да мал көтүе итеп карарга гадәтләнгән. Алар, спортчы җыелма командага алынган икән, анда башкалар кебек үк булырга, барысы да бертөрле әзерләнергә, бер үк кагыйдәләр буенча яшәргә тиеш дип уйлый, барлык спортчыны да бер тарак белән тарарга тырышалар. Сафинның исә, талантлы шәхесләрнең һәркайсы кебек үк, андый кысаларда яшисе килмәгән чаклары да булмагандыр дип уйламыйм.

**Лев ШИРШАКОВ:**

—Минем фикеремчә, Сафин Хельсинкидан соң да элек безнең өчен нинди булса шундый ук булып калды. Ул гомерендә масаюның нәрсә икәнен белмәде. Олимпия чемпионы булып, бөтен Җир шарына танылып кайткач та элеккечә үк зурмы ул, кечкенәме—барлык ярышларда да катнашуын дәвам итте. Бу сүземне раслау

өчен гади генә бер мисал китерәм. Бер уйласаң, бөтен дөньяга танылган кешегә Мәскәүдәге Совет Армиясенең Үзәк йорты беренчелегенә оештырылган ирекле көрәш (әйе ирекле, бу юлы классик көрәш түгел) ярышларында катнашуның нигә кирәге булды икән? Бу бәйгенең дәрәҗәсен күтәрү өченме? Кемнәндер ектырып, аннан соң гомере буена ул кемнеңдер: «Мин Олимпия чемпионын ектым»,—дип мактанып йөрүен ишетергәме? 1954 елның 28 февралендә Сафин андый ярышта да катнашып, ярымурта үлчәүдә 2нче урынга чыкты. ЦДСА башлыгы—генералның аны—рядовойны бүләкләгән 2нче дәрәҗә дипломын ул башка бүләкләре белән бергә гомере буена саклады. Боларның барысы да аның көрәшне ихластан яратуы, аңа гомере буе хезмәт итүе белән бәйле дип уйларга кирәк.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ:**

—Татарның беренче Олимпия чемпионы Студентларның һәм яшьләрнең 1955 елда Варшавада узган 2нче фестивалендә дә катнашты. Шул чакта алар янә Фрей белән очраштылар. «Тимер Густав» инде олыгая башлаган, көрәшүдән туктаган, бай тәҗрибәсен үз илендә үсеп килүче яшьләргә тапшыру белән мәшгуль икән. Сафинны хөрмәт итүен күрсәтеп, ул башлап үзе килеп күрешә, шәкертләре белән аны «Мине җиңгән бөек көрәшче» дип таныштыра. Фестиваль ярышларының монысын аның күптәнге тагын бер көндәше—Хельсинкида, Неапольдә, ике ел элек Бухарестта көрәшкән һәм һәрьюлы җиңелү ачысын татыган Кук та килгән була. Сафин бу юлы да аның күзендә «Тагын сине алып килделәрмени инде? Миңа бу юлы да беренче булырга язмаганмени?» дигән сүзләрне укый. Алар арасындагы көрәш бу юлы да бик киеренке уза. Һәм бу юлы да өстенлек Сафин ягында була. Бу хәлне күргән көндәшләренең берсе чех Матушек, Сафинга каршы чыгуның мәгънәсезлек икәнен аңлап, көрәшүдән бөтенләй баш тарта. Аның каравы Шәзамның Мисыр баһадиры Хөсәен белән көрәшүе бик истә калган. Алты минут уза. Исәп—0:0, Көрәш партерда дәвам итә. Аңа кадәрге елларда безнең көрәшчеләр партерда үзләрен йомшаграк хис иткән булсалар, Сафин чорында бу кимчелектән инде арынылa. Хөсәен дә, ничек кенә өметләнмәсен, партерда Шәзам белән берни дә эшли алмый. Сафин исә үз чиратында аны ике тапкыр әйбәт кенә күтәреп алып, әйләндереп ташлап, җиңүгә ирешә. Чираттагы көндәш—Лехтонен. Шәзам фин белән дә эшне озакка сузмый һәм соңгы көндәше чех Атанасов белән көрәшәсе барын истә тотып, ял итәргә кереп китә. Ләкин бу финал очрашуы булмый кала—Сафинның бу юлы да бик көчле икәнен күргән Атанасов келәмгә чыгып тормый, көрәшмичә генә җиңелүен таный.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Олимпиададан соң Сафиннарның тормыш хәлләре аз гына да яхшырмады. Шәзам йә әнисе янында, йә хатыны белән аның апасы янында унбер квадрат метрлы бүлмәдә яшәп йөрде. Балалары тугач та тормыш шартлары яхшырмады. Аның еш кына атналар буе эчүе, ара-тирә гаиләсеннән китеп, Валя дигән тегүче янында югалып торуы—болар барысы да шул тормышының җайга салынмаганлыгы белән бәйле булгандыр дип уйлыйм. Әмма Фәймә молодец, андый чакта да үзенең бик акыллы хатын булуын күрсәтә алды.

**Фәймә Абдулла кызы:**

—Олимпиячеләрне орденнар-медальләр белән бүләкләгәндә дә Шәзамны никтер читтә калдырдылар. «Атказанган спорт остасы» дигән исем дә Шәзамга артык зур бәхет китермәде. Башта ул таныклыгын югалтты. Аны яңадан сорап архивларда йөргән арада бу мактаулы исеменнән дә мәхрүм иттеләр.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Гаиләсеннән китеп йөрү дә аны аз гына да үзгәртмәде, элек нинди булса, шундый ук булып калды: бер карасаң, чиста итеп киенеп, чәчәк кебек балкып йөрде, икенче караганда тротуарда аунап ятты. Минем үземнең дә аны урамда пычранып ятканда күтәреп өйләренә кертеп куйган чакларым булгалады.

**Фәймә Абдулла кызы:**

—Алай да мин аны өй җанлы кеше дип искә алам. Дуслары белән ярыштан кайтырлар иде дә, гел бездә җыелып утырырлар иде. Бигрәк тә яшьтән үк бергә үскән Виктор Антошин белән дус иделәр. Йә булмаса үзе янына күнегүләргә

йөргән малайларны җыеп кайтыр иде дә: «Әнисе, бу егетләрне тамаклары туйганчы ашат әле бер...»,—ди торган иде. Иң яраткан ашы пилмән булды. Әчә башласа, билгеле, тиз генә туктый белмәде, холыксызланды...

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ:**

—Ул зурдан кубып, матур яшәргә гадәтләнде. Әчә икән, егылганчы эчте, кемгә дә булса ярдәм итәсе килсә, соңгы тиененә кадәр таратты. Даны яңгыраганда, акчасы күп булганда аның янында йөрүчеләр дә күп булды. «Акча исе чыкмый торса», андый «дуслары» таралышып бетә иде. Гаиләсен яшәтергә ярдәм булыр дип, Мәскәүдәге татарлар, аерып әйткәндә, Фәимәнең туганнары, аны үз араларына алдылар. Олимпия чемпионы базарда алтын белән сату итә башлады. Дөрес, аның бу шөгыле артык озакка сузылмады, 1957 елда бөтен илгә шаулаган «Валюта эше» буенча байтак кеше чак кына атарга хөкем ителмичә калды. Акчалы эше беткән көрәшче яңадан да күнегүләргә әйләнеп кайтты. Ул чакта кайбер тренерлар аны инде илнең төп командасына бик үк чакырырга теләмәсәләр дә, Олимпия чемпионы көрәшкә тугрылыгын саклады, нинди генә ярышта чыгыш ясарга туры килмәсен, осталыгы һаман да кимемәвен күрсәтеп, көрәш тамашачысын сокландырды. Аның турында нилар генә сөйләсәләр дә, ул Зур Батыр булып калуын дәвам итте.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Аның турындагы имеш-мимешләрнең ул чакта иге-чиге булмады. Имештер ул Хельсинкида яулаган алтын медален дә сатып эчкән. Имештер ул юләрләр йортына эләккән. һәм башкалар, һәм башкалар... Юк, Сафин алтын медален сатарлык дәрәҗәдә үк түбән тәгәрәмәде. Хәтта бик авыр чакларында да ул хатыны Фәймәнең булышлыгын тойды. Тәнендә мишәр каны уйнаган, Мәскәүдәге нык гаиләдә үскән бу кыз бик авыр чакларында да иренең ныклы таянычы була белде. Шәзамны аякка бастырып, чиста итеп киендереп ул аны Сирень бульварындагы базарга чыгарып бастырса бастырды, әмма югалтмады. Иренә ул кечкенә генә булса да бизнес белән шөгыльләнергә мөмкинлек табып, шуның белән гаиләләрен яшәтте. Атаклы көрәшчене анда күпләр таныды, аның тирәсендә һәрчак халык булды. Ул шулай аралашудан тәм тапты. Дөрес, аннары аның яңадан да кара көннәре башланды.

**Таһир СӘЛӘХЕТДИНОВ:**

—1957 елда Мәскәүдә Студентларның һәм яшьләрнең Знче бөтендөнья фестивале узарга тиеш иде. Бу вакыйгага безнең илдә бик зурдан кубып, Европа, дөнья чемпионатларына җыенган кебек әзерләнделәр. Ул чакта башкаланың үсмерләр командасына кергәнлектән, миңа да көрәш осталарының җыенында булгаларга туры килде һәм анда Сафинның ничек үз-үзен кызганмыйча әзерләнүе әле дә күз алдымда тора. Аңа кадәр—һәм 1нче, һәм 2нче фестивальләрдә җиңү яулаган татар егетенең бу юлы ничек көрәшәсен карарга ул чакта меңнәрчә тамашачы җыелды. Бу юлы инде ул бераз «тазарып», ярымурта үлчәү авырлыгында чыгыш ясады. Алай да келәмдә үзен һаман да хуҗа итеп сизде. Швейцарияле Рене Шардонассны беренче минутта ук матур итеп янбашы аша алып ыргытты. Аннары аны кочаклап «обратный пояс»ка алды, «күперчек»кә ятарга мәҗбүр итте. Һәм селкенергә дә ирек бирмичә 2 минут 58 секунд эчендә бирелдерде. Икенче көнне иртән чех Карел Матоушекны очколар буенча җиңде, ә кичен финалда бик оста көрәшүче Владислав Секадны 3 минут 15 секундта бирелергә мәҗбүр итте.

Шушы җиңүдән соң аның эшләре җайланырга тиеш иде кебек. Ул Россия һәм ил чемпионатларында катнашты, ләкин инде беренче урынга чыга алмады.

**Лев ШИРШАКОВ:**

—Шәзам Сафин көрәшергә дип келәмгә соңгы тапкыр 1956-57 елларда чыкты. РСФСР халыклары спартакиадасында ярымурта үлчәүдә көрәшеп беренчелекне яулады, аннары спорт җәмгыятьләре командалары арасында ил беренчелегенә оештырылган бәйгедә Россия данын яклашып, алтынчы булды... Беренчелекне алмагач, канаты каерылган, рухы сынган кешегә охшап калган иде инде ул.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ:**

—Ул чакта кайбер тренерлар аны инде илнең төп командасына бик үк чакырырга теләмәсәләр дә, Олимпия чемпионы көрәшкә тугрылыгын саклады,

нинди генә ярышта чыгыш ясарга туры килмәсен, осталыгы һаман да кимемәвен күрсәтергә тырышты, көрәш тамашачысын сокландырды. Аның турында ни генә сөйләмәсеннәр, ул Зур Батыр булып калуын дәвам итте.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Спорт оешмалары житәкчеләре аңа яхшырак караган булса, Шәзам, билгеле, көрәш келәменнән алай тиз генә китмәгән булыр иде. Үзенә кешеләрчә караш булса, ышанып әйтәм, ул мондый хәлгә төшмәс иде.

Система шундый иде бит... Кешедән үзенә кирәкне сыгып алгач, аның хаҗәте беткәч, дәүләт кеше турында онытты...

**Фәймә Абдулла кызы:**

—1953 елда ул физкультура техникумын тәмамлаган иде. Ярышларда катнашудан туктагач тренер булып эшләргә җыенды. Көрәшне яхшы аңлыйсың дип 70нче еллардан соң аны еш кына судьялык итәргә дә чакыргаладылар...

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Көрәшеп туктагач, аның башка бер эшкә дә ярамавы күренде. Чөнки ул яшьлегендә көрәштән бүтән башка бернәрсәгә дә өйрәнеп кала алмаган иде. Мин үзем аннан яхшы тренер чыгарга мөмкин дип уйладым, «Урожай» спорт җәмгыятендә эшләгәндә аны үз яныма чакырдым. Миңа ул чакта: «Син нишлисең? Кемне эшкә чакырасың. Ул бит эчә...»,—диючеләр дә булмады түгел, булды. Андыйларга мин: «Аның бер генә тапкыр булса да авылга килеп, андагы халыкка күренүе дә яшьләрне көрәшкә тартачак»,—дип кенә җавап кайтара идем. Сафин бездә биш елга якын тренер булып исәпләнде.. Берара без аның белән Мәскәү өлкәсендәге авылларга, районнарга, кечерәк шәһәрләргә йөреп алдык. Еш кына Раменское районындагы ак балчыктан савыт-саба, уенчыклар ясавы белән бөтен дөньяга мәшһүр Гжель дигән авылга бара идек. Юл ерак—барырга өч сәгать, кайтырга тагын шул кадәр үк вакыт кирәк булса да, ул баштарак бик теләп, матур гына эшләп йөрде, ә аннары, тәненә тегелгән даруының тәэсире беткәч, яңадан эчәргә салышты. Ә эчә башласа, ул бөтенләй башка кешегә әйләнде—дуамалланды, нәрсә сөйләгәнен, нишләгәнен аңламас дәрәҗәгә житте. Югыйсә, эчмәгәндә бик акыллы—барысын да уйлап, тәүфикъ белән яши торган кеше иде. Аның белән сөйләшеп утыруы кызык, ул күп нәрсәләрдән хәбәрдар иде, аның танышлары бик күп булды. Ул Шәрык телләре институтының гарәп телләре факультетында укырга хыялланды, үз халкының милли мәдәнияте белән кызыксынды. Ул хәтта дини кеше дә иде, Аллага ышанды. Шуларның барысы өстенә ул киң күңелле, эчкерсез дус та булды.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ:**

—Шәзам абыйны үзем эшләгән Раменскоедагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенә тренер итеп чакырдым. Чакыруны ул рәхәтләнеп кабул итте. Безгә ул күбрәк яшьләрне көрәш серләренә өйрәтерлек үрнәк буларак кирәк иде. Хельсинкидагы җиңүле көрәшеннән соң ничә еллар узса да, илдәге, дөньядагы спорт мәктәпләрендә әле һаман да аның—егерме яшьлек егетнең атаклы Фрейны җиңүе серләренә төшенеп бетә алмыйлар иде. Спорт мәктәбе җитәкчеләреннән ул әлләни күп акча сорамады, алай гына да түгел, мәктәптә акча бетеп торганда ярышларга барырга үзе биреп торгалады... Дөрес, аны барлык тренерлар да аңлап бетермәде, «Бездән азрак эшләсә дә күбрәк ала»,—дип рәнҗетүдән дә тартынмадылар. Ә ул, «Элегрәк җыелма командада да шулай иде, инде менә монда да» дип үпкәли иде. Бер еллап эшләүгә ул тагын юкка чыкты. Билгеле инде, аны азат иттеләр. Ул бер спорт җәмгыятеннән икенчесенә күчеп йөрергә мәҗбүр булды. Үзе әлләни күп акча да сорамады : «Миңа сезнең хезмәт хакыгыз кирәкми, эштә генә тотыгыз»,—ди торган иде ул.

**Виталий БЕЛОГЛАЗОВ:**

—Ярышларда катнашудан туктауга ук Сафин халык күңеленнән сызып ташланды димәс идем. Аның спорт дөньясындагы батырлыгы үсеп килүче яшь буынга үрнәк итеп куелды. 1957 елның 24 июлендә, Бөтенсоюз физкультурачылар көне уңаеннан «Правда» газетасының 3нче битендә Бөтенсоюз спорт комитеты җитәкчесе Николай Николаевич Романовның «Совет физкультурачылары бәйрәме»

дигән мәкаләсе белән бергә илне данга күмгән бер төркем спортчыларның—төрле милләт вәкилләренең—СССР, Европа, дөнья чемпионнары Арменак Ялтарян, Виктор Чукарин, Галина Шамрай, Владимир Сафронов, Армаис Саядов, Яков Пункин, Олег Караваев белән бергә татар егете Шәзам Сафиннын да фоторәсеме басылып чыкты. Шул елның 5 августында «Комсомольская правда» газетасында дөнья күргән бер язмада Сафинны «Көрәш келәменең рыцаре» дип искә алдылар. Октябрьдә «Красный воин» журналы үзенең «Спортчылар турында хикәяләр»ен шушы бөек көрәшчегә багышлады.

Миндә Ленин орденлы Мәскәү хәрби округының 1979 елның 19 июнендә чыккан «Красный воин» газетасы саклана. Газетаның 4нче битен тутырып, рәсемнәр белән бизәп Сафинның 27 ел элек Хельсинкидагы батырлыгы турында зур язма урнаштырылган. 1970 елда Мәскәүдә чыккан «Олимпийские игры. Маленькая энциклопедия» дигән китапка да ул «Сафин Шазам Сергеевич. 1932 елгы. Хәрби хезмәткәр, атказанган спорт остасы, Мәскәүдән, Армия Үзәк спорт клубы, җиңел үлчәүдә классик көрәш буенча 1952 елгы Олимпия уеннары чемпионы» дип кереп китте. Вафатына бер ел кала, 1984тә дөнья күргән «Справочник. Классическая и вольная борьба»да аның турында болай диелгән: «Сафин Шәзам Сергеевич—7.04.32 ел. Атказанган спорт остасы (1952). Көрәш белән 1947 елда шөгыльләнә башлады. СССР чемпионатларында 6 мәртәбә катнашты. 1950-52 елларда Мәскәүдә, Короллы Көчләр командасында көрәште... 1956-60та—Мәскәү өлкәсе, 1956, 1957дә—«Строитель», 1960та—«Хезмәт резервлары» командалары данын яклады, 1951,1952 елларда бронза медальләр яулады. Халыкара бәйгеләрдә 4 тапкыр (1951,1953,1955,1957) җиңү яулады, 1952 елгы Олимпия уеннарының беренче чемпионы, Дөньяның 1953 елгы чемпионатында 67 килода 3нче урынны алды.»

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—1987 елда СССР Министрлар Советы каршындагы бөтенсоюз физкультура һәм спорт комитетының 50нче еллардагы рәисе Николай Николаевич Романовның «Трудные дороги к Олимпу» дигән китабы дөнья күрде. Көчле оештыручы иде ул, соңрак илдәге профсоюзлар белән дә җитәкчелек итте, безнең беренче Олимпиаданы, аның геройларын искә алганда Сафин турында «бик көчле, талантлы, кыю, куркусыз, үз дигәнендә нык торучан, техник яктан яхшы әзерләнгән көрәшче... ләкин шул ук вакытта тотрыксыз, йомшак холыклы кеше...»,—дип язып чыкты. Бөтен дөньяны хәйран калдырып, ялтырап алу һәм сүнү. Гаепләләр табылмады. Барысы да: «Үзе гаепле» генә диделәр. Әйе, алай диярргә дә буладыр. Ләкин һәр юлы янәшәсендә иптәшләре, тренерлар, спорт оешмалары җитәкчеләре дә булды бит.

**Фәймә Абдулла кызы:**

—Минем ирем кая гына барса да, нәрсә генә эшләсә дә аның хезмәтен һәркайда зурлап билгеләделәр... Тренер буларак та аның даны бик югары йөрде. Күп кенә бүләкләр алды. 1979да башкала командасын СССР халыклары спартакиадасы финалына әзерләшкәне өчен, әйтик, истәлек медале һәм спорт костюмы белән бүләкләделәр. Тик ул бар алган әйберләрен, бигрәк тә киемсалымын, яшь чагында киеп калсыннар, матур булып йөрсеннәр дип, үзе янына күнегүләргә йөргән укучыларга, студентларга таратты...

1995 елның ахырында әнием вафат булды... Егерме көннән, гыйнварның өчесендә каенанам—Шәзамның әнисе дөнья куйды. Икесен дә Тагилевский зиратына җирләдек.

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Шәзам безгә тренерлыкка урнашкач, мин аның турында партиянең Перов район комитетына кереп сөйләшергә булдым. Беренче секретарь Давыдов спортны яхшы белүче кеше булып чыкты.. «Минем илле икенче елда даны бөтен дөньяга шаулаган бу легендар көрәшче белән танышасым килә»,—диде ул. Мин аларны очраштырдым. Шуннан соң бер-ике атна да узмады, Сафиннар гаиләсенә районның иң матур җирендә, Сталеварлар урамындагы йортларның берсеннән бер бүлмәле фатир бирделәр. Алар шул чакта гына кешечә яши башлады. Шәзам яхшылыкның кадерен белә торган кеше булып чыкты. Фатирлары белән котларга килгәч, Фәймә белән алар миңа рәхмәт йөзеннән тун бүләк иттеләр. Аннан соң

да аларда еш булгаларга туры килде. Килгән саен Шәзам мине: «Фәймә, кунак килде. Табын әзерлә...»,—дип каршылый торган иде. Татарча белеп бетермәсәм дә, мин аның «Кил әле., бир әле...»,—дип сөйләгәннәрен әле дә хәтерлим. Кечкенә генә кухняда өстәл тутырып ризык куеп, барлык серләрне уртага салып озаклап сөйләшеп утыра торган идек. Гаиләсенең матурлыгы, кызының, улының тәртипле булып үсеп килүләре—болар барысы да бик сөендерде.

**Фәймә Абдулла кызы:**

—Ул балаларны бик яратты. Без аның белән менә дигән балалар тәрбияләп үстердек. Икесе дә мәктәптә яхшы укыдылар. 1964 елда, мәсәлән, Мәскәүдәге 633нче мәктәп җитәкчелеге һәм укытучылары кызыбыз Эльмираның уку елын уңышлы тәгәлләве уңаеннан балабызга яхшы тәрбия биргән өчен Шәзам белән миңа рәхмәт хаты юлладылар. Мәктәптән соң кызыбыз университет тәмамлап, юрист булды. Уллары тугач, бабалары хөрмәтенә аңа Сафа дип исем куштылар. Димәк, Сафиннар әле егерме беренче гасырда да булачак.

Кече улыбыз Ленар геолог һөнәре үзләштерде, чит илдә эшләп яши. Ленар дигәндә, көрәшчеләрнең Ташкентта узган 1956 елгы Советлар Союзы беренчелеге искә төшә. Җиңүчеләр Австралиянең Мельбурн каласында узасы Олимпия уеннарына барачак. Шәзам да шунда. Байтак вакытлар күрешмичә торганлыктан, ул мине бик сагынып Ташкентка чакырды. Бу вакытта Эльмира әле тугыз айлык кына иде. Без икенче балабызны көттек. Авырлы булуыма да карамастан, җыенып юлга чыктым. Спорт сараенда ярыш бара иде, иремне шунда эзләп таптым. Шәзам минем килүемә бик сөенде. Без янәшәдәге бакчага һава суларга чыктык. Ә эчтәге хәлләр турында радиодан тирә-якка хәбәр таралып тора. Менә бер заман диктор: «Келәмдә Ленар Сәлимуллин»,—дип игълан итте. «Нинди матур исем!»,—дидем мин шул чакта. «Ленар—безнең милләт егете, бик чибәр, Казаннан»,—диде Шәзам. Аннары елмаеп өстәде:—Улыбыз туса, аңа Ленар дип исем кушарбыз, ярыймы?..» Ленар Сәлимуллин ул чакта Мельбурнга барып, Олимпия уеннарында ирекле көрәш буенча алтынчы урынны алып кайтты. Без дә, улыбыз тугач, аңа Ленар дип куштык. «Улым көрәшче булыр» дип хыялланган иде Шәзам.

**Таһир СӘЛАХЕТДИНОВ,** *СССРның спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры:*

—Ленарны мин 12-13 яшьләрендә үзем җитәкләгән төркемгә алдым. Өч ел эчендә ул яшьтәшләре арасында Мәскәү чемпионы булды. Мин аны нык үсәр дип өметләнгән идем. Тик, медицина тикшерүе узгач, анда әнисе ягыннан нәселдән килә торган йөрәк авыруы таптылар. Үсеп килүче яшь кешегә авырлыклар бирүнең файдасы юклыкны барыбыз да яхшы аңладык. Ленар Сафинның көрәш биографиясе шуның белән очланды. Ләкин аңа карап кына Сафиннар белән бәйләныш өзелмәде әле.

1979 елда мине яшь көрәшчеләрем белән Нижневартовскида оештырылган ярышка чакырдылар. Бераз җилләнеп кайтыр, кеше белән аралашыр дип Шәзам абыйны да үзем белән алырга булдым. Мәскәүдәге аэропортта самолет көткәндә ул кайдадыр югалып торды. Әйләнеп килгәч, карасам, күзе пыялаланган... Үзеннән алай ис тә килми юкса. Бу йә нәрсәдер ашаган, йә нинди дә булса дару эчкән дигән фикергә килдем. Түмәндә туктап, башка самолетка күчеп утырганда ул исерек иде инде. Алай да, очкычка керттеләр тагын. Калган юлда мин аңа эчәргә ирек бирмәсәм дә, ул юл буе ниндидер төймәләр ашап барды. «Бавырын бетерә бит бу», дип уйладым мин шул чакта. Барып җиткәндә ул инде басып торырлык хәлдә түгел иде. Ирегеннән мәхрүм ителгәч, шушы аэропортны коруда катнашканлыгын, шуңа да үзен-үзе белештермичә исерүен ул миңа ахырдан гына сөйләде. Ярышта аны Олимпия чемпионы буларак каршы алдылар, зурлап кунак иттеләр, олылап озаттылар. Ул чагында толып кебек озын туннар модага кереп бара иде, Шәзам абый да ике тун алды, аларның берсен миңа бирде. Аның нинди юмарт, риясыз җан икәнлеген мин тагын бер мәртәбә шунда күрдем...

**Лев ШИРШАКОВ:**

—Безнең беренче олимпиячеләрнең, алардан соңгы буын вәкилләренең уңышларын таныган Халыкара Олимпия Комитеты 1980 елгы Уеннарны Мәскәүдә уздырырга булды. Уеннарга бер ел кала, 1979 елда Мәскәүдә СССР халыкларының

7нче җәйге спартакиадасы узды. Аны Олимпиадага генераль репетиция рәвешендә, бик күп көч куеп, зурдан кубып оештырдылар. Бик күп кунак чакырылды. Халыкара көрәш федерациясе президенты Милан Артеган да килде. Шул чакта ул: «Сафинны күрәсем, аның белән танышасым килә»,— дип, үзенең күптәнге хыялын белдерде. Мин аларны очраштырдым. Байтак кына сөйләшеп утырдылар. Шунда Сафин, Артеганның: «Ничек яшисең? Нәрсә белән көн күрәсең?»—дигән соравына каршы: «Берни белән дә көн күрмим, Бер шатлыгым да калмады. Көрәшкән чакларымны искә алып, өйдә значокларыма карап утырам шунда»,—дигән. Артеган аңа бер уч тутырып федерация значокларын бирде...

**Фәймә Абдулла кызы:**

—1982 елда Шәзамга 50 яшь тулды. Дуслары, көрәшчеләр бу вакыйганы бик зурлап билгеләп үттеләр. «Сафин-50» дип яздырып, бик матур истәлек медале ясаттылар. Мәскәү шәһәренең спорт комитеты рәисе А. Ковалев, «Труд» спорт җәмгыяте җитәкчеләре, динамочылар, Зеленоград шәһәрендәге балалар-яшүсмерләрнең олимпия әзерлеге спорт мәктәбе коллективы котлады. Юбилеен ул зурдан кубып, олы бәйрәм кебек итеп «Националь» ресторанында уздырды. Элек бергә көрәшкән, аннары бергә эшләгән бик күп дуслары җыелды. Шунда атказанган спорт остасы Александр Григорьевич Мазур Армия Үзәк спорт клубы ветераннары советы исеменнән «Шәзам Сергеевич, Сез безнең бик зур кеше—беренче Олимпия чемпионы!—дип, бик җылы сүзләр әйтте.

**Лев ШИРШАКОВ,** *халыкара спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры:*

—Сафин ул елларда миңа үзен бер дә начар хис иткәндәй тоелмады. Шуңа да аның үлеме турындагы хәбәр мине бик аптыраш та калдырды.

**Фәймә Абдулла кызы:**

—1985 елда безнең районда яңа спорт залы ачарга җыендылар. Ирем шунда келәм җәеп, көрәшчеләрен җыярга әзерләнде. Беркөнне шуннан кайтты да: «Кулым, ай, кулым», дип зарланды. Бу вакытта мин үзебезнең районда гы санэпидстанциядә эшли идем, аны шундук хастаханәгә алып киттем. Анда баргач, Шәзам табибка: « Күнегүләр вакытында өстемә авыр үлчәүдәге көрәшче төште»,—дигән. Баштарак әтисе туберкулездан үлгәнлектән, улында да бөер туберкулезы булмагае дип, бөере чирле дигән диагноз куйдылар. Дәваланырга салдылар. Ләкин файдасы булмас дип әйттеләр. Ирем чынлап та берничә көн эчендә бик нык ябыкты. Өйгә кайтасы килүен әйткәч, аны ял көннәренә дип чыгарганнар. Ул юл уңаеннан кибеткә кереп ит алган да: «Әнисе, мә, шушыннан пилмән пешереп ашыйк әле»,—диде. Мин итне юып, турап, пешерергә куйган арада алар күрше хатын белән дөнья хәлләре, сәясәт турында сөйләшеп утырдылар. Юынып, ашап йокларга ятканда төнге унберләр иде инде. Иртәнге өчләрдә мин үземә кемдер төрткәндәй уянып киттем. Шаярта торган гадәте бар, ирем уята торгандыр дип уйладым. Баксам... Шәзамның инде җаны юк, ә үзе ...тере кешедәй елмаеп ята. Күршеләрне уяттым... Улыбыз геологлар экспедициясе белән Магаданга киткән иде, ул кайтып житә аламы-юкмы дип хафаланган, башка мәшәкатьләр белән булышкан арада өч көн эчендә 43 килога калдым...

**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ:**

—Йөрәге ярылгандыр дип уйлыйм. Бу дөньядан гөнаһсыз, изге кешеләр генә шулай йокыда килеш китеп баралар.... Сафин вафат булгач, «Советский спорт» газетасы хәтта кайгы уртаклашу хәбәре дә чыгармады. Спорт оешмаларында эшләүче кайбер кешеләр, ә алар күпчелекне тәшкил итте дип саныйм, начарны яхшыдан аера алмадылар, бер агач артында нинди зур урман үсеп торганлыгын күрмәделәр. Алар өчен кеше, бөтен дөньяга танылган шәхес әчкече, мораль яктан таркалган зат булып кына саналды.

**Роза ҖИҺАНШИНА:**

—Абыйны Мәскәүдәге Даниловское дип йөртелгән үзәк мөселман зиратына, әти һәм 1968 елда үлгән туганыбыз Ситдыйк бабай янәшәсенә җирләдек. Чүкеп ясалган чәчәкле тимер рәшәткә эчендә очына ай куелган чардуган тора. Кабер өстендәге ак мәрмәргә Горький өлкәсе Кочка-Пожарка авылы кешесе Зарипов Сафа Фәхретдин

улының 1909 елдан 1951 гә кадәр яшәгәнлеге чокып язылган. Абыйның үзе биеклеге итеп куелган ташына мондый сүзләр уелган: «Заслуженный мастер спорта САФИН ШАЗАМ. 17.1У.1932—1985. 23. III. Помним. Любим. Скорбим. Жена, дети, внуки».




**Яков СТАРОБЫХОВСКИЙ,** *СССРның спорт остасы, Россиянең атказанган тренеры:*

—Сафиннын вафаты хәбәрен ишеткәч, бик күп көрәшчеләр җыелды. Хатыны Фәймә ул чагында: «Без татарларда күмеп кайткач эчеп утыру юк»,—дип табын әзерләмәде. Җиде көннән соң гына җыелып искә алып утырдык. Кайсыбыздыр шунда: «Урыслар өчен Пушкин нинди зур шәхес булса, татарларда—Сафин»,—дип әйтеп салды, һәм мин бу сүзләр белән тулысынча килешәм... Килешмичә мөмкин дә түгел... Зур спортчы ул Зур рәссам, Зур музыкант кебек. Андыйлар йөз елга берәү генә туа... Һәм андыйлар онытылырга тиеш түгел. Татар халкы аны үзенең бөек уллары рәтендә санарга тиеш...

**Александр МАЗУР,** *СССРның атказанган спорт остасы, СССРның атказанган тренеры, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре:*

—Шәзам Сафин Советлар иле көрәшчеләре арасында өченче кеше булып Олимпия уеннары чемпионы исемен яулаган спортчы. Ләкин СССР таралып, Гуревич та, Пункин да Украина милли геройлары булып йөргән, без Шәзам Сафа улы Сафинны Россиянең Олимпия чемпионы исемен алган беренче көрәшчесе дип санарга тиешбездер...

*Шундый бер тормыш менә! Шундый бер язмыш менә!..*

---

## *Алхәбәр. «Казан утлары» — 2009*

Галимҗан
Ибраһимов

### ДОШМАННАР АРАСЫНДА ДҮРТ АЙ

Олуг язучыбыз 1919елның май–август айларында,исемен,төс–кыяфәтен үзгәртеп, йөкче рәвешендә Колчак тылында йөргән. Нинди эшләр майтарган ул анда, ни күргән, ни ишеткән—боларны без аның «үз авызыннан» беләчәкбез.—Әдипнең шул хактагы «хисап докладының кыскасы» (Г. Ибраһимовның үз билгеләмәсе) басылачак.

«...Боларның берсе мәшһүр провокатор Вәгыйз Нәврүзов,икенчесе аксак ишан Корбангалиевтер.

Вәгыйзне Россиядә чагында ике мәртәбә тотып япкан булсак та, ул ничектер котылып колчакстанга барып чыккан. Хәзер гарби армия штабы янында «Ватан» исемендә татарча гәзитә чыгара... Петропавелда бу явызга очрап һәлак була яздым. Гомер бетмәгән икән,язмыш коткарды...»

# КАЗАКЪНЫҢ ШИГЪРИ ПӘЙГАМБӘРЕ

Казакъ халкының күренекле шагыйре Магжан ЖУМАБАЕВ—шигырьләрендә үзе язганча, Кояштан (Көннән) туган бала.

«Инглизләргә—Шекспир, руслар өчен Пушкин нинди булса, Магжан Жумабаев казах халкы өчен шундый ук әһәмияткә ия»,—дип яза академик Алькей Маргулан.

Магжан Бекен улы Жумабаев 1893 елда Петропавел өязенең Полудин волостенда дөньяга килә. Әтисе волость идарәчесе булганга, Магжан шул заман өчен шактый югары белем алуга ирешә. Әүвәл өйдә, аннары мәдрәсәдә укыганнан соң, 1910 елның көзендә Уфадагы танылган «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә. Анда гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә һәм мөгаллиме, киләчәктә мәшһүр язучы булачак Галимҗан Ибраһимовның иң югары бәяләмәсен ала. Нәкъ менә ул Магжанга Омскидагы укытучылар семинариясендә укырга тәкъдим итә. Һәм Магжан, аның киңәшен тотып, 1913 елда әлеге семинариягә укырга керә.



Аның беренче шигырьләр китабы «Шолпан» («Чулпан») 1912 елда Казанда басылып чыга. Магжанга әле унтугызынчы яшь кенә була. Ә инде ул чакта ук Абайның дәвамчысы итеп карыйлар. 1922 һәм 1923 елларда (Казан белән Ташкентта) аның янә ике китабы дөнья күрә.

Магжан Жумабаев шагыйрь генә түгел, күренекле педагог та була. 1922 елда Оренбургта аның «Педагогика» дигән китабы басылып чыга. Рус телен камил белгәнгә, Пушкин, Блок, Цветаева, Ахматова китаплары аның өстәл китабына әйләнә. Ул Гёте белән Гейнены да тәрҗемә итә.

Шул ук елларда аны Ташкентка казакъ-кыргыз мәгърифәт институтына укырга чакыралар. Анда укыткан елларында «Батыр Баян» поэмасын иҗат итә һәм аны җирле журналларда бастырып чыгара.

Соңрак Мәскәүдә, Көнчыгыш хезмәтчәннәренең коммунистик университетында көнчыгыш телләрен укыта. Рус әдипләре әсәрләрен тәрҗемә итә. Казакъ мәктәпләре өчен дәреслекләр яза. Шул ук вакытта үзе дә Әдәбият институтында белем ала.

1927—1929 елларда шагыйрь Петропавелга кайта. Казакъ педагогия техникумында укыта.

1929 елда аны беренче мәртәбә, милләтчелектә гаепләп, кулга алалар. Мәскәү Бутыркасындагы сорау алулар—суд һәм Карелия лагерьларының берсе белән төгәлләнә. 1935 елда М. Горькийга юллаган хатыннан соң, бөек әдип һәм аның хатыны Е. Пешкова ярдәме белән вакытыннан алда азат ителә... 1936-37 елларда ул янәдән Петропавелга кайта, Пушкин исемендәге мәктәптә рус теле һәм әдәбиятын укыта.

1937 елда шагыйрь һәм прозаик Сәкен Сәйфуллин чакыруы буенча Алматыга

килә. Монда аны яңадан кулга алалар һәм 1938 елның мартында атып үтерәләр.

М. Жумабаев Совет Көнчыгышының иң белемле, зыялы мәдәният эшлеклеләренең берсе була. Кыска гына гомерендә гаять зур эшләр башкарып өлгерә. Беренче җыентыгында нәкъ менә ул казакъларны берләштергән Аблай ханның зирәклегенә, акылына мәдхия җырлый.

Магжан Жумбаев—һичшиксез, кабатланмас, якты һәм гаҗәеп талантлы шәхес. Бүгенге көндә Төньяк Казахстан өлкәсендәге бер район аның исемен йөртә. Петропавелда үзәк мәйданнарның берсендә аңа һәйкәл куелган. Педагогика көллияте аның исеме белән аталган.

М. Жумабаевның укучыларыбызга тәкъдим ителә торган бу шигырьләре турыдан-туры казакъ телендәге нөсхәсеннән тәрҗемә ителде.

**Флёра ТАРХАНОВА**

# Магжан Жумабаев

## Пәйгамбәр

*Устремляя наши очи*
*На бледнеющий Восток,*
*Дети скорби, дети ночи,*
*Ждём , не придет ли наш Пророк.*
Д. С. Мережковский.

**Көнбатышны караңгылык каплаган,**
**Кояшы батып, яңа таңы атмаган.**
**Өерелешкән төннән туган пәриләр,**
**Хәтта Тәңресе табаннан тапталган.**

**Көнбатышны караңгылык каплаган,**
**Күгендә юк бер йолдыз да батмаган.**
**Төн баласы, үз Тәңресен үтереп,**
**Табынырлык башка Тәңре тапмаган.**

**Көнбатышны караңгылык каплаган,**
**Бер җан да юк караңгыдан яклаган.**
**Иман дигән нәрсәне һич белмичә,**
**«Карын»[1] дигән сүзне генә ятлаган.**

**Төн баласы. Төн юлына төшкән ул,**
**Сакаусың дип, Муса телен кискән ул.**
**Тәңренең сөекле улы Гайсәнең**
**Уртлап-уртлап кайнар канын эчкән ул.**

**Төн баласы төн япмасын ябынган,**
**Ходайга түгел, газазилгә табынган.**
**Инҗилне сүгеп, таптап изге Коръәнне,**
**Гаделлекне көткән туймас карыннан.**

[1] Карын — ашказаны.

Төн баласы гел бәхәстә таң белән,
Кабил улы авызланган кан белән.
Табына торган хәтта ки бер җанвар да
Булмаган һич бәйле андый җан белән.

Ташымыймы ярларыннан ашкан су,
Үтермиме чәчелеп яткан бу агу?
Төн баласы мең төрлегә төрләнә,
Күзеңне сал—Көнбатышта канлы шу[2].

Күзгә төртсәң, күренмәслек кара төн,
Илерә-көлә котырадыр әллә кем.
Елаучы да, көлүче дә ул иде.
Кем ул? Улмы—төн баласы төссез җен.

Кап-кара төн. Төн баласы күренер,
Күренү белән башкаларга көч бирер.
Сүгенер дә, сөртенер дә егылыр—
Кара төндә сукыр күзләр ни күрер?

Кап-кара төн. Шагыйрь җанын кыйныйдыр,
Кап-кара төн. Кайгы вә кан уйныйдыр.
Кайгы белән кара канга тончыгып,
Төн баласы авыр уйлар уйлыйдыр.

Кап-кара төн. Вакыт авыр үтәдер,
Уй артыннан уйлар килеп китәдер.
Төн баласы, сукыр күздән яшь түгеп,
Көнчыгыштан бер Пәйгамбәр көтәдер.

Ярты көндә була кайчак Төн туган,
Кап-караңгы төн эчендә Көн туган.
Утлы кояш нурларыннан ут алып,
Ут күзле һәм ут җанлы бер Һун[3] туган.

Ярты көндә ут кояштан Һун туган,
Ут күз Һуннан ут күк уйнап мин туган.
Йөземне дә, кысык кара күземне
Туганда ук ялкын белән мин юган.

Бел, бәхетсез, елауның да чиге бар,
Мин—Көн улы, күземдә көн нуры бар.
Мин киләмен, мин киләмен, мин киләм—
Көннән туган, Һуннан туган Пәйгамбәр.

Мескен сукыр, күрмидер шул күрмәс күз.
Көнчыгыштан ал таң килә—инде күр.
Ал таң килә, мин киләмен—Пәйгамбәр,
Көт син мине, «ләхәүлә»ңне укый тор.

Көнчыгыштан таң киләдер—мин киләм,
Күкләр күкри: мин дә күктәй күкримен.
Җирнең йөзен караңгылык каплаган,
Җир йөзенә нур бирәмен, Көн бирәм!

[2] Шу—тамаша (шау-шу).
[3] Һун—төркиләрнең элгәрләре.

Кап-кара төн. Кайгы иңгән җир җыры,
Кап-кара төн. Үкерәдер төн улы.
Көнчыгышта ак алтын бер сызык бар:
Мин киләмен, мин Пәйгамбәр—Көн улы.

## Ут

Көннән[1] туган баламын,
Ялкынланып янамын.
Тик Кояшка багынам.
Үзем—Кояш, үзем—ут,
Сүздә, кысык күздә—ут.
Үземә үзем табынам.
Җирдә тик бер Тәңре—ут,
Уттан башка Тәңре юк.

Ялкыны назлап сөя,
Сөйгән һәрнәрсә көя.
Көлеп узган «юргалар»
Очраганны шок кылыр,
Шок кылыр да юк кылыр,
Моның исеме ут булыр.
Мин дә утмын, мин янам,
Ут Тәңремә табынам.

Комач уты асманның
Төссез итә башканы,
Ялкынын йотам—көч тоям.
Әүлиям, иям, котыма,
Тиңсез Тәңрем—утыма
Тамчы-тамчы май коям.
Май коямын—дөрлидер,
Колачы күккә үрлидер.

Кайчак елан сихерли,
Аждаһа кайчак йота—
Шулар куркуда тота.
Юкса мин үзем дә ут,
Кысык кара күзем дә ут.
Мин—уттанмын, ут—миннән,
Ялкынмын мин—янамын,
Уттан туган баламын.

Караңгылык качканда,
Кызарып таң атканда,
Көн утыннан туганмын;
Йөрәгемне, җанымны,
Иманым, вөҗданымны
Ялкын белән юганмын.
Йөрәгем, җаным да ут,
Иманым, саным да ут.

Кызу булып туганга,
Аң-белемле булганга,
Караңгылык—дошманым.
Шул явызны басарга,
Сукыр күзен ачарга
Күп кат уктай очканмын:
Әлпигә[2] бардым Алтайдан,
Балканга бардым Кытайдан...

Очып менеп асманга,
Әлпидән ары ашкан да
Утлы Атилла, Баламер
Мин идем. Тагы барганда
Үлем салып Балканга—
Юлбарыс Жучи, Сүбәдәй ир.
Җиңелмәс җирләр аз калып,
Басылдым бераз ут алып...

Үтә кыргый тел килде,
Көнбатыштан җил килде,
Караңгылык каплады.
Оят әсәре калмады,
Идеалны—Алланы
Туймас карын таптады.
Кояшым, дөрләп яна күр,
Көнбатышка бара күр!

Инде дөрләп янасың,
Көнбатышка барасың—
Барын үзең карарсың.
Караңгы таш каласын,
Ялмауыз[3] явыз баласын
Ялкын ялап сөйгәчтен,
Ни калыр соң каладан,
Ялмауыз явыз баладан?!

Көннән туган баламын,
Ялкынланып янамын,
Тик Кояшка багынам.
Үзем—Кояш, үзем—ут,
Сүзем, кысык күзем—ут,
Үземә үзем табынам.
Җирдә тик бер Тәңре—ут,
Уттан башка Тәңре юк.

---

[1] Көн—бу очракта Кояш.
[2] Әлпигә—Альп таулары.
[3] Ялмауыз—гуҗ,туймас җан.

## Хатын

Гаеп эш кылып Тәңрегә,
Каршы килеп әмеренә,
Куылды адәм оҗмахтан.
«Кайт,—дигән,—кара җиреңә,
Бишегеңә, гүреңә!»
Боерык килде шул хакта.

Батмас якты көне юк,
Фәрештәләр өне[1] юк.
Тирә-юньдә тып-тыныч.
Үтмәслек биек тавы бар,
Исәпсез төрле явы бар—
Караңгы гүрдәй куркыныч.

Җиргә төште ялангач,
Җанда—хәсрәт, күздә—яшь.
«Ярлыка!»,—дип сорады.
Курыктымы җәзадан,
Алда күрәчәк казадан—
Зар булды, нык елады.

Җирдә ялгыз зарыгып,
Күктәге оҗмахны сагынып,
Елады үксеп, шешенеп.
Бер үк көндә яраткан,
Ут дәрья булып аккан
Ачты рәхмәт ишеген.

Оҗмахның йомшак җиленең,
Мәңге сулмас гөленең
Хуш исләрен аңкытып,
Көмеш кәүсәр суыннан,
Сунын алтын буыннан
Битендә нурлар балкытып,

Күкнең батмас көненнән,
Фәрештәләр өненнән,
Хур кызлары җырыннан,
Үз нурыннан нур бүлеп,
Хисси, назлы җан биреп,
Сөю, рәхмәт күленнән—

Яратты Тәңре хатынны
Куылган адәм—колына,
Бассын диеп бар җирдә
Тугърылык, ышаныч юлына.
«Адашмассың, азмассың,
Туры юлдан язмассың—
Ир бул,—диеп,—соңыннан.

Оҗмахтан ерак киттем, дип,
Зур гөнаһка җиттем, дип,
Елама зар-зар, кайгырма!
Юлбаштан үрнәк алсаң,
Күңлеңне акка мансаң,
Оҗмах килер тагын да!»

Үтте заман. Яшь кипте.
Курку вә хәтер китте,
Онытты адәм Алласын.
Күзьяшькә ялган тулып,
Явызлык максат булып,
Җир йоттымы вәгъдәсен?

Кичәге хатын-фәрештә
Адәмне чөйде гарешкә.
Йөзе ак якты айдан,—
Елап туйгач, гәп сатып,
Иркендә уйнап ятып,
Булып калды бер хайван.

Йөзенең күптән күрке юк,
Күргәне хурлык, ирке юк.
Зардан тора бар өне—
Моны исеңә уймасаң,
Хатын бән[2] өзми уйнасаң,
Озакка бармас ил-көнең!

*Казакъчадан* **Флёра ТАРХАНОВА** *тәрҗемәләре.*

---

[1] Өн – тавыш, аваз.
[2] Бән – белән.



Индүс Таһиров

# СӨТ КАЛСА, ВАТАН КАЙТЫР

## Кайсысы газизрәк: ватанмы, кавемме?

Бу сорауны затлы шагыйребез Дәрдемәнд куйган, һәм үзе үк аңа җавап та биргән.

*Ни газизрәк—бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз!*
*Ул мөкатдәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!..*
*Сөт калыр, ватан китәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!*

Дәрдемәнднең бу чагыштыруы бер караганда урынсызрак кебек тә тоела. Ләкин бер караганда гына. Чөнки Дәрдемәнд «бу ватан» дип үзе яшәгән рус империясен күз алдында тоткан. Аңа ул газиз түгел. Чөнки анда татарлар, Мәҗит Гафури язганча, һәрвакыт үги бала була килгәннәр. Анда шагыйрьнең «туган кауем»е гасырлар буе нужа чиккән, иксез-чиксез кан-яшь түккән. Әйе, шагыйрьгә бу ватанга караганда милләте күпкә якын.

Дәрдемәдне бер вакыт пессимистик шагыйрь дип билгели торганнар иде. Ә дөреслектә исә ул күпләргә карата оптимистрак булган. Ул шушы шигъри сүзләр аша рус империясенең бетүен көрәзәләгән һәм татарның мәңгелегенә дан җырлаган. Ул татарның югалган ватанын сагынып һәм яратып яшәгән. Аның өчен дастаннарда дан җырланган Идел-йорт газиздән газиз булган.

*Әй Идел-йорт, Идел-йорт!*
*Идел буе имин йорт!*
*Атам кияү булган йорт—*
*Иелеп тәгъзим кылган йорт.*
*Анам килен булган йорт...*

Татарның дастаннардагы Идел-йортын аякка бастыра алуына нык ышанып яшәгән Дәрдемәнд. Чыннан да, 1917 елны империянең сәгате суга. Тик большевиклар гына, ялган федерация төзеп, аның гомерен тагын җитмеш

Индүс ТАҺИРОВ (1936)–*тарихчы, ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы, җәмәгать эшлеклесе; «Татарстан һәм татар халкы тарихына караган очерклар», «Татарстан һәм татар халкы милли дәүләтчелеге тарихы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

елга озайталар. Әгәр ул шул елны ук юкка чыккан булса, русларның үзләре өчен дә күпкә хәерлерәк булган булыр иде. Чөнки ул заман әле илнең демократия юлына басу мөмкинлеге бүгенгегә караганда күпкә артыграк иде. Шуның өчен дә татарлар җаннары-тәннәре белән шушы мөмкинлекне тормышка ашырырга тырыштылар. 1917 елның май аенда булып үткән Мөселман съездында Нижгар мулласы Габдулла Сөләйманинең Россияне штатлар нигезендә демократик федератив дәүләт итеп корып, шул штатларның берсен татарныкы итү тәкъдиме шушы хакыйкатьне раслый. Идел-Урал штатының тамыры әнә шуннан башлана, хөрмәтле укучыларым!

Әгәр дә большевистик революция җиңмәстән, Учредительный собрание җыелган булса, Россиянең шул вакытта ук федератив нигездә корылган демократик дәүләткә әверелүсе шиксез иде. Коточкыч хәвефле еллар, дистәләгән миллион кешенең гомерен өзгән репрессияләр дә булмас иде.

Бу кеше тарихчы башы белән нигә инде була алмый калган эшләр турында сөйли, дияр кемнәрдер. Чыннан да, буласы булган бит инде. Боларны һичничек тә үзгәртә алмыйсың.

Тик—сөйләргә кирәк, чөнки тарихи хәтер дигән төшенчә бар. Ул әнә шул Дәрдемәнд язган мөкатдәс кан белән сугарылган изге сөттә саклана. «Изге сөткә ни җитә?» Бу сөттә буыннан-буынга күчә килгән татар каны, шул канга сеңгән татар рухы, аның җыр-моңы, барысы да шунда. Менә ул ни өчен изге.

Заманында төркиләр, шул исәптән татарлар да бихисап дәүләтләр төзегәннәр. Төрки каганатлар, һуннар империясе, Болгар, Алтын Урда, аннан соңгы татар ханлыклары—болар барысы да татар канына үз тамгаларын сала барганнар. Тарихи хәтер әнә шунда ята. Әнә шул хәтердә саклана торган милли моң үзе генә дә ни тора! Борынгы төрки заманда ук барлыкка килеп, меңәр еллар дәверендә чарланган зиннәтебез ул безнең. Аңа һәр буын үз өлешен өстәп, баета килгән. Бу моңга халкыбызның бөтен тарихы сеңгән. Дөньяны шаулатып-гөрләтеп яшәгән шанлы чорлары да, авырдан авыр, коллык михнәтендә иза чиккән гасырлары да, монда барысы да бар. Зәки Вәлиди татарлар шушы моңның варислары, алар аны саклап калганнар дип бик дөрес язган.

Татарлар, күрәсең, моңнан яралгандыр. Ул моң, күрәсең, төркиләр яшәгән Алтай гүзәллегеннән, татарны татар иткән дала киңлекләреннән барлыкка килеп, аның канына сеңгәндер. Шунлыктандыр инде аның дөньяны таң калдырырдай көче бар. Юкка гына кытайлар безнең музыкабызны үз итмәгәннәрдер. Һәм аны Ерак Көнчыгыш халыкларына, шул исәптән Япониягә кадәр үк илтеп җиткермәгәннәрдер. Беренче төрки аваз да шул моңнан барлыкка килеп, телебезне тел итүгә өлешен керткәндер.

Татар гаиләләре өчен телебез һәрвакыт газиз һәм мөкатдәс була килгән. Ул балага бишектә үк сеңдерелгән. Гаилә баланың телен баета, аны яшәү коралына әверелдерә. Моның шулай булырга тиешлегенең төп шарты—ата-ананың балалары белән бары аларның туган телләрендә генә аралашуы. Әгәр ата-ана үзара рус яки башка телдә аралаша икән, аларның балалары да шул телгә күнегә. Аларга тумыштан бирелгән тел ачылмый кала, онытыла.

Телебездә тарихыбызның бөеклеге чагыла. Аңа төркиләрнең дөньяны таң калдырган чорлары сеңгән. Әгәр дә мәгълүм рус сәяхәтчесе Афанасий Никитин аны белмәгән булса, Һиндстанга барып җитә алмас иде. Барып җитсә дә, исән-имин кайтуы бик тә шикле. Ул үткән җирләрдә, хәтта Һиндстанның үзендә дә мең ел дәверендә төрки тел хакимлек иткән. Әбу Гали ибне Синә, Гомәр Хәйәм кебек бөек шәхесләр төрки патша Газнавилар сараенда иҗат иткәннәр. Афанасий Никитин сәяхәтен юкка гына Йосыф исеме белән кылмаган, һәм үзенең «Хождение за три моря» исемендәге әсәренең шактый урыннарының татар җөмләләре белән бизәлүе дә тикмәгә түгел. Укучылары шушы телне белмәсә, ул аларны әсәренә керткән булыр идеме? Юк, әлбәттә.

Татар теле дөньяның ундүрт теле арасына кертелү очраклы хәл түгел, хөрмәтле укучыларым! Менә ул татар сөте. Бу хәтта сөт кенә дә түгел. Бу—куе каймак!

Европа язучылары, алар артыннан рус галимнәре дә төркиләрне кыргыйлар рәвешендә күрсәтә килделәр. Һәм, ни кызганыч, бу гамәл әле дә булса дәвам итә. Имештер алар урак урмаганнар, игеи икмәгәннәр, башкаларны талап кына яшәгәннәр. Алай булгач, ни өчен барлык төрки халыкларда да бодай, тары һәм башка бөртекле культураларның исемнәре бер төсле яңгырый икән? Югыйсә аларның бер-берсеннән аерым яши башлаганнарына инде мең еллар үтте. Димәк,

алар Төрки каганатлар чорыннан башлап ук, хәтта аннан да алдарак чорларда да иген иккәннәр. Алай гына да түгел, бакчачылык белән дә шөгыльләнгәннәр. Рус һәм башка славян телләрендәге кавын, карбыз кебек сүзләр безнең телебездән күчкән. Димәк, алар бу культураларны үстерү һөнәренә безнекеләрдән өйрәнгәннәр.

Америкада чыккан бер журналда, Европаны кәбестә тозларга һуннар өйрәткән, дип язылган. Шулайдыр. Тик алай гына да түгел. Чөнки аны тозларга өйрәнгәнче үстерә белергә дә кирәк. Белоруссия президенты Александр Лукашенко үзе белән бер очрашу вакытында республикаларында яши торган татарларның яз җитүгә базарга беренчеләрдән булып яшелчә чыгара башлаганлыкларын әйтеп, бу һөнәрдә аларны уздыра алучылар юк икәнлеген ассызыклаган иде.

Барлык төрки халыкларда да үлчәм һәм саннарның әйтелеше бер төрле яңгырый. Моның сәбәбе аларның борын заманнардан бирле үлчәмле тормыш белән яшәгәнлекләрен раслый. Халык санын алуны алар башлап җибәргән, һәр кешенең саны булган борынгы бабалар заманында, һәрбер кешенең кадере булган. Русларның күренекле кешеләрен сановник дип атаулары да шул «сан» сүзеннән булса кирәк. Алар үзләренең санлы, абруйлы кешеләрен шулай дип атаганнар.

Болар барысы да, хөрмәтле укучыларым, милләтебезнең төп сыйфат билгеләмәләре. Бу—чын татарлык, миллилек.

Әгәр дә сөт бернигә дә карамастан, әчемәстән, куера барса, ватан була. Ул хәтта, киткән булса да, яңадан кайта. Без татарлар гасырлар дәверендә инде берничә ватан югалттык. Ә сөтебез, Аллага шөкер, кала килде. Телебезне, моңыбызны, гореф-гадәтләребезне саклый килдек. Рухыбызны беркем дә сындыра алмады. 1870 елны чыккан китапларның берсендә, татарлар безгә [русларга—И. Т.] рухи яктан түгел, тик сәяси рәвештә генә буйсындылар, диелгән. Ефимий Малов исемле бер миссионер 1911 елгы көндәлегендә «алар инде ничәмә йөз еллар буе безнең белән яшәсәләр дә, без аларны руслаштыра алмадык. Тагын ничә йөз ел көтәргә кирәк булыр икән», дип уфтанып язган. Бу сорауга русча җавап биреп була: «не дождетесь!» Әйе, күпме көтсәгез дә, көтеп җиткерә алмассыз! Безнең җегәребез җитәрлек, безгә Аллаһы Тәгалә иксез-чиксез яшәү көче биргән. Дәрт тә, дәрман да җитәрлек бездә.

## Безгә өмет чаткысы керде, дәрт һәм дәрман барлыкка килде

Без тарихның зур бер борылышы чорында яшибез. Ул 1917 елдан бүгенге көнгә кадәр дәвам итә торган чор. Бик күп мөмкинлекләр юкка чыккан чор бу. Аларның иң әһәмиятлеләреннән берсе—демократик альтернативаның ычкынуы. Чөнки нәкъ шуның нәтиҗәсендә илдә большевистик тоталитар режим урнаша.

Тик менә бер генә тарихи вакыйгага да берьяклы гына караш булырга тиеш түгел. 1905—1917 еллар—халкыбызда зур өметләр тудырган, татарны йокысыннан уятып, аны тарихи мәйданга алып чыккан еллар.

Шул зилзилә елларына бәя биргәндә, моның халкыбыз өчен булган кайбер уңай якларын әйтеп үтми мөмкин түгел. Аларның берсе—1920 елның 27 маенда барлыкка килгән Татарстан автономияле республикасы. Әгәр дә безгә шул вакытта кечкенә генә бер мәйданчыкта булыр-булмас хокуклар белән генә булса да җир бүлеп бирелмәсә, без бүген үз ватаныбызны гамәлгә ашыру мөмкинлегеннән бик ерак торыр идек. Мин булыр-булмас хокук дип әйтәм, чөнки ул вакытта да һәм бүген дә Мәскәү татарларга чын дәүләтчелек бирергә җыенмады һәм җыенмый да. Гомумән, татарларга гына түгел, башка халыкларга да.

Марксистлар миллилеккә һәм шуңа бәйле федерациягә һәрвакыт тискәре караштa булалар. Россия марксистлары республикалар төзүне вакытлы, котылгысыз бер чара гына, Россиянең бөтенлеген һәм бүленмәслеген саклау гамәле итеп кенә күргәннәр. 1922 елда Сталин Ленинга язган бер хатында, бу «бәйсезлек уеннарын» туктатырга вакыт, дигән. Ленин бу тәкъдимгә каршы булмаган. Тик ул хәзердән үк бу юлга басуны иртәрәк дип санаган, моны акрынлап, сиздермәстән, беркемне дә куркытмастан башкаруны кулайрак күргән. Сталин исә Ленин үлгәннән соң авызлыксызланды, ашыгыч рәвештә унитар дәүләт төзү юлына басты.

Үткән гасырның егерменче елларында ук республикаларны гадәти

административ берәмлекләргә әверелдерү эше башлана. СССРның 1936 елгы һәм Россиянең 1937 елгы Конституцияләре нигезендә Татарстан бөтенләе белән дәүләти хокуклардан мәхрүм ителә. Союздаш республикалар хокукы даулаган Татарстан һәм Башкортстанга шушы «халыклар юлбашчысы», им этого «не видать как своих ушей», ди. Хәер, союздаш республикаларның да хокуклары елдан ел кими барды.

Шулай итеп, СССР дөнья мәйданына ялган федерация рәвешендә чыга. Андагы республикалар алдакчыл курчак дәүләтләр булып кына яши килделәр. Мәрхүм, репрессия корбаны Мирсәет Солтангалиев шул вакытта ук, СССР кыяфәтендә сәяси мәйданга чыккан Россиянең гомере озын булмас, ул тиздән таркалыр, дип язган иде. Чыннан да, Россия, бик тиздән булмаса да, таркалды. Моның сәбәбе—илдәге ирексезлек. Кеше ирексезлеге, халыклар ирексезлеге.

Җитмеш ел эчендә СССР республикалары гадәти административ берәмлекләр генә булып калдылар. Хәтта союздаш республикалар да хокуксызлыкларыннан зарлана килделәр. Балтыйк буе республикасында яшәгән бер галим, 1998 елны Рига шәһәрендәге үткән «түгәрәк өстәл» вакытында, «республикаларның ичмасам АКШ штатларындагы хокуклары гына булса да, бездәге федератив мөнәсәбәтләр бөтенләй башка булыр иде», дип зарланды.

Ил капкасын федерация 1922 елдан бирле кага килде. Ләкин ил җитәкчеләре бу капканы ачарга теләмәделәр. Киресенчә, аңа яңадан яңа йозаклар элделәр. 1998 ел СССРны саклап калуның соңгы мөмкинлеге иде. Тик Горбачев моны аңлардай кеше түгел иде. Аңа сәяси акыл да, сәяси тәвәккәллек тә җитмәде. СССР кояшка чыгарган боздай эреде, юк булды. Әйе, тарихны алдап булмый. Аның үзен алдарга тырышучыларны куып тотып, артларына тибә торган гадәте бар.

Татарстан СССРның таркалуын теләмәде. Ул 1922 елдан башлап ук аның чын федератив дәүләткә әверелүен алга сөрә килде, һәм аның составына тулы хокуклы республика булып керүне максат итеп куйды. 1990 елның 30 ˆавгустында кабул ителгән Декларация моңа ышанычлы дәлил. Анда республикабыз берни составында да итеп күрсәтелмәгән. Ул СССРда да түгел, Россиядә дә түгел. Чөнки ул әле СССРга мөстәкыйль рәвештә алынмаган. Ул моңа омтыла гына. Россия белән исә ике яклы шартнамә нигезендә яшәүне максат итә. Бу Декларациядә аермачык итеп язылган, һәм шунлыктан ул, чын-чыннан бәйсезлек документы буларак, бүген дә көчен җуймаган. Алай гына да түгел, аның төп принциплары 1992 елның 21 мартында үткәрелгән бөтен халык референдумы аша ныгытылды. Ә Россия белән ике яклы шартнамә төзелде. Безнең арттан ияреп, Россиянең кырыктан артык төбәге Үзәк белән шартнамә нигезендә яшәү юлына басты. Шуның белән Татарстан Россияне федератив рельсларга бастыра алды. Бу елларны татар татарлыгын күрсәтте. Татарстаныбызны ул чакта юкка гына горур республика дип атамадылар. Чөнки ул башкалар өчен үрнәк була алды. Хәттә Косово статусын билгеләгән вакытта да шул хакта сөйләшүчеләр өстәлендә Татарстан белән Россия арасындагы шартнамә яткан.

Ә бит бу очраклы хәл түгел. Бу эшләрне халык башкарды. Ул мәйданнарга җыелып, республика җитәкчелеген яклап чыкты. Күп милләттәшләребез бәйсезлек даулап ачлык игълан итте. Әйе, президентыбызны халык һәрвакыт яклый килде. Шахрай кебекләр теш кайраганда да, Хасбулатовлар тимер читлеккә бикләп Мәскәүгә алып китү белән янаганда да халык аны дәррәү яклап чыкты. Аңа «камыр булма, тимер бул!», дип көч, куәт, дәрт һәм дәрман өстәп торды, һәм Шәймиев чыннан да тимер булды.

Тик менә аз гына ныгып алу белән, бигрәк тә Ельцин хакимияттән читләштерелгәннән соң, империалистик көчләр республикаларга, аларның хокукларына һөҗүм ачтылар. Кабул ителгән Конституциябез, законнарыбыз федераль Конституция һәм законнар белән тәңгәлләштерелде. Латин графикасына кайту юлыбыз бикләнде. Инде телебезгә, тарихыбызга каршы дау башланды. Республикабызның укыту стандартларындагы милли компонентка кизәнү нәкъ шул турыда сөйли.

Милли компонент ни-нәрсә? Ул—күп милләтле дәүләттә милли яшәү рәвеше. Безнең өчен бу—татар булып яшәү рәвеше. Ул безнең көндәлек тормышыбызда, гаиләбездә, дусларыбыз белән аралашканда, җырлый торган җырларыбызда һәм башка яшәү гамәлләребездә чагылыш таба. Ул балага бишек җырлары, әби әкиятләре белән сеңдерелә башлый, һәм инде мәктәпкә кадәр килеп җитә. Уку стандартындагы өстәмә—аның тик бер, ләкин бик тә әһәмиятле өлеше. Шунлыктан

бу компонент өчен көрәшне без татарлыгыбызны саклау көрәш итеп күрәбез. Бу шартларда да Шәймиев беренче адымны үзе атлады. «Кайберәүләргә, күрәсең, милли телләрне бетерү процессы бик акрын бара кебек тоеладыр»,—диде ул Россия Фән һәм мәгариф министрлыгының шушы мәсьәләгә багышланган Казандагы утырышында. «Без, дип әйтте ул, Россия министры Фурсенконың йөзенә карап,—чигенмәячәкбез, конституцион судка кадәр барып җитәчәкбез һәм отачакбыз».

Ни кызганыч, без әле чигенәбез. Чигенүдән кайчан туктарбыз, монысы да билгесез. Күрәсез ки, хөрмәтле укучыларым, инде була язды дигән ватан китеп бара. Кайтырмы икән?

## Изге сөтебез сакланса, әчемәсә, ул көн килер

Әйе, сөтебез әчи башлады. Телебез аяныч хәлдә. Туган телләрен белмәгән татарларның саны артканнан арта бара. Татар теле инде күп гаиләләрдән дә кысрыклап чыгарылды. Ә бит, Аллаһы Тәгалә һәрбер кешене теле белән ярата. Шунлыктан ата-ананың изге бурычы шул телне матур һәм дөрес итеп ачудан гыйбарәт икәнлеген аңлыйсы иде. Тукаебыз бит юкка гына, иң элек шул тел белән әнкәм бишектә көйләгән, дип язмаган. Ул балага бишектә үк милли моң-җыр белән бергә сеңә, ныгый. Моң җыр сорый, сүз таләп итә. Бишек җыры балага милли хис сала, теле ачылуга юл ача. Тел һәм моң—милләт сакчылары.

Күп вакыт ата-ана балам русча белсен, русча укысын ди. Рус теленнән башка яшәү авыр, җәмгыяттә урын алу кыен, ди. Мондый ата-аналарның күпчелеге рус телен начар белү аркасында интеккән, авырлыклар күргән була. Балаларына андый язмышны теләми. Моны аңлап була. Беркем дә үз баласына начарлык теләми. Укысыннар балалалар русча да, инглизчә дә, французча да, немесчә дә. Татар кешесе берәүдән дә ким түгел. Тик менә шушы телләрнең, гомумән, белем-мәгърифәтнең ачкычы туган телебез икәнлеген генә онытмасын. Бала үсеп буйга җиткәч, җәмгыятьтә үз урынын алгач: «Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы» диярлек булсын. Телебезгә рәхмәтле булсын.

Ата-аналарның кайберләре балаларының үз телләрен белмәүдә мәктәпне гаепләмәкче. Имештер, мәктәптә татар телен өйрәтмиләр, укыту рус телендә генә бара. Бу сүзләрдә дә дөреслек юк түгел. Чыннан да, безнең шәһәрләрдәге, хәтта татар дип аталган мәктәпләребездә дә, күп фәннәр русча укытыла. Балалар үзара русча гына сөйләшәләр. Ә менә Финляндиядә, Америка яки Кытай һәм Япониядә татар мәктәпләре юк. Ләкин балалар татар телен камил рәвештә беләләр, чөнки татар теле—гаилә теле. Тел аларга бишектә үк сеңдерелгән. Ата-ана үзара да да, балалары белән дә бары татарча гына сөйләшә. Газиздән газиз телебез бу милләттәшләребезгә «изге сөтебез» аша килә. Бу илләрдә тел балага ана сөте белән сеңдерелә, бишек җырлары белән уралып, аны дөньяга алып чыга.

Бер мисал китерүне урынлы саныйм. Бүгенге көнне Америкада яшәп ятучы милләттәшебез Сәгыйт Салах Корeяда Сеул шәһәрендә туып үсә. Бу шәһәрдә барлыгы 26 татар гаиләсе була. Шулар өчен бер затлы милләттәшебез мәчет һәм мәктәп салдыра һәм аларны үз исәбенә тота. Сәгыйт абый шушы мәктәптә укып, Америкага килгәч ике югары белем ала, профессор булып, хөкүмәтнең атом-төш коралы буенча киңәшчесе дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул туган телебезне камил рәвештә белүе аркасында җиде тел өйрәнә, фәннең иң югары баскычына күтәрелә.

Сәгыйт абый татар җырына гашыйк. Алар хәләл җефете Равилә ханым белән җырлап яшиләр. Шушы уңайдан татар җырының телгә йогынтысы турында тагын бер мәртәбә кисәтеп үтәм. Бер вакыт Бишкәк шәһәрендә җирле татарлар оештырган концертта яшь егетнең сәхнәгә чыгып «Әйтмә˜ син авыр сүз» дигән җырны башкаруын тыңладым. Искиткеч хисләнеп җырлады. Ул сәхнәдән төшкәч, янына килдем. Татарча көчкә-көчкә генә сөйләшә егетем. Ә кулында шушы җырның тексты. Егетнең күңеленә сеңгән милли моң сүз сорый, татар сүзен сорый. Телебезне ныклап өйрәнү омтылышын тудыра.

Очраклы мисал гына түгел бу. Әйтик, инде мәрхүм атаклы җырчыбыз Гали Ильясов Владивостокта туып, асылда туган телсез үскән. Ләкин күзәнәкләренә сеңгән моң аның татарлыгын уяткан, җыр аны житәкләп туган теленә китергән. Бу да моңның тел ачкычы икәнлегенә мисал.

Нәкъ менә шунлыктан, бүгенге җыр сәнгатебез гасырлар буе җыйналган татар

моңының сагында торамы икән, дигән сорау туа. Ни кызганыч, моңа уңай җавап бирү бик кыен. Эстрадабызда халык җырлары, Салих Сәйдәшев, Заһидулла Яруллин, Фәрит Яруллин, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи, Рөстәм Яхин, Солтан Габәши кебек классик композиторларыбыз тудырган әсәрләр бик сирәк яңгырый. Йолдыз исеме белән тамгаланган җырчыларның кайберләре аларны хәттә белми дә.

Күп вакыт, яшьләр халык җырларын өнәмиләр, алар заманча җырларны гына яраталар, дигәнне ишетергә туры килә. Имештер, алар халык җырларына корылган концертларга йөрмиләр. Әгәр дә сәхнәдәге артист чын җырчы икән, ул халык җырларын, классик композиторларыбызның әсәрләрен һәммә тыңлаучының йөрәгенә үтеп керердәй итеп башкара. Җырчының халкыбызның зәвыгын тәрбияләүдәге җаваплылыгын онытырга хакы юк. Ул моң һәм тел сакчысы икәнлеген аңлап эш итәргә тиеш. Бүгенге сәхнә биләүчеләргә Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Галина Казанцева Римма Ибраһимова, Фердинанд Сәлахов, Рафаэль Ильясов, Георгий Ибушев, Мирсәет Сөнгатуллин, Зөһрә Сәхәбиева, Искәндәр Биктаһиров һәм кайбер башка җырчыларыбызның иҗаты үрнәк булсын иде. Шушы җырчылардан торган ниндидер рәвештәге комиссия экспертлык эше башкарса, бик тә яхшы булыр иде.

Әлбәттә, бу очракта дәүләт органнарының да җаваплылыгы зур икәнлеген онытырга ярамый. Алар меңәрләгән кеше җыелган залларны акча сугу станогына әверелдерүгә юл куймаска тиешләр.

Сөтебезнең акрынлап әчи баруына наркомания, эчкечелек кебек заман чирләре дә йогынты ясамый түгел. Аларның татар авылларына үтә баруы, бигрәк тә хатын-кызларыбызның аларга бирешүе аяныч. Боларның берсенә дә күз йомарга ярамый.

Бу безнең дин әһелләребезне дә борчыйдыр дип уйларга кирәк. Авылларда мәчетләр ачыла, ләкин аларның шактые буш. Анда йөрүчеләр аз. Дөрес, үрнәк булырлык авыллар да бар. Татарстанда гына түгел, башка җирләрдә дә. Пенза өлкәсенең Урта Илүзән, Чуашстанның Шыгырдан авылларына гына күз салыйк. Бу авылларның һәрберсендә биш-алты мәчет, һәм аларда һәрвакыт халык тулы. Монда наркоманиягә дә, эчкечелеккә дә урын юк. Саратов өлкәсендә дә шушы рәвештәге яшәеш гамәлгә кереп бара.

Гомумән, авылга күбрәк игътибар кирәк. Гомер буе авыл татарлыкны саклауның төп үзәге була килде. Тел, милли җырлар, гореф-гадәт шунда сакланды. Бүген исә авыл яшәеше саегая. Аннан яшьләр китә, халыкны эшсезлек борчый.

Бүгенге глобальләшү шартларында, бигрәк тә дөньяны кризис билләп алган халәттә, милли яшәеш зур сынау үтә. Россия карабын, Дәрдемәнд әйткәнчә, җил сөрә. Ләкин халкыбызның яшәү көче җитәрлек әле. Аңарда дәрт тә, дәрман да юк түгел. Ул мәңгелеккә юл тота. Татар карабын җил-давыллар һаман сөрә тордылар. Татарның ватаны китеп, фаҗига эчендә кайнаган чаклары да булмады түгел. Ләкин аның сөте, татарлыгы кала килде. Ул шуның белән үзенең бөеклеген раслый торды. Аның менә шушы гүзәл сыйфатын Ижауда яшәүче шагыйрь Ибраһим Биектаулы дөрес күрә алган:

*Мәңгелек дан Сиңа, татар,*
*Әкияти батыр—Алып,*
*Кайгыны да, үлемне дә*
*Җыр белән җиңгән халык!*

Безнең, хөрмәтле укучыларым, киләчәккә өметебез зур. Тик без өмет белән генә яшәргә тиеш түгел. Һәрберебез, кем булуына да карамастан, милләтебез өчен кулдан килгәннең бөтенесен дә эшләсәк кенә максатыбызга ирешә алачакбыз. Сөтебезне сыегайтмыйча, әчетмичә, киресенчә, аны куерта барып яшәргә бурычлыбыз!



Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ГУМИЛЕВ САБАКЛАРЫ

*«...Как ни странно, некоторые события, пережитые нами в XX веке, находят себе объяснение в далекой истории, где заблуждения причудливо переплетаются с истиной, но истина их превозмогает.»*

Л. Н. Гумилев.

1969 елда, язмыштыр инде, Азнакайдан көньякка күчеп киткән якташларым, гаиләм белән мине Ленинабад шәһәренә чакырдылар. Алтын таулары вәгъдә итмәсәләр дә, үзенә дә, хатыныңа да эш-гамәл булачак, хәтта фатиры да табылыр дип ышандырдылар. Тәвәккәлләдек. Жыендык та киттек. Тажикстанга кергән Чорух-Дайрон дигән шәһәр кырындагы шахтерлар яшәгән салага килеп, эшкә урнаштык. Бу салада нигездә Татарстанннан һәм башка төбәктән килгән татарлар эшли. Кайда авыр эш— татар шунда ич инде.

Әле булса гажәпләнәм, тәвәккәл булганмын да соң! Дөнья чите дияргә була бит инде. Тик анда мине, барыбер, язмыш алып килгән булып чыкты. Мәктәптә тарих фәне укытып йөргәндә мин биредә яшәгән татар аксакалы белән очраштым. Ул руслар жәберләү аркасында —көчләп чукындырудан качып—күптәннән бирегә килеп урнашкан кеше иде. Гади генә әйткәндә, туган илен ташлап, качып китәргә мәжбүр ителгән асыл зат. Күпмедер вакыт Оренбург каласында имам булып торган. Ул мине үзенә чәйгә чакырды. Монда да ул югалып калмаган, имам вазифасын үти. Өе тулы борынгы китаплар. Менә кем минем тәүге тапкыр күземне ачты— Оренбург аксакалы Мөхәмматжан имам! Ул татар халкының чын тарихы турында сөйләде, бигрәк тә безнең бабаларыбыз татар-болгарларның тарихында булган вакыйгаларны үз язмаларыннан кириллица имласына күчереп бирде. Житмәсә, киткәндә галим В. Бартольдның томнарын бүләк итте. Шушы очрашудан соң Мөхәмматжан агай тәмам минем мөгаллимем булып китте. Мин анардан дәресләр ала башладым. Ул дәресләр татар халкының чын тарихы иде. Шул хакта мәктәптә укучыларыма да житкергәләдем. Ә минем сыйныфта руслар бик аз, тажик, татар, украин, үзбәк

---

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН (1927)–*Татарстанның Халык язучысы; «Чоңгыллар», «Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Хан оныгы Хансөяр», «Атилла» һ.б. романнар авторы. Казанда яши.*

һәм кыргыз балалары утыра. Көтмәгәндә борынгы бабаларыбыз турында укучы балаларга хакыйкый мәгълүматлар бирергә җай чыкты. Һәм мин кыю рәвештә аңлатмалар бирә башладым. Балалар дикъкать белән тыңладылар. Бу хакта мәктәп директорына җиткерүче дә табылган, әмма күпне күргән директорның мона бер дә исе китмәде: «Сезне балалар ярата, тарих ул—чәбәләнгән ятьмә, сөйләгез, тик зыянга булмасын»,—диде.

***

Әнә шулай мәктәптә тарих фәне укытканда минем тормышымда янә бер кискен борылыш булып алды. Мин аны да язмышыма юрадым. Сонрак, инде тәгаен тарихи әсәрләр язарга керешкәч, беренчесе кебек үк янә бер олуг шәхесне миңа Аллаһ үзе җибәргәндер дигән фикергә килдем. Көннәрдән бер көнне мине мәктәп директоры чакырып алды.

—Мусагит Мударисович, приехал к нам известный ученый, он согласился встретится с учителями города. Пожалуйста сходите, послушайте его.

Мин карусыз килештем, галимнең кем икәнен белмәсәм дә, кызыксынуым җиңде. Мин анда ашкынып, борынгы бабаларыбыз турында үзем белмәгән яңа хәбәрләр ишетермен дип бардым. Һәм ул шулай булды да, күңелем дөрес сизгән икән. Очрашу борынгы шәһәрнең зур сараенда узды. Лекцияне йөзгә үк мөлаем булган, миңа таныш исемле галим тюрколог Лев Николаевич Гумилев укыды. Миңа бу галим турында Мөхәммәтҗан ага сөйләгән иде инде. «Менә кем Русиядә хак тарихчы!» дип әйткән иде. Лекцияне бераз сакаулап, матур аһәң белән укыды галим. Мин ихлас күңелдән тыңладым. Кайбер Хак Тәгаләгә якын сүзләрне әйткәндә аңардан кат-кат әйттерәсе килә. Ул бүгенге татарларны борынгы заманда Кытайда яшәгән борынгы татарларның бабалары булган «һуннарга,» Аурупа тарихчылары «гуннар» дип язган халыкка илтеп ялгады, һуннар каһарманы Атилла, аның дәвамы булган һәм VII гасырда Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып дәүләт төзегән Кубрат хан турында аеруча дәртләнеп сөйләде кебек тоелды миңа. Һәм шуның белән минем бабаларым тарихы белән кызыксынуыма янә ялкын өстәп җибәрде. Сорау бирдертеп тормадылар, юкса теләүчеләр күп иде. Әмма лекцияне оештырган райком вәкиле эшне кыска тотарга уйлады. Галимнең вакыты тар, самолетка ашыга дип, сораулар бирүне туктатты. Минемчә, ул һәрьяктан хәзерлекле бу галимгә кирәкмәгән сораулар бирерләр дип курыкты бугай. Совет чорында рус халкы тарихыннан бүтәнне сөйләргә дә, язарга да ярамый иде. Русиянең бөеклеген әнә шулай да күтәрергә тырыштылар. Тик менә гасырлар буе яшәсә дә, башка халыкларга да илләргә дә үрнәк була алмыйча бүгенге көнгәчә интегә Русия. Хәер, лекция бетүгә, ул кеше юкка да чыкты. Мин ашыга-кабалана галим чыгасы коридорга ашыктым, галим үтеп барганда каршына төшеп, сорауым бирергә авызым ачкан идем, кунак өлгеррәк булып чыкты. Минем каршыга туктап бертын дәшми торды да, үзе үк сөйләп китте: «Откуда такой народ здесь?» —дип, бармагы белән күкрәгемә кагылып алды. Миңа җитә калды: « Татарстаннан мин, Лев Николаевич. Хотел бы с вами познокомиться, я интересуюсь своим народом, историей татар».

—Казан татары, димәк,—диде бу татарчалап, бераз сакаулап.—Ты и есть внук Кубрат хана, молодой человек! А он впервые в Восточной Европе создал государство Великая Булгария. Волжская Булгария и есть осколок древних гуннов-татар. Да, вообще история булгарских татар начинается с великого Кубрат хана. Каждый народ от какой-то личности начинает историю своего народа. Хотя история древних татар очень далек, с Алтая, но история казанских татар начинается с Кубрат хана. Запомните это, молодой человек, если вы интересуетесь историей своих предков. Древние хунны-татары в лице ваших предков еще в 156 году нашей эры перекочевали в Предуралье и Поволжье... Это точная дата, эту дату подверждает и древние источники.

—Я писатель, у меня есть книги ...

Ул миңа якын ук килде һәм янә бармагы белән күкрәгемә төртә-төртә:

—Вот вам совет бывалого человека, молодой писатель: пишите исторические произведения. Через художественные произведения история того или иного народа

скорее доходит до сознания читателя. Да, я вижу, вы не долго будете в этих краях, вернувшись в Татарстан выберите время, приежайте ко мне в Ленинград, я вам о ваших предках, в частности о татарах, дам исчерпывающие ответы... А пока вот возмите мой труд о хуннах. От них, с Алтая, начинается жизнь ваших предков.

Ул янәшәсендә торган егет кулыннан китабын алды һәм аяк өсте генә автограф куеп,үзенең беренче хезмәте «Хунны в Китае» китабын миңа сузды. Һәм озатучылар белән сөйләшә-сөйләшә китеп тә барды.

Әнә шулай мин татар халкын яклаучы олуг галим Лев Николаевич Гумилев белән очраштым. Галим кул куйган китапны куеныма кысып, очып диярлек, мәктәпкә кайттым. Директорга елмая-елмая килеп кердем, галимнең лекциясен тыңларга җибәргән өчен рәхмәт әйтеп, куенымдагы Лев Николаевич китабының җылысын тоеп, өйгә кайтып киттем. Тизрәк, тизрәк укыйсы килә иде олуг галим биргән китапны.

***

Тагын бер елдан, янә көтмәгәндә, Язучылар берлеге рәисе Зәки Нури һәм «Казан утлары» журналы баш редакторы Гариф Ахунов икесе киңәшеп—мин бахырыгызны Казанга Язучылар берлегенә эшкә чакырып алдылар. Әнә шулай язмыш мине Казанга алып килде.

...Минем тормышымда яңа сәхифә башланды. Мин бу күчешне янә язмышыма юрадым. Гүя мине шулай борынгы бабаларыбызның рухы йөртә иде. Иҗади берлектә эшли башлавыма ярты ел да үтмәде, мин командировка алып, Ленинградка киттем. Башта Ленинград Язучылар союзына барып, Лев Николаевичның телефонын таптырдым. Аннары аңа шалтыраттым. Телефонда аның сакаурак тавышын ишеткәч, аңа «Таҗикстанда сез «Хунны в Китае» хезмәтегезне биргән татар малае», дидем. «Ә-ә, Кубрат хан оныгы» дип кабатлады ул татарчалап һәм шундук җитди сүзгә күчте: «хәзер үк Союздан, тарихи әсәр язам дип, Эрмитажга юллама ал, диде ул күптәнге танышын тапкандай, һәм Эрмитажга килгәч, Борис Борисович Пиотровскийга кер. Иң зур түрә ул анда. Мин аңа минем шәкертем килә, ул теләгән Кубрат ханның хәзинәләрен күрсәт дип әйтеп куярмын. Калганын соныннан миңа шалтыратып аңлатырсың. Торыр урының бармы соң?.. Юк. Минем адресны Борис Борисович бирер. Эрмитаждан соң туры миңа килерсең. Аңлаштыкмы?..»

«Аңлаштык,»—дидем мин бераз унайсызлана калып. Әмма кинәнә-кинәнә Ленинград Язучылар оешмасыннан юллама алдым да, Эрмитажга йөгердем.

...Олы кеше булуына карамастан Борис Борисович мине өстәл артыннан торып ук каршы алды. Ике куллап күрештек. Мин аңа юлламаны суздым. Ул юлламага карап алды да, хәлнең асылына төшенеп, селектордан гидлар чакырып алды һәм мине алар кулына тапшырды. «Кубрат ханның бар булган хәзинәләрен күрсәтегез һәм хәзинәләр турында язган мәгълүматларыгызны менә бу егеткә бирегез»,—диде. Бер егет һәм хатын-кыз мине калын тимер ишекләр аша кыйммәтле хәзинәләр саклаган аскы катка алып төшеп киттеләр. Кубрат ханның бай хәзинәсен күргәч, таң калуым, тәмам ни кылырга белми һәр хәзинәне тотып карарга омтылуым турында язмыйм—моны бер сүз белән генә аңлатып булмый. Гидлар шул хакта сөйләделәр: хәзинә төркиләрнекe булгангамы, ичмасам бер тапкыр да халыкка күрсәткәннәре юк икән. Бары тик галимнәргә генә күрсәтәләр, анда да шушы өлкәдә хезмәт язганнарына гына. «Сез яшь галимме?»—дип сорадылар миннән. Мин «яшь язучы» дип кенә котылдым. Ике сәгатьләп экспонатлар карап йөргәч, без янәдән Борис Борисович кабинетына кайттык. Гидлар аңа хәзинәләр турындагы мәгълүматларын бирделәр һәм чыгып та киттеләр. Ә Борис Борисович мине чәй өстәле янына дәште. Мин аңа Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил китапларын бүләк иттем. Китапларны кулына алгач, ул бераз актарып утырды да: «Йә чәйлик, үзең ни турында язарга исәбең соң?»—дип сорады. «Кубрат хан турында язарга исәп, шул исәп белән сезгә килүем иде»,—дидем. «Тарихны әдәби әсәр аша укучыларга җиткерү иң камил чараларның берсе,—дип, Борис Борисович та кинәндерде мине.—Мин дә менә җыентык чыгардым. Сезгә бүләк итим әле. Борынгы көнчыгыш халыклары тарихы. Монда шул өлкәдә эшләгән төрле галимнәрнең хезмәтләре,»—диде.

Без сөйләшә-сөйләшә һәйбәтләп чәй эчтек. Олуг галим Борис Борисович биредә инде бик күптән эшли икән, киләсе елга пенсиягә китәсе, менә шунын өчен истәлеккә бу китап чыкты да инде дип әйтте. Чәй эчеп утырганда телефон шалтырады. Лев Николаевич икән, мине Борис Борисовичтан үзенә озатуны үтенә. Борис Борисович мина үзенең машинасын бирде һәм шофер мине җилтерәтеп Лев Николаевичка алып китте. Шофер юл буена үзенең туган авылы турында сөйләде. Шофер мишәр малае булып чыкты. «Изге адәмдер сез, сезне Борис Борисович та яратты...—ди.—Мин үзем, брат, Пензя якларыннан, биредә армиядә хезмәт иттем, шунда бер татар кызы белән танышып киттем һәм ана йортка кердем. Атам «йортка керү—утка керү» дип үртәлсә дә, сонрак килеште тагын. Килен ипле, дип кинәнде. Ә үзләре ел саен килеп, кунак булып китәләр. Эрмитажга алып керәм үзләрен. Исләре китә, малай! Ике малаем бар, икесен дә әтәйләрдә авылда үстерәм, татарча сүләшсеннәр. Сүлиләр, такылтап торалар! Хатын кинәнә—үзе юньләп татарча белми, ә малайлары татарча такылтап торалар... Сина, кордаш, Лев Николаевичка бит әле?.. Борис Борисович Пиотровский белән җан дуслар алар, тегесе килсә, бер самавырны егалар. Сүләшәләр, сүләшәләр, бәхәсләшеп тә китәләр. Әмма беркайчан да өсталләрендә шәраб күрмәдем. Тәмам әүлиялар инде, алимнәр, хөрмәтле адәмнәр...»

Лев Николаевич ишекне мина үзе ачты. Өстендә пижама, берьялгызы. Өйдә башка беркем дә юк.

—Исәнме, Кубрат хан онытгы!—диде бу әллә шаяртып, әллә чын-чынлап елмая-елмая татарчалап.—Әйдә, чишен дә түрдән уз. Мин татарча беләм, 15 ел сөргеннен файдасы татарлар тарихын өйрәнүгә китте. Анда минем белән гадәттә төрки-татар халыкларынын галимнәре утырдылар. Алар барысы да, ни хикмәт, татарча сөйләшәләр иде. Ярый, ул хакта сонынннан. Кулын ю да, башта чәй эчеп алырбыз.

Ул кухняга кереп китте, мин исә галимнен эш кабинетына үттем. Һәм стеналар, өстәл аслары, бүлмә почмаклары тулы китап шүрлекләрен күреп, туктап калдым. Саташырлык иде—кай шүрлектә нинди китап ятканын галим үзе генә белеп бетерәдер, мөгаен. Һәм шулай булып чыкты да. Чәйләп алгач, ул үзе генә белгән киштәдән мина борынгы бабаларыбызга караган папка-папка язмаларны, гарәп имласында, яналифтә, революциягә кадәр урыс телендә басылган китапларны күрсәтте. Ахырда: «менә бу папкада Кубрат хан хакындагы материаллар» дип мина сузды. «Цензурадан үткәннәре дә, үтмәгәннәре дә», дип өстәде. «Ләкин язучы кешегә мәгълүматлар гына җитми, ана әле башка бик күп сыйфатлар кирәк. Мин ышанам, синдә ул бардыр. Юкса бирегә килеп чыкмас иден», диде. Шунда мин ана татарча Казанда, русча Мәскәүдә чыккан «Водовороты» китабымны күрсәттем. Ул—китапны актарып чыкты да, янәшәсенә куйды һәм күзләремә карады.

—Күрәм, зур эшкә кереп китәргә җыенасын. Әгәр дә мәгәр Кубрат хан турында язарга телисен икән, башта җәяүләп дисәм дә ярыйдыр, Таман ярымутравына барып кайт. Мин шулай йөреп яздым « Открытие Хазарии» дигән хезмәтемне. Төрки халкынын VII гасыр каһарманы Кубрат хан биләгән ил-җирләрне күреп кайт, күнеленә сендер. Җиһангир буларак, ваш Кубрат хан неординарный шәхес булган. Ул христиан, мөселман диннәре ныклап аякланып киткән чорда яши, барысын да анларга тели һәм... үз фәлсәфәсе аша! Безнен галимнәребезнен күбесе төркиләрнен Тәнре динен мәҗүсилеккә кайтарып калдыралар. Бу хәл хата дип уйлыйм мин. Һәр диндә Тәнре чыганагын күрергә була. Шунын өчен ул образ синен романында төп шәхес булырга тиеш. Калган геройларын барысы да анын тирәсендә уралсыннар, барысы да! Ләкин Кубрат хан—төп героен—һәрвакыт укучынын күз угында торырга тиеш. Юкса тарихи роман юк.

Ул елмаеп мина карап торды-торды да, көлеп җибәрде һәм: «Язучыны ничек язарга өйрәтүе рәхәт тә сон, ә! Ләкин нишләмәк кирәк, тарихи роман дәреслеккә юл тотарга тиеш. Тарих фәнен язучы академиклар гадәттә империя сәясәтенә йөз тоталар, ягъни белә торып ялганга баралар, дәүләт ашата ич! Беркемнен дә иписез каласы килми. Ләкин матур әдәбиятта түгел, чөнки матур әдәбиятнын ышандыру көче күп тапкыр өстенрәк—тормыш шул дәвердә яшәгән образлар аша бирелә, шул чорнын каһарманнары аша...»

Әлегә кадәр мин аны бүлдерергә кыймадым. Әйе, олуг галимгә сүз катырга ни хакың бар, җитмәсә үзендә кунакта. Шулай да сорап куйдым.

—Мин бу хакта китап язарга хыялланып кына йөрим әле,—дидем.

—Иң мөһиме, язучыга хыяллана белү. Бу—бик һәйбәт сыйфат. Ничек әйтәләр әле сездә, «иншалла»мы?..—рәхәтләнеп көлеп алды, инемә кулын салды.—Мин сиңа бу мәсьәләдә ярдәмчең булырмын. Төрки-татар халыкларының тарихы шулкадәр бай ки, ул әле сезнең халыкка кереп кенә килә, сез әле үз-үзегезне ачасыз гына, туганкаем...

Бер хатын килеп керде, безнең белән исәнләшеп алды да кухня ягында савыт-сабалар белән нидер хәстәрли башлады. Лев Николаевич һични булмаган кебек һаман сөйләде-сөйләде дә, ахыр болай диде:

—Мин университетка китәм, бер пар лекциям бар. Без хәзер Марфа апаң әзерләгән ризыкны ашыйбыз да, аерылышабыз. Син өйдә каласың. Сиңа мин татарларга караган барлык язмаларымны бирәм. Карап чык. Кирәкләрен сайлап ал!—диде.

Кухняга кердек. Марфа апа булган ризыкларны куйган, өстәлне матур итеп хәстәрләгән иде. Без ашаган арада ул арлы-бирле йөрде, әле чәй ясады, әле калаклар куйды. Соңыннан ишек янына басты да, кулларын кушырып:

—Кичкә нәрсә китерим?—дип, Лев Николаевичка дәште.

—Кичкә килмә, Марфа, без кунакка барабыз,—диде Лев Николаевич.

Марфа апа «кая» дип тә сорамады, «нигә» дип тә кызыксынмады, дәшми-тынмый без ашаган савыт-сабаларны җыярга, юарга тотынды.

Лев Николаевичта минем кебек кунаклар шактый еш булгалыйлардыр, күрәсең... Алар бер ишектән диярлек чыгып киттеләр. Мин сарай кебек фатирда, кабинет тулы китаплар арасында, берүзем калдым. Әле бу китапны, әле теге китапны ачып укыйсым килә. Хәер, кемнәрнең хезмәтләре генә юк иде сарай кебек бу кабинет шүрлекләрендә?! Алай да татарлар турындагы китаплардан башладым.

Лев Николаевич кайтмады да кайтмады, ә мин укый-укый арып-алҗып, өстәл янында ук йокыга киткәнмен. Уянып китсәм, Лев Николаевич кайткан, чәй кайнаткан, табын әзерләгән. Мин уянуга, чәйгә дәште.

—Булгалый,—диде ул көлемсерәп.—Өстәлгә капланып минем дә йокыга киткән чакларым була. Менә кинәнеп утырам әле: авыз тутырып татарча сөйләшергә җай чыкты. Ә бит кайбер сүзләрне оныта башлаган идем инде.—Ул бертын миңа карап торды.—Әйтсәм әйтим, татарлар тарихы руслар тарихыннан күп тапкыр бай. Хәер, Русиянең нигез ташы татарлар тарихында ята. Бар хокукларыннан мәхрүм ителгән татар алпавытлары, «чабаталы морза» исеме алып, өй-каралтыларын, җир-торакларын калдырып, көнчыгыш тарафларына күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Китәргә теләмәгәннәре чукыналар—православие динен кабул итәләр. Әнә шулай православие дине Русиянең төрле милләт вәкилләреннән торган халыкларына сугыштан да яман фаҗига китерә: ул янау, үтерү, бәкеләргә ташлау, куркыту чаралары аша халыкка индерелә. Тик бит Русия ул бер үк халык була—венед-болгар кавемнәре, ә инде монголлар килгәч, татар аты алган халык. Тарихи татарларны яклаучы буларак, менә нәрсә кыен хәлгә куя мине. Әйтик, Аксаковны, Апраксинны, Арсеньевны, Бекетовны, Булгаковны, Милюковны, ахыр Третьяков, Тургенев, Ушаков, Урусов, Юсупов, Салтыков, Беляев кебек йөзләрчә татарларның исемлеген төзегән Баскаковка кадәр... Һәм тагын урыслашып киткән меннәрчә татар алпавытларын кая куясың... Ярый, әйдә җыеныйк, безне Габдрахман абыен Таһир дәшә. Сине күрәсе килә. Татарстанда сезнең кебек шәрә батырлар азаеп бара, юк хәлендә диярлек була. Ә тарихчы Таһирҗанның тарих белән кызыксынган татар балалары өчен җаны фида! Таһир, әйтсәм әйтим, Атилла хан оныгы диярсең, үз халкы өчен утка-суга керергә әзер олуг галим. Миңа да ул татарлар турында бик күп материаллар тапты. Рәхмәт аңа...

Лев Николаевич татар алпавытлары хакында сүз алып барганда минем күз алдыма «чабаталы морза»лардан булган хөрмәткә ия язучыбыз Әмирхан Еники язмышы килде. Бу нәселнең бер тармагы чукына, икенче тармагы—Әмирхан Еникинең атасы—булган хезмәтчеләрен алып, Башкортстанга күчеп килә һәм ярлылар санында

шунда яшәп кала. Менә нишләтә чамадан тыш үҗәтләнеп киткән дин кешене! Милләтне—милләттән, атаны—баладан, баланы— атадан, туганны—туганнан аера, хәтта кан дошманнарына әверелдерә!

Әнә шулай итеп язмыш мине янә бер олуг галим белән очраштырды. Әллә соң бар галимнәр дә шулай Лев Николаевич кебек гади-садә булалармы?.. Габдрахман абый безне бусагага ук килеп каршы алды.

—Узыгыз, узыгыз, рәхим итегез. Лева, син кунакны түргә алып керә тор, мин Мәрфуга апана кайбер әмерләр бирим әле...

Сәер дә соң бу дөнья. Мин кем дә, исем-атлары дөньяга билгеле ошбу галимнәр кем? Шаклар катмалы. Ә бит мин—гади авыл малае. Алар алдында сүз катырга да кыймый торам... Ул арада бер апа безнең янга чыгып, безнең белән исәнләште, Лев Николаевичның сәламәтлеге белән кызыксынды, аннары миңа карады. «Казан шәкерте» диде бугай мина Габдрахман. Бик әйбәт. Тарих белән кызыксына икән. Кирәк бит, кешесенә тап булган, арысланның үзенә. Ә ул сезгә бераз ошаган да, улыгыз түгелдер бит,—дип, шаяртып алды Мәрфуга апа.

Һәм шундаен башын артка ташлап көлеп җибәрде ки, күрше бүлмәдән нәрсә булды дип, Габдрахман абый килеп чыкты.

—Мин сина үзем сөйләрмен,—диде рәхмәтле апа һәм картын кухня ягына алып кереп китте.

Габдрахман абый, гомере буена фарсылар тарихын өйрәнгән кеше буларак, төрки дөньясының үзе бер кабатланмас шәхесе иде. Ул татарлар тарихын, гомумән, төрки дөньясының борынгы әдәбиятын шул чиккә җитеп өйрәнгән иде ки, мин аны сәгатьләр буена тыңласам да тыңлап туя алмадым.

—Русия тарихчыларының татарларга каһәр укулары кайдан да түгел, Көнбатыштан башлана. Бу яман гадәтне беренчеләрдән булып, Польшада католик динен кабул иткән патша Михаил Романов кертә, ары таба тәхеткә менгән аның улы Алексей исә атасының тәүге хыялын тормышка ашырырга керешә. Иң гаҗәбе, аларга Русиянең исемле тарихчылары ярдәмгә килә. Әйтик, Карамзин, Соловьев, Ключевский, Иловайский, Кузмин һ. б., хәтта татардан чыккан Каргаловка, Америкага качкан Пушкаревка кадәр! Алар барысы да—академиклар, ил халкына таныш кешеләр. Ләкин кылган гамәлләре... Русия халкын дошманлаштыру була. Тезислары—тарих ул—сәясәт. Һәм татарларга каршы корылган сәясәт. Әнә шуннан соң Русиядә татарларга карата сәясәт үзгәрә, татарларны «басып алучылар, урыс халкын йөз еллар буена коллыкта тотучылар,» дип яза башлыйлар һәм дүрт-биш тапкыр Мәскәү сәясәтенә җайлаштырып төзәтелгән «Повесть временных лет» елъязмасы аша үзләренең бабаларын IX-X гасырларда дөнья караклары саналып йөргән варягларга илтеп ялгыйлар, гәрчә бу елъязма XVIII гасырда гына пәйда булса да. Әйе, гәрчә бүгенге урысларда варяглар каны дингездәге бер тамчыдай гына булса да! Хәтта Карамзин, Соловьев, Ключевский, Вернадский, Иловайский, Платонов, Бердяевка кадәр каберга кергәнче « безне татарлар яулады» дип язуларын дәвам иттеләр түгелме, кардәшләрем!? Ә варягларны, имеш, үзләре чакырып китергәннәр. Тик берсе бу хәлне изгегә юраса, икенчесе яманга кайтарып калдырды. Русияне көнбатыш идеологиясенә борырга теләүчеләр кулында дәреслекләр—мәктәп балаларына дәреслекләрне сакаллы академиклар яза, дәүләт сәясәте алар кулында.

Ул шкафтан үрелеп китап алды һәм кәгазь кыстырган битен ачып:

—Менә тыңлагыз, ни яза чыгышы белән татар булган Бердяев: «Все будущее русского народа зависит от того, удастся ли победить в нем нехристианский Восток, стихию татарскую, стереть с лица русского народа монгольские черты Ленина, которые были в старой России.» Кадерлем Лев Николаевич, яшь язучы Мөсәгыйт туган, шуннан соң сез ни әйтә аласыз? Чыгышы белән татар булган Бердяев яза моны, Бердяев...

—Мин аларның барысын да беләм, кадерлем Габдрахман, беләм. Алар—койрыклары белән дәүләт сәясәтенә бәйләнгән иезуитлар! Владимир Ильичның каны калмыкларның «ойрат» кавеменнән килә. XVI гасыр азагында XVII гасыр башында бу халыкның бер өлеше көнчыгыштан Русиягә күчеп килә. Бердяевнең «татарская стихия» сүзе ул—фикция. Татар сугышчылары арасында тәртип корычтай була,

ә «татар» сүзе Урда дәверендә этник сүзне аңлатмаган, «Урда сугышчысы» дигән мәгънә ул. Бердәмлекне саклау өчен бирелә аларга бу борынгы «ТАТАР» атамасы. Шуның өчен без синең белән татарларны якларга кирәштек тә инде, Габдрахман дустым. Хәер, чыгышы белән калмык булган Әренҗән Карадауанның «Чыңгызхан» хезмәтен мин югарырак баскычка куям. Бу тарихчы хакыйкатькә якынрак килгән. Бер җайдан безнең яндагы бу яшь кешене дә онытмыйк. Без инде өчәү,—дип рәхәтләнеп көлеп җибәрде Лев Николаевич. Һәм шул уңайдан урысларның өч батыры турында мәзәк тә сөйләп алды.

Үзләрендә кунак булганнан соң мин олуг татар галиме Габдрахман абый белән янә бер тапкыр очраштым. Ул Казанга килде. Күп еллар хыялында йөрткән «Тарихтан—әдәбиятка» дигән хезмәтен бастырып чыгару нияте белән килгән иде ул. Мин аны татар ашханәсенә алып кереп милли ашлар белән сыйладым. Ә университет галиме профессор Миркасыйм Госманов аның хезмәтенә күләмле һәм җылы итеп кереш сүз язды. Ул вакытта галимнәр хезмәтенә Лениннан цитаталар кертмәү зур гөнаһ санала иде. Ни гаҗәп, Ленинның әсәрләрен яхшы белгән Габдрахман абый үз хезмәтенә шундаен оста итеп революция тиранының цитаталарын керткән иде ки, хәтта китапның редакторы Григорий Трофимов та һични кыла алмады—барысын да ничек бар шулай уздырып җибәрде. Хезмәт чыкты, киң катлам укучыларга җитте һәм ул татар дөньясында үзенә бер энҗе кебек җемелдәп торды. Габдрахман абый үз хезмәтен күрде, ләкин татар халкы өчен гаять кирәк булган бу хезмәт юка тышлык белән бары тик ике мең тираж белән генә басылды. Йа Хода, нинди елларда яшәдек: үз тарихыбызны үзебезгә язарга ярамый иде! Әнә шул елда мин, тәвәккәләп, «Кубрат хан» романына тотындым да инде.

... Халкыбыз тарихыннан зур сабак биргән мөгаллимем вафат булгач, мин Ленинградка бара алмадым. Ә җай чыгу белән бардым. Олуг галимнең таныш булган өе каршында бик озак басып тордым. Мин янә бернәрсәгә күңелем тулышыр дәрәҗәгә җитеп шатландым. Безнең президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев Лев Николевич яшәгән өйгә истәлек тактасы куйдырды. Соңрак башкалабыз Казан каласының үзәгендә гомер буена татарларны яклаган галимгә чын һәйкәл дә калкып чыкты. Нәкъ менә җир астыннан калкып чыккан кебек. Миңа калса, татар халкының Рухы күтәрде бу һәйкәлне!

Адәм баласы кылган изге гамәл җирдә ятмый икән. Үз гомере буена татарларны яклаган, бабаларыбызның сынмас рухын без татарларга васыять итеп калдырган бу шәхесне тудырган «Татар Рухы» гүя гасыр вә дәверләр аша калкып чыкты. Әбисе татар, әнисе Русия халыклары өчен мәңге ялкынланып торган шигырьләр язган корыч ихтыярлы горур шагыйрә Анна Ахматова рухы да бу тактада балкый кебек тоелды миңа!..

Иң мөһиме: Русиядә яшь тарихчылар пәйда булды, ягъни Лев Николаевич Гумилевның гадел карашларын дәвам итүчеләр. Әйтик, язучы вә тарихчы Александр Бушков үзенең хезмәтләренең берсе булган: «Мираж Великий империи»да болай дип яза: « История—неточная наука, поскольку базируется не на беспристарстном эксперименте, а на пристрастных бумагах.» Икенче бер хезмәте «Тайны смутного времени»да ул болай дип өсти: «...первая художественная зарубежная книга была переведена на русский язык только в 1760 г.—французский куртуазный роман аббата Талемана «Езда на остров любви.» До того переводились лишь учебники артиллерейского дела и руководство по управлению парусами. Культурой и не пахло.» «Иван Грозный—кровавый поэт» хезмәтендә исә ул империянең аякланып китүен тасвирлый. Мурад Аджи да үзенең «Кыргый кыр—Бөек Дала» китабында Атилла хан эз калдырган бабаларыбызның тарихын Санк-Петербург галимәсе Лилия Йосыфҗан кызы Тугушеваның озак еллар дәвамында берәр битләп төрле архивлардан җыйган язмаларын файдаланып бәян итә. Шушы материаллар нигезендә ул Атилла даирәсендәге барча зыялыларның уйгыр имласында язмалары булуын раслый. Чынлап та, шул Уйгур имласы татар-монголларга кадәр килеп җиткән, чөнки Чыңгыз хан үз оныкларына сабак бирүне уйгыр мөгаллимнәренә тапшыра. Татар галимәсе Алсу Арсланова да үзенең « Остались книги от времен былых...» хезмәтендә татар этносының бакый заманнардан килүен күп санлы чыганакларга таянып дәлилли. Америка галиме Эдуард

Паркер Кытайда утыз ел буена археологик казу эшләре алып барып, үзенең «Татары» (История возникновения великого народа) хезмәте белән безнең эрага кадәр ике мең еллар элек «татар» этносының аякланып китүен раслый.

Яшь галимнәргә булган хәер-хакның нигез ташын менә нинди сүзләр белән сала Лев Николаевич Гумилев: «... этот континент за исторический обозримый период объединялся три раза. Сначала его объединили татары-тюрки. Создание каганата, который охватывал земли от Желтого моря до Черного. На смену тюркам пришли татары-монголы. Затем, после периода полного распада и дезинтригации, инициативу взяла на себя Россия...» Менә ничек күзаллый Руси империясенең аякланып китүен олуг гуманист галим. Шуннан соң мин түбәндәге нәтиҗәгә килдем—Русия безнең уртак Йортыбыз. Русиядә яшәгән һәр милләт вәкиленә шул җитмәгәнме!?.. Нигә безне күпсенә рус халкы?.. Расизм, шовинизм чире белән авырган славяннарга мин якты дөньяга аек акыл белән карарга тәкъдим итәр идем... Русиядә яшәгән һәр милләт вәкиле кимсенү тоярга тиеш түгел, юкса бу зур һәм куәтле Илнең гомере озын булмас. Тарихтагы гыйбрәтле хәлләр шуны раслый.

***

...Менә без Кырымда—борынгы туганнарыбыз илендә. Кырым ярымутравына керүгә үк, үз туган җирләреннән куылган канкардәшләрем күз алдыма килде. Бирегә ялга килгән Кырым татары язучысы, бабалары яшәгән кыр-далаларны күргәч, ничегрәк хис итә икән үзен?! Йөрәге кысылып куядыр. Күз яше белән елыйдыр. Мин дә, гәрчә бу тарафларда тумасам да, кардәшләрем өчен тетрәнеп куйдым. Җанга шом салып, вагон тәгәрмәчләре тыкылтый. Күз алдыма ил-халкыннан, туган туфрагыннан куылганнан соң бирегә ялга килүче кырымлы каләмдәшем килә һәм янә йөрәк кысылып куя. Чарасыздан күнел төпкелегеннән сыкрану авазы чыга. Ни кылырга белми арлы-бирле йөри башлыйм. Йа Ходаем, нинди каһәрле һәм имансыз илдә яшибез! Түз, сабыр ит, татар бабаларыбыз «сабыр төбе сары алтын» дигәннәр, килер ул азатлык безгә дә, килер, киләчәк, чөнки телиме моны империя, теләмиме дөнья халкы татулыкка таба бара... Инде күптән туган илләренә кайта алмый, чит-ят җирләрдә әле булса интегеп көн күргән Кырым татарларын янә-янә кызганып куям. Туган җиренә, туган туфрагына аяк басуга, кем генә булмасын, һәрвакыт йөрәге кысылып, сыкрап куядыр инде аның...

***

Кырым иленең юл божрасы буйлап, гаиләм белән сәфәрне дәвам иттек. Авыллар аша үтәбез. Бер авыл кырындагы өй каршына туктап, кукуруз арасында арык кына сыерын ашатып торган украин картын күреп, туктадым, килеп сәлам бирдем һәм бу авылның исеме элек ничек булган дип сорадым.

—Ташлыяр, батенька, Ташлыяр...—диде карт һәм озын мыегын сыпырып өстәде:—Раньше здесь татары жили. Порядок был. А наш народ все развалил. Татары виноград выращивали, диковинные фрукты, мы вот кукурузу растим да худых коров держим. Для коровы луга нужны, сочная трава, а тут одни камни. Отсюда прежные татары, наверное, назвали свою деревню Ташлыяр. Мы со старухой прежде в Башкирии жили, еще в тридцатые годы Сталин проклятый погнал на Урал... Когда нам сказали, что в Крым вербуют, мы со старухой ближе к Украине перебрались. И тут застряли. Состарились. Вот весь мой сказ, батенька...

Мин Башкорстан мәхшәреннән Кырымга күчеп, туган ягыма якынаям дип татарларның әзер өй-каралтыларын биләгән ак сакаллы украин картына бик озак карап тордым. Кайчандыр туган туфрагыннан мәҗбүри рәвештә куылган карт, туган ягы оҗмахына кайтырга җыенса да, үз туфрагына кайтып җитә алмый, Кырым татарлары җирендә туктап калган... Мин империя сәясәте җидегә бөккән бу карт белән саубуллаштым да, үз юлыма ашыктым.

***

...Таман ярымутравына таба кузгалдык. Төп максатым—ерак бабабыз Кубрат хан биләгән җир-туфракны күрү иде. Юл бик озак дала буйлап бара. Керчь каласында

Айвазовский музеена туктадык, олуг рәссамның үлемсез картиналарын күреп, рухланып чыктык. Ары таба Кереш (Керчь) каласыннан паром белән Таман ярымутравына юнәлдек.

***

Ниһаять, без—борынгы бабаларыбызның туган туфрагында. Мин күрергә теләгән Фаногория каласы юк, кечкенә бер сала—Сенная дип аталган сала гына калган икән. Зур булмаган өйдә музейлары бар. Музейга кергәч, анда утырган өлкәнрәк хатын белән исәнләштем, исем-атасын сорадым, үзем белән таныштырдым. Һәм сорадым: « Кая булды тарихларга кереп калган борынгы Фаногория каласы?» Безнең халыкка ошаган, әмма киемнәре украин халыкларыныкы булган Наталья Ивановна миңа болай диде:

—Алыштырдылар ул исемне. «Сенная» дип бу саланы биредә дәүләт атларына печән чабучы казаклар атадылар. Һәр җәйне алар Хан болыныннан сугыш атларына печән чабарга киләләр иде. Алар шулай атап калдырдылар—«Сенная.» Минем үземә дә ошамый ул исем дә, нишләмәк кирәк, бездән исемнәрне генә түгел, бабаларыбыз тамырларын да сорамыйлар. Менә, күрәсез, биредәге һәммә экспонат болгар телендә, борын заманда биредә татарлар яшәгән диләр.

—Ә тагы да борынгырак заманнарда биредә, Наталья Ивановна, безнең бабаларыбыз татар-болгарлар яшәгәннәр,—дидем мин.

—Һәй, белмәссең бу дөньяны, барысы да асты-өскә килде инде. Минем әни дә әбиемне төрки болгары нәселеннән дияр иде... Сез кем сон, әллә сез дә безнең халыкмы? Балаларыгыз да, үзегез дә бер татарларга охшамагансыз?

—Минем борынгы бабаларым биредә яшәгәннәр, бу каланы күтәрүче безнең бабабыз Кубрат хан була.

—Батюшки, дайка я вам чай поставлю. Куда еще направляетесь? А я ведь, батенька, понимаю вас, мои предки тоже говорили по болгарски, на вашем языке.

—Татарами были?

—Нет, болгарами, но говорили равно что по-татарски. Потом их крестили, батенька, мама говорила мне, был у нас свой бог на небе, а теперь другой и даже не знаю где он. То ли в небо вознесся, то ли на земле остался. Молимся и радуемся. Чай готов, позови своих. С детьми приехали, и так далеко, не боитесь?..

Наталья Ивановна безне шикәр куеп чәй эчерде, мин аңа чәйгә акча түләргә иткән идем, ике кулын күтәреп:

—Что вы, батенька, я очень рада была вас видеть. Таких я хотела видеть древных земляков. Слава богу, порядочные, добрые, красивые. А бог он един у нас, один... Но судьбы у нас разные... От судьбы не убежишь, батенька...

—Да, один,—дидем мин килешеп. Наталья Ивановнага рәхмәт әйтә-әйтә чыгарга кузгалдык. Мин инде музейга кергәч тә игътибар иткән идем, биредәге күп кенә экспонатларның исемнәре татарча, карсак төлке белән мич каршындагы чуенга кадәр. Димәк, гасырлар буена яшәсәләр дә, халык көнкүреш әйберләрен борынгы бабаларыча йөртә икән.

Башта без дингез буендагы зур булмаган, әмма мәйданы шактый зур калкулыкка туктадык. Борынгы заманнарда кайсы халык кына биредә яшәмәсен, менә шул калкулыкта коллар сатканнар. Колларны нигездә Рим, Хәлифә сәүдәгәрләре алган. Чибәр кызларны шаһиншаһ, хәлифә сарайларына зур бәһагә сатканнар. Чынаяктай ак тәнле, салам чәчле гүзәлләребез Рим сенаторларының сарайларын, соңрак хәлифәлекләр барлыкка килгәч, хәлифәләрнең гаремнарын бизәгән. Бу хәлләр бик күптән булган инде. Ә безгә хәзер Кубрат бабабыз көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып дәүләт оештыргач күтәргән Тимерук шәһәрчегенә барып җитәргә кирәк...

Тимерук шәһәренә юл күлләр арасыннан бара. Шушы күлләрдә борынгы бабаларыбыз балык тотканнардыр. Кубрат хан тиккә генә Византия илчеләрен кабул иткәндә балыкны корбанга китерми. Менә нинди уйлар килде минем башыма бихисап күп күлләр яныннан үткәндә. Һәм бу эпизодны мин романыма

да керттем. Тимерук каласы калкурак урында утыра, зур кала түгел, бер ягыннан Терек елгасы ага. Лев Николаевич шул елга турында сөйләде дә инде миңа—«тере ул, тере елга», дип. Һич тик тормый, яз көннәрендә дә, көчле яңгырлар булса да эз-юлын алыштыра. Шуның өчен бирედәге борынгы халык елга буена бик утырмаган, калкуырак җирләрне сайлаган. Ә читтән килгән халык, әнә, елга ярына терәп үк өйләр сала. Ташу сулары шуңа күрә аларга бихисап фаҗига китерә. Бу төбәккә оҗмах күрергә Русия калаларыннан күчеп килгән халыклар һәр елны диярлек фаҗигагә дучар була, өй-каралтылары йә су астына кала, йә нигезләре җимерелә. Ә биредә көн күргән борынгы бабаларыбыз елганың бу холкын белгән, алай эшләмәгән.

Безнең Кубрат бабабыз нигезләгән Тимерук каласы—Хан болыны кырында ук. Безне шаккаттырганы шул булды: биредәге халык—кибеткә керәсеңме, урамда күрәсеңме—безнең Казан халкына охшаган. Таң калмалы! Кибетләргә кергәч, татарча дәшәсе килә, сатучы кызлар тәгаен безнең татар кызларыдыр кебек, ләкин сузыбрак, хәтта бераз моңлырак итеп, украин телендә сөйләшәләр. Рус телендә безгә берәү дә дәшмәде. Мин мәктәпкә кереп чыктым. Ләкин укытучылардан башка бер бала да юк иде. Җәйич, барысы да җәйге ялда. Менә шунда мин рус телендә сөйләшкән укытучыны очраттым. Бирегә күптән түгел генә, Мәскәүдән пединститут тәмамлап килгән икән. Ул безнең кай тарафлардан килүебез хакында сорашты. Мин Татарстанннан дигәч, башын кырын салып, күзгә карап торды-торды да, кызларыма күз салып алды. Шуннан соң гына:

—А вы на татар не похожи,—диде. Русия тарихын укытырга килгән бу мөгаллимә фикеренчә, барча кеше дә русларга ошаган булырга тиеш икән. Менә нәрсәгә илтә тарихны берьяклы гына итеп укыту!

Әйе, ялган тарих белән тәрбияләнгән бичара рус халкы башларына төшкән һәр бәлане татарлардан күрә һәм безне монгол яулары белән килгән татарлар дип белә. Ләкин ничек итеп аларга без монголлар кавеменнән түгел, безнең бабаларыбыз татар-болгарлар Идел буенда Атилла заманнарыннан ук көн күргәннәр һәм далаларда гына түгел, авыл-калаларда яшәгәннәр дип, тиз генә аңлатмак кирәк?! Менә нишләтә ялган тарих халыкны! Ә Русиянең тарихы «Повесть временных лет» елъязмасыннан башлана. Аны исә дүрт-биш тапкыр күчереп, төзәтеп, Мәскәү сәясәтенә җайлап язганнар. Һәм бу елъязма бары тик XVIII гасырда гына, анда да немец телендә Германиядә бастырыла. Ә үләр алдыннан Русиянең аксакал тарихчысы Дмитрий Лихачев бу елъязма хакында: «Повесть»... Русия тарихы һәм хроникасы да түгел, ә төрле гасырлардагы борынгы бәян-хикәятләрдән җыелган әдәби әсәр,» дип язып калдыра. Шул «әдәби әсәр»не ихлас тарихлары дип, йөзләрчә галимнәр вә тарихчылар—данлыклы Татищев, Карамзиннан башлап, Соловьев, Ключевский, Иловайский, Костомаров, Пушкарев, Шамбаров, Кузьмин һәм башкаларга хәтле үзләренең хезмәтләрендә беренчел чыганак итеп файдаланалар. Кая монда хакыйкать...

Менә, ниһаять, без урам-урам булып утырган, кай ягы беләндер безнең авылларны хәтерләткән кала читенә җиттек. Чынлап та, таң калмалы иде! Ин әүвәл мине шаккаттырганы һәм тәмам өнсез иткәне «Хан болыны» булды. Ә өйләр әнә шул болын туктаган җирдә күтәрелеп киткән яр өстендә утыра. Болын үзе күзләрең әсир итәрдәй еракка-еракка китә дә, зәңгәр диңгезгә барып тоташкан офык белән кушыла. Ул болын күз-күремендә шундаен тигез иде ки, күз төшүгә, күргән манзарага ышанмый торасың. Хан болыны... Исеме сакланган, ә ханнар, аларның каберләре кая? Хәер, Кубрат ханның хәзинәләрен мин күрдем инде, хәзер ул салган кала кырындагы Хан болынына карап торам.

Бу каланы Кубрат хан күлләрдә чыккан рудадан уклар ясау өчен төзеткән була. Күлләрдән руда чыгарганнар, ә руданы эретеп, тимер уклар ясаганнар... Аннары мин тарих атасы Геродот хезмәте аша да белә идем: безнең бабаларыбыз сөн-скифләр шушы болында мал асраганнар. Ул: «Скифләр көтү көтмиләр, кыш көннәрендә дә шушы болында мал асрыйлар—атлар һәм башка терлекләр, сугыш атларын яу чабарга дигәндә генә тотып өйрәтәләр,» дип яза үзенең «Тарих» хезмәтендә.

Болынны күргәч, бер тыкрыктан чыкканда, мин капка төбендә нәкъ безнең бабаларыбызча эскәмиядә утырган бабай янына туктадым. Исәнләштем, болын

турында сорадым. Янә бер нәрсәгә гаҗәпләндем, бабайның башында безнең авыл картларыныкы кебек киез эшләпә иде, кыяфәте белән дә ул безнең авыл картларына ошаган. Тик һаман шул украин телендә җырлаган сыман, сузыбрак сөйли. Бабайга мин йөз сум акча бирдем, ул чукынмады, рәхмәт әйтеп, торып басты, кулларын күккә күтәрде, ниндидер дога укыды һәм миңа бил бөкте. Сәер дә соң бу дөнья, нинди хәлләргә генә төшерми халыкларны... Аннары миңа карап: «Бог единый, сынок, мы все равны для него,»—дип, баш ия-ия безне озатып калды. Димәк, бу бабай борынгы бабаларының Тәнре алласын яхшы белә, дип уйладым мин.

Бу юлы хәтта кичке ашка да кайтып өлгерә алмадык. Булган ризыкларыбызны капкаладык та, яттык. Төшемдә мин Тимерук каласындагы картны күрдем. Нигәдер карт тоташ ак киемнән, чәчләре дә, сакалы да ап-ак иде. Ул миңа юл күрсәтте, ләкин тәгаен гына аңлатмады. Юллар барысы да синеке, кай тарафка китсәң дә, үз туган туфрагыңа кайтырсың, диюе булгандыр инде. Мин уянып киттем һәм күргән төшемне юрап тормыйча, Аллага шөкер минем машинам бар, Казаныбызга ничек тә кайтырбыз дип, үз-үземне юаттым. Карт янә күз алдыма килде, хәтердә калганы шул: машинага утырыр алдыннан карт миңа: «Бар юлларың да сине Кубрат ханга алып бара!»—дип кычкырды. Тик абайлый алмадым, өнемдәме, төшемдәме булды бу хәл? Төшемне мин беркемгә дә сөйләмәдем дә, юрамадым да. Әмма сәяхәттән кайтуга ук «Кубрат хан» романын язарга утырдым. Тиз яздым мин романны, сизми дә калдым. Аннары Мәскәүдә яшәүче Яхъя дустым Германиядә чыккан машинка алып җибәрде. Союзда эшләгәндә безгә машинка тотарга да ярамый дисәм дә хак булыр кебек, чөнки КГБ кешеләре килеп, машинкалары булган бар язучыларның да хәрефләр аша кемнеке икәнен белү өчен берәр бит кәгазь яздырып алганнар иде. Татар шрифтләре куйдыргач, мин дә язып бирдем. Шуннан соң гына «Кубрат хан» романымны машинкада басарга тотындым. Роман, әлбәттә, күп мәртәбәләр төзәтелә-төзәтелә басылды. Кульязма кульязма инде, ә машинкада чыгаргач ул башкачарак күренә икән. Төзәттем, кайбер бүлекләрен кыскарттым, ә кайберләренә өстәргә туры килде.

Ахырда «Казан утлары» журналының поэзия бүлегендә утыручы мәһабәт гәүдәле, татарлар тарихы турында бик күп белгән шагыйрь Нури абый Арслановка укырга бирергә булдым. Ул романны бик теләп алды һәм күп тә үтми укып та китерде. Мин инде бу олуг шәхес ни әйтер дип котым алынып көтеп тора идем. Ул мине кич якта, барысы да китеп беткәч, үзе утырган бүлмәгә дәшеп алды һәм бүлмә буйлап киләп сала-сала, болайрак сөйләде:

—Ошады миңа романың, Мөсәгыйт туган! Мин романыңа кайбер борынгы сүзләрне керттем. Баш тартма, килеш. Ханша ул ханбикә дигән сүзне аңлата. Борынгы болгарлар чорында ханбикәләр әле булмаган. Ә Кубрат хан образ буларак һәйбәт килеп чыккан. Олуг шәхес булып күз алдына килеп баса. Чынлап та, шул чор шәхесе. Башка образларың да уңышлы. Романдагы минем күрсәткән билгеләргә игътибар ит, яхшылап яңабаштан карап чык та, безнең журналга бир... Безне яңа бинага күчерәләр бугай, әмма моннан һични үзгәрмәс. Мин инде анда күчмәм. Журналдан китәрмен. Ә хәзер, әйдә буфетка, бераз анда сөйләшеп алыйк. Иң мөһиме, мин бу романга кул куйдым! Роман чыгарга һәм бүгенге татар укучылары кулына керергә тиеш. Кыю бул...

Буфетта без ике сәгать буена һаман роман турында сөйләштек, мин Нури абый Арсланга галим Гумилев кинәше белән Кубрат хан калаларында булып кайтуым, Харьков шәһәрендә күргән могҗизаи балбаллар турында сөйләдем. Ул барысын да хуплап, дикъкать белән тыңлап утырды. Рәхмәт аңа, романны журналга биргәч, редколлегия утырышында да ул янә минем кульязмамны яклаган. Әнә шулай барып житте татар укучысына минем беренче тарихи романым. Аннары ул китап булып чыкты. Романны университетны тәмамлагач та нәшриятнең проза бүлегенә эшкә килгән Кыям Миңлебаев редакцияләде. Ул да романны хуплады. Нәкъ шул чорда без аның белән дуслашып киттек. Кыям инде якты дөньядан китте, ләкин соңгы сулышына кадәр ул минем белән дус булып калды. Ашыгыбрак, булган хезмәтләрен чыгара алмыйча киткән Әбрар дустым Кәримуллинны теге дөньяга озатканда (без аны туган авылына илтеп күмдек) миңа бик кыен булган иде, инде икенче дустым

вә фикердәшемне дә Дәрвишләр бистәсендәге зиратка илтеп җирләгәч, бермәлгә тәмам канатларым сынгандай тоелды. Компьютороым янына утыра алмый интектем. Ә башлаган романым «Айбиби» бар, аны тәмамлыйсым килә! Әнә шулай кәефем китеп йөргәндә, миңа Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирделәр. Рус телендә чыккан «Кубрат хан» романым өчен. Ә 2008 елда «Халык язучысы» дигән исемгә лаек булдым. Бу хәл миңа янә канат өстәде, аннары мине яшь язучылар да онытмыйлар, үзләре белән очрашуларга алып чыгалар. Бу эш Берлегебезнең пропаганда бүлегенә Рәдиф Сәгъди килгәч тагы да җанланып китте.

...Әйе, әдәби әсәрләр язарга мине беркем дә өйрәтмәде. Өйрәтеп булмый торган һөнәр ул, Ходайдан килә булса кирәк. Кайчак, үз китапларынны кулыңа аласың да, аптырап каласын—мин яздыммы соң моны? Камиллектән ерак йөргән җөмләләрне күреп, хәзер болай язмас идем дип, үртәлеп тә куясың. Ләкин мин галимнәр Лев Николаевич Гумилев белән Габдраман ага Таһирҗанов, ахыр килеп Таҗикстанда очрашкан Мөхәммәтҗан имам биргән фатихаларга хилафлык кылмадым. Булдыра алган кадәр үз халкыбызның хакыйки тарихын әдәби әсәрләр аша халкыма җиткерергә тырыштым. Ә инде ни дәрәҗәдә максатыма ирешкәнмен, миңа хөкем итәргә түгел, укучыларыма. Вәләкин мин үз халкымның тарихын әдәби әсәрләр аша бирә алган кадәр бирдем дип уйлыйм.

Татар халкы тарихы бик борынгы заманнардан башлана бит. XVIII гасырларда ук татар халкының тарихына ачыклык кертергә тырышкан Ш. Мәрҗани, Г. Курсави, Х. Фәезханов, К. Насыйри, Г. Гобәйдуллин, Һ. Атласи кебек күренекле фикер ияләре татар халкын торгынлыктан вә йокыдан уятып, сискәндереп җибәрсәләр, XIX гасырда дөньяга килеп, үзенең тирән эчтәлекле хезмәтләре белән минем кебек авылда укып та, ярты гомерен урыс арасында уздырган егетне үз хезмәтләре белән сискәндереп җибәргән, хөрмәткә ия олуг галим Ризаэддин Фәхреддин булды. Ахыр килеп, борынгы бабаларыбызның тарихына әдәбиятта замандашым Нурихан Фәттах «Әтил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар» романнары аша буразна сызган иде инде. Көч-куәтем җиткән кадәр мин бу юлны дәвам иттем. Хәзер бу юлга Вахит Имамов, Рабит Батулла, Фәүзия Бәйрәмова, Равил Вәлиев, Солтан Шәмси, Марат Әмирханов кебек әдипләр аяк бастылар. Марсель Галиев тә үзенең шигъри вә тарихи мәдхияләре белән безнең борынгы бабаларыбызның данга күмелгән тарихын хиссияти-тәэсирле тасвирлауга иреште. Ул Калмык тарихчысы Эренҗән Карадауанның «Чыңгызхан» китабын татарчага тәрҗемә итеп, бастырып чыгарды. Миңа бу хезмәтнең 1991 елда Элиста шәһәрендә басылганын Лев Николаевич бүләк иткән иде. Кыймый гына рәхмәт әйтеп алган идем, ул: « Ал-ал, миндә аның 1929 елда Белградта басылган нөсхәсе бар,»—диде.

Тагын шунысын әйтим: бабаларыбыз тарихын язарга керешкәнче, миңа мөгаллимем Лев Николаевич күрсәткән бик күп тарихчыларны укырга туры килде. Әлбәттә, иң әүвәл аның үзенең хезмәтләрен. Эдуард Паркерның борынгы бабаларыбыз хуннар турында язылган «Мең ел түбән төшеп Татарлар тарихы» һәм «История возникновения великого народа,» Горальд Лэмбның «Чингизхан» хезмәте һәрдаим кулымда булды. Ахыр килеп, Русия тарихчылары В. В. Бартольд, Н. А. Баскаков, Н. М. Артамонов, Б. Я. Владимирцев, А. П. Навоцельцев, А. П. Бернштам кебек галимнәр хезмәтләре. Ә инде күкрәк киереп татарларны яклаган Л. Н. Гумилев, Мурат Аджи... Тагын Йосыфҗан кызы Лилия Тугушева. Ул IV-V нче гасырларның Атилла хан дәверендәге язмаларны укый һәм шул хакта тинсез хезмәт яза. Рәхмәт аларга. Тарихыбызны аякландырган һәм хакыйкатькә йөз тоткан хезмәтләре белән Альфред Халиков, Гайнетдин Әхмәров, Әзһәр Мөхәммәдиев, Дамир Исхаков, Гамир Дәүләтшин, Флюн Мусин, Мәсгуд Гайнетдин, Алсу Арсланова кебек белгечләр миңа ярдәм кулы суздылар. Юкса Аурупа һәм Русия иезуитлары безне тәмам тарихсыз, ерак бабаларыбызның яшәү дәверләрен тәмам эзсез итәселәр иде бит!

Һәр тарихи әсәр язучы татар әдибе халкыбыз тарихында булган хәлләрне үз ноктасыннан чыгып карый. Бу да табигый хәл. Бер үк темага берничә әсәр дә туарга мөмкин, ләкин һич кенә дә охшаш, бер сюжет, бер композиция була алмый. Аллага шөкер кылам, соңгы елларда татар әдипләре арасында борынгы бабаларыбыз тарихы белән кызыксынучылар ишәйде. Мине шунысы куандыра: галимнәребез тарафыннан

ерак гасырларга караган тарихи мәгълүматларга, археология казанышларына таянып, шактый саллы һәм объектив хезмәтләр язына башлады. Барыбыз да рухи яктан тазарып киләбез. Мина Лев Николаевич: «Тарихы булмаган халыкның киләчәге дә юк,»—дигән иде. Хак әйткән. Ә без татарлар—тарихлы халык, моңа кадәр Русия империясе мәктәп балаларыбызга хак тарихыбызны укытуны тыя килсә дә, соңгы елларда һәр татар язучысы һәм галиме «безнең бик борынгы заманнардан ук тарихыбыз булган,» дигән тезисны расларга тырышып, яңадан-яңа әсәрләр, галимнәребез хак тарихыбызга йөз тоткан хезмәтләр яза. Алар ихлас хезмәтләре аша тарихыбызның мәңгелеген расларга тырышалар. Шул исәптән мөгаллим вә мөгаллимәләребез киләсе буыннарга тарих капкаларын каерып ачырлар дигән өмет белән яши татар халкы. Еллар үткән саен Русия империясенең кул астындагы милләтләргә сәясәте үзгәреп торуга карамастан, аның демократиягә йөз белән борылачагына ихластан ышанабыз. Чөнки җир йөзендә яшәгән һәр милләтнең Ана телендә белем алу хокукы бар!

Кадерле укучым! Борынгы бабаларыбыз тарихыннан «Атилла,» «Кубрат хан,» «Илчегә үлем юк,» «Шайтан каласы,» «Хан оныгы Хансөяр,» «Аллаһы бүләге,» «Батый хан һәм Ләйлә,» «Айбиби,» «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» романнарымның берсе булса да синең кулына керә икән—ал, укы, ерак бабаларыңның тарихы белән таныш! Дөрес, минем тарихи романнарга кадәр язылган әсәрләрем дә бар, әйтик: «Җиде юл чатында,» «Икмәк кадере» дигән повестьлар, «Чоңгыллар,» «Хәтер ярлары,» «Сулар үргә акса да» дигән романнар һәм күп санлы хикәяләрем. Шул ук вакытта рус телендә Мәскәү һәм Казанда, башкорт телендә Уфада чыккан әсәрләрем, Дунай буе болгарлары телендәге «Хан Кубрат», «Сказание за Казан», «Божий дар» һәм «Владетелката на Казан Сююбике» романнарым... Лев Николаевич Гумилев белән очрашканга кадәр язылган кайбер әсәрләрем Россия укучысына барып ирешә: «Сагди», «Водовороты», «Сказание о Казани и дочери хана», «Божий дар», «Кто убил Серого»... Татар телендә укый алмаган татар кешесе минем әнә шул рус телендә чыккан романнарымны укып та борынгы бабаларыбызның хакыйкый тарихы белән танышыр дигән өмет белән яшим. Үз халкының тарихын белмәгән бала бик тиз милли рухын, милли йөзен югалта. Һәм үз халкының тарихын белмәгән, бабалары рухы белән яшәмәгән балалар, милли тамырсыз калып, өметсезлеккә бирелүчән булалар, еш кына яман язмышларга дучар ителә. Мин беләм һәм киләчәкне бераз шулайрак күзаллыйм: безнең халык дустанә-тату һәм гадел-тигез рәвештә Русия белән яшәү җаен табар, дөнья халыклары белән аралаша-аралаша, үзара сәүдә итә-итә көн күрүгә ирешер. Килер ул көн, килергә тиеш! Чөнки без зур тарихлы халык! Иң мөһиме: уй-теләкләребез, кылган гамәлләребез изге, киләчәгебез өметле.

***

... Бер баруымда тарих турында бик озак сөйләшеп утыргач, Лев Николаевич китап тулы шүрлекләренә карап болай диде:

—«Бабаларының тамгасын, телен, динен, тарихын белмәгән кеше — туфраксыз-сусыз тилмереп корыган агачны гына хәтерләтәчәк... Мин татар тарихчыларына шуны гына әйтә алам. Үзләштерегез, языгыз бабаларыгызның бай тарихын! Мин сезгә юл ярдым инде. Хәзер ашыкмый гына дәвам итегез—барысына да ирешерсез...

—Сез болай да тауларны актардыгыз, Лев Николаевич, тауларны! Безнең халык үз тарихына сезнең исемне алтын хәрефләр белән язачак. Мин болай да сезнең хезмәтләрегезне укыганда төрки-татарларның ат кешнәүләрен ишетәм...

Әле дә булса күз алдымда: ул миңа үз итеп, елмаеп карады һәм:

—Чәйләп, зиһеннәрне сафландырып алыйк әле!—дип, кухняга таба кузгалды. Мин аның артыннан иярдем...

# ТӨП ГЕРОЙЛАР—ШӘҮЛӘЛӘР, КОРТЛАР...

Унышлы иҗат җимешләре белән әдәбият сөючеләр арасында танылып, күпләр өчен якын таныш булып өлгергән, каләме чарланган язучы яки шагыйрьнең яңа әсәре белән «Казан утлары» аша танышкан яисә өр-яңа китабын кулына алган укучы, мөгаен; «карап-карыйк, әдип бу әсәре белән безгә ни әйтергә теләде, үзен кайсы яктан күрсәтә алды, таланты ничек ачылды?» диебрәк уйламый калмыйдыр. Яңа әсәр яисә китап бу каләм иясенең иҗат юлында бер үсешме, күтәрелешме, әллә яулаган дәрәҗәсендә тукталыш ясап бер тын алуымы, дип тә уйларга мөмкин ул. Эчтәлеге, тема тирәнлеге ягыннан да, җисеме-күләме белән дә саллы-саллы проза әсәрләре биреп өлгергән Факил Сафинның күптән түгел дөнья күргән роман һәм хикәяләр мәҗмугасы да укучыларда шундый кызыксыну тудырмый калмагандыр.

Бу китап андагы бердәнбер роман исеме белән «Шәүлә» дип аталса да *(Татарстан китап нәшрияты, 2008)* сәнгатьлелек ягыннан әлеге әсәрне җыентыктагы иң унышлысы дип кистереп әйтү читенрәк. Болай килеп чыгуның бик аңлаешлы сәбәпләре дә бар. Ил тарихында иң дәһшәтле, иң фаҗигале һәм иң каршылыклы утыз җиденче еллар вакыйгаларын Факил Сафин бераз гына элегрәк «Саташып аткан таң» трилогиясендә шактый тирән яктырткан, үзенең төп сүзен әйткән иде инде. Шуңа күрә, авторның шул темага кабат әйләнеп кайтуы (яки аннан китә алмавы), бу очракта зур әсәргә эпилог яисә постскриптум өстәп язу кебегрәк тәэсир калдыра. Беренче әсәр каһарманы Дәүләтъяров белән икенче романдагы Рабига Сарымсакова бер үк чорда яшәп, бер үк явызлык шаһитләре булсалар да, роман герое иткәчтен ирле-хатынлы бу икәүне тиңләштерү, әсәрләрнең укучыга бер үк дәрәҗәдә тәэсир итәчәгенә исәп тоту мөмкин түгелдер инде. Шуны күздә тотып микән, Рабига Сарымсакова романның бер урынында да алгы планга чыгарып гәүдәләндерелми, авторның моңа фактик материалы да житми. Рабиганың тоткынлыкта язылып, кырык тикшерү узып килгән хатлары да, романның байтак өлешен биләүләренә карамастан, аны вакыйганың үзәгендә гәүдәләндерүгә әллә ни булышмыйлар. Ике улы тырышып эзләп, әниләренең каберен дә таба алмыйлар хәтта, кая анда миллион-миллион явызлык корбаннарының берсе хакында роман итеп язарлык дәлилләр юнәтү! Илне каплап, буып алган коточкыч җәлладлар челтәре үзенең ни кылганын, нинди зур җинаятькә барганын ачык аңлаган һәм эзен дә яшерә белеп яшергән. Каберләрен билгеләп кую түгел, кайбер корбаннарының исемен дә кәгазьгә теркәп тормаганнар. Минем Габдерәшитов Шәрәфетдин бабайны, репрессия корбаннарының «Хәтер китабы»нда әйтелгәнчә, ярлы игенчене, кулак төркемендә катнашкан өчен, дип, беренче тапкыр 58-11 матдә белән 1931 елда 71 яшендә кулга алганнар да, гаебе расланмау сәбәпле (ярлы игенче ничек инде кулак төркеменә керсен?) , 1932 елда эшне туктатканнар. Шуннан соң, бер авылдашы белән бергә, аның кабат алып китеп юк ителүе хакында беркайда берни язылып та калмаган.

Факил Сафин, әлбәттә, Ходай биргән таланты, әдиплек күзаллавы белән, Рабига Сарымсакованы калку күтәреп, чып-чын роман каһарманы итеп тә сурәтли алган булыр иде. Әмма ул, күрәсең, «Саташып аткан таң»нан соң Рабигалар, сәяси золымның бүтән корбаннары «яшәгән» чор, мохит, тиңдәшсез золымны тудырган шартлар хакында өр-яңа сүз әйтә алмаячагын аңлагандыр һәм, нәкъ шуңа күрә, мондый талпыныш та ясамагандыр. Билгеле, шул темалар буйлап романнан-романга отыры тирәнгәрәк төшү, «тамырына карау» мөмкинлекләре дә юк аның. Аерым бер татар әдибенең чикләнгәнлеге, сайдан йөзүе генә сәбәп түгел моңа: бөтен цивилизацияле дөньяның котын алган тиран феноменын (нинди кыю «Азатлык» радиосын да Сталин үлгәч кенә ачарга батырчылык иткәннәр), андый явызның ил

башына күтәрелү сәбәпләрен Россия хакимиятенә якынрак торып, берара архивларда да иркенрәк эшләп (хәзер ул иркенлекләр кабат чикләнә бара, диләр) иҗат иткән яһүд һәм рус язучылары да тәмам ачып бетерә алмады әле. Мөгаен, әлеге «феномен» «акыл белән аңлап булмый торган» ил халкының үзгә сыйфатына, хәзергечә әйтсәк, менталитетына нык бәйледер. Югыйсә, «гаделлек һәм тигезлек, якты киләчәк хакына» Сталинны каберennән торгызып ил башына кайтарырга хыялланучылар болай ук күп булмас иде. Сталинны революция тудырды, дип, мәсьәләне берьяклы аңлатырга маташучылар да каты ялгышалардыр яисә, түнтәрелешләр аша бәхетле тормышка тиенү өметеннән халыкны биздерү өчен (аңысы ярый да әле!), күрәләтә алдашалардыр. «Бөек» Тиранның Явыз Иван, шашкын Петр кебек әлгәрләрен тәхеткә революция китермәгән ләбаса! Сталин репрессияләренең иң элек чын революционерларга карата кулланылуы да күпне аңлата.

Әмма, мөмкинлеге чикле булса да , Факил Сафин кебек әзерлекле, киң карашлы әдип романга алган зур темасын да, Рабига Сарымсакова ише миллионлаган дәһшәт корбаннарының фаҗига сәбәбен дә тирәнрәк ачарга омтылмыйча кала алмый, билгеле. Әлеге очракта әсәр авторы моңа шактый үзгә юлдан бара—романга бик үк табигый булмаган Шома кушаматлы персонаж кертә. Алай гына да түгел, аңа Шәүлә дип, характерлы икенче исем бирә, романны да шул исем белән атый, димәк, аны әсәрнең баш каһарманы итә, «Саташып аткан таң»да әйтелеп бетмәгән «яңа сүз»не дә шушы Шәүлә әйтергә тиеш була. Әлбәттә, реаль Рабига Сарымсакова вакыйгасына «баш» итеп конкрет булмаган, фамилиясез, чын исемсез Шәүләне кую, бер яктан, автор фантазиясенә киң ирек бирә: ул безнең тиңдәшсез бәла-казалар сәбәпчесен күз алдына китергәнчә, кара буяуларны җәлләмичә сурәтли ала. Шәүлә генә булса да, нәкъ тормышыбыздагыча, ул бик үк көчсез дә түгел: әсәрдә аңа каршы куелган Язучы үзенең һәр адымында диярлек Шәүлә күзәтүен сизеп җайсызлык, тарсыну кичерә, Шома үзе горурланып уйлаганга, «Шоманы үтеп бер генә эш тә эшли алмый.» Әниләренең каберен эзләп табып баш ию нияте белән йөрүче Марат белән Марлис Дәүләтъяровларның да кәефен кыргалап тора Шәүлә. Кыскасы, романдагылар һәркайсы аның барлыгын тоярга, аның белән азмы-күпме санлашырга мәҗбүр һәм мондый халәт Шоманың яшәү мәгънәсенә бик тә туры килә. Уен кагыйдәсен ул билгели бит! Язучы хәтта бер урында Марат Дәүләтъяровка: «Шома Оешмада хезмәт итеп шымчылык, башкаларны сату, яла ягу мәктәбен үткән. Һәм шул бәндәне сөйләп, күңелне пычратмыйк»—дисә дә, әледән-әле юлына аркылы төшеп торган Шәүләне «күрмичә» үтә алмый, әсәрендә аның хакында кайта-кайта сөйли, укучыларыннан да «Шәүлә-Шәүлә» дип гел кабатлаттыра, исемен Рабига Сарымсакованыкыннан да алгарак, җитди роман башына чыгарып мәңгеләштерә, сатирик әсәр персонажы гына булырлык «бәндә»дән заман герое ясый. Кыскасы, үзен татарның Ромен Ролланы, Брехты, тагын әллә кемнәре дип хис иткән, «исемем тарихта калырга тиеш» дип лаф орган Шоманың шул хыялын гамәлгә ашырырга булыша автор. Аңа артык зур хөрмәт күрсәтүен абайламый, күрәсең.

Ләкин, икенче яктан, Факил Сафинның Шома-Шәүләсе тарихта тиңнәре аз булган зур Явызлыкның—кабатлана күрмәсен, Ходаем, дип, искә төшкән саен теләк теләтерлек Золым Һәм Җаһиллекнең—мең шәүләләреннән бер сынары гына. Аны хәтта әллә ни гаеплисе, илкүләм фаҗигаләрнең төп сәбәпчесе дип таныйсы да килми. Ил-көнгә, яшәеш кануныбызга Явызлык хуҗа икән, аңа хезмәт итүчеләр һәрвакыт табылачак. Хуҗалар кем һәм нинди генә булуга карамастан, аларга каршы баруны динебез дә хупламый түгелме соң? Романда телгә алынган Оешма да үзеннән-үзе тумаган, аны Хуҗа бар иткән. Шундый Оешма яши икән, аңа хезмәт итүчеләр бетмәячәк, киресенчә, аларга гел ихтыяҗ туып торачак. Дөрес, «иблис хезмәте»ндәгеләр азрак булса, Баш Иблис үзенең мәкерле кара эшләрен шулкадәр үк җәелдерә алмас, корбаннар да күп миллионнарга китмәс иде. Әмма, барыбер, зур Явызлык гәүдәләнеше буласы урынга, аның бер шәүләсе генә итеп сурәтләнгән Шома бу роман өчен шактый кечкенә булып тоела. Хәтта аның белән булашкан Автор да элекке роман-трилогиясендәге Әхмәтсафа Дәүләтьяровлар, Шамил Усмановлар, шагыйрь Такташлар, Мусалар мохитендә «яшәп алган», аларның кайберләре белән бергә Оренбурның шанлы мәдрәсәсендә «укыган»,

соңрак Казанның НКВД камераларына «төшкән», каһарманнарының какшамас рух ныклыгын җаны аша үткәреп, шулар белән бергә үзе дә рухи үскән гыйлемле, киң карашлы әдиптән шактый аерыла кебек. Кызганыч, Ф. Сафинның әлеге «Саташып аткан таң» әсәре җәмәгатьчелектә лаек бәясен алып житкермәде әле. Татар әдәбиятында андыйлар ел саен языла икән, диярсең!

Өстәвенә, Шәүләне роман авторы үзенә бик яхшы таныш булган, ләкин «женнәре килешми» торган реаль шәхескә нык ошатып детальләштерә, ә бер «детале»—аның зур таланты—күрсәтелмичә кала. Чөнки бездә, гадәттә, Ходай үзләренә талант бирмәгәнгә, талантлыларны куралмый торган хөсетле җаннар гына аларга явызлык кыла, дигән берьяклы караш яши. Бу исә Шомаларның женле холкын ачарга, бүтәннәргә этлек эшләүдән ничек ләззәт алуларын аңларга комачаулый. Илнең иң асыл затларын планлы төстә меңәрләп юк иткән Сталинның (бу хакта, Тиран имзасы белән, һәр республикага һәм өлкәгә лимит җиткерелгән) залимлек чыганагын аның талантсызлыгы, көчсезлеге, шуна күрә үзеннән булдыклыларны кырып бетерүе белән аңлатырга маташу көлке булыр иде. Анда бит Аллаһка да баш бирми торган Иблис куәте, Иблис таланты һәм мәкере! Факил Сафин да, Шәүләнең ятышсыз холык-фигылен, шайтани гамәлләрен аңлатканда, артык тирәнгә кермичә, шушы гадирәк юлны сайлаган. Нәтиҗәдә Иблиснең үзе итеп гәүдәләндереләсе зат (каһарман) гап-гади бер вак җанга—бөеклек хыялында унмаган, талантлылар арасында үз урынын таба алмаган хөсетле шәүләгә калдырыла. Гадәти бер әдәби әсәр өчен ярарлык булса да, үтә сирәк языла торган, ил-халыкның иң фаҗигале тарихына багышланган роман өчен бәләкәй бу. Мондый гына герой аерым бер Әхмәтсафа Дәүләтъяров яисә Рабига Сарымсакова язмышын бик каты бутап ташлый алса да, зур-зур илләр халкының, милләт кадәр милләтләрнең коточкыч фаҗигасен башкарып чыга алмас идедер. Автор Шоманы роман азагында исән-сау, үз көчендә, бер җәзасыз калдыра. Менә да, мөгаен, аның «натурадан», ягъни, үзе тапкан прототиптан «китә» алмавы сәбәпчедер. Әмма биредә тормыш дөреслеге дә юк дип булмый шул...

Автор «шәүлә»не шулкадәр үз итә, башка әсәрләрен язганда да бу төшенчә, бу атама аның каләменнән тамып төшәргә генә тора. «Һәр утыргычта бер-ике шәүлә шәйләнә»—дип яза ул «Гөлләрем, сиреннәрем...» хикәясендә. «Ара-тирә урамның бер янындагы күршенең каршы яктагы шәүләгә дәшеп алулары ишетелеп киткәли»—дип дәвам иттерә шунда ук. Хәер, Әхмәтсафа Дәүләтъяров, Рабига Сарымсакова кебек миллионнар фаҗигасен, шул фаҗиганең ил өстендә әлегәчә сакланган һәм мәңге сакланачак, кара күләгәсен байтак өйрәнүе һәм күңеленә бикләве Факил Сафинның башка әсәрләрендә дә сизелеп-сизелеп ала. Һәрхәлдә, «Шәүлә» җыентыгындагы берничә хикәясендә автор, үз каһарманнарының тормыш юлын сурәтләгәндә, «теге еллар»ны телгә ала.

Китаптагы «Гөлләрем, сиреннәрем...» хикәясе, минемчә, арада иң уңышлысы, теле белән дә, җанлы булып күз алдына килә һәм истә кала торган якты күңелле гап-гади геройлары белән дә «моны оста каләм иясе язды» дип кычкырып тора торганы. Автор «Шәүлә»дәге Шома, аның «әдәби» фикердәшләре, Мәдияләр белән әвәрә килүдән күләгәләнә башлаган күңелен сафландырырга, укучыны да авыр кичерешләрдән беркадәр арындырырга теләгәндәй, моңлы җыр сүзләре белән исемләнгән бу хикәясендәге Хәсбиулла белән Әкълимәне дә, Әхмәди картны да шулкадәр яратып сурәтли, аңа ихластан ышанасың, тирә-ягында шундый кешеләр барлыгына сөенеп туймыйсың, укыганда алардан аерыласы да килми. Фәрештә дә, әүлия дә түгел үзләре. Яшьлегендә күзе төшеп йөргән Әкълимә карчыкка да, Әхмәди абзасына да «ямьле яшәдек, матур яшәдек, әйеме, бу дөньякайларда» дисә дә, Хәсбиулла узган тормышын исенә төшергәндә җырлый да, елый да. «Теге елларда» юк кына гаебе өчен каба да язып калган, ярый әле уполномоч Хәйри белән милиция Гатау эләктерүдән алда Әхмәди кисәтеп өлгергән. Әле дә, үзе әйткәнчә, капчыгы буш түгел: улы ят кавемнән өйләнгән, килене үз балаларын Хәсби йортына кайтармый. Оныкларын күрәсе килүдән Хәсбиулланың үзәкләре бер өзелсә, барып күргәч муеннарына асылган тереләр җанын икенче сыкрата. Менә әле дә Сандр авылыннан, оныклары янынан кайтып килеше аның. Шуңа җырлый да. «Гөлләрем, сиреньнәрем лә...»

«Хат ташучы» хикәясендәге Әлфәтне дә, мәрхәмәтлелеге, киң һәм хөр күңеллелеге

ягыннан, «Гөлләрем, сиреньнәрем...» геройларына тиңләп булыр иде. Ләкин бусы—яңа заман, безнең чор кешесе. Тормышында Әлфәт юлыккан гаделсезлек тә—безнең көннәрнеке. Әмма бу гаделсезлек Әлфәтнеке генә булып калмый, таралып бетеп бара торган Урманасты авылының барлык әби-бабайлары өчен бәлагә әверелә. Автор, сүзләр ярдәмендә, хикәянең мәгънә йөген, тәэсир көчен шулкадәр тыгызлый, аңа героеның характерын тулы ачу өчен Әлфәтне Урманасты кешеләре белән бер күрештерү җитә. Әле шул арада авылның фаҗигаләр тулы үткәнен дә күз алдына китереп өлгерәбез. Әлфәт урынына эшли башлаган яңа хат ташучы да, безне үзе белән таныштырудан бигрәк, әсәрдәге баш геройның күркәм сыйфатларын яхшырак күрүебезгә булыша.

«Тулганай» хикәясендә автор бик күп бәла-казаларыбызның сәбәпчесе булган явызлык, бәгырьсезлек күренешен мал табибы Шәүкәтнең, «теге еллар» күләгәсе булып калган сәвит Фәсхинең бер эткә мөнәсәбәте аша җаннарга үтәрлек итеп сурәтли. Бу алым, билгеле, Факил Сафинның гына ачышы түгел: соңгы еллар эчендә генә дә без моңа охшаш хәлләрне Флүс Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга», Рәшит Бәшәрнең «Акбалык» әсәрләрендә очраткан идек инде. Шәүкәтләр, «Бәйсез этләрне атарга»дагы милиционер, «Акбалык»тагы Ибәтләр һәммәсе дә Шоманың күп тармаклы өереннәндер, мөгаен. Бу өч әсәрне тагын бер нәрсә нык бәйли: өчесендә дә җан өшеткеч вакыйгалар балалар күз алдында бара һәм балалардан сөйләтелә, өчесендә дә тигезсез көрәштә «шәүлә»ләр җиңүче булып кала. Шуңа күрә, укып байтак вакыт үткәч тә аларны онытып булмый. Җаннары җәрәхәтләнү ул балаларны кая, кемнәр ягына алып барыр? Шомлы Шәүләләр өеренә китермәсә ярый ла. Әдипләр безне нәкъ шул хәтәрлектән кисәтә бит.

***

Искиткеч талантлы сеңлебез Фирүзә Җамалетдинованың «Догалы корт» повестын «Казан утлары»ннан укыгач та, бу сокландыргыч әсәрнең исеме повестьның шәплегенә торырлык түгел, минемчә, диебрәк авторның үзенә дә әйткән идем. Повесть кешеләр, кеше күнелләре хакында бит, хәтта догалы булса да, кортлар турында түгел. Автор, әлбәттә, бер укучысының ялгыз фикере белән килешмәде, «киресенчә, бу исемне хуплаучылар күп булды» дип белдерде, соңрак ике повестын һәм егермеләп хикәясен эченә алган китабын да шул исем белән атап дөньяга чыгарды *(Татарстан китап нәшрияты, 2007).* Мин исә һаман да «дога» һәм «корт» төшенчәләрен бергә куша алмыйм. «Корт» дигәндә, файдалы һәм игелекле бал кортлары гына күз алдына килми бит әле. Ул мәхлукларның ниндиләре генә юк! «Кортка агу сибә-сибә тәмам күзләр сукырайды минә» дигәндә, китаптагы «Ишетәсеңме, байгыш?» повестының бер персонажы да «корт» төшенчәсен үзенең туры мәгънәсендә генә куллана. Әсәрдә дә «Корт» догасы турында сүз бара, димәк, беренчел мәгънә «дога» төшенчәсенә салына. Ә китап исемендә мәгънә үзәге «корт»ка күчә. Повестьның үзегендә исә мондый алмашыну күзәтелми: корт—корт урынында, кеше—кеше урынында. «Ходай кортка да, җан иясе итеп, дога индергән икән, адәм балаларын хәер-фатихасыннан һич тә ташламас»—ди Илгизәнең әбисенә бер остабикә.)

«Кортка да» дию әнә шул урыннарны ачыклап-аерып бирә дә инде: ул кешегә тиңдәш була алмый! Монда дога Ходай тарафыннан чынлап та корткамы, әллә «Корт» исеме белән кешеләргәме индерелгән, дигән сорауга да урын кала. Ятимә Илгизәнең укучы җанын да яктыртырлык күңел балкышлары һәм тормышның кара, өметсез чакларында да каралмыйча кала алуы да аның үзендә әбисе биргән «Корт» догасы йөртүеннән, дөресрәге, ул йөрткән доганың нәкъ менә «Корт» исемле булуыннан түгел, яшьтән догаларга, изгелекләргә тартылып, кайчандыр мулла булган ерак бабайларының рухын саклап яшәргә өйрәнүеннән, ләбаса. Янында дога йөрткәч, автор, бәлки, повестьның баш каһарманы Илгизәне догалы корт итеп күз алдына китергәндер, шул сәбәпле әлеге сүзләрне әсәр башына чыгаргандыр? Анысы да аңлашылып җитмәс иде, чөнки Фирүзә сеңел үзенең ак күңелле каһарманын бик яратып, бүтәннәр дә яратырлык итеп сурәтли, кая аны ниндидер бөҗәккә тиңләү! Әсәрнең соңгы җөмләсендәге күренеш—Илгизәнең әбисе җирләнгән зиратта бер каен кәүсәсе буйлап «тартыла-сузыла ап-ак кортның югарыга, кояшка таба» үрмәләве дә—укучыларның һәммәсендә автор көткән тәэсирне («Сөбханалла» ди Илгизә, аңа исе китеп) уятмагандыр...

Ә повесть—китапның нибары 64 битен биләгән, эчтәлеге белән бик заманча булган, язылышы, камил теле, героеның хис-кичерешләрен монга төреп, үзәкләргә үтәрлек ачып бирүе белән әдәбиятта Әмирхан Еникиләр иҗатын хәтерләткән әсәр—һәртөрле хуплауга лаек, ул Фирүзә Жамалетдинованы бүгенге татар прозасының аз санлы әйдәманнары—Марат Әмирханы, Факил Сафины, Камил Кәримовы, Зиннур Хөснияры, Мәдинә Маликовасы, Фәүзия Бәйрәмовасы, Рәмзия Габделхаковасы... белән бер рәткә куя. Хәер, Фирүзәбезнен шагыйрьләр арасында да үз урыны бар инде. Бәлки нәкъ менә шагыйрьлеге ана Илгизәнең изгегә, шәфкатькә тартылган жанын, күңел тирбәнешләрен шәп шигырьләрдә генә була торган нәфислек һәм нечкәлек, илаһи моң белән ачып бирергә ярдәм иткәндер. Монда бүгенге әдәбиятыбыз өчен тагын шунысы кадерле: догалы, миһербанлы әсәрдә Илгизә өчен генә хас булып калмый, мондый сыйфат татар хатын-кызларының һәммәсенеке итеп сурәтләнә, һәрхәлдә, Илгизәне белүчеләрдә шундый тәэсир кала. Чит илдә Илгизә ялланып карап торган грек карчыгы, аның иленә кайтып китәсен белгәч, агентлыктан үзен карарга «татар кызын җибәрсеннәр» дип ялвара. Повесть аша Илгизә белән танышкан, аны үз иткән, авторга ихлас ышанган (ышандыра белә, чөнки) укучы чит милләт әбекәенең бу ялваруын аңлап, табигый кабул итә. Хәер, төрле-төрле чит милләт ир-егетләренең сайлап-сайлап татар кызына өйләнүен дә гел хуплап торган көнебез безнең, алардан туган балаларны да үзебезнекеләрдән ныграк үз итәбез.

Әдибәнең «Ишетәсеңме, байгыш?» повестындагы Фәрзәния дә—бар адашулары, кыйбласызлыгы аркасында, үзе кебек үк бәхетсезләрдән өсте-өстенә алданулары белән, нәкъ үзебезнеке, бүгенге татар кызы. Изгелекләр, олыларның акыллы сүзе бөтенләй санга сугылмый башлаган чоңгыллы чор баласы Фәрзәния, әгәр акылына килсә һәм, әйтик, шигырь яза башласа, Илдар Юзеев сүзләре белән, бәлки, «Үрнәк түгел, миннән була—Бары гыйбрәт алып» дияр иде. Автор аны әсәр азагында да үзенең коточкыч адашуларын аңламаган, тәүбәгә-иманга килмәгән кызганыч хәлендә калдыра һәм бу бик табигый кабул ителә. «Менә шушындый татар кызы булса иде» дип, эшкә дә, тормыш итәргә дә аны беркем кирәксенмәячәк инде. Әнисенең генә аның өчен үзәге өзелә. Ярый әле олы кызы, Зәһирәсе, бар, ул Фәрзәния ише түгел. «Сезнең чорда секталары да, пирамидалары да ишетелгән әйбер түгел иде... Сез бит әбиегезнең намаз укыганын күреп үстегез»—ди Җәүһәрия олы кызына, сеңлесенең бәлагә тару серен төшендереп.

Фирүзә Жамалетдинова китабын уку барышында бер нәрсәгә исең китеп уйланасың: тирә-ягыбызда гыйбрәтле язмышлы кешеләр бик күп икән ләбаса. Күңел күзләребез белән күреп кенә житкермәгәнбез аларны. Әдибә сеңлебез үз геройларының берсен дә уйлап чыгармаган, ышандырырлык, һәрберсен арабызда тоярлык итеп сурәтләп кенә биргән. «Васыять» хикәясендәге Марияне дә, «Почтальон, карт һәм мәхәббәт»тәге Мәсрүрә белән Хәмидулланы да, хәтта «Җинү» хикәясендәге «сәер» Картны да янәшәбездәге кешеләр арасыннан тиз танып була. Командаларында татарлар күбрәк булган өчен, «Безнекеләр булдыра!» дип, каршы якның җиңүен хуплаган Карт бигрәк тә үз безгә. Нәкъ шул ягыбыз белән, футбол карарга өерләре белән килгән «хуҗалар»дан аерылабыз да. «Безнең алда әле»—ди киләчәктән өметен өзеп бетермәгән карт. Зур сугышта җиңүенең әҗерен күрмәгән үзе, милләте өчен кирәкле йомыш белән дә «хуҗалар» ишегең үтеп керә алмый, шуларга бер сүз кушарга җай эзләп футбол кырына йөри. «Буранда» хикәясендәге Ана белән аның улы мөнәсәбәте дә Әмирхан Еникинең «Матурлык» әсәре югарылыгына күтәреп, хәтта ки теләсә кем аңлый алмаслык дәрәҗәгә житкереп сурәтләнә.

Хәер, хыялдан мәхрүмнәр, җаннарында әдиплек булмаганнар өчен Фирүзә Жамалетдинованың риваятьләргә, тылсымлы дини кыйссаларга аваздаш әсәрләре гайре табигый булып күренергә дә мөмкин. Чөнки аларда вокзаллар да, кояш нурлары да сөйләшә, байгышлар гыйбрәт сөйли, дога сүзләре дә, гармун моңы да, ана мәхәббәте дә кешеләр белән могҗизалар эшли. Монысы кабул ителә. Тик, шулай да әдәбият, китап сүзе халыкның дине дә, тормышчан да әдәбеннән аерылмасын һәм әдәби әсәр каһарманы билгесез шәүләләр, реаль булмаган изгеләр күләгәсендә кала күрмәсен.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ.**

# САБАНЫҢ СУЫНДА БАР...

Рөстәм Зарипов беренче әдәби чирканчыкны Саба районыбыз газетасы битләрендә ала. IV класста укыганда аның «Галләм маскасы» исемле шигыре СССР Язучылар берлеге әгъзасы Газиз ага Нәбиуллин хәер-фатихасы белән «Җиңү байрагы» битләрендә дөнья күрә. Игътибар итик, бу—житмешенче еллар, Африка кыйтгасында яшәүче халыкларның бер-бер артлы азатлык алып, мөстәкыйль дәүләтчелеккә ирешкән заман. Безнең Рөстәмебез нибары ун яшьтә язган шигырен коллыктагы халыкларның азатлыгы темасына багышлый:

*Яңа ел җитте, бүген зур бәйрәм.*
*Бик күптән көтте пионер Галләм.*
*Шатлана Галләм, маскасы әзер.*
*Маскасын киде,—негр ул хәзер.*
*Кулында аның өзелгән чылбыр.*
*Ул халык көчен күрсәтеп торыр.*
*Шуны аңлата Галләм маскасы,*
*Шуны белдерә дөнья картасы!*

1976 елгы «Идел» альманахында Рөстәмнең «Аууу!» исемле тәүге хикәясе басылып чыкты. Әлеге әсәр дөнья күрү уңаеннан «Татарстан яшьләре» газетасында тәнкыйтьче Наис Гамбәрнең әтрафлы мәкаләсе дөнья күрде. Ул анда Марсель Галиевнең «Кар абагалар» повестенә һәм Рөстәм Зариповның «Аууу!» хикәясенә аерым тукталып, якташым язган әсәрне һәр яктан уңай дип бәяләгән иде.

Әсәрнең сюжеты гади генә. Егет белән кыз яратыша. Аларның мәхәббәт тарихы каладан авылга кунакка кайткан Сафа атлы малай авызыннан хикәяләнә. Болар, өчесе, урманда җиләккә дип барып, адашып «Ауууу» дип кычкырышып йөриләр. Тора-бара Әлфинур белән Һади кавышып, үз йортларын булдыралар һәм алмагачлар утыртып яшәп китәләр. Көтмәгәндә Һади һәлакәткә юлыгып, дөнья куя. Еллар уза, Әлфинур икенче кешегә кияүгә чыга, балалары туа, гәүдәсе тазара, йортларын зурайтып төзекләндерәләр, күп итеп мал асрыйлар, агач бакчалары матурланып, урманны хәтерләтә башлый, ә теге малай инде егет булып боларга кунакка кайткач, әлеге бакчага чыга һәм үткәнне искә төшереп «Аууу, аууу, апа!» дип кычкырып җибәрә. Апасы абзарга ябарга азапланган башмак тана, ычкынып китеп ишегалды буйлап чабуларга керешә. Менә Әлфинур апасының арган, шелтәле тавышы яңгырый:

—Шаярма әле, Сафа, хайванны куркытасың бит!...

Оста тәмамлаган автор хикәясен! Монда юмор да бар, сәнгать һәм тормыш дөреслеге дә ярылып ята. Мин бу хикәяне Татарстан радиосыннан танылган актер Равил Шәрәфиев укуында ишеткәнем булды. Тагын шул ук затлы радиобыздан Празат ага Исәнбәт тарафыннан аның «Сабан туе» исемле әсәре яңгыраганы хәтердә. Егетнең саф мәхәббәте белән башланып киткән хикәянең азагында гашыйк шул егет белән каладан кайткан үткен кыз «тавык тизәкләре ябышып каткан баскыч»тан печәнлеккә күтәреләләр... Менә бит нинди «күтәрелү!» Шушы бер деталь ярдәмендә Рөстәм Зарипов күкләргә, йолдызларга укталдырган укучысын гөнаһлы җиргә «тып» итеп бастыра да куя.

Аның «Алтылы чыбык» дигән хикәясе район газетасында дөнья күргәч, бер

хөрмәтле иптәшкә әлеге атама ябышты да калды. Һәм шуннан соң, Рөстәмебез әлеге җитәкче чакыруын кабул итеп, аның белән бергә эшләп алганы да истә.

Рөстәм Зарипов—бүген дүрт китап авторы. Аның шигырьләре, хикәяләре, эссе, новеллалары, фәлсәфи мәкаләләре һәм хәтта «Ни мамык, ни каурый» исемле пьесасы басылып чыкты. Пьесада бер үк шәхесне ике «мин» гәүдәләндерә, беренчесе теләсә кем күзенә күренә торган «мин», ә икенчесен бик сирәкләр, шул «мин»е тәмам яньчелгән булачак текә түрәләр генә күрә башлый. Әсәрдә менә дигән мәһабәт гәүдәле шәп җитәкченең һәм аның чибәр секретарьшасының икенче «мин»нәре берсе җен, икенчесе убырлы карчык рәвешенә кергән. Карьера ясау хакына дәвамлы түбәнсенүләр шул хәлгә китергән аларны.

Рөстәмнең хикәяләрендәге каһарманнар беренче карашка кызганыч, бәхетсез һәм көчсез кебек. Алда, пьесада үткәрелгән фикер ызанынннан китсәк, беренче «мин»нәре шундый. Ә инде икенче «мин»нәре менә дигән хәлдә. Автор геройларының кешелеген бәхеткә тиенгән яки сагышка баткан чакларында ача. Бу җәһәттән «Сине сөйдем, гүзәлем» хикәясе үтә дә гыйбрәтле. Ярымйорты акыллы егет, көч хәл мәктәпне тәмамлап, көтү көтә башлый. Әнисе өч хәрефле яман чирдән вафат була. Әмма үләр алдыннан, күрше авылда яшәүче үтә дә коры холыклы яшьлек дустына барып:




—Бир минем улыма кызынны,—дип үтенергә өлгерә.

Һәм янәшә тирәдә чибәрлеге белән дан тоткан Гүзәлия боларга килен булып төшә. Әмма ул, әтисе сүзен хаклап Габделнурга кияүгә килсә дә, сөйгәне белән арасын өзми. Габделнурны алдап-йолдап ничәдер көн торгач, сөйгән яры белән китеп бара. Габделнурны янадан өйләндерәләр һәм бераз гына «ялгышкан», Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, почти кыз булган, әмма шулай ук бик чибәр нәрсә туры килә. Монысы китәм дип тә йөрми, аны бик зурлап яши. Балалары туа. Әмма тәүге җәмәгате Гүзәлияне дә оныта алмый икән. Мәҗлесләрдә җырларга кушкач, ул гел «Яшьлегем» җырын суза. «Яшьлегем чәчәк атканда, сине сөйдем эһэһем»,—дип җырлый. «Эһэһем» ди, ягъни гүзәлем дип әйтми, хисләрен әнә шулай авылдашларыннан һәм хатыныннан яшермәкче була. Рөстәм әлеге образны яратып, һәм укучыны да яраттырырлык итеп тасвирлый, кешелеклелеген, күңеленең матурлыгын ачып бирә алган.

«Тозлы яңгыр» хикәясе сагышларга да батыра һәм күз яше аша юмор кояшы нурларына да коендыра. Авылның беренче гүзәле «үз фамилиямдә калам» дип йөри торгач, тора-бара «утырып» ук кала. Күрше авылда яшәүче йомыкый, әмма оста куллы диндар егет колхозда бухгалтер булып эшләүче шушы кызны кияүгә сорый. Өйләнешкәнгә кадәр какшау өстәлен һәм урындыгын, ачылса ябылмый, ябылса ачылмый интектергән тәрәзәсен төзәтеп бирә. Бу эш төрләре башкаруга символик мәгънә йөге дә салынган, әлбәттә, чөнки бергә яшәп киткәч гүзәлкәйнең какшау тормышы да урынына утыра. Егет уңган, тормышның матди ягын җиңел хәл итә. Әмма икесе ике кыйбла кешесе булу бу парга сагышлар китерә... Ханым ирен аңларга теләми.

«Сөялдем сөяннәргә» хикәясе каһарманы Нурлыгаян атлы егетне авылда Нурлы дип кенә йөртәләр. Баксаң ул су асты көймәсендә хезмәт иткәндә нурланыш алып, өйләнергә яраксыз булып кайткан икән. Егет яраткан җырның сүзләре Фәнис Яруллинныкы... Менә шул җырны тыңларга дип Казанга бару һәм бәхетле мизгелләр кичерү турында бу җан тетрәткеч һәм җылы, нәзакәтле юморга да урын табылган әсәр...

Рөстәм Зариповның бер хикәясе дә гади генә түгел. Аларның берсе дә бармактан суырып язылмаган, образлар тере, истә кала торган үзенчәлекләр...

Гомумән, Рөстәм Зариповның башка жанрларга караган тарихи фәлсәфи язмалары, ягъни үзе әйтмешли, җан чайпалышлары да байтак. Аларның кырыклабы узган ел «Чыңгыз хан китергән бәйрәм» (күренекле якташыбыз көрәш остасы, автоузышчы Җәүдәт Миннәхмәтов һәм аның эшкуар улы, «Чыңгыз хан» атлы фирма хуҗасы, шулай ук автоузышчы Ирек оештыра торган Мингәр сабан туе, тулаем әлеге милли бәйрәмебез турындагы авторның күләмле язмасы исеме белән аталган бу җыентык) дигән китап булып дөнья күрде. Мин әлеге «чайпалышлар»ның эчтәлекләренә тукталырга җиенмыйм. Аларның исемнәре дә нindидер мәгълүмат бирә кебек: «Суверенитетыбыз чагылышлары», «Застойный еллар—достойный еллар!», «Син дә морза, мин дә морда, атка печән кем сала?», «Эт күнеле—бер сөяк», «Әфлисүн җиле», «Мин начальник—мин дурак», «Татарча сулыйсы килә», «Милициянең йөз аклыгы» һәм башкалар.

Әмма ләкин Рөстәмне хикәяләр һәм публицистик мәкаләләр остасы дип кенә уйласак, ялгышырбыз. Ул язган шигырьләр дә әкәмәт тә хикмәтле бит...

*Житәкчене шуннан таныйм:*
*Басуга кереп китә дә*
*Үрелә гел башакка.*
*Өзә, бөртекләрен саный,*
*Исни, куя ашап та...*

Икмәк басуында фотога, йә кино-телевидениегә төшкәндә хактан да ил җитәкчесеме ул, җөмһүриятнеке, районныкы яисә колхозныкымы, бөтенесе дә ничектер шушылай кылана. Хәер, бу калыпны сурәткә алучылар кайчандыр таккан һәм ул инерция буенча дәвам итә. Газета өчен оешма җитәкчеләрен кабинетларында телефон трубкасы тоттырып төшерүләр дә шул гамәлдән... Ә Рөстәм әфәнде шушы стереотиптан рәхәтләнеп көлә һәм башкаларны да елмаерга мәҗбүр итә. Танылган әдип Флүс Латыйфи бу шигырьнең, автор әйтеп бетермәгән тагын бер юлы булырга тиеш дип исәпли.

Рөстәмнең үткен юмор белән язылган шигырьләре байтак. «Тел яздыру», «СССР тарихы», «Исе китәр иде әсәрнең», «Академиклар», «Газаплы гашыйк» кебекләре шул эргәдә. Әмма авторның тирән эчтәлекле фәлсәфи шигырьләре дә байтак кына. Аның «Кеше» дип исемләнгәне укучыны сискәндереп җибәрә. Шигырь атеистик түгел түгелен, әмма автор кайчандыр халыкларның фаллоска табынуларыннан этенеп төрле конфессия гыйбадәтханәләре манараларында шуның кайтавазын таба...

Рөстәм Зариповның шигырьләренең күпчелегенә оптимизм, алдагы көнгә өметне җуймау хас. Алдагы дүртьюллыкны лейтмотив дип тә карап була:

*Инде менә күпме уйладым:*
*Таш яуса да, давыл кузгалса да*
*Җилгә очмас төсле, яшәр сымак*
*Минем тузганактай хыялым...*

Әмма шагыйрь күңеле, балаларныкы сыман кырыкка төрләнүчән. Рөстәмнең дә кайбер шигырьләрендә пессемистик ноталар яңгырап киткәли:

*Кайчакларда сагыш ачыттыра,*
*Талый, борлыктыра күңелне.*
*«Хуш килдең!»—дип, ишек ачып тора,*
*Түрләренә әйдәп, үлемне...*

Рөстәм иҗатта да төрле жанрларга мөрәҗәгать итә, ягъни бертуктаусыз үзеннән үзен эзли һәм канәгатьсезлеген дә белдереп куя:

*Алга бараммы, арткамы—төшенмим,*
*Башкарсам да дөньяның бер эшен мин.*
*Менә сиңа чикләвек дип әйделәр,*
*Ваттым барсын, тик тапмадым төшен мин...*

Бу урында якташыбызның 2008 ел ахырында тагын бер җыентыгы, нигездә шигырьләрдән торган «Әфлисүн җиле» дигән китабы дөнья күрүен дә әйтеп китү кирәктер.

Рөстәм Зарипов—популяр җырлар авторы да. Шуңа күрә аның кайбер шигырьләре җырга күчеп куя, көйләр дә яза. Шундыйлардан халыкта иң нык таралганнарының берсе «Бүре»дер (сүзе дә, көе дә үзенеке).

Салават Фәтхетдинов башкаруында яңгыраган «Бүре» җыры, әлбәттә инде, төрле фикерләр уятты. Бәгъзеләр аны чеченнар турында дип тә гөман кылган. Әмма бик тә хөрмәтле һәм дәрәҗәле бер якташыбыз:

—Бу җыр безнең халык турында. Без—бүрек эчендә,—дип кырт кискән.

Җыр: «Урманга карый дип гаеплиләр, бүректәге бүре баласын, бәгырьсезләр мәңге аңлый алмый нарасыйның йөрәк ярасын», дип башлана һәм: «Ә бит ул тумыштан ватанпәрвәр, шуңа илен барлый үрелеп»,—дип тәмамлана...

Шул ук Салават башкарган «Юлчы» дигән җырны гел яратып тыңласам да, соңыннан һәрвакыт ниндидер тирән хисләр дөньясына чумам. Чөнки өчлек берлеге—шагыйрь, композитор һәм башкаручы—тудырган бик тә гыйбрәтле иҗат әсәре бит бу. Әйдәгез, Эдуард Мостафинны, хөрмәт белән искә алу йөзеннән чигенеш ясап, аның бу җыр текстын (көе Рөстәм Зариповныкы) тагын бер сендереп укып чыгыйк әле.

*Әй, юлчы, кая барасың?*
*Кереп хәл ал, арысаң,*
*Бәлкем куныи та калырсың,*
*Ходай кушып, яр булсаң.*

*Тир чыгарып, чәй эчәрбез,*
*Гапьләшербез туйганчы.*
*Яшәп карарсың үземдә*
*Агач яфрак койганчы.*

*Алмалар җыярбыз бергә,*
*Өзәрбез чәчәкләрне,*
*Сагынып искә алырбыз*
*Иләс-миләс чакларны.*

*Юкка мыни дәшәм сиңа*
*Ялгызыма ямансу,*
*Күңелдә сагыш уята*
*Хәтта аннан аккан су.*

*Әй, юлчы, зинһар тукта,*
*Учагым сүнеп бара...*
*Күңелем дә, әкренләп,*
*Бу хәлгә күнеп бара...*

*Изге җан, сизгер җан булсаң,*
*Өреп җибәр, учакка.*
*Бәлкем өметләр терелер,*
*Ике җан типкән чакта.*

Миңа, бу юлларның авторына, Эдуард Мостафин да бик таныш. ...Сиксәненче еллар уртасына кайтыйк әле. Бүгенгедәй хәтеремдә, Бауман урамындагы Матбугат йортында дәрәҗәле генә шәхес миңа болай диде:

—Мөмкин булса, Саба редакциясенә эшкә Эдуард Мостафин дигән искиткеч талантлы шагыйрьне ал әле. Яшәү чыганагы юк аның. Әз булса да акчасы булыр. Иткән яхшылыгың җирдә ятмас, үзеңә изгелек булып кайтыр...

Каршы килә алмадым.

—Бер буш штат бар, эшләп карасын,—дидем.

Ярар, килде Эдуард абый. Яши торырга акча, ягъни аванс та бирдек. Бер-ике атна әйбәт кенә йөрде. Аннары Теләче янәшәсендәге Ачы дигән рус авылына үзе сорап иҗат командировкасына китте һәм... юкка чыкты. Ун көн үткәч кайтты бу. Кыска гына бер хәбәр язган. Әмма «командировочное удостоверение»сенә килгән-киткәнгә мөһер суктырып, тамга ясаткан. Район эчендә генә йөргән көннәргә редакциядә беркемгә дә тәүлеклек түләнми иде. Шуңа күрә башкаладан килгән хәбәрчебезгә «югалып торган» ун көне өчен хезмәт хакы бирдек тә, җайлап кына болай дидем:

—Эдуард абый, матур гына килден, нәкъ шулай итеп кит тә инде син, яме, ачуланма. Тавышка кергәнче, әйбәт кенә аерылышыйк...

—Ярар,—дип каләме белән куен дәфтәрен (башка әйбере юк иде) кесәсенә тыкты да, тыныч кына юк булды.

Шуннан берәр ел үткәч, анын сукбайлыкка төшеп фани дөньядан киткәнлеге, җәсәде табылмавы турында авыр хәбәр таралды. Шулай итеп, җаны... шигырьләрендә генә калды анын... Кыскасы, Р. Зариповнын «Бүре»се белән «Юлчы»сы «Татар жыры» фестивальләрендә «Алтын барс» премиясенә лаек була.

Рөстәмебез узган гасырнын житмешенче елларында ук «Тамчы гөл» дигән җырын (сүзе дә көе дә аныкы, шул исемдә ике китап та чыгарды) үзе уйнап һәм җырлап зур популярлык казанды. Үзенен балалык һәм яшүсмер елларын районыбызнын Лесхоз бистәсендә үткәргән мәшһүр композитор Фасил Әхмәтов анын аркасыннан сөеп: «Менә бу егет бер җыр язды, шунын белән халык күнеленә керде»,-дигән. Дөрестән дә, бу җөмләдә хаклык зур. Хәтта яна туган кызларына Тамчыгөл дип исем кушучылар да булды. Рөстәм анын белән генә тукталып калмады, әлбәттә. «Мөһәҗҗир» (Гаяз Исхакыйга багышлана), «Алфавит» (Кави Нәҗми шигыренә), «Дуслар җыелган» (сүзләре дә үзенеке), «Беркем сизмәде» (Фәнис Яруллин шигыре), һәм башка байтак җырларын тамашачы бик җылы кабул итте.

Рөстәмнен тынгысыз җаны «чикләвек төшен» эзләп поэзия, проза, музыкада гына тукталып калмый. Публицистикага да еш мөрәҗәгать итә. Анын язмаларына «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Мәгърифәт», «Звезда Поволжья» газеталары, «Казан утлары», «Мирас» журналлары мәйдан бирә. Һөнәри журналист буларак мин Рөстәмнен һәр мәкаләсен кызыксынып укып барам. Ул, тәҗел мәсьәләләрне кин мәгълүматка таянып, фәлсәфи фикерләр белән сипләп дәлилләү аша укучыга житкерергә тырыша. «Кояшка һөҗүм» дигән язмасы яналыгы һәм тирәнлеге белән күпләрнен күнелен сискәндергәндер дип уйлыйм. Ул, татар халкына карата «оештыру коралы» кулланылуы хакында беренче булып сүз кузгатты шикелле. Мәкаләнен азагында борынгы шәрык фәйләсуфы, суфи әл-Газалидән өзек тә китерелә (Әл Газали Коръәнне күнел Кояшы дип саный) һәм СССР чорында Коръәннән биздерү юнәлешендәге гамәлләрне күнелләрне сукырайту сәясәтенә чыгара һәм шул сәясәтне бүгенгебезгә китереп бәйли.

Бер язмада кызыклы автор Рөстәмнен иҗаты хакында бөтенесен дә сөйләп бетерү мөмкин түгел. Әле ул үзен әдәби тәнкыйтьче сыйфатында да сынарга өлгереп, мәртәбәле «Казан утлары» журналында кыска гына вакыт аралыгында өч әтрафлы мәкалә бастырырга өлгерде. «Звезда Поволжья» газетасы битләрендә (русча да камил яза) ул азау тешле политолог буларак мәкаләләр бастыра. Гомумән, күргәнегезчә, Рөстәм—күпкырлы талант. Ул Бөтендөнья Татар конгрессы уздырган «Татар авазы» конкурсларында катнашты. 2004 елда беренче урынны яулады. Рөстәм Зарипов 2005 елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

Зыялы нәселдән ул. Шуны раслау өчен язма ахырында анын тәрҗемәи хәленә күз салыйк әле. Рөстәмнен әтисе Зәет—табиб булган, ә әнисе ягыннан—муллалар нәселеннән алар. Тарихка тирәнрәк күз салсак, Рөстәмнен Йосыф абзасы Казан губернаторы кинәшчесе вазифасын алып барган. Бу хакта татар классигы Фатих Әмирханнын «Фәтхулла хәзрәт» дип исемләнгән фантастик әсәрендә түбәндәге юллар бар: «... Бу, фаразан, закунсыз жир түгел, Алла боерса Шайтан Елга (Урта Саба авылынын шул вакыттагы исеме—Т.Н.) Йосыфны очратмам микән әле, барыгызнын, мәсәлән, эшен китерермен, мировойга бирдерермен...»

Йосыф Раков Казанда яшәгән, адвокатлык һөнәренә ия, губернатор кинәшчесе булган. Ул Рөстәмнен бабасы имам Мирза Мөхәммәтшәрифнен әтисе белән бертуган Мөхәммәтгарифнен энесе була.

Икенче бер чыганакта Йосыф абзыйнын вазифасы губернатор каршындагы советник дип (ягъни кинәшче) тәгаенләнгән.

Нәкъ менә шушы урында Рөстәмнен әнисе ягыннан әбисе Гайнижамал белән Татарстаннын халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнен әтисе Сөнгатулланын бертуган икәнен дә искәртеп үтик әле.

Шушы затлы нәселне дәвам итүче Рөстәмнен әнисе Сажидә апа Ракова гомер

буе укытучы булды. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Кызы Лена һәм улы Рөстәм белән Юлбат авылында яшәделәр. Газетабызның даими хәбәрчесе дә иде. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр каләменнән аерылмады. Ни кызганыч, Сәҗидә апаның бу фани дөньядан бакыйлыкка күчкәненә дә байтак еллар үтте. Урыны җәннәт түрендә булсын.

Рөстәмнең бертуган апасы да, үзе кебек баянда уйный-уйный җырларга оста иде, кешене авызына каратып тота белде. Казан дәүләт университетын кызыл дипломга тәмамлаган Лената гомере дә бик тә аяныч тәмамланды: суга төшкән кебек югалды ул, гәүдәсе табылмагач, зиярәт кылырга кабере дә юк. Бәлки, әлеге вакыйгалар белән тетрәнеп, шундый моңлы, гыйбрәтле, үзәкләрне өзгәли, җаннарны телгәли торган җырлар иҗат итәдер Рөстәм Зәет улы.

Р. Зарипов—төзүче-инженер. Белгечлеге буенча Сабада да эшләп алды. Аннары янадан Мөслимгә күчте. Алты ел шундагы район эчке эшләр бүлегендә сәяси эшләр буенча начальник урынбасары була. Һәм органнарда эшләгәндә (!) Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең Мөслимдәге бүлегенең беренче рәисе итеп сайланды. Кыскасы, үзе әйтмешли, «мент» булса да, милли хәрәкәтнең башында йөрде, ТИҮ корылтайларында даими катнашты. Ул погон таккан килеш тә әнисе янына бик еш кайткалап торды. Бер елны мәйдан уртасына чыгып, «Саба Сабантуйлары» дигән өр-яңа музыкаль «күчтәнәчен» якташларына үзе уйнап җырлаганы күңелдә уелып калган. Җыр тәмамлангач, халык мәйданнан чыгармыйча алкышлады Рөстәмне, кабатларга мәҗбүр булды ул яңа «табадан төшкән» иҗат җимешен:

*Сагыш басса, рух сыгылса,*
*Авырайса уйларым,*
*Күңелләргә канат куя*
*Саба Сабантуйлары...*

Әйе, сагыш басса кулына баянын, нота кәгазен, йә каләмен ала, компьютерына утыра якташыбыз.

Фикеремне йомгаклап шуны әйтергә телим. Рөстәм кебек талантлар байтак безнең төбәктә. Элек тә күп булган. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә җиде якташыбыз лаек булуы да шуны раслый. Хәер, Саба ягыннан күтәрелгән иҗатчылар шулай күпкырлы, рухи бай һәм егәрле, бер сүз белән әйткәндә, талантлы булырга тиеш тә. Суында бар аның.

**Тәлгат НӘҖМИЕВ.**

# МӘҢГЕЛЕК БЕЛӘН ТОТАШУ[1]

ӘХСӘН ФӘТХЕТДИНЕВКӘ 70 ЯШЬ

Энциклопедик характердагы «Татар мифологиясе» сүзлеге әдәбият тарихында тиңдәше булмаган күләмле мирасны бер системага китерү, тулыландыру һәм укучыга бөтен архаик гүзәлллеге, эчкерсез самимилеге белән кайтарып бирү ниятеннән нәшер ителә. Бу катлам фольклорның масштаблылыгы, бүгенге зыялылар һәм төрле дәрәҗәдәге әдәбият сөючеләр өчен рухи азык була алу хикмәте—инде исбатланган хакыйкать, аксиома. Мифлар татар әдәбиятына, сәнгатенә, музыкага килеп керә, аңа тарихи тирәнлек, эзлеклелек, борынгылык хисен, меңъеллыклар ритмын бирә, ата-бабаларның дөньяны танып белү, сурәтле фикерләү ысулларын күз алдына китереп бастыра... Инде татар мәдәниятендә тулаем мифлар белән рухланган иҗат күренешләре дә юк түгел. Шуларның берсе—рәссам Әхсән Фәтхетдинев иҗаты.



Ә. Фәтхетдинев татар мифологиясе дөньясына үткән гасырның 80 нче еллары ахыры–90 нчы еллар башында, милли күтәрелеш чорында килеп керде. Әйтерсең, ул сәяси һәм экологик зәхмәттән, торгынлыктан, милли чикләнүләрдән котылу юлларында яшерен бер энергия чыганагы тапты. Йөз еллар буенча ата-баба аңында формалашкан, әдәп һәм гамәл нечкәлекләрен сеңдергән, күзгә күренмәс, ләкин тотрыклы рәвештә Җир-су, Күк, Галәм, табигать стихияләре белән камил идарә итүче «илаһи затлар» институты аңа әнә шундый бай, әлегә эшкә җигелмәгән хәзинә булып күренде. Әлеге хәзинәгә юл адәм баласы тарафыннан шактый кырыс тормыш сабаклары бирелгән Шүрәле образына якынаюдан башланды (1982–1986). Әйтергә кирәк, иҗатның үзкыйммәтен бүгенге көн ихтыяҗлары йөзеннән билгеләргә өйрәнгән пассионар рәссам, Шүрәлене гөллләр-абагалар арасында курай уйнап, урман халкын биетеп-җилкендереп, аларга мәҗүси тамашалар оештыручы антик персонаж яисә ялгыз юлчыны кытыклап үтерүче явыз кодрәт (Идел буе халыклары мифологиясендә) итеп түгел, ә халыкның табигать белән аһәңдәшлектә яшәү мөмкинчелеге, цивилизация белән Җир-су хиссиятен тоташтыручы илаһи көч итеп сурәтләде. Ерак бабаларыбыз иҗатының балачак зирәклеген һәм халкыбызның тарихи сынаулар алдында югалып калмавын, адаптация көчен мәңгеләштергән–зур интеллектуаль мәгънә йөкләнелгән образ, әлбәттә, Ә. Фәтхетдинев тарафыннан гадәти җирлектә «урман сарыгы», кыргый җанвар, кинәт эчендә «җан кабынган» шәрә агач ботагы итеп түгел, ә кеше сыман газаплана, кайгыра, табигатьне аңлый һәм ярата белә торган кешегә охшаулы зат итеп–хакыйкать эзләү юлларында рәссамның ише, фикердәше итеп сурәтләнде. Житен тукымаларда башкарылган сурәтләрдән тыш («Бусагадагы Шүрәле», «Күзәтүче Шүрәле», «Ачуланган Шүрәле», «Яшеренгән Шүрәле», «Көзгедәге Шүрәле»), героенның тумыш халәтен тирәнрәк ачу нияте белән, табигать материалы–язлар-

[1] Бу мәкалә Фатих Урманчеевның «Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек» дигән китабыннан алынды. I том. 2008, Казан. «Мәгариф» нәшрияты.

көзләр, янгыр-давыллар эз төшергән орнамент-бизәкләр тулы алтын такталарны уеп, анын стихияләр тудырган тышкы кыяфәтен, эчкерсез күңел күркен, сабыйлыгын һәм нарасыйлыгын «сырлады». Ул–күбәләкләр, кош-корт, урман-чишмәләр белән сөйләшүче дә, мүкле агач кәүсәләрен сыйпап утыручы да, мон иясе дә, табигать вөжданы да, гомумән, тирә-як мохитенен игелекле улы, газиз иҗаты.

Шунысы әһәмияткә лаек: «урман даһие» Шүрәле Ә. Фәтхетдиневне 1987–1989 елларда башланып, 1993–1996 елларда тәмам көчәеп, зур бер дастан–эпос кыяфәтен алган «Ияләр» циклына алып чыкты. Эчтәлеге бертуктаусыз катлауланып, баштагы кешелеклелек ноталары тирән гамьсез сурәтләү рухы, драматик авазлар белән алышынган төп геройларнын образы шулай ук Кеше образы аша хәл ителгән төрле жанрлардагы бу әсәрләр тезмәсе, борынгыга таянып, бүгенге көн яшәү концепциясен кору, анын зарурлыгын дәлилләү иде. Автор, меңъеллыклар эчендә формалашкан мифологик образларны сурәтләү-кабатлау, сәнгати параллель бирү эшеннән еракта булып, аларга заман ихтыяҗларыннан туган яна мәгънә салырга омтылды. «Ияләр» аша татар кавеменең тарих төпкелләреннән чыккан этник-милли яшәү ысулларын, иман гүзәллеген, акыл җәүһәрләрен, табигатькә таяну, аны олылау, саклау принципларын алга сөрде, дәһрилеккә, имансызлыкка, илне талау, башка милләтләрне йоту кебек яман йолаларга каршы ут кубарды. Табигать һәлакәтенә, татар халкынын әхлак-иманы үзгәрүгә, тел йотылуга борчылып, этноснын һәм табигатьнен, мәҗүси «ияләр» кебек, чын мәгънәсендәге «Илаһи хуҗасы» балалар һәм бакчалар үстерүче, дәүләт, цивилизация торгызучы көчле рухлы шәхесләр тәрбияләү проблемасын куйды.



*«Әйрән эчү». Нарат агачы. Ә.Фәтхетдинев эше.*

Әлбәттә, Ә. Фәтхетдинев тудырган «Ияләр»–«Хуҗалар» пантеоны татар традицион мифологик образлары даирәсеннән үзенен темпераменты, бүгенге көн белән жинел тоташуы һәм, гомумән, ирекле сурәтләү принциплары белән аерылып тора. Хәтта татар рухлары, жен-пәриләр энциклопедиясендәге котылгысыз таныш образлар да биредә яна нәфасәти кыяфәт, психологик эчтәлек ала бирде. Мәсәлән, бу пантеондагы ин борынгы һәм куркынычлы мифологик зат «Убыр»ны гына алыйк. Традицион караш буенча, ул–мифик әверелүләр остасы, ямьсез, тешсез карчык. Ә. Фәтхетдинев интерпретациясендә–очлы борынлы, жор телле, күзләре янып торган, үзенә гашыйк булганны тиз вакыт эчендә корбан итәрлек үткен яшь хатын. «Убыр. Үзе усал, үзе ирләрдән курка» ди рәсемнен рамдагы шаян язмасы.

Өрәк–мәҗүсилек идеологиясе буенча, үлгән кеше рухы. Кабынып китә, күзгә күренеп яшәми. Ә. Фәтхетдиневтә–үзе кечкенә генә, ишегалдындагы бер киштә бүрәнәләргә сыенган, кан коюлардан тетрәнеп, газапларыннан шыр сөяккә калган ялгыз ана. «Бу сугышлар барысы да ана йөрәге аша үтә»,–ди сырлы язмаларында автор, тукыма өстендәге канлы чәчәк кебек кабынып киткән ана сагышына ишарә итеп. Традицион мәгънәләре күп төрле булган «Ярымтык» та (версияләрнен берсе буенча, төрки эпоснын кулсыз-аяксыз-гарип каһарманнары) Әхсән сурәтләвендә–чарасыз, ялгыз бәндә, тормыш корбаны. Камиллеккә сусаган, тулылыкка омтылучы ялгыз җан. Хәтта кыланыш-гамәлләре күптән стереотип характер алган «Абзар иясе»ндә дә позитив чалымнар бар. Фольклор буенча малнын ялларын бутаучы, аякларын тышаулаучы ия–биредә «атларны ярата», ялларын тарый, сыйпый. Мунча хуҗасы «Бичура»–Ә. Фәтхетдинев күрүенчә, алсу-яшел гөлләргә күмелгән, өй эчендә телогрейка, калош киеп, бил буып, сугыштан кайтмаган ир-заты эшен башкаручы тол хатын, сагышлы

жан. «Игелекле»,–ди анын турында рәссам агач рамдагы руникасында. Сәяси, җәмгыяти нюанслар бигрәк тә «Өй хуҗасы» образында ачылалар. «Өй рухы», «Өй пәрие» традицион караш буенча, тынгысыз зат, чормада яши, аякларын селкетә, шаулый, кыштырдый, акча эшли. Әхсән фаразлавынча, «Йорт хуҗасы»–ил турындагы уйлардан чәчләре чаларган фәйләсуф, шагыйрь; төн йокламый, сәясәт, дипломатия җебен эрли, гамәл кыла. Ул–йортны ниндидер глобаль эчтәлектә саклаучы ил башы, Хуҗа.

Традицион мифлар аша миф тудыру технологиясен шактый нечкә үзләштергән рәссам, тора-бара чолгап алган бөтен дөньяны антропоморфик илаһлар кодрәтенә буйсындыру юлына баса. Ияләрнең сафы кинәйгәннән-кинәя бара. «Давылдагы һәрнәрсәнең: иген-кырның, бакча-урманның, хәтта чокырның, кешелекненең иясе бар»,–ди автор. Бу караш нәтиҗәсендә безнең алдыбызда әле рәсми «ия» статусын алмаган, шул ук вакытта традицион пантеонга керергә лаеклы яңа образлар тезмәсе пәйда була. Мәсәлән, «Җир хуҗасы». Җир өстенә ишелгән чүп-чар, җимерек парчалар өстендә борчылып утырган әллә мулла, әллә җирсез калган авыл крестьяны–«Җир хуҗасы»; бишеккә иелгән самими ана–«Бишек иясе»; алма бакчасын багучы, алма өләшүче–«Бакча иясе»; болгар порталларының бизәгенә сынландырылган чал чәчле карчык–«Сагышлы»; «Кыр иясе»; «Капка иясе»; «Ураман иясе»; «Кое иясе»; «Чәчәкләр иясе», «Шахта иясе»; «Мич иясе»; «Моң иясе» һ. б. «Традицион ияләрдән аермалы буларак, минем «ияләр» (рухлар) аз динамикалы, уйчан, сыйфатлары бары уңай. Аларда «сабак бирү», хөкем итү хакимияте юк. Алар җәмгыять үзе төзелер, тотрыкланыр һәм тазарыр дип өмет итәләр»,–дип яза автор үзе бу турыда.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, мифлар дөньясында кайнаучы сәнгатькәр–аларны реконструкцияләүче, торгызучы оста гына түгел, ә алар нигезендә яңа, кодрәтле мифологик образлар тудыручы, идеяләр үткәрүче идеалист-импровизатор. Аның интерпретациясендә (концепциясе буенча) икейөзлелекне белмәгән кешеләр–стихияләр белән житәкчелек иткән риясыз ия, җир саклаучылар онытылган тәгълимат, иман кодексы гына түгел, ә образлы итеп әйткәндә, хокукый дәүләтнең гипотетик моделе. Алар–мохитнең, яшәешнең кагылгысыз терәкләре, дөнья тотучы изгеләр. «Ияләр» татар кешесендә үз борынгысының, бүгенгесенең һәм киләчәгенең хуҗасы тойгысын, тарихи җаваплылыкны уяталар.

Шулай итеп, ниндидер мәгънәдә гүзәл, якты, серле, ә кайчак куркыныч вә караңгы татар мифологиясе тәэсирендә, мифлар пантеонының масштаблылыгын, символик-мистик эчтәлеген, ерак ырымнарын, кинаялеген эченә алган яңа катлам мифлар тезмәсе туып чыкты. Автор иҗат иткән «миф стиле» катлаулы түгел; кечкенә сурәт, мистик интерьер, табигать, яшел-көмеш, зәңгәр-төтенле гамма; киндер тукыманы каючы бизәкле тылсымлы кыса-рам, «чөй» белән язылган текст. Яктылык. Нур. Шул ук вакытта–бүгенге йөзләр, этнография, татар теле-моңы, сәясәте, сәнгате, милләт («Куркынычлы», «Ачуланган»). Татар дөньясы, аның бүгенге көне, киләчәге. Авторның 6 өлештән торган панно-әсәре «Ай астындагы ияләр»–әнә шундый мәңгелек белән бүгенгене тоташтыручы синтез. Рәссамның яшьлек-балалык чагы–сугыштан соңгы чор, авыл тормышы, зифа буйлы киленнәр, һава чөмерүче атлар, авыл философлары, агачларда канатланып утыручы малайлар, суга баручы җингиләр, йорт нигезен тотучы картлар, изге аналар. Бер сүз белән әйткәндә, халык тормышы. Мәңгелек миф.

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече.*

# СӘХНӘ—ИЛҺАМ МӘЙДАНЫ

Театр сәнгатен, ни хикмәт, без, билгеле булганча, күбрәк артист яки драматург иҗаты аша кабул итәргә күнеккәнбез. Еш кына спектакль караганнан соң: «Драматург шәп әсәр язган», яки «әсәре шундый гына инде, ә теге артист шәп уйный, молодец!»—дип бәя бирәбез. Югыйсә спектакльнең чын сәхнә хуҗасы, төп авторы режиссер бит. Ә ул исә үзе күзгә чалынмагач, күренмәгәч, күп очракта халык аның шәхесен игътибарга да алмый, аңа әһәмият тә итми. Тамашачы аны күбрәк спектакльне оештыручы, сәхнәне рәткә китерүче бер кеше итеп кенә күзаллый. Репетицияләрдә режиссер вазифасындагы кеше ни белән шөгыльләнә, артистларга нинди күрсәтмәләр бирә,—алар өчен бу як карангы. Артист сәхнәгә чыгып кемне дә булса уйный, бусы шиксез, ә бит бер үк рольне ике артист башкарса, икесе ике төрле диярлек образ бирә. Күп очракта бу хикмәт дигәнебез режиссерның әнә шул күрсәтмәләренә кайтып калмый микән?



Режиссер шөгыленең асылына төшенә башласаң, аның бик катлаулы һәм житди шөгыль икәнлеген аңлыйсың. Режиссерларның да бит төрлесе бар. Кайберләре матур мәгънәсендә диктатор була. Ул бар кешене дә һәм бар нәрсәне дә үзенә буйсындыра торган, берәүгә дә бер адым да читкә тайпылырга ирек бирми торган «каты куллы» житәкче. Икенчеләре исә күбрәк артистның сәләтенә таянып, аңа ышанып эш итә. Беренчеләренең исә драматург әсәрен сәхнәдә үзләре генә «башкарып» чыгачагына иманнары камил. Ә кайберәүләре исә кулына килеп кергән әсәрне үз йөрәге аша үткәреп, аның бөтен тирәнлеген һәм кинлеген тойган хәлдә артистларны да үз халәтләре, үз кичерешләре аша тәэсирләндереп, үзләренең хыялларында кичерешләрне тасвирлый алуларына ышанып эш итәләр. Үзенең иҗади халәте ягыннан мин режиссер Фаил Ибраһимовны соңгылар рәтенә кертер идем.

Фаил Ибраһимов—ул чын мәгънәсендә иҗади шәхес. Аның кулында рәсми рәвештә расланган «һөнәре–режиссер» дигән документ-таныклыгы булганга күрә, үзенең эчке халәте ягыннан көн үткәнгә ризалашып яшәүче генә түгел, ә бәлки «жан басымы» белән авырып, иҗат белән мавыгучан шәхесләрнең берсе. Әйе, Фаил Ибраһимов артистларга теге яки бу рольне бүлеп, сәхнәдә коры күрсәтмә бирүче генә түгел, ул иң әвәл теге яки бу пьесаның сәхнәдә идея-художество янгыраешын тоючы, ишетүче, күрүче рәссам-режиссер да. Әйе, әйе, бу режиссерның иң кыйммәтле ягы–куярга дип сайлаган әсәренең сюжет эчтәлеген сәхнәгә «коры күчерү» генә түгел, ә бәлки аның фикер үзәген табып, тамашачыны да әнә шул фикер куәтенең хис-тойгылары аша тамашачыга киеренкелек иңдерү, аның игътибарын шуңарга юнәлтүе. Шул сәбәптән булса кирәк, Фаилнең режиссурасы артистлардан да үз максатларына аңлы рәвештә нык дикъкатьле булуларын һәм халыкка житкерә торган фикерләрен үзләренең йөрәк тибешләре аша чагылдыруларын таләп итә.

Фаилнең матбугат аша әйткән сүзләренә игътибар итик:

«80нче елларда, Актаныш халык театрында эшләгәндә, Аяз Гыйләжевнең «Өч аршын жир»ен куйдым. Бу спектакль республика театр жәмәгатьчелегенең игътибарын жәлеп иткән. Шуннан соң инде Минзәлә татар дәүләт драма театрында «Сүнмәс учагым» (В. Крымко) спектаклен куеп карадым. Тәржемә әсәр иде бу. Бу очракта да үжәтлек күрсәтергә туры килде. Шагыйрә Гөлшат Зәйнашева өч көн саен

самолет аша битләп-битләп әсәрнең тәрҗемәләрен җибәреп торды. Каршылыклар шактый гына булса да, бу әсәрне сәхнәгә кую бәхетенә ирештем. Шуннан соң инде мине Минзәлә театрына баш режиссер итеп чакырдылар. Анда эшләү дәверендә «Зәңгәр шәл» (К. Тинчурин), «Сөйгәнемнең туган көне» (И. Юзеев), «Ярым ятларга кала» (Р. Батулла) һәм башка спектакльләрне куйдым. Ә 1990 елда яңа оешкан Чаллы татар дәүләт театрына күчтем...

Әти-әнием көчле рухлы кешеләр булгангадыр, мин дә тормыш сынауларына артык бирешмәдем. Әтием Мөхәммәт Мирза (энем шагыйрь Илфак әтинең исемен псевдоним итеп алды) 18 яшендә Бөек Ватан сугышында яраланып, ике аягын өздереп кайта. Ул гомере буе мөгаллим булып эшләде. Әнием аңа кияүгә чыгып 11 бала таба»[1].

Үзенең гомер агышын, ничек итеп театр дөньясына аяк атлавын, режиссер буларак кереп китүен ул миңа шулай дип искә ала. Дөрестән дә, профессиональ сәхнәгә килгәнче үк аңа чын мәгънәсендә бу өлкәдә үзенә күрә сират күпере аша кичәргә туры килә–ул үзенең режиссерлык сәнгатендә нәрсәгә лаеклы булуын, аның тулы хокуклы вәкиле икәнлеген бу өлкәнең иң нечкә җире, иң кыен юлы аша узып дәлилли, раслый. Режиссер буларак, Фаил сәнгатьтәге иҗат юлын һәвәскәрләр белән эшләүдән башлап җибәрә. Дөрес, алар белән эшкә керешкәнче дә, ул үзе дә сизмәстән балачактан ук сәнгать һөнәренең асылына төшенергә омтылган. Туган авылында сигез классны тәмамлаганнан соң 1966-70 елларда Минзәлә педучилищесында белем алган, аннан соң Иске Кормаш мәктәбендә укытучы булып эшләгән, ә инде 1971 елда Казан дәүләт мәдәният институтының режиссерлык бүлегенә укырга кергән, аны тәмамлагач, яшь егет туган ягы Актанышка кайткан һәм анда халык театрын җитәкли башлаган. «Профессиональ сәхнәгә килеп җиткәнче аңа байтак эзләнүләр аша үтеп, һәвәскәр артистлар белән спектакльләр куеп бимазалы иҗат тәҗрибәсе узарга туры килә. Ләкин Фаил Ибраһимов бу өлкәдә судагы балык кебек үзен иркен хис итә, һәвәскәр уенчыларны ул һөнәрмәнд (профессиональ) сәхнә алымнарына өйрәтә, үзенә теләктәшләр туплый. Нәтиҗәдә Актаныш халык театрында эшләгәндә үк ул югары кимәлдәге спектакльләр куя. «Өч аршын җир» (А. Гыйләҗев), «Хуш, Назлыгөл» (М. Байҗиев), «Кичер мине, әнкәй» (Р. Батулла) һәм башка спектакльләр моның чын дәлилләре»,–дип искә ала аның остазы Рабит Батулла.

Тиз арада ул куйган спектакльләр хакында Казанга берсеннән-берсе матур хәбәрләр килеп җитә: Актаныштa бер егет бар икән, ул һәвәскәрләр белән кызыклы спектакльләр куя икән... Озак та үтми, А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәрен актанышлылар Казанда ук күрсәтергә дә өлгерәләр. Спектакль җәмәгатьчелектә киң яңгыраш алып, аның режиссеры Ф. Ибраһимовның исемен халыкка таныта. Ул үзенең куелышы, тирән фикерләргә, рухи кичерешләргә бай булуы белән үзенчәлекле була. Республика халык театрлары конкурсында 7 номинация буенча лауреат дипломнары аңа бирелә. Аннан соң ул Чаллы халык театрына күчә, анда да К. Тинчуринның «Американ»ын куеп, шактый ук уңыш казана. Бу спектакль белән Бөтенсоюз халык театрлары конкурсында катнашып, лауреат исемен яулап ала. Шуннан соң аны якындагы Минзәлә дәүләт театрына В. Крымконың «Сүнмәс учагым» драмасын куеп карарга чакыралар.

–Әсәр русча иде, тәрҗемә итәргә кирәк үзен. Таныштым да, «моннан берни дә чыгарып булмас» дип, кире кайтып киттем. Башкаларның ачуы килгәндер инде, «йөрисең шунда» дигәндәй карап калдылар. Чаллыга кайттым, төне буе тагын бер тапкыр укып чыктым әсәрне. Шушы бер төн эчендә спектакль «туды»: образлар да, сәхнә бизәлеше дә күз алдында иде инде. Йоклап та тормыйча, иртән иртүк, өр-яңа идеяләр белән «коралланып», янә киттем Минзәләгә! Җиң сызганып эшкә керештек. Шулай итеп, әсәрне сәхнәгә кую бәхетенә ирештем, һәм бу спектакль мине Минзәлә театрына баш режиссер итеп «чакырды»,–дип искә ала Фаил.

Сугыш чоры темасына багышланган бу спектакльдә ул аерым бер психологик нечкәлек белән шул чорның шомлы атмосферасын художниклар гына куллана торган, ниндидер аларның үзләренә генә хас буяулар аша, каракучкыл зәңгәрсу төсмерләргә манып, кешеләр йөрәгендәге борчулы халәтне күрсәтә алды. Аннан соң аны Мәскәүгә,

[1] Ватаным Татарстан. – 1995 ел, 13 сентябрь.

режиссерлар әзерли торган Югары курсларга укырга җибәрәләр, инде аннан кайткач, Минзәлә театрының художество җитәкчесе итеп билгелиләр. Бу театрда ул аның халыкчанлык традицияләренә таянып, сәхнә сәнгатенең заманча алымнарын мул кулланып эш итә, сәхнәсен яңа алымнар белән баета. Ф. Ибраһимовка багышланган бер язмасында Рабит Батулла болай дигән иде: «Ф. Ибраһимов—театрның миссиясен тирән аңлап эш итүче режиссер. Ул пьесаның «орлыгын» тапмыйча спектакль куярга алынмый»[2]. Биредә 1984-1991 елларда баш режиссер булып эшләү дәверендә барлыгы 8 спектакль куеп өлгерә Фаил. Мәскәүдән соң тәүге эше К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» әсәре була. Бу мелодрама монарчы Минзәлә сәхнәсендә—1936, 1956 елларда режиссер С. Өметбаев, 1965, 1969 елларда режиссер М. Мостафин тарафыннан куелган була инде. Минзәлә театры халыкка иң якын торган коллективлардан санала, мондагы этнографик, фольклор элементларының мул кулланылуы табигый хәл санала, спектакльне кабул итүгә аз гына да комачауламый. Нигә әле алар безнең милли хисебезне ялкытырырга тиеш ди?! Татар халкының электән киелә торган киемсалымнары, бизәнү әйберләре, чулпы-калфак, алъяпкычларның сәхнәдә бер ялтырап алулары, андагы җыр-биюләрнең дә күңелләребезгә хуш килүләре берсе дә артык түгел—барысы да үзебезнеке. Шул ук вакытта аларга режиссер, әсәрнең социаль яңгырашын көчәйтү теләгеннән чыгып, сәхнәдә шактый күп янача күренешләр дә өстәгән.



*Ф. Ибраһимов, үз театрында яңа спектакльләр әзерләү арасында, Казан, Минзәлә, Әлмәт, Уфа сәхнәләрендә дә уңлап уңышлы спектакль куйды. Рәсемдә: Әлмәт театрындагы премьерадан соң (М. Гыйләҗев. «Сафиулла»).*

А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» спектакле Минзәлә театрының иҗат биеклегенә ирешкән спектакльләренең берсе булды. Режиссер әйтүенчә, ул бу әсәрнең инсценировкасына театр китапханәсендә актарынып утырганда тап була һәм «әсәрдәге вакыйгалар үз эченә шулкадәр урап-урап алып кереп китте ки: укыганда ук күңелемдә җанлы образлар хасил булды. Әсәрне укый бардым, шул ук вакытта күз алдымда спектакль дә уйнала торды». Шуннан соң ул аны Актаныш халык театрында 1980 елда сәхнәләштерә. Спектакль бу чор өчен үзе үк зур кыюлык була. Ф. Ибраһимов тарафыннан куелган әлеге сәхнә повесте режиссерга танылу алып килә һәм аны тәки тынгылыкта калдырмый, һәм менә ул—Минзәлә сәхнәсендә. Бу спектакль чын югарылыгында сәхнә шигъриятенә корылган иде, ул үзе үк бер поэманы хәтерләтте. Монда бар да бар иде—киеренке хисләр, эчке тойгыларның чынлыгы, шул ук вакытта саф нәфислек, кеше дөньясының җанына үтеп керергә тырышу, эчке динамизмның катлаулы бер чагылышта бирелүе. Бу әсәр үзенең рухы белән авыл тамашачысына нык якын, аңлаешлы, аның туган җиргә карата йөрәк түрендә сакланган кичереш дулкыннарына тәңгәл иде...

Минзәлә театры—күчмә театр, авыл театры, шуңа да аның эш шартлары аерым кысаларга ия. Аның калыбында гына иҗат итү, әйтик, мәйдан тарлыгы үзен сиздерми калмый, билгеле. Сиксәненче еллар азагында Минзәләдән 60 чакрым ераклыкта гына ярты миллион халык яшәгән Чаллы шәһәре үсеп чыкты. Анда яшьләр, анда тормыш кайный! Табигый ки, иҗат кешесенең тынгысыз җаны шунда ашкына, шуңа тәбәлә. Чаллы шәһәрендә профессиональ театр төзү уе белән янып, Фаил да шунда таба омтыла. Хыяллар чынга аша. Чаллыда театр ачылгач, аның сәнгать җитәкчесе итеп режиссура өлкәсендә образлы фикерләүгә ия, куела торган әсәрләрнең мәгънәви

[2] Р. Батулла. Ярашканлык. — Идел. 1996.N3,626.

асылына, анын фикер һәм поэтик янгырашына аерым игътибар итүче режиссер Фаил Ибраһимовның билгеләнүе табигый адым буларак кабул ителә. Ул илһамланып, егетләрчә жин сызганып эшкә чума. Тиз арада Р. Батулланың «Күбәләк булып жаның кайтыр», В. Шашинның «Ут төртүче», И. Юзеевның «Гашыйклар тавы», Ә. Гаффарның «Язлар моны», З. Хәкимнен «Курку», «Кайтаваз», Р. Хәмиднен «Тигезәкләр» кебек аның жанының рух чагылышына тиң килгән әсәрләр сәхнәгә күтәрелә. Монда куйган беренче спектакле Р. Батулланың «Күбәләк булып жаның кайтыр» драмасында ук ул кеше рухының жаны чиста, саф, нык булырга тиеш дигән төшенчәне алга сөрә һәм бу темага алдагы постановкаларында тора-тора әйләнеп кайта. Ул, күнеле белән үз әсәрләрендә фәлсәфи эчтәлеккә ия авторлар Аяз Гыйләжев, Ризван Хәмид, Зөлфәт Хәкимнәр белән фикердәш булганлыктан, алар ижатына таяна. Андый әсәрләрне сәхнәдә рәвешләү шактый четерекле эш. Өстәвенә, Ф. Ибраһимовның тануы буенча, «бүгенге көндә татар драматургиясе житди әсәрләргә берникадәр кытлык кичерә, тамашачы жинел кабул итә торган уен-көлкеле әсәрләргә өстенлек бирә кебек. Тамашачыны уйландыра, үз-үзен эзләргә мәжбүр итә торган драматурглар кайда микән?–дип офтана ул. Ләкин булганнары белән ризалашып, алар белән хезмәттәшлек итәргә туры килә. Анын фикеренчә, прозада синен күнеленне биләп алган, режиссерга буйсынырга теләми торган, көчен житмәс кебек тоелган әсәрләр күбрәк. «Кайчагында карыйсын, үзе ук сәхнәгә сикереп менәргә әзер проза әсәрләре очрый. Анын шулай икәнлеген автор үзе дә сизмәскә мөмкин. Мәсәлән, Зөлфәт Хәкимнен «Курку» әсәре белән әнә шулай булды. Укып чыктым, күрәм–сәхнә өчен менә дигән итеп эшләргә мөмкин, һәм ана тотынгач, менә дигән спектакль чыкты»[3],–дип искә ала ул. Бу әсәрдә режиссер үзенә якын сәхнә алымын–нечкә хисләрне психологик яктан тагы да тирәнәйтүне, икенче, өченче пландагы фикерләрне дә тагы да ачыклауны максат итеп куя.

Дөрестән дә, Ф. Ибраһимов үзенең ижат позициясендә сәхнәдән тамаша залына аерым бер хәбәр булырга тиеш дип исәпли. Ул нинди хәбәр, анын эчтәлеге нидән гыйбарәт–бу ягы инде режиссерның ижади шәхес буларак тормышны, яшәүне, бүгенге көнне ничек анлавына, аны ничек кабул итүенә бәйле. Әсәрнең актуальлеге лозунгтай кычкырып торырга тиеш түгел, ә бәлки һәр сүзнең, һәр репликаның, һәр язмышның эчке бер аныклыгы һәм максаты булу–анын өчен төп кагыйдә.

«Фаил Ибраһимов спектакльне гадәти примитив алымнарга кормый, ә психологик яссылыкта чишә. Бөтен фикер тамашачыга сүз, пластика, уен аша житкерелә»[4],–дип бәяләнә режиссерның эш ысулы матбугатта басылган бер мәкаләдә. Драматургиягә булган таләпчәнлеге ягыннан үзенен сәхнә почеркы белән исә, минем фикеремчә, ул татар театрының танылган режиссеры Празат Исәнбәткә якын тора. Артистлар белән булган эш тәжрибәсендә ул ана тартым–сәхнәдә артык «мөгез» чыгармыйча, аларны күбрәк уйланырга мәжбүр итеп, үзләренең ижат мөмкинлекләрен тышкы эффектка гына кормыйча, акыл көчен барлауны таләп итә, образның эчтәлегенә тирәнрәк кереп, мәгънә асылына да төшенүләренә игътибарын юнәлтә. Режиссер буларак, гомере буе эзләнә, ул аерым бер калыпка салынган режиссер түгел, үзен-үзе кабатламаска тырыша, конкрет сәхнә материалы–пьесадан чыгып эш итә. Ул–бу очракта фикер колы.

Бүгенге көнгә кадәр бу театрның кечкенә генә сәхнәсендә 70кә якын спектакль күрсәтелгән инде. Дөрес, ижат итү өчен театрның яшәү шартлары башлангыч чорда әллә ни булмый. Анын хәтта спектакльләр уйнар өчен жайланмалы сәхнәсе дә юк. Пәрдә юньләп ябылмый. Сәхнә кечкенә булгач, зур декорация дә куеп булмый. Сәхнә белән тамашачы арасы бик якын–нибары ике метр. Ләкин бу яшь коллективның яшәве, үсеше, ныгуы һәр ижади тереклеккә хас булганча аерым бер үзенчәлеккә ия була. Шунлыктандырмы, Фаил үзе профессиональ күзлектән бу киртәләргә алай артык пошынмый. Ул хәтта: «Киресенчә, моны өстенлек дип санарга була,–ди.–Тамашачыга көчлерәк тәэсир итү өчен тамашаның анын белән рәттән диярлек, каршысында ук баруы бик әйбәт. Ул уйнаучының йөзендәге һәр үзгәрешне «йотып» торсын, тын алуына кадәр сизеп-тоеп утырсын... Без заманында махсус шушы кечкенә зал өчен берничә спектакль әзерләгән идек: «Язлар моны», «Курку», «Гашыйклар тавы»н... Театрның вазифасы, минемчә, шундый: тамашачы

[3] Аргамак,2000 ел,№1,138б.
[4] И. Сиражи. Чаллының рух мәркәзе. Мәдәни жомга. 18.04.2003.

анда тетрәнсен, аның тынычлыгы, битарафлыгы югалсын, үзен танысын, хәтта үзе белеп тә бетермәгән якларны күреп, уйланып кайтып китсен. Театр менә нибары бер-ике сәгать эчендә ирешә бит. Әгәр ирешми икән, әлеге спектакльнең дә, бу тамашаның, ахыр чиктә бу театрның да кирәге юк дип саныйм мин»[5].

Шиксез ки, ул үзенең позициясендә хаклыдыр. Ләкин һәр очракта да бу хәл алай ук отышлы дип әйтмәс идем. Режиссерга булган мөмкинлекләрдән чыгып эш итәргә туры килә һәм Фаил, хәленнән килгәнчә, шушы камерага тиң кечкенә сәхнәдә шактый гына спектакльләр куеп, үз максатына ирешә. Аның бу уйлануларында, сәхнә рамкасына карата булган мөнәсәбәтендә, билгеле ки, артистларның иҗат мөмкинлекләрен, аларның сәләтен киңлеккә караганда тирәнрәк мәгънәдә ачарга омтылу, психологик эш алымнарын ешрак куллану интеллектуаль планга тартым икәнлеге чагыла. Ул драматургик әсәрләрдәге образлар системасына, алардагы кичереш алымнарының үзара бәйләнешенә күбрәк игътибар итә. Мөгаен, шунадыр да аны күбрәк автор тарафыннан язылган пьесаларның эчке хасияте кызыксындыра һәм ул аларны сәхнәгә күчергәндә, үзенең асылы белән рәссам табигатьле режиссер буларак, әсәрнең нәкъ шул мәгънәви асылына күбрәк игътибарын юнәлтә, аны психологик яссылыкка кора. Фаил чынлыкта бер генә төрле калыпка салынган режиссер түгел, ул үзен-үзе кабатламыйча, әсәрдән чыгып эш итәргә, фикер артыннан барырга тырыша. Эзләнү һәм тәҗрибәләр кылу–аның холкына хас сыйфатлар. Ачыктан-ачык сәхнә эффектлары, декорацияләр белән мавыгу аның өчен чит нәрсә (кайбер очракларда хәтта артыграк саранлана да сыман).

Р. Батулланың «Күбәләк булып җаның кайтыр» драмасын сәхнәләштергәндә режиссер катлаулы заман проблемасына үзенең төп игътибарын юнәлткән иде. Әсәрнең героинясы Дәүҗиһанның гомере заяга уза, тормышы теләгәнчә бара алмый–ул тәрбияләп үстергән алты малаеның да язмышлары аска таба тәгәри–кайсы сугыштан инвалид булып кайта, кайсы эчә, кайсы марҗага өйләнеп каядыр читтә яши, кайсы йомшак холыклы, соңгысы әнә мафия кулыннан үтерелә. Нәрсә соң бу, яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә–Ана аптырашта, ул кая барып бәрелергә белми...

Бу әсәр үзенең күтәргән темасы белән әхлак күзлеге ягыннан һәр чор кешеләре өчен тирән әчтәлеккә ия булгангамы, режиссер бу пьесага 13 елдан соң кабат мөрәҗәгать итә һәм аны «Нурислам нигезе» дип атап сәхнәләштерә. Дөрес, пьеса автор тарафыннан бүгенге көн күзлеге аша эшкәртелгән, тема-идеяләр тагы да тирәнәйтелгән: баштагы варианттагы сыман–кешенең җаны, аның рухы бу дөньяда, җирдә яшәгәндә бүген үк нык, мәгънәле булырга тиеш дигән фикере тагы да тулыландырылып бирелә, һәм бүгенге реаль барлыкка нигезләнеп, фаталь фаҗига дәрәҗәсенә күтәрелә. Автор да, режиссер да соңгы вариантта Нурислам гаиләсенең рухи упкынга ничек итеп тәгәрәве хакында сүз алып баралар. Спектакльнең төп героинясы Дәүҗиһан балаларының шушы рухи упкынга ничек итеп тәгәрәүләрен чамалый, төшенә, анализлый, бәя бирә башлый. Аек акыллы, нык ихтыярлы бу Ана. Чехов әсәрләрендәге сыман–кешенең үз-үзеннән канәгать булмыйча, яшәү мохитенең ниндидер баткаклыкка нигезләнгәнен аңлый башлый. Күңел газабы биләп ала Ананы. Режиссер спектакльнең атмосферасын эзли, ул социаль сатирадан качып (бу әсәрне шул җирлектә сурәтләргә мөмкинлекләр монда шактый күп иде), әсәргә социаль-психологик драма жанры фокусы аша карый, һәм артистлардан бер-берсен нык ишетеп, сизеп-тоеп, сәхнә ансамблен барлыкка китерүләрен, димәк, алар кеше характерының тулы канлы булуы белән берлектә кеше язмышын да тасвирлауларын таләп итә.

Фаил Ибраһимов Чаллы театрында эшли башлауга үзалдына: «Һәр театрның үз йөзе–үз репертуары, үз алымнары булырга тиеш», дигән максат куя. Татар милли характерына хас үрнәк сыйфатларны саклаган хәлдә, без үзебезне Чаллы театрының «үз йөзен ачачакбыз» дип фаразлый. Сәхнә сәнгатенең көчен ул әнә шул юнәлештә үстергәндә генә үз максатына ирешүенә ышана. Бу драмадан соң В. Шашинның «Ут төртүче», И. Юзеевның «Гашыйклар тавы», З. Хәкимнең «Сулкылдап елый җаннар», Ә. Гаффарның «Язлар моны» драмалары әнә шул максаттан чыгып сәхнәгә күтәрелгән әсәрләр. Гомумән, Фаил Ибраһимов бүгенге көн татар драматурглары белән тыгыз элемтә урнаштыра. Аның Аяз Гыйләҗев белән булган мөнәсәбәтләре турында алда әйтелде инде. Чаллы театрында гына да ул үзенә замандаш драматурглар әсәрләрен сәхнәгә менгезә: Р. Батулла,

[5] «Нур» газетасы (Чаллы). 25 ноябрь,2000 ел.

И. Юзеев, Т. Миннуллин, З. Хәким, Р. Хәмид, Ә Гаффар, М. Гыйләҗев, Р. Сәгъди, Э. Янһудин, Д. Салихов,, Б. Сәләхов, Ф. Галиев, Аманулла–җәмгысы 14 автор (кайберләренен икешәр әсәре куелган). Бу әле бары тик аның үзләре белән генә турыдан-туры эш иткән авторлары–алар бит югыйсә, иҗади алымнары, күтәргән проблемалары, темалары дип әйтмим, язу куәтләре ягыннан да гаять төрлеләр. Режиссер исә аларның һәркайсыннан тамашачы күнеленә якын уй-фикерләрен, тематик үзенчәлекләрен, тормыш принципларын күтәреп чыкты.

Репертуарга кертелгән һәр әсәр дә ниндидер унай дәрәҗәләргә ирешә дип әйтү бик үк дөреслеккә туры килеп бетмәс, ләкин театр тарихында тирән эз калдырганнары да шактый. Шундый спектакльләр рәтенә мин беренче чиратта Т. Миннуллинның «Саташу» драмасын кертер идем. Анда автор һәм режиссерның хис һәм фикерләү, сурәтләү культурасының бердәмлеге аермачык чагыла, чорыбызның каршылыклы идеологиясенең буыннар язмышында нинди аянычлы нәтиҗәләргә китерүе тирән итеп ачыла, героиня Гүзәл (арт. Ч. Садыйкова) исә хөкемдар буларак рәвешләнә. Ул гаделлек эзли. Тик... таба алмый. Монда бар да Шекспир әсәрләрендә чыгыш ясагандай,чын күнелләреннән бирелеп, ярсып, әрнеп, иләсләнеп,ачынып уйныйлар, психологик чишелештә фаҗигаи нотага күтәреләләр. Шунысы куанычлы, һәм режиссер, һәм актриса 2007 елда бик хаклы рәвештә республикабызның М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булдылар.



*Мансур Гыйләҗевнең «Бурлак» драмасы.*
*Фаил Ибраһимовның соңгы премьераларының берсе.*

Соңгы елларда аның тарафыннан куелган «Бурлак» әсәре (М. Гыйләҗев) шулай ук үзенең алынган темасы, рәвешләнеше ягыннан катлаулы әсәрләрнең берсе, бу да–режиссерның иң беренче чиратта рәссамчы иҗат кешесе икәнлеген раслый торган спектакль.

Әйе, Фаил Ибраһимовның режиссер буларак иҗади шәхси халәте үзе үк катлаулы бер дөньяны хәтерләтә. Аның киләчәктә бу дөньяда «ачасы капкалары» шактый күп булырга охшый. Чөнки ул көн үтсенгә түгел, ә бәлки югары сәнгатькә омтылып, үзенең рухи ихтыяҗына буйсынып, күнеле сусаган көй-моң, олы хисләр, тойгылар дөньясында иҗат итә. Шуңадыр, артист халкы аның белән бер сулышта булуны үзенә бәхет дип кабул итә, иҗат сәгатьләрен көтеп яши.


Татар театрының 100 еллыгы уңаеннан Чаллы театры Казанда уздырылган театр фестивалендә «Банкрот» спектакле белән катнашты һәм тагын бер тапкыр иҗади яктан үзенең көчле коллектив икәнлеген раслады. Бүгенге көндә бу театрда Татарстанның халык артисты һәм Татарстанның атказанган артисты дигән мактаулы исем йөртүчеләр саны җиедән узып бара. Шиксез ки, режиссер Фаил Ибраһимовның да аларның мактаулы исемнәргә лаек булуларында өлеше гаять зур. Ул–аларның таянычы һәм ышанычы. Аның үзенә дә 1994 елда «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән исем бирелде.

**Дания ГЫЙМРАНОВА,**
*театр белгече.*

## САГЫНМАСКА АНЫ МӨМКИН ТҮГЕЛ!..

*Чын иҗатның горур падишаһы,*
*Чын иҗатның горур колы ул!*

Татар опера сәнгатендә: «Татарга опера кирәкме?»—дигән бәхәсле бер вакытта килеп кереп, татарга опера кирәк һәм аның нинди булырга тиешлеген Самат (Х.Вәлиуллин. «Самат»), Җик (Н.Җиһанов. «Алтынчәч»), Җәлил (Н.Җиһанов. «Җәлил») Батыржан (С.Сәйдәшев. «Наемщик»), Закир (Б.Мулюков. «Кара йөзләр») образлары аша таныткан Татарстанның халык, Россиянең һәм Башкортстанның атказанган артисты,Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты мәшһүр җырчы Хәйдәр Бигичевка, исән булса, бүген 60 яшь тулган булыр иде. Кызганыч, туу-үлем адәм баласының үз иркендә түгел шул. Вафатына дистә елдан артык вакыт үтсә дә мәһабәт буй-сыны, горур, шул ук вакытта бераз моңсу да булган карашы күз алдыннан китми, кабатланмас тавышы әле һаман да онытылмый.



Дистә ел-кем өчендер күп, ә кем өчендер аз тоелырга да мөмкин. Ә сәнгать өчен-тулы бер буын үсеп җитәр вакыт. Иҗатының гөрләп чәчәк аткан чагында арабыздан киткән бу җырчыны алыштыра, аңа тиңләшә, аның дәрәҗәсендә бердәй опера һәм җыр сәнгатенә дә хезмәт итә алырлык җырчы табылдымы соң? Юк, табылмады шикелле. Вакыт тәгәрмәчен кирегә әйләндереп булса, ул җырлаган залга бүгенге яшь «җыручыларны» кертеп утыртыр идем дә: «Күрегез, тыңлагыз, татар җырчысы менә нинди булырга тиеш, татар җыры менә ничек башкарылырга тиеш!»—дияр идем. Иманым камил, күбесе үзе өчен оялып чыгып ук китәр иде. Тукаебыз әйткәндәй: «Үзгәрде эшьялар төсе»... «Җыручылар» күбәйгән саен, татар җырының дәрәҗәсе төшә, очсызлана бара. Сәнгать—товарга әйләнде. Бер үк төрле товар күп булганда, бәһасе дә югары була алмыйдыр шул. Хәзерге татар җыр сәнгате турында эстрададан гына чыгып фикер йөрткән бу заманда дистә еллар буе милләтебезнең йөзек кашы булган «Җыр һәм бию» ансамбльләребез дә, милли җырчыларыбыз да күләгәдәрәк калды. Шоу-бизнес дия-дия житәкчеләребез, җырчыларыбыз, хәтта тамашачы үзе дә акны-карадан,талатлыны-талантсыздан аера алмаслык хәлгә килде. «Татар җыры», «Татар моңы» кебек тагын әллә нинди исемнәргә төренеп «моң» исеме белән сату итү, акча эшләү шулкадәр дәрәҗәгә җитте ки, танылган җырчыларыбыз үзләре үк күз йома башладылар. «Әйдә, җырлыйсылары килгәч җырласыннар, татар җыр сәнгате бетмәсен генә»,—диюләреме... Ит югында—үпкә тансык сымаграк... Ә бит бу дөньяда һәркем үз урынын, үзенең ни-нәрсәгә ни дәрәҗәдә сәләтле (хәтта сәләтсез!) икәнлеген белергә тиеш!

«Миңа ин әлек үз фикерем кадерле. Түбәнгә төшмәс, югалмас өчен, үсү

өчен жырчы һәрчак үзенә-үзе бәһа бирергә тиеш...»—бу сүзләр бөек моң иясенең сәхнәгә килергә теләгән һәрбер яшь жырчыга васыятьнамәсе булып калса иде.

Ижатына карата кайчакларда кемнәрнеңдер салкын карашларын сизсә дә, куркып яши торганнардан булмый ул. Аның таланты, моны татар жырыннан—рус, итальян опера–жыр сәнгате дәрәжәсенә күтәрелә ала. Моны үзе дә тоеп, белеп эш итә, бары тик үзенеке дип тапкан эшләргә, рольләргә, жыр-романсларга алына. Аларның да әле нindiләренә! Очсызлы дан артыннан кусаң, үзенең дә бик тиз очсызланасын белә. Үз-үзенә нык таләпчәнлек, кайчакларда хәтта режиссерлар белән дә бәхәскә кереп, үзеннән дөреслегенә ышандыра алу өчен жырчы гына түгел, шәхес булырга да кирәк шул.

Язучылар-каләм ияләре өчен ак кәгазь изге әйбер саналырга тиеш булса, артист-жырчылар өчен изге урын ул–сәхнә. Әле консерваториядә укыган чагында ук Х.Бигичев: «Опера театры сәхнәсендә жырлаганда үлсән иде!»—дигән була. Һәм шулайрак булып чыга да: соңгы көнендә дә эштә, көне буе репетициядә... Вердиның «Аида» операсыннан Радамес партиясен итальян телендә башкарачак ул! Пуччининың «Тоска»сында, Чайковскийның «Пики дама»сында, Бизеның «Кармен»ында, Вердиның «Отелло»сында канатланып ижат иткән кебек, Радамес партиясен башкарырга да дәртләнеп алына. «Бу партия әйтерсең, гел минем өчен язылган»,- ди якыннарына.



*Н.Жиһановның «Жәлил» операсыннан бер күренеш. Жәлил ролендә–Х.Бигичев. Акылдан язган хатын—Алла Фадеичева.*

Хәйдәр Бигичев ядкаренә багышлап чыгарылган истәлекләр китабын актарам... Кемнәрнең генә язмалары юк анда. Остазлары, хезмәттәшләре, авылдашлары, туганнары... Һәммәсендә аның белән чиксез горурлану, вакытсыз үлеменә уфтану, сәнгать белгечләренең аның ижатына югары сәнгать дәрәжәсеннән чыгып биргән бәясе. Хәйдәр Бигичев өчен «Отелло» операсын сәхнәгә махсус куйган режиссер В.Раку үзенең истәлекләрендә: «Әгәр Хәйдәр Бигичев үз гомерендә башка бернәрсә жырламыйча бер Отелло ролен генә башкарса да, дөньяның музыкаль тарихында калыр иде. Отелло партиясе тенорлар репертуарындагы иң катлаулы партияләрнең берсе. Бездә дә, чит илләрдә дә аны башкарырга бик сирәк жырчылар гына алына»,—дип яза.

Сәхнәдәге Жәлил, Батыржан, Отелло белән тормыштагы Хәйдәр арасында охшашлыклар күп, ул да үзенең геройлары кебек яклауга, аңлауга мохтаж, аның да жаны яралы. Беренче карашка бераз кырыс, корырак тоелса да, яралы йөрәк астында үтә дә сизгер, нечкә, тиз жәрәхәтләнүчән күңел ята...

Бер караганда гап-гади татар авылында (Түбән Новгород өлкәсе, Чүмбәли авылы) туып-үскән егеттә опера сәнгатенә тартылу каян килгән соң, дип уйланып та куясың. Бу өлкәдә балалар бакчасы яшеннән әби-бабалары музыка мәктәбенә житәкләп йөрткән шәһәр балаларыннан зур уңышлар көтәбез, юкса.

Армиядән кайткач Х.Бигичев Түбән Новгород консерваториясенә юнәлә. Әле

ярый, андагы укытучылар анын тавышынын опера сәнгате өчен генә түгел, милли жырлар башкару өчен дә яратылганын тоеп Казан консерваториясенә барырга киңәш итәләр. Азмы чит сәнгатькә хезмәт итүче талантларыбыз? Йөр аннары фамилиясе татар булганы өчен генә дә: «Ул–безнеке!»–дип куанып...Чын мәгънәсендә милләткә хезмәт иткән ул-кызлары белән генә халкыбыз горурланырга хаклы.

Анын репертуарындагы милли байлыгыбыз саналган халык жырлары үзе бер аерым сөйләшүгә лаек.

«Халык жырлары Хәйдәр өчен–жан таләбе. Ул аларны рухланып, илаһиланып жырлый иде. Диапазонынын киңлеге һәм тынынын иркенлеге аңа үзе гажәеп яратып башкара торган борынгы татар халык көйләрендә иң нечкә нюансларга ирешергә мөмкинлек бирде»,–дип яза бу турыда жырчы Әлфия Заһидуллина.



*Хәйдәр Бигичев хатыны Зөһрә Сәхәбиева белән.*

Бихисап күп жырлар-романслар да бары тик анык гына булып халык күңелендә калды,жыр сәнгатенен алтын фондында урын алдылар. «Идел суы ага торыр...», «Иң якты йолдыз», «Тын сукмакта тал тирбәлә», «Керим эле урманнарга», «Көзге моң»...

Хәйдәр Бигичевны югалту—шәхси югалту булып кына түгел, милләтебезнен йөзек кашы булган Тукай, Сәйдәшләрне югалту дәрәжәсендәге яра булып, халкыбыз күңелендә эле бик озак әрнер...

...Жир йөзендә яшәгән 49 ел гомеренен яртысыннан артыгы—Казанга килеп яңа тормыш башлаганнан алып соңгы минутка кадәр алар бергә... Яшәү, ижат, бәхет, мәхәббәт турында бер төсле фикер йөртеп, киңәш-табыш итешеп булсынга дип гомер кичү... Нинди матур янәшәлек! Талантлы кеше белән гомер итүнен үзе исән чакта гына түгел, вафатыннан соң да никадәр жаваплылык өстәгәнен үзе дә ижат кешесе булганнар яхшы белә.

Хәйдәре белән Хәйдәрсез генә тормышка күчкәч, вакыт беразга туктап калган сымак булса да, Татарстаннын халык артисткасы Зөһрә ханым Сәхәбиева-Бигичева яралы йөрәген учына кысып үзендә халык каршына чыгып баса алырлык көч таба. Президентыбыз хәер-догасы белән, Мәдәният министрлыгы үткәргән, татар жыр сәнгатенә житди караган яшь вокалист-жырчыларнын Х.Бигичев исемендәге I халыкара конкурсын оештыруда да башлап йөри, диск-язмаларын чыгара, истәлекләр яза, татар яшәгән төрле төбәкләрдә анын ядкаренә багышлап концертлар куя... Барсы да Хәйдәре хакына, анын ижаты, милләтебезнен бөек хәзинәсе булган галижәнап жыр хакына... Халкыбызнын аны яратуы, сагынуы хакына... Ә сагынмаска аны мөмкин түгел!..

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

Лирон
Хәмидуллин

# ЕРАКТАГЫ АК ҖИЛКӘННӘР

ТАРИХИ ОЧЕРК

## I

Үзенчәлекле шагыйребез, күренекле җәмәгать эшлеклесе Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә багышланган зур фотоальбомга материал туплау нияте белән 1994 елның җәендә без Оренбург якларына барып чыккан идек. Юлдашым—күренекле фотограф, күптән түгел генә «Габдулла Тукай» альбомын нәшер итүдә төп вазифаны үтәгән Зөфәр Гомәр улы Бәширов. Билгеле инде, Оренбург төбәгендә атаклы шагыйрьнең балачагы эзләрен саклаган Жиргән, Юлык авылларын да читләтеп үтмәдек. Бераз соңрак шагыйрь яшәгән Орск, Баймак шәһәрләренә, Чиләбе өлкәсендәге Балкан авылына да бардык.


*«Изге таш» янәшәсендә.*

Оренбург шәһәре янәшәсендәге бай тарихлы Татар Каргалысында да булдык. Бертуган Рәмиевләр монда бик еш килеп-китеп йөргән. Шакир Рәмиев хатыны «Гәүһәр абыстай» Оренбург кызы исәпләнсә дә, аның ата-аналарының тамыры шушы авылга бәйле булса кирәк. Дәрдемәнд «зәүҗаны» Мәһүбҗамал да бу «зыялы каланы» үз иткән—узган гасыр башларында монда кызлар мәктәбе оештырып йөргән.

Язма әдәбиятта ул авыл «Оренбург Каргалысы» дип тә атала. Монда мина элегрәк тә булгаларга туры килгәләгән иде. Мәсәлән, 1984 елда шагыйрь Һибатулла Салихов варислары белән очрашырга, алардан истәлекләр язып алырга насыйп булды. Каргалы авылы элегрәк заманнарда мин үскән төбәкнең рухи-дини бер башкаласы булып торган. Безнең Бозаулык суы буе татар авыллары ул дәвердә рәсми рәвештә Самара губернасына буйсынсалар да, мулла-мәзиннәренең күпчелеге шушы Каргалы мәдрәсәләрендә укыган затлар була. Совет хакимияте дәверендә дә Каргалыдан чыккан укытучылар ишле иде. Сугыштан соңгы елларда Бозаулык суы башланган Иске Белогорда безне дә шул авылның бер кешесе укытты. Үз исеме Мөхәммәтне балалар теленә кертмәскә тырышып, ул үзенә «Салихов абый» дип эндәшүне генә хуп күрер иде.

Бу авылның халык телендә «Сакмар буе Каргалысы» дигән исеме дә бар. Чөнки ул Сакмар буенда, Сакмар-су тамагына якын гына җирдә урнашкан. Хәзерге рәсми язмаларда ул Татар Каргалысы дип атала. Еникиев, Терегулов морзаларның төп йорты саналган «Бәләбәй Каргалысы» (элек ул Бәләбәй өязенә кергән) белән Татарстанның Чистай шәһәре янәшәсендәге Каргалыдан аермалы буларак, Оренбург

янәшәсендәгесенең тагын бер рәсми атамасы булуын да әйтеп үтик. Унсигезенче, унтугызынчы йөзләргә караган язма документларда ул «Сәгыйд бистәсе» («Сеитов посад») исеме белән дә йөргән. Татар дөньясында бу авылга багышлап иҗат ителгән аерым хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, Чулпанай Мирхәйдәр дигән берәү 1890 елда Оренбургта «Сәед бистәсе» исемле китабын бастырып чыгара. Мәшһүр галимебез Ризаэддин хәзрәт Фәхреддиневнең дә Уфада яшәгәндә, 1898 елда ук бу авылга багышлап «Сәгыйд» исемле китап нәшер иткәнлеге һәм Оренбургта вакытта «Әхмәт бай» китабын язганда (1911 ел) аерым бүлек багышлаганлыгы мәгълүм.

* * *

Каргалы элек Оренбург—Казан юлы өстендә утырган иң зур авылларның берсе булган. Хәзер дә әле ул Сакмар елгасы буйлап өч-дүрт чакрымга җәелеп утыра. Зур урамнары Сакмар ярыннан күтәрелә башлаган сөзәк үр буйлап сузылган. Аркылы урамнар үр сыртындагы борынгы кабер ташларына таба бара. Табигый таштан корылган зират коймасы белән авыл арасыннан киң асфальт юл уза. Мәңгелеккә дип эшләнгән бу зират коймасының кайчан корылганлыгын белүче юк. Ул койма, шундый ук таштан төзелгән элекке кибет, келәтләр авыл белән бер үк вакытта корыла башлаган булса кирәк. Басу ягы табигате үрле-калкулы япан кырдан гыйбарәт. Сакмар-суның аргы ягын тоташ урман хасил итә. Өянке, усак, каен урманы. Ул урманның зур өлеше элек бер алпавыт карамагында булган. Хәзер ул шәһәр яны урманчылыгына керә.

«Әхмәт бай» китабының «Каргалы шәһәре» бүлегендә Ризаэддин Фәхреддинев егерменче йөз башы авылын болайрак тасвир кыла: «Оренбургтан егерме чакрымнарда, Сакмар елгасының уң яры буйлап сузылган бер шәһәр булыр. Халык телендә ул Каргалы дип кенә йөртелә. (Бу исем аңа шәһәр уртасыннан Сакмарга агып төшүче Каргалы елгасына нисбәтле рәвештә бирелгән.) Аның «Сәгыйд бистәсе» дигән атамасы да бар. Анда мөселманнар гына яши. Бу бистәне сәүдәгәр Сәгыйд Хаялин нигезләгән, шунлыктан шәһәр аның исеме белән дә йөри. Җаек һәм Идел елгалары буйларында башка андый саф мөселман шәһәрләре юктыр. Шушы көндә Каргалыда ун сан мәсчет булып, күбесендә икешәр указлы мулла бар... Каргалының барлык әһлиясе (халкы) чама белән унөч меңдер. Укымышлысы, хәлфә вә суфыйларны кертмичә, йөз ярым чамасы булачактыр. Каргалы шәһәрендә һәр гасырда үзенә күрә шөһрәтле галимнәр, аз булса да шагыйрь вә әдипләр яшәгән. Сәгыйд бистәсен Елизавета императрица 1745 елда төзергә рөхсәт бирә... Шушы көнге Каргалыда әлегә почта вә телеграф юк, хастаханә дә юк. Моңа шәһәр исеме бирелүе башкалардан аеру ниятеннән эшләнгәндер. Оренбургта исә бу көндә йөз мең чамасы кеше яши, шуның дүрттән бер өлеше әһле ислам кешеседер».

Боларга өстәп шуны гына әйтик, патшабикә әмере чыкканчы ук Казан төбәгеннән бу авылга берничә гаиләнең күчеп килгәнлеге мәгълүм. Алар 1743 елда Оренбург губернаторы И. И. Неплюев рөхсәте белән монда килеп төпләнәләр. Димәк, Каргалы авылы хәзерге Оренбург шәһәре белән бер үк вакытта төзелә башлый. Ә кайбер галимнәр фикеренчә, ул җирдә элек-электән үк ерак бабаларыбыз яшәгән булырга тиеш. Чөнки ул безгә кардәш халыклы Урта Азия мәмләкәтләре белән Уфа, Казан төбәкләрен тоташтыручы сәүдә юлы өстендә утрак тормыш алып бару өчен иң җайлы урыннарның берседер. Шушы төбәк авыллары мазаратын хәтерләткән зират күренеше дә шул ук фикерне раслый сыман. Казан арты авылларыннан күченеп килгән мөселманнар монда каберлеккә агач утыртмый башлаганнар. Димәк ки, биредә алар элек-электән яшәүчеләр йоласын үтәргә мәҗбүр булганнар.

Оренбург тарихчысы Сергей Попов хәбәр итүенчә, 1747 елда Каргалыда йөз җитмеш өч йорт-каралты булган, анда яшәүче ир-ат саны меңгә җиткән. Бу авылга зур сәүдәгә керешерлек бай мөлкәтле һәм әз-ким сәүдә тәҗрибәсе туплаган кешеләрне генә алырга тырышканнар. Беренче күченеп утырган ике йөзләп сәүдәгәр башлыча Казан, Вятка, Сембер губерналарыннан китерелгән. Әлбәттә, алар арасында дин әһелләре дә ишле генә санала. Мәсәлән, Каргалының икенче ахуны, соңыннан илле ел чамасы Рәсәйнең Европа һәм Себер өлеше мөселманнары мөфтие вазифаларын үтәгән Мөхәммәтҗан бине әл-Хөсәен әл-Борындыкый нәселе

монда Зөя елгасы буе Борындык авылыннан килгән була. Һәр сәүдәгәр, һәр мулла йорт-кура һәм мал-туар тоту өчен үзе белән берничә хезмәткәрне алып килә алган. Аерым һөнәр осталарын чакырып китерү дә рөхсәт ителгән. Мондый мәсьәләләрне хәл итү авылның беренче старостасы Сәгыйд Хәялинга йөкләтелә, билгеле.

Патша хөкүмәте Каргалы бистәсенең оешу көннәрендә үк Урта Азия ханлыклары белән сәүдә арадашлыгын башлап җибәрү бурычын куя. Ташкент тарафына беренче зур сәүдә кәрваны 1741 елда, Оренбург һәм Каргалы төзелә башлаганчы ук, Орск кальгасыннан җибәрелә. Аны оештырып җибәрүдә Сәгыйд Хәялин дә катнашкан дигән фикер бар. Шубай Арсланов белән Мансур Йосыпов җитәкләгән ул кәрван үз бурычын уңышлы үтәп чыга. Казакъ, үзбәк ханлыклары җирләреннән үтеп, сәүдәгәрләр Ташкент каласына барып җитә һәм бер елдан соң зур табыш белән үз илләренә әйләнеп кайталар. Сәгыйд бистәсе тарихына багышланган соңгы китап авторлары—аталы-уллы Искәндәревләр раславынча *(«Сеитов посад», Казан, 2005)*, шул ук тарафка икенче зур рәсми кәрван берничә елдан соң Каргалы авылыннан чыгып китә. Кәрван башы итеп Сәгыйд Хәялиннең бертуганы сәүдәгәр Габдулла Хәялин билгеләнә. Бу кәрван да, үз бурычын уңышлы үтәп, 1749 елда Оренбургка әйләнеп кайта. Әлеге китапта китерелгән архив материалларына караганда, бу кәрван ефәк, парча, чәй ише товардан тыш, җиде пот көмеш тә алып кайта. 1750 елда шул ук Габдулла Хәялин, Надир Сәфәров һ.б. катнашында тагын бер кәрван Хива ханлыгы башкаласына юнәлә. Аны шул ханлык илчесе Ширбәт озата бара. Ә бер елдан соң зур бер кәрван тагын да ераграк юлга дип чыга. Исмәгыйль Бикмөхәммәтев җитәкләгән ул кәрванга Һиндстанга барып җитү бурычы куелган була. Бу сәүдәгәрләр бик җитди бурычның бер өлешен генә үтиләр—Һиндстанга барып җитәләр, ләкин илләренә әйләнеп кайту күпләргә насыйп булмый. Чирек гасырдан артыграк вакыт үткәч кенә кәрван башы Оренбургка кайтып егыла, юлда күргәннәренең бер өлешен язып калдыра. «Исмәгыйль ага сәяхәте» язмасын Ризаэддин Фәхреддинев, 1903 елда Оренбургта нәшер итеп, киң җәмәгатьчелеккә житкерә.

Әлбәттә, әлеге кәрваннарны оештырып җибәрүдә, төбәк түрәләреннән тыш, рус сәүдәгәрләренең дә өлеше зур була. Мөселманнар яшәгән җирләргә рус кешесенең аяк басуы тыелганлыктан, алар анда үзләре бара алмаган, билгеле. Дөя үркәчләренә өелгән мал-мөлкәтләре генә ул якларда «сәүдә кылып йөргән.» Каргалы кешеләре аша эш йөртүче сәүдәгәрләр исемлегендә Мәскәү төбәгеннән рус В. Журавлев, грек И. Мавродин, соңрак Казанда сәүдә өлкәсендә дан казанган Кекиннардан берәү, Урал-тау казылма байлыкларын аяусыз үзләштерүче сәнәгатьче Твердышевлар һ.б. бар.

Билгеле инде, патша түрәләре ул сәүдә кәрваннары белән әлеге ханлыкларга үз шымчыларын да даими рәвештә җибәреп торганнар. Шундый шымчыларның иң танылганы, әлбәттә, Ян Виткевич була. Ул Ташкент, Сәмәркандлар аша үтеп, Кабулга ук барып җиткән. Берләштерелгән Һиндстан империясен нигезләгән «мәшһүр татар» Заһретдин Бабур шаһның Кабулдагы затлы сарай һәм бакчаларында йөргәндә, бу разведчик рус патшаларын шул бай мәмләкәтне яулап алу мөмкинлекләре бар дип тә ымсындыра. Аның шуңа тартым хәбәрләре һәм күргән-белгәннәре турындагы язмалары безнең сәүдәгәрләр аша Оренбург якларына даими рәвештә җибәрелеп торган. Ана багышланган кайбер хезмәтләрдә «Виткевич коръән сүрәләрен мөселманнардан яхшырак белгән, намаз гамәлләрен алардан остарак башкарган», дип арттырыбрак та язалар. Дөреслектә кем булган соң ул? Польшада, туган-үскән илендә, Россиягә каршы фетнәдә катнашкан бер ир-егет. Мөгаен, тумыштан ук мөселман өммәте кешесе булгандыр. Сөргенгә Казакъ ханлыгы чигендә урнашкан Орск каласына җибәрелгән. Шунда, имеш, мөселманча гамәл кылырга һәм сөйләшергә өйрәнә. Аннары бер сәүдә кәрваны белән Урта Азия тарафына озатыла. Тизрәк иленә кайтасың килсә—безгә хезмәт ит, дип. Билгеле инде, чит-ят җирләрдә булганда ул татар исемен йөрткән, разведка мәгълүматларын Орск, Оренбург, Каргалы татарлары аша җибәреп торган...

Каргалы кешеләренең үзләренең мондый эш белән шөгыльләнүе турында әлегә берниндн мәгълүмат та юк.

* * *

Унсигезенче йөзнең сиксәненче еллары башында Каргалыда өч мәчет эшләгән. Аннары һәр ун-унбиш ел саен диярлек берәр мәчет салынган. (Шуна да игътибар итик: нәкъ шул чорда Казан төбәгендә мәчетләр җимерелә, мәктәп-мәдрәсәләр ябыла. 1745—1755 еллар аралыгында 418 мәчетнең юк ителүе мәгълүм.) Сакмар буендагы бишенче агач мәчет «әүвәл 1760 елда төзелә. Бер янгын вакытында ул янып бетә. Соңрак аның урынында яңа мәчетне булачак миллионер Хөсәеневләрнең бабасы Хөсәен бай салдырган», дип хәбәр итә Ризаэддин хәзрәт. Унсигезенче-унтугызынчы йөзләр аралыгында төзелгән кайбер таш мәчет биналары хәзер дә исән әле. Зәки мулла тырышлыгы белән төзелгән беренче таш мәчет 1775 елда ачылган. Элекке агач мәчет урынына яхшы кирпечтән өч катлы итеп 1883 елда төзелгән базар мәчете унтугызынчы йөзнең соңгы мәчете була. 1912 елгы зур янгыннан соң авылда тагын бер мәчет торгызыла.



*Сәгыйд Ает улы Хәялин йортының сакланып калган өлеше.*


Хәзерге көндә анда ике мәчет эшли. 1930 еллар ахырына авылның унөч мәчете дә үз вазифасын үтәүдән мәхрүм ителгән була. Күбесенең манаралары сүтелә. Мәсәлән, унтугызынчы йөз башларында таштан салынган «Кушманаралы мәчет»нең язмышы шундый. Аның манаралары 1941 елның көзендә, мәчет бинасында кавалерия полкы ашханәсе ачылганда сүтеп ташлана. Авылның нәкъ уртасында, Муса Җәлил тыкрыгы белән Габдулла Тукай урамы кисешкән урында урнашкан ул мәчет, халык таләбе белән, 1963 елда кабат ачыла. 1966 елда аңа яңа манара куела. Каргалы елгачыгыннан башланып, авылның буеннан-буена сузылган Тукай урамында тагын берничә борынгы таш корылма саклана әле. Соңгы елларда аларның кайберләрен төзекләндерүгә керештеләр. Сакмар очындагы борынгы бер таш мәчетне дә матурлап яңадан эшли башлаганнар. Авыл уртасында Каргалыга нигез салган Сәгыйд Ает улы Хәялинның табигый яссы таштан төзелгән йортының һәм коймасының бер өлеше дә саклана әле. Элек ул туптан атып та җимерә алмаслык нык корылма булган. Йортның бу өлешен зур кибет һәм товар сакларлык бүлмә, келәтләр биләп торган. Хуҗалар исә икенче катта, бүрәнә өйдә яшәгәннәр. Башка эре сәүдәгәрләрнең һәм һөнәрчеләрнең йорт-хуҗалыклары да элек шул рәвешлерәк итеп эшләнгән була. Аста, эре таштан төзелгән, челтәрле тимер ишек-тәрәзәле «пулатлар»да кибет яки остаханәләр урнаша, өстәге бүрәнә өйләрдә хуҗалар яши.

Авылның ярлырак өлешендә, «Дунай бистәсендә» агач мәчетләр булган. Шулардан Әюб бине Ибраһим әл-Бөгелмәви имамлык иткән 9нчы мәхәллә мәчетенең XIX йөз ахырында җәдидчелек хәрәкәтенә үз өлешен кертүе билгеле. Гани бай Хөсәенев тәкъдиме белән 1899 елда мәчет карамагындагы мәдрәсәдә җәдитчә укытырга теләк белдергән хәлфәләр өчен махсус уку оештырыла. Моның барлык чыгымын, укырга килүчеләрне тәэмин итү чыгымнарын да Гани бай үз өстенә ала. Каргалыга төрле тарафтан бик күп хәлфәләр белем ишәйтергә килә. Алар арасында татарның күренекле шәхесләреннән Һади Атласи, Гаяз Исхакый, Габдерахман Сәгъди һ.б. бик күпләр була. Бу эшкә исә Төркиядә укып кайткан язучы, булачак «Вакыт» газетасы мөхәррире Фатих Кәрими җитәкчелек итә.

## II

Олуг галимебез Ризаэддин Фәхреддинев «Әхмәт бай» китабының Каргалыга багышланган бүлегендә: «Бу шәһәр киләчәктә үз трамвае, телефон станциясе, хастаханәсе булган тагын да зуррак шәһәргә әверелер әле», дип язса да, ул өметләр өлешчә генә акланды. Без яшәгән гасырның утызынчы-кырыгынчы елларында бередә йортларга электр уты, радио кертелә башлый, телефон линиясе сузыла. Ә медицина пункты (амбулатория) белән аптека—унынчы елларда, унбиш авыруны дәвалауга исәпләнгән төбәк хастаханәсе исә 1961 елда ачыла. Мәгәр Совет хакимияте дәверендә элекке «шәһәр» үсми, киресенчә, йортлар саны бермә-бер, халык саны исә өчләтә-дүртләтә кими. (Хәзер авылда дүрт мең чамасы кеше яши.) Мондый «кимү»ләрнең сәбәпләре һәркемгә аңлашыладыр, шәт. Ике-өч йорт хуҗасының берсе байлар исәбендә йөргән ич ул вакытта. Дин әһелләре дә бик ишле булган.

«Һәр мәчет хозурында ибтидаи (башлангыч) вә бәгъзеләрендә рөшди (җиде сыйныфлы) мәктәпләр ачыла», дип хәбәр итә Р. Фәхреддинев. Әйе, авылда төзелеш барган елларда ук мәктәп-мәдрәсәләргә дә нигез салына. Тәүге мәдрәсә мөдәррисләре Каргалыга күченеп килгәнче үк дини уку йортларына җитәкчелек иткән абруйлы шәхесләр булалар. Шундый шәхесләр арасында Габдессәлам бине Уразмөхәммәд мулла беренче булып тора. 1746 елда Каргалыга күченеп килгәнче ул Казан артындагы Ташкичү авылы мәдрәсәсендә балалар укыткан. Каргалыга күчкәндә аңа кырык алтынчы яшь була. Белеме, тәҗрибәсе дә җиту бу мулланы авыл сәүдәгәрләре махсус чакырып китерегәннәрдер, мөгаен. Килгәч тә ул монда беренче мәдрәсәне ачып җибәрә. Үзе белән ияртеп кайбер шәкертләрен дә алып килгәнлектән, хәлфә-мөгаллимнәргә кытлык кичерми. Тарихтан мәгълүм ки, патша хөкүмәте җәберләвенә түзә алмыйча баш күтәргән татар-башкортлар фетнәсен оештырган Батырша да шушы Габдессәлам ахун шәкерте була.



*Оренбургтагы беренче таш мәчет.*

Оста янына оста, зыялы янына зыялы җыелыр дип әйтә бит халык. Шигъри җанлы мулла Габдессәлам артыннан ук диярлек Каргалыга Буа тарафыннан Вәлид мулла да килә. Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминне икенче мәхәллә каршындагы мәдрәсәгә баш итеп билгелиләр. Вәлид ишан хәзрәтләре белән Уразмөхәммәд ахунның (тәхәллүсе Габдессәлам Урай) шигырь үрнәкләре безнең көннәргәчә сакланган. Аларның кайберләре «Татар поэзиясе антологиясе»ндә дә урын алганнар. Габдессәлам Урайның шигырьләрен үз заманында Гавриил Державин да русчага тәрҗемә итә, дип белдерә әдәбият галиме Хатип Миңнегулов.

Боларның мәдрәсәсенә әдәби һәм гыйльми иҗат белән шөгыльләнүгә дәрте булган шәкертләр төрле тарафтан килә башлый. Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Тимәш авылыннан килгән шәкерт Габдерәхим дә Каргалыда Вәлид ишан мәдрәсәсен үз итә. (Бөгелмә өязе 1851 елдан яңа оешкан Самара губернасына керә.) Укуын тәмамлагач Габдерәхим, үз мәдрәсәсендә үк калып, берничә ел балаларга белем бирә. Шушы җирлектә ул шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарый буларак таныла, тәүге гыйльми эзләнүләрен шушында башлап җибәрә. Утыз Имәни белән бер үк чорда Каргалыда аның яшьтәше, каһарман язмышлы Салават Юлаев та белем ала. Билгеле, ул да олуг шагыйрьләр арасында үзенең шагыйрьлек көчен сынап карагандыр. Бу ике яшьтәшнең шәхес буларак җитешүләре һәм иҗатларының чәчәк ату чоры, шөбһәсез, шушы Каргалы дәверенә туры киләдер. Габдерәхим Утыз Имәнинең Каргалы кызына өйләнүе, 1774 елда аларның монда Бәдыйгелҗамалы туганлыгы да мәгълүм.

Күпмедер вакыт Харәземдә һәм Казан артындагы Казаклар, Кышкар

мәдрәсәләрендә шәкертләргә белем биреп байтак тәҗрибә туплаган шагыйрь һәм фикер иясе Ишнияз бине Ширнияз бине Ярмөхәммәд әл-Харәзми дә 1776 елда Каргалыга килеп төпләнә. Монда аны да мәдрәсә мөдәррисе итеп куялар. Ишнияз мулланың әдәби һәм гыйльми мирасы өлешчә Казан мирасханәләрендә саклана. Каргалы авылы зиратында тулы исем-атамасы язылган гадирәк кенә кабер ташы да бар әле. Аның төрки дөньяда мәшһүр булган «Ләйлә илә Мәҗнүн» поэмасы җирлегендә, шул исем белән аталган җыйнак эчтәлекле матур бер әсәр иҗат иткәнлеге, Каргалыда яшәү дәверендә 1780 елда «Болгарда дини ышанулар» («Гакаиде Булгария») фәлсәфи хезмәтен язганлыгы мәгълүм. Бу мәгърифәтче мулланың дини эчтәлекле дәреслек кульязмаларының булуы да билгеле.

Бер авылда бергә яшәгән Ишнияз бине Ширнияз остаз белән Утыз Имәнинең үзара аралашмаулары һич тә мөмкин түгел. Ләкин ул хакта әлегә тулы мәгълүмат юк. Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Ишнияз мулланың күпчелек мирасын якташлары Үргәнеч каласына алып китәләр. Андагы мирас белән безнең галимнәр таныш түгел дияргә була. Утыз Имәнинең 1788 елда ишле гаиләсен алып Бохарага чыгып китүендә дә бәлки Ишнияз остазның йогынтысы булгандыр. Ләкин әлегә ул хакта мәгълүмат юк шикелле. Ишнияз бине Ширнияз 1791 елда Каргалыда вафат була. Гаиләсе шунда торып кала. Варислары бүгенгә мәгълүм түгел. Каргалының беренче шагыйрьләреннән булган Габдессәлам Уразмөхәммәд (Урай) Утыз Имәни Каргалыга килгәнче үк, 1762дә вафат булган. Вәлид мулла 1800 елда хаҗ сәфәренә китә һәм 1803 елда шунда гүр иясе була. Ләкин авылда аларның күпсанлы варислары, иҗатташ шәкертләре кала.

* * *

Мулладан мулла, җир сукалаучыдан сукачы чыгар дип әйтелә. Каргалы халкының зыялы катламыннан чыккан, татар дөньясында күренекле эз калдырган шәхесләр дә ишле генә. Шулардан берничә исемгә генә тукталып үтик. Каргалы төбәгенә беркетелгән авыл муллаларына баш, ягъни ахун хәзрәтләре вазифасын да үтәгән Габдессәлам бине Уразмөхәммәднең оныгы Әбелмәних Әбелфәез улы Габдессәламов әдәбият сөючеләребезгә бик таныш кеше. Ата-бабасы кебек мулла вазифасын үтәүдән бигрәк ул безгә классик шагыйрь Әбелмәних Каргалый буларак билгеле. Аның икенче тәхәллүс-кушаматы исә Сәгыйд бистәсенә нисбәтле була: Хаҗи Әбелмәних әл-Бистәви әл-Сәгыйди. Бабасы вафатыннан соң дөньяга килгән бу бала бик тынгысыз холыклы булгандыр, күрәсең. Үз авылында мәдрәсә белемен үзләштергәннән соң, ул берникадәр вакыт Бохара, Истанбул кебек төрки дөньяның ул дәвердәге мәшһүр үзәкләрендә дә укып йөргән. Шул үзәкләрдә иҗат иткән әдипләр белән аралашкан. Алар белән ярышып шигырь вә поэмаларын язган. Танылган әдәбият галиме Мөхәммәт ага Гайнуллин аны унтугызынчы йөз татар әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе дип атый. Ризаэддин хәзрәт Фәхреддинев тә аның иҗатын бик югары бәяләгән: «Язылган шигырьләре һичбер җирдә вә гасырда йөз кызартачак түгел», дип әйткән.

Шагыйрь 1830 еллар урталарында, илле биш яшьләр чамасында, икенче мәртәбә хаҗга барган җирендә изге туфракта ятып кала.

Әбелмәних Каргалыйдан ундүрт-унбиш елга соңрак, 1794 елда туган Һибәтулла Сәетбаттал улы Салихов Сәед бистәсе данын татар дөньясына тараткан өченче күренекле шагыйрь санала. Аның атасы Каргалыныкы, бабасы исә бу авылга Чистай өязе «Такталы карьясыннан» килгән кеше. (Хәзер ул авыл Аксубай районына керә.) Һибәтулла туганда аның атасы Каргалыдан ерак булмаган Түбәнге Чебенке авылында мулла вазифасын үтәгән. (Авыл исемен шул төбәк халкы атаганча язуны хупладым. Бала чагымда укыткан Хөснә апам да шул авылныкы иде. Үрге һәм Түбәнге Чебенкеләр арасында элек, Оренбург каласын төзегәндә, вак таш—щебенка чыгару базы булган. «Матур туганда» романында Ш. Камал да ул баз-чокырларны тасвирлап үтә. Бу авыллар атамасы нигезендә шул «щебенка» сүзе ятадыр кебек. Безнең әдәби язмаларда кабул ителгәнчә, чебенгә бәйле сүз: «Чебенле» түгелдер.)

Һибәтулла шулай ук Каргалы мәдрәсәсен тәмамлый. Мәдрәсәдә аның остазы шагыйрь Вәлиәтдин Багдадый була. Һибатулла Салиховның мулла, мәдрәсә

башлыгы һәм шагыйрь буларак дан казанган төп йорты Каргалыдыр. Бу авылның Сакмар очы зиратында ишан хәзрәтләренең җыйнак кына кабер ташы сакланган. Ул 1867 елда вафат була. Кабер ташының арткы өлешенә «дүртенче сөйгән хатыны Бибимәхтүмәнен дә кабере» дигән сүзләр дә язылган. Димәк, бу кабер ташы астында аркага-арка терәп ике җан ята. Каргалыда шагыйрь нәселе вәкилләре исән әле. Аларның кайберләре Салихов, бер ише Сәетбатталов фамилиясен йөртә. Күпчелеге укытучы һөнәрен сайлаган. Каргалыдан йөз утыз чакрымнар көнбатыштарак урнашкан Иске Белогор авылында Мөхәммәт Салиховның балалар укытканлыгы алда әйтелде. «Сугышмаган, әсир ителгән» дип, аны ул елларда бераз кыерсыттылар да шикелле. Әдәбият фәненнән укытмаса да, «Салихов абый» безгә кайчак, онытылып, дәреслектә булмаган шигырьләр сөйләве белән истә калган.

Һибатулла Салиховның дүрт хатынының берсе (борынгы бабаларыбыз әйткәнчә беренче—«алтын хатын»ы) атаклы татар морзалары Айдаровлар нәселеннән. Элек Оренбург, Уфа төбәкләрендә бу нәселдән чыккан зыялылар бик ишле булган. «Хөсәения» мәдрәсәсендә дә бу токымнан берничә кеше укыта. Татар матбугатында еш тиргәлгән Казан арты «Түнтәр авылы ишаны»ның кияве дә шул морзалар нәселеннән. Совет чоры татар язучысы Әсгать Айдар да шул токымнан иде.

* * *

1984 елда Каргалыда Һибатулла Салихов мирасына ия булган олы яшьтәге ике апа исән иде әле. Хәзрәтнең кызының кызы, туксан бер яшьлек Кәримә Габделлатыйпова ул җәйдә инде урын өстендә ята, авыр сөйләшә иде. «Минем әбием морза Айдаровлар нәселеннән була. Кызым Зәйнәп белән хәзер без шушы абруйлы ике токымның соңгылары», дип әйткән иде ул. Кәриманең атасы Җәмил хәлфә ишан хәзрәтләренең яраткан шәкерте була. Әлбәттә, Һибатулла хәзрәт һәм аның мирасы турындагы әңгәмәнең дәвамы пенсия яшенә җитеп килүче Зәйнәп апа белән дәвам ителде. Ул Каргалы мәктәбендә татар теле һәм әдәбиятын укыта иде. Илленче еллар башында Оренбург педагогия институтының татар бүлеген тәмамлаган. «Яраткан укытучым Үлмәс апа Беляева иде. Ул Каргалыга еш килеп йөрде. Иске язмаларны, китапларны укый, алып та киткәли иде. Үзем дә ул сораган иске китапларны аңа илткәләдем. Килгәндә күбрәк бездә торды... Әйе, Зөһрә әбиләрдә дә була иде»...

Зөһрә әбинең дә Һибатулла хәзрәт нәселеннән икәнлеген белә идем. Каргалы урта мәктәбе башлыгы авылдашым Илдус Зәбиров белән сиксән дүрт яшьлек Зөһрә Сәетбатталова өендә дә булдык. Авылның «Дунай бистәсе» очында. Зөһрә әби житез хәрәкәтле, зиһенле татар апа-әбиләренең берсе буларак хәтердә калган. Ләкин инде ул без килгәндә сукырайган иде. «Күзем күрми башлаганга бишенче ел була. Шул сәбәпле әле өченче ел гына биатамнан калган биш-алты калын дәфтәрне Жизактан килгән бер зыялыга биреп җибәрдем. Бик озаклап дога кылып алды. Зур итеп сәдака бирде. Сукырайгач, үзем укый алмыйм. Балалар да кызыксынмый...» дип сөйләгән иде ул.

Әйе, Утыз Иманидән, Әбелмәних Каргалыйдан, Һибатулла Сәлиховтан һ.б. Каргалы зыялыларыннан калган язма мирас белән кызыксынучылар элегрәк күп була. Сугышка чаклы Оренбург педагогия институтында укыткан Жамал Вәзиева да, илленче еллар урталарында монда берничә көн булып киткән Нәкый ага Исәнбәт тә борынгы язма истәлекләр белән кызыксынганнар. Соңрак Каргалыда әдәбият галимнәребездән Мөхәммәт Гайнуллин, Миркасыйм Госманов һәм тагын кемнәрдер була. Житмешенче-сиксәненче елларда Уфадан Зәйтүнә Шәрипова Каргалыга берничә мәртәбә килә. «Зәйтүнә монда ялгызы да, студентлар белән дә күп тапкырлар булды инде»,—дип искә алалар Каргалылар. Туксанынчы еллар башында монда Казаннан Миркасыйм Госманов шәкертләре Җәүдәт Миңнуллин, Раиф Мәрданов, Ирек Һадиевләр житәкләгән археологик экспедиция дә булып китә. Урта Азия гыйлем үзәкләре дә Каргалының язма мирасы һәм тарихы белән элегрәк елларда бик кызыксынганнар. Тик үткәндәге ул олы мирасның әлегәчә тулы килеш бүгенге укучы кулына ирештерелмәве генә беркадәр борчу тудыра. Әйтик, Үлмәс Беляеваның үз заманында, илленче-алтмышынчы елларда Оренбург

төбәгендә туплаган язмаларының бик аз өлешен генә матбугатка чыгара алганлыгы көн кебек ачык. Ул дәвердә мулла чапаны кигән галимнәр һәм шагыйрьләр турында иркенләп язып булмый, тупланган мирасны күрсәтеп бетереп булмый иде. Сакланган булса, бүген ул байлыктан иркенләп куллан да бит. Сакландымы икән соң ул кульязмалар—бөртек-бөртек хәреф белән чуарланган ул иске дәфтәрләр?

Зөһрә әби Сәетбатталова белән әңгәмәдән тагын шуны ачыклаган идем—күренекле радио вә телевидение журналисты Фәрит Сәйфелмөлековның бабасы да Һибатулла хәзрәткә кардәш тиешле икән. Ә ни рәвешле кардәш—Зөһрә әби безгә аңлатып бирә алмады. Чөнки ул кеше революциягә чаклы ук Каргалыдан киткән. «Мин әле ул чакта кияүгә чыкмаган ием. Уналтым тулгач, мине ишан хәзрәт оныгына ярәштеләр. Биатам (кайнатам) Әхмәт хәлфә төп йортта яши иде...»

## III

Әлеге олуг хәзрәтләрнең һәм шагыйрьләрнең чордашлары һәм авылдашлары булган беренче мөфтиләребезне дә искә алып китү зарурдыр. Болар Россия мөселманнары арасында иң мәртәбәле вазифаны биләүче иң тәүге мөфтиләр Мөхәммәтҗан Хөсәенев, Габдессәлам бине Габдеррәхим һәм Сәлимгәрәй Тәфкилевләр. Мөхәммәтҗан Каргалы төбәгенең беренче ахуны Мөхәммәд бине Гали әл-Дагыстанинның шәкерте була. Остазы вафатыннан соң байтак вакыт үзе дә ахун вазифасын үти. Аның атасы Хөсәен баштарак, унсигезенче йөзнең беренче яртысында, Эстәрлебаш авылы мулласы була. Мөхәммәтҗан Каргалыга атасы белән бергә күчеп килгәнме, яисә үзе генә килеп монда укыгандырмы, әлегә ачыкланмаган. Ахун дәрәҗәсе алгач, ана Урта Азия мөселман вәкилләре белән арадашлык итү бурычы да йөкләнүе мәгълүм. Мөхәммәтҗан ахунның Россиягә әле буйсынмаган чиктәш казакъ илендә дә абруе зур була. Мәсәлән, Оренбург генерал-губернаторы барон О. А. Игельстром Каргалы ахунын берничә мәртәбә Кече Жүз казакъ түрәләре янына дипломатик сөйләшүләр алып бару өчен җибәргән. (Мөхәммәтҗан мөфтинең яшьлектә яшерен рәвештә Бохарага барганлыгы һәм шуннан соңгы еллардагы эшчәнлеге турында 1939 елда СССР Фәннәр академиясе нәшер иткән «Исторический архив» журналында кызыклы фактлар китерелә. Борынгы документларда мөфти фамилиясенең «Гусейнов» рәвешендәге язылышы да очрый.)

Екатерина II идарә иткән дәвердә Оренбург губернасының бик зур мәйданны биләвен һәм, Уралның аръягындагы казакъ ханлыкларыннан тыш, Кавказ төбәгендәге мәмләкәтчекләр белән дә чиктәш булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ул вакытта губернаның чикләре Иделдән Уралгача һәм Нократ елгасыннан алып Каспий диңгезенәчә җәелгән була. Пугачев фетнәсе бастырылгач та ул чордагы Россиянең өчтән бер өлешен биләп торган әлеге губерна җитәкчесе итеп Әби патша швед О. А. Игельстромны билгели. Һәм ул катлаулы, күп милләтле биләмә белән ничегрәк идарә итәргә кирәклеге турында ике арада хатлар йөри башлый. (Ул хатларның бер өлеше 1886 елгы «Русский архив» журналында, «Граф Игельстром архивы» өлешендә китерелә.)

Патшабикә хат-фәрманнарыннан бер-ике өзеккә күз төшерик: «Подданствобызда торган һәм сез идарә иткән төбәктә яшәгән, яки шунда күчеп килгән халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Аларга карата җәбер кылмагыз, басым ясамагыз. Җәбер кылган тәкъдирдә, канун кушканча аларга дөреслекне табарга рөхсәт ителсен.» Икенче хатта: «Шул халыклар арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләр таратылмасын. Зарарлы үгетләрне... мөмкин кадәр йомшаграк чаралар белән туктатыгыз», диелгән.

Екатерина II белән язышкан хатларыннан күренгәнчә, Игельстром үзе дә, әйтик, татар-башкортларга карата йомшаграк мөгамәләдә булуны яклый. Дини карашка бәйле эзәрлекләүләргә каршы була. Урыннарда мәчетләр ачу кирәклеген хуплый. Әби патша да мөселманнар яшәгән төбәкләрдә мәчетләр төзергә рөхсәт бирү нияте барлыгын иң әүвәл Игельстромга хәбәр итә шикелле.

Яңа губернаторның мөселманнарга карата булган карашы, аларга беркадәр дини ирек бирергә кирәклеге турындагы фикере, мөгаен, Мөхәммәтҗан ахун белән якыннан аралашу нәтиҗәседер. Бу барон идарә итә башлагач та Мөхәммәтҗан

Хөсәеневне киң вәкаләтле Чик буе комиссиясенең ахуны итеп билгели. Ягъни әлеге ахун өлкә чигеннән көнчыгыштарак урнашкан Урта Жүз һәм Бүкәй казакъ ханлыклары белән тыгыз элемтә тотучы түрәләрнең берсенә әверелә. Шул рәвешле булачак беренче мөфтигә багышлы рәсми язмалар СССР чорында нәшер ителгән, казакъларга бәйле булган тарихи документларның 4нче томында да урын ала *(«Собрание документов по истории колониальной политики царизма в Казахстане», 1939 ел).*

Мөселман татар-башкортлар 1773-74 елларда Е. Пугачев күтәрелешендә актив катнашалар. Шул ук чорда башланган Россия белән Төркия сугышы 1774 елда тәмамлана. Дунай елгасы буендагы Кече Кайнаржа авылында төзелгән солых килешүендә Төркия хөкүмәте мөселманнарның Россиядәге язмышына карата җитди тәкъдимнәр кертә. Шушы вакыйгалардан соң патшабикә Екатерина илдәге милли сәясәтне беркадәр үзгәртергә ниятли һәм хөкүмәт карары белән «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе»н оештыра. Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбәр...» китабының ул идарәгә багышлы өлешендә: «1192 (1778) ел сентябренең егерме икесендә Оренбург кальгасында бер мөфти һәм өч казыйдан торган «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» ачыла... Казыйлар һәр өч елда чиратлашып алышыналар... Кайбер сүзләргә караганда, бу идарәнең ачылуы, Коръән басылуга рөхсәт бирелү һәм мөселманнарны башкаларның җәберләвеннән тыю—Кечек Кайнарҗа килешүе шартларының берседер», дип язылган.

Яңа идарәнең беренче рәисе итеп тәҗрибәле ахун Мөхәммәдҗан бине әл-Хөсәен бине Мансур әл-Җәбәли әл-Борындыкый билгеләнә. Ш. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбәр...» китабында: «Тәрҗемәи хәле сөйләнә торган зат, озын гомер сөреп, якынча илле ел мөфти булып, Уфа янәшәсендәге үз милкендәге җирдә, Уфа шәһәреннән алтмыш чакрым ераклыктагы Атҗитәр исемле авылда 1239 (1823) елда вафат була... Мәрхүм атабыз мелла Баһаветдин...һәм башкалар һәммәсе аның фазыл һәм камил булуын, зур белемгә ия икәнлеген бердәм рәвештә таныйлар. Халык телендә дә бик галим буларак танылган», дип яза. Бу идарә 1788 елда Уфага күчерелә, исеме-аталышы да берникадәр үзгәртелә шикелле.

Россия империясендә мөфтиләрнең дәрәҗәсе вә вәкаләте зур була. Алар үзләре теләгән вакытларда патша җәнаплары белән турыдан-туры элемтәгә керү хокукына ия булган. Петербургтагы һәм Кырымдагы патша сарайларының ишекләре алар өчен һәрчак ачык торган. Мөхәмматҗан үз вазифасын үтәгәндә империя белән өч шәхес җитәкчелек итә: Екатерина II, аның улы Павел I һәм аның улы Александр I. Шиксез ки, Әби патша идарә иткәндә Мөхәмматҗан Хөсәенев аның белән танышуга чакырылмыйча калмагандыр. Павел белән Александрның тәхеткә тәгаенләнү тантаналарында катнашкан булуы да һич тә шик тудырмый. Дәүләт карамагындагы бер сәяси идарә башлыгы буларак (мөфтият Эчке эшләр министрлыгының бер идарәсе саналган), барлык мөфтиләр дә патшаларны коронацияләү тантаналарыннан калдырылмаганнар. Андый олуг мәҗлесләргә мөселман өммәтендәге иң абруйлы дип күзалланган шәхесләр дә чакырулы булган. Мәсәлән, алтын приискалары хуҗалары, аталы-уллы Рәмиевләрнең шундый ике зур җыенда катнашканлыклары мәгълүм. Мөхәммәтсадыйк Рәмиев 1881 елда Александр IIIкә таҗ кидерү тантанасына чакырулы була. Кайбер хәбәрләргә караганда, ул яшь императорга бик кыйммәтле һәм үзенчәлекле бүләк тапшыра. Мөхәммәтшакир Рәмиев 1894 елда император Николай IIне коронацияләүдә катнаша. Ул тантанага Мөхәммәдьяр мөфтидән тыш тагын берничә мөселманның, шул исәптән Кырым морзасы Исмәгыйль Гаспринскийның чакырылганлыгы билгеле. Беренче мөфтиләргә шулай ук Урта Азия яисә Кавказ ханлыкларыннан килүче дәрәҗәле кунакларны Оренбургта яки Саратовта каршы алып, пайтәхеткә кадәр озата бару, ул кунакларның Россия түрәләре белән сөйләшүләрендә катнашу бурычы да йөкләнгән була.

* * *

Ш. Мәрҗани беренче мөфтинең «тәртипсез вә тәүфыйксыз Мирзаҗан (Мирзакай) исемле углы» булуын гына яза, кызларын искә алмый. Мөфтинең ничә хатынга өйләнүен дә хәбәр итми. Башка чыганакларга караганда, Мөхәмматҗанның ике

кызы казакъ ханнары варисларына кияүгә бирелә. Кече кызы Фатыймага багышлы берникадәр мәгълүматны Карл Фукс китабында да очратып була. Казан университеты профессоры, танылган табиб Фукс ул Фатыйма һәм анын ире Җиһангир хан белән 1826 елнын көзендә Казанда очрашкан.

1886 елда Петербургта нәшер ителгән «История родов русского дворянства» китабынын икенче томында (55—56 битләр) Кече Җүз ханнары исемлеге китерелә. Һәм шунда Бүкәй хан улы Җиһангирнын «Оренбург мөфтие кызына өйләнгәнлеге һәм аларнын дүрт улы һәм ике кызы» булганлыгы бәян ителә. «Кызлары Зөләйха полковник Тәфкилевтә кияүдә», дип тә өстәлгән. Бу полковникнын бабасынын бабасы генерал Котлымөхәммәт Тәфкилевнен 1731 елда Кече Җүз казакъ ханы Әбелхәерне Россиягә йөз тоту килешүен төзергә күндергәнлеге мәгълүм. Шул көннән башлап казакъ халкынын көнбатыш өлеше Россиягә ярым буйсыну хәлендә яши. Әбелхәердән сон идарә иткән Нургали, Ишим, Бүкәйләрне ханлыкка тәгаенләү «ак патша» кинәшенә һәм әмеренә таянып эшләнә башлый. 1800 елда хан тәхетенә Нургалинен уртанчы улы Бүкәй утыра. Император Александр I вакытында, Бүкәй хан вафат булгач, 1812 елда ханлык ике өлешкә бүленә. (Мона кадәр инде Александр Россиягә Грузия, Финляндия, Молдавия кебек мөстәкыйль илләрне кушып өлгергән була. Сонрак Әзәрбайҗан белән Польшанын көнчыгыш өлешен дә «руслыкы" итәргә житешә.) Җаек (Урал) белән Идел елгалары аралыгындагы кече ханлыкка Бүкәйнен өлкән улы Җиһангиргәрәй билгеләнә. Ләкин ана әле 20 яшь тулмау сәбәпле, вакытлыча идарә итү бурычы Бүкәйнен энесе Шиһабигә йөкләнә.

Җиһангир 1823 елда хан тәхетен били. Төркичә «бине-бине»ләп китерелгән шәҗәрәне кыскартып русчалаштыргач, патша фәрманында ул Җиһангир Нургали улы Бүкәев рәвешендә языла. Бу хан 1826 елда Николай Iне тәхеткә тәгаенләү тантанасында катнаша. Шуннан сон үз иленә кайтышлый Казанда дүрт көнгә туктала. Аны озата йөрүче солтаннар арасында үз мулласы, «нугай» Ает Мөхәммәт тә бар. «Ханга 24 яшь. Европалыга тартым аксыл йөзле... Чибәр кыяфәтле. Рус телендә... һәр сүзне дөрес, чиста итеп әйтә белә. Безнеңчә язуы әйбәт... Татар теленнән кала фарсы, гарәп телләрен белә...» дип яза К. Фукс. Галимнен шушы сүзләренә таянып, без казакъ ханнарынын элек-электән үк татар бәк-морзалары белән якыннан аралашып яшәгәнлекләрен чамалый алабыз. Яшь ханнын рус телен яхшы үк үзләштерүенә килгәндә, башта казакъ кардәшләрнен 1957 елда чыгарган китабына күз төшерик *(«Присоединение Казахстана к России», Мәскәү)*. Анда «Җиһангир берникадәр вакыт Әстерхан губернаторы Андриевский өендә тәрбияләнә», дип язылган. Ә фарсыча, гарәпчә белемне кайда һәм кайчан үзләштерүе турында мәгълүмат юк. Андый мәгълүматларны укучыга житкерер өчен татар мәдрәсәсен искә алырга кирәк булыр иде шул. Ә Совет хакимияте чорында «иске мәдрәсәне» искә алу килешеп бетми... Бигрәк тә «татар мәдрәсәсен» телгә алу килешми.

Ә анын тарихы болайрак. Оренбург каласы төзелгәч, казакъ халкы түрәләрен Россиягә тагын да якынайта төшү ниятеннән чыгып, анда бер алдынгы уку йорты ачу нияте барлыкка килә. Ә анын өчен башта мәчет салырга кирәк. Шәһәрдә затлы таш мәчет төзетү өчен патша казнасыннан акча бүлеп бирелә. Император Александр Iнен 1802 елгы махсус указы белән. Мәчетне төзү, анын карамагында мәдрәсә ачу бурычы мөфти Мөхәммәтҗанга йөкләнә. Мөфти бу эшкә авылдашын, булачак икенче мөфти Габдессәламне тарта. Ул аны 1799 елда ук инде шәһәрнен беренче мәхәлләсе имам хатибы һәм Оренбург ахуны итеп билгеләгән була.. Шәһәр үзәгендә, Урал елгасыннан ерак булмаган бер калкулыкта тиздән кызыл кирпечтән матур итеп төзелгән мәчет бинасы пәйда була. 1805 елда анын карамагында махсус мәдрәсә ачыла. Хәзергечә итеп әйтсәк, ул ябык типтагы уку йорты була. Ана күрше дәүләтләрнен хан-солтан балалары гына укырга алына. Җиһангир солтан һәм анын кардәшләре дә шушы мәдрәсәдә белем үзләштергән булырга тиеш. Бер хезмәттә: «Кыргыз-кайсак хан-солтан балалары өчен ачылган мәдрәсә», дигән сүзләр күзгә чалынган иде. Ул мәчет карамагында сонрак, хан-солтанлыклар бетерелгәч, гади мулла балалары өчен мәдрәсә эшли. Шул ук гасыр ахырында анда күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимов белем үзләштерәчәк. Хатыны Гөлсем апа Мөхәммәдева сөйләвенчә,

«Коръән алладанмы, түгелме?» дигән язмасына этәргеч биргән нindидер бер кулъязма да әдип кулына шул вакытта килеп керә.

Мөхәммәтҗан мөфтинең кызлары... Өлкәннәренең язмышы әлегә ачыкланмаган. Казанга ханбикә булып кунакка килгән Фатыймага унҗиде яшь. Ул үзләре тукталган сәүдәгәр Муса өендә профессор Фукс хатынын, шагыйрә Александраны кунакка ала. Чәй мәҗлесеннән соң алар диванга утырышып бик иркенләп гәпләшәләр. Фатыйманың русча сөйләме бик камил, «бер дә рус кешесеннән аерырлык түгел» икән. Йөз-кыяфәте дә ягымлы, күркәм. Бик нәфис киенгән: атлас күлмәктән, аның өстеннән затлы камзул кигән. Муенында зиннәтле муенса, калфагы җем-җем килеп торучы энҗе бөртекләре белән бизәлгән. Җиһангир Фатыймага өч ел элек, ханга тәгаенләнү фәрманын алган елда өйләнгән. Шул елның көзендә Фатыйманың әтисе вафат була. Әнисенә, Кәримә бикәгә патша әмере белән зур гына пенсия билгеләнә. Фатыйма—ханның яшь хатыны икән. Казанга сәяхәттә катнашмаган хатыныннан ханның ике улы—җиде һәм биш яшьләрдәге Искәндәр белән Зөлкәрнәй бар, дип хәбәр итә К. Фукс.

Фатыйма кемнән һәм кайчан рус шагыйрәсе белән тиндәш булырдай итеп русча сөйләшергә өйрәнгән соң? Профессор Фукс бу хакта берни дә язмый. Фатыйма туганда мөфтият инде Уфага күчерелгән була. Димәк, аның бала чагының бер өлеше шушы калада узган. Җәй айларын алар, билгеле, Мөхәммәтҗан «алпутның» ул вакыттагы «үз авылы»нда, Уфадан алтмыш чакрымдагы Атҗиттедә үткәргәннәрдер. Хөкүмәт карамагындагы идарә (мөфтият) башлыгы буларак, мөфти хәзрәтләренең үз балаларын Петербугның иң дәрәҗәле уку йортларында укытырга мөмкинлеге була. Фатыйма да шундый уку йортларының берсендә белем алгандыр, мөгаен. Казакъ халык шагыйре Олҗас Сөләйманов та, 2007 елның көзендә Казанда булганда, шундыйрак фикер әйткән иде. Карл Фукс язмалары шул фикерне раслый.

Җиһангиргәрәй Бөкәй хан Саратов губернасындагы үз утарында 1845 елда вафат була. Ул вакытта инде ул, хан булудан бигрәк, Россиянең рәсми рәвештә расланган кенәзе санала. Генерал дәрәҗәсендә була. Кенәз статусын алгач, ул һәм аның балалары, Чыңгыз хан варислары икәнлекләрен яшермичә, Җиһангир Чыңгыз, Гәрәй Чыңгыз рәвешендә йөриләр. Димәк, ул шәхес һәм аның варислары патша нәсел-нәсәбе белән тиңләшә дигән сүз. ХҮ111—Х1Х йөзләрдә Россиядә рус милләтеннән булмыйча кенәз дәрәҗәсен алучылар бик аз. Кайчандыр үз ил-мәмләкәтенә хуҗа булган, төрле яклап кысканнан соң «үз теләге белән» Россиягә кушылырга мәҗбүр ителгән грузин патшалары нәселе шундыйлардан. Нугай урдасы идарәчеләреннән Ырыс бәк (Урус бәк, кенәз Урусовлар) белән Йосыф морза (кенәз Юсуповлар) варислары да шул бик кыска исемлеккә керә.

Җиһангир Чыңгыз бу дөньядан китү белән Бөкәй ханлыгы аерым өлкә дәрәҗәсендә генә яши башлый. 1876 елда ул Әстерхан губернасына кушыла. Бу вакытта инде казакъ иленең байтак өлеше яулап алынган була. Арал дингезенең көньягындагы өлкәләрне яулау 1880 елларда тәгәлләнә.

Соңгы чор казакъ ханнары, бигрәк тә Бөкәй урдасы вәкилләре кардәш-ыру төрки халыклар мәдәниятен үстерүгә билгеле бер күләмдә өлеш керткән шәхесләр. Аларның Саратов губернасындагы утарына күренекле галимнәр һәм татарның зыялы кешеләре дә килгәләп йөргән. Шул исәптән Казан галимнәреннән Карл Фукс, Николай Катанов һ.б.ның алар белән аралашкан булуы бәян ителә. Бу традиция Җиһангир хан вафатыннан соң да дәвам иттерелгән. Фатыйма ханбикәнең озак гомер кичергәнлеге мәгълүм. Аның уллары Россия дәүләтенә хезмәт иткән кенәзләр: Сәхиб, Ибраһим, Әхмәт һәм Гобәйдулла Чыңгызилар була. «История родов дворянства...» китабында алар да теркәлгән. Кызлары Ходжаның (Хәдичәнең?) язмышы билгесез. Зөләйха, алда әйтелгәнчә, татар морзалары Тәфкилевләр килене. Аларның язмышы Оренбург белән Каргалыга да берникадәр бәйле. Элек-электән Тәфкилевләрнең зур җир биләмәләре шул тирәләрдә була. Совет хакимияте дәверендә Тәфкилевләрнең Каргалы янәшәсендәге төп утарында Ленин исемендәге совхозның үзәге урнашкан иде.

## IV

Икенче мөфти Габдессәлам бине Габдеррәхим әл-Бөгелмәви ул вазифаны унөч ел дәвамында үти (1825—1838). Анын Оренбург губернасы Бөгелмә өязе Габдерахман авылында туганлыгы (хәзер Әлмәт төбәгендә), яшьли Каргалыга килеп укыганлыгы мәгълүм. Мәдрәсәдән соң шунда ук мулла булып кала. Хива һәм Бохара ханлыклары илчелеге Россиягә килер алдыннан, 1799 елда беренче мөфти аны Оренбургка ахун итеп күчерә. Анда таш мәчет төзетү бурычын йөкли. Бу мулла шактый ук өлгер, үткен һәм үз чорына күрә белемле кеше булган. Рус телен дә яхшы ук үзләштергән. Урта Азия якларыннан килүче хан-солтан һәм илчеләрнең патша җәнапларына тапшырасы хат-прошениеләренең шушы ахун тарафыннан язылган булуы мәгълүм. Бохарадан һәм Хивадан килгән илчеләрне кабул иткәндә ул губернатор җәнаплары алдында да абруй казанып өлгерә. Ә инде император Александр I Оренбургка килгән 1824 елда Габдессәлам ахун мөфти кәнәфиен биләрлек дәрәҗәдә тырышлык вә өлгерлек күрсәтә. Һәм патша әмере белән 1825 елда мөфти итеп билгеләнә. Император Оренбургта дүрт көн була. Патша җәнапларын каршыларга дип ул шәһәргә күрше мәмләкәтләр солтаннары да чакырыла. Аларны каршы алу, урнаштыру мәшәкатьләренең бер өлеше Габдессәлам ахун өстенә төшә. Элекке шәкерте, янарак кына хан тәхетен биләгән Җиһангиргәрәй һәм анын өч бәк-солтаны белән бергә Габдессәлам дә император тарафыннан кабул ителә. Каргалы шагыйре Гомәр бине Мөхәммәтнең ана багышланган ике зур шигъри әсәре сакланган. Бохара, Үргәнеч кунакларын кабул итү вакыйгалары «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» (1832) поэмасында бәян ителсә, булачак Александр II патшаны кабул итү күренешләре «Сәфәрнамаи шаһзадә Александр» (1837) дигән әсәрдә чагылыш тапкан. Шаһзадә Александр Оренбургка 1837 елның июнендә килә. Мөфти буларак, Габдессәлам аны берничә көн дәвамында озатып йөри. Казакъ ханлыгы чигенә якын торган Тозтүбә каласына да шаһзадә белән бергә бара. Казакъ солтаннары, рус түрәләре һәм татар, башкорт байлары белән бергә оештырылган милли бәйге-бәйрәмнең әйдәүчесе дә мөфти хәзрәтләре була. Тәхет варисы уздырган, санаулы сандагы мөселман өммәте вәкилләре кантнашкан зур мәҗлес тә, әлбәттә, мөфти Габдессәламнан башка узмый.

Бу сәяхәт вакытында булачак императорны укытучы-тәрбиячесе, күренекле шагыйрь Василий Жуковский озата йөри. Мәгълүм ки, шагыйрьнең анасы Салиха татар нәселеннән. (Сонрак үземе, яки биографиясен әвәләүчеләрме, анын анасын «турчанка» дип язалар. Ягъни элекке Касыйм ханлыгы биләмәсендәге Биләү шәһәрчегендә туган «төрек кызы» дип. Икенче бер рус шагыйре—Константин Бальмонт та, кемгә ияреп тер, Урал төбәгендә туган анасын татар нәселеннән дип атаудан тартынып, «шигъри җанлы турчанка иде», дип яза. Шигърияткә яшьли күнел бирүем дә анам тәэсиреннән килә, ди ул 1914 елда «Нива» журналында чыккан автобиографик мәкаләсендә.) Жуковскийнын анасы бер алпавытта хезмәт итә («ключницей была», дип язалар шагыйрьнең биографлары). Ул замандагы гадәт буенча, алпавыт үз утарындагы теләсә кайсы кыз балага кул сала алган. Аннары ул кызны үзе үк бер крепостноена кияүгә биреп котылган. Шул рәвешле туган «уйнаш балалар» исемлегендә без күренекле рус шагыйре Афанасий Фетны, мәшһүр рәссам Орест Кипренскийны һ.б. бик күпләрне очрата алабыз. Кайчандыр Лев Толстойның секретаре вазифасын үтәгән язучы Виктор Шкловский да әдип авылларында «графка охшаш мужикларны очратып була иде», дип яза. Салиха уйнаштан тапкан улын баштарак үзе генә тәрбия кыла. Димәк, Василий әз-ким генә булса да үз ана телен дә белгәндер, шәт. Бу очрак та шаһзадәне озатып йөрүче Габдессәлам мөфти белән жирле шагыйрь Гомәр Мөхәммәтев файдасына була, билгеле. Гомәрнең Петербург архивында сакланган поэмаларын һәм хаҗ кылу сәфәрнамәсен укый алган очракта, без ул вакыйгаларны тагын да тулырак итеп күзаллаган булыр идек. Жуковскийның да шаһзадәне озатып йөрүгә бәйле көндәлек язмалары 1902 елда «Русская старина» журналында нәшер ителгәннәр. Ләкин безнең Милли китапханәдә журналның нәкъ шул 1837 елга караган көндәлек язмалары кергән саннары юкка чыккан икән. Шул сәбәпле шагыйрьнең Оренбург төбәгенә бәйле язмалары белән әлегә танышып булмады... Гомәр бине Мөхәммәтнең тагын бер калын кульязмасының кайсыдыр

архивта сакланган булуы ихтимал. 1873 елда ул Төркия—Мисыр якларында йөреп кайта. Шулчак үз сәфәрнамәсен яза.

1910 еллар башында Каргалыдагы бер мәчет чормасыннан Гомәр Дәүләтьяров хәлфә Габдессәлам мөфтинең көндәлек кульязмаларын табып ала. Һәм аны Риза хәзрәт Фәхреддиневкә илтеп тапшыра. Ул язмалар 1913 елгы «Шура» журналының алты санында басылып чыгалар.

Шиһабетдин Мәрҗани Габдессәлам мөфти эшчәнлегенә, ни өчендер, бик аз туктала. Аның кылган эшләрен бик саран тасвирлый. Гаилә әгъзалары да хәзрәтнең китабында телгә алынмыйлар. Бәлкем, Каргалы шагыйре Гомәр бине Мөхәммәтнең бу мөфтигә багышлап иҗат ителгән күләмле ике поэмасы барлыгын белгәнлектән шулай эшләгәндер ул. Мөфтинең балаларыннан улы Гыйният алда тасвир ителгән поэмаларның беренчесендә телгә алына, дип яза әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдинов.

Гомәр бине Мөхәммәтнең бу ике поэмасы С.-Петербург архивларында һәм берсе Ташкенттагы Көнчыгышны өйрәнү институтының кульязмалар бүлегендә саклана икән. «Тәзкирәи Габдессәлам мөфти» поэмасы татар әдәбиятына үзенчәлекле яңалыклар алып килгән, татар тормышындагы кайбер үзгәрешләрне чагылдырган әсәр... Аның тагын бер мөһим яңалыгы—реаль вакыйгаларның гадәттән тыш географик киңлеге. Сөйләм Оренбург, Петербург, Таганрог, Уфа вакыйгаларына күчеп тора...» дип бәяли аларны М. Гайнетдинов. Әйе, шушы ике поэма эчтәлеге белән таныш кеше Габдессәлам мөфти эшчәнлеген дә тулырак бәяли алачак.

## V

Шундый ук дәрәҗәдәге тагын бер шәхесне—гаскәри хезмәттән мөфтилеккә тәгаенләнгән Сәлимгәрәй Шаһингәрәй улы Тәфкилевне дә өлешчә Каргалыга мөнәсәбәте булган кеше дип санарга хаклыбыз. Ул 1865—1884 елларда мөфти кәнәфиен били. Шиһабетдин хәзрәт китабында Тәфкилев бәк-морзаларының Чыңгыз ханга барып тоташкан озын шәҗәрәсе китерелә. Сәлимгәрәйнең 1852 елда Истанбулда һәм хаҗда булганлыгы күрсәтелә. «Россия хөкемендәге мөселманнардан әлегәчә болар кадәр бай һәм дәүләт иясе булган кеше мәгълүм түгел», дип яза Ш.Мәрҗани. Әлбәттә, бу очракта «мөселман» төшенчәсен «татар» сүзе белән алмаштыру кирәктер. Чөнки алдарак берничә мөселман өммәте вәкиленең Россиянең патша йорты вәкилләре генә йөрткән кенәз дәрәҗәсенә лаек булулары турында да сүз барган иде. Сәлимгәрәй Уфада мөфтият бина-утарын төзеп бетерүе белән шөһрәт казанган шәхес. «Сәяхәт кылырга ярата. Кешеләргә дус һәм яхшы күренергә тырыша... Теле белән әсир итә торган зат... Ләкин, карашында тотрыклылык булмаганлыктан, күп эшләре тәмамланмыйча, ярты юлда кала. Еш кына үз әмерен үзе бозар иде...Сиксән ике яшендә вафат булды, Уфа шәһәренең таш мәчет күршесендә җирләнде. Балалары булмады», диелә «Мөстәфадел-әхбәр...» китабында.

Алда билгеләп үтелгәнчә, Тәфкилевләрнең иң тәүге зур җир биләмәләре Каргалы тирәлегендә булып, төп утарлары да аның янәшәсендә урнаша. Ә ерак бабасы исемен йөртүче соңгы морза, Котлымөхәммәд Батыргәрәй улы Тәфкилев, патша чорындагы дүрт чакырылыш Дәүләт думасы депутаты, ул җир биләмәләренең ике мең дисәтинәсен Мәхмүт бай Хөсәеневкә сата. Сатканда исә түбәндәге шартны куя: әлеге җирдән алынган керемнең бер өлеше, элеккечә үк, Каргалы мәчет-мәдрәсәләре файдасына бүлеп бирелергә тиеш. Әлбәттә, андый кешеләрне Каргалы мәхәлләсеннән аерырга мөмкин түгелдер. Каргалы зиратында Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабернең саклануын да әйтеп үтү кирәктер. Урта зиратның иң алгы өлешендәге ул каберләр, борынгы төрбәләр рәвешенә китерелеп, биек таш койма белән уратып алынган. Төбәк тарихчысы Мәдинә апа Рәхимкулова ачыклавынча, беренче кабердә шушы төбәктә зур эшләр башкарган генерал Котлымөхәммәд Мәмәш улы Тәфкилевнең хатыны ята. Ул Тәфкилев заманында Урал-су буендагы Орск, Оренбург шәһәрләрен нигезләүдә катнашкан олуг бер шәхестер. Каргалы «каласы»н нигезләшүдә дә өлеше булгандыр, мөгаен. Тәфкилевләргә нисбәтле ике кабер ташы да сакланган. Ләкин икесе дә йөзтүбән капланып, яртылаш җиргә сеңгән

булу сәбәпле, андагы язуларны уку мөмкин түгел иде. Фәкать Тәфкилевнен Тимәш морзага ярәшелгән кызыныкы дип уйланган таш сыртына «1215 сәнә» дип чокып язылган язуны гына укып була иде. (Бу сан хәзерге исәп белән 1800—1801 елларга туры килә шикелле.) Хәзер инде ул ташларнын берсе күтәртеп куелган. Таштагы язу өлешчә укыла: кабер иясе Хадичә бикә икән, ул илле биш яшендә—1751 елда шушы сонгы йортына индерелгән. Фараз ителүенчә, ул Котлымөхәммәт морзанын беренче хатыны булган.

## VI

Оренбург төбәгенен яна чор морза-дворяннары нәселеннән чыккан Шаһимәрдән Ибраһимов мәрхүм Сәлимгәрәй мөфти урынын биләргә лаеклы кешеләр исемлегенә кертелгән була. Баштарак ул шул кәнәфине биләргә ин лаек шәхес саналган. Ләкин ана каршы руснын югары дәрәҗәле дин әһелләре һәм карагруһчы зыялылары күтәрелүе мәгълүм. Миссионер, берара Казан университетынын төрек-татар кафедрасы мөдире дә булып торган Ильминскийнын шул хакта Синоднын өлкән прокуроры К. Победоносцевка язган хатлары мәгълүм. Аларда ул Ш. Ибраһимовны «цивилизованный, энергичный», акыллы, тирән белемле, русча бик иркен сөйләшә алучы, Урта Азия һәм башка шәрекъ дөньясынын билгеле кешеләре белән якыннан аралашкан зат дип мактый да, нәкъ шул сыйфатлары безне куркытырга тиеш, дигән нәтиҗә чыгара. Унай сыйфатлары белән ул мәрхүм Тәфкилевтән күпкә өстен тора. Шул өстенлеге белән ул безнен дин әһелләрен һәм чиновникларны мөшкел хәлдә калдырачак, ди («может обаять и ослепить наших господь и чинов высшего управления»). Мөфти урынына безгә русча белеме чамалырак булган, түбән дәрәҗәле түрә алдында да калтырабрак торучы кеше кирәк. Мин ул урынга Солтановны кулайрак күрәм, дип яза Н. Ильминский 1885 елнын 29 апрелендә җибәргән хатында. Һәм тиздән башкалада «башкорт төркеменнән булган» Мөхәммәдъяр Солтановны мөфтилеккә тәгаенләү турында фәрман бәян ителә.

## VII

Каргалы авылы һәм анда гомер кичергән олуг шәхесләр мине балачактан кызыктырып килделәр. Мәктәптә укыган елларда Каргалыны күреп белмәсәм дә, безнен Бозаулык суы буе татар авыллары белән ныклы элемтәсе барлыгын ишетеп, укып үсәргә туры килгән иде. Мин үскән Искеавыл (Иске Белогор), анын янәшәсендәге Янавыл (Яна Белогор, ике уртадагы биек Актауга нисбәтле исемнәр), Аюлы, Имангол, Кондызлы картлары белән сүз чыкканда әледән-әле шул сихри Каргалы мәдрәсәләре, Каргалы мәчетләре, Каргалы муллалары телгә алынып иде. Фәлән мулла Каргалыда укыган, икенчесе Каргалыдан килгән, имеш. Янавылдан чыккан язучы һәм галим Габделбарый Баттал да атасы мәктәбендә башлангыч белем үзләштергәннен сонында укуын Каргалыда дәвам иттергән.

Каргалы һәм анда яшәүчеләр белән кызыксыну ни өчен сон әле яшьтән үк күнелдә кузгалган? Бу кызыксынунын сәбәпләрен беркадәр анлатып китү кирәктер. Әйе, башлангыч классларда укыткан укытучым Хөснә апа да Каргалыны бик еш телгә алып сөйләр иде. Түбәнге Чебенке авылында туган булса да, ул Каргалыны, анын кешеләрен дә бик сагына иде. Бернечә ел шунда укыган да булса кирәк. Оренбург төбәгенен элеккеге барлык зыялысы да Каргалыдан чыккан дип, мисалга Айдаровлар гаиләсен китерер иде. Әнә бит, Кәраметдин Айдаров хәзер Сәмәрканд университеты профессоры, анын туганы Галим Айдаров Оренбург педагогия институтында укыта икән. Бозаулык буе татар авылларынын сонгы ахуны Харис хәзрәт тә шул нәселдән булган.

—Анын улы Әсгать Айдар—күренекле язучы. Сез аны яхшы белергә тиешсез. Кечкенә Әсгать сезнен кебек вакытта шушы Искеавыл урамнарыннан йөргән. Авыл читендә, Иртәк инеше буенда аларнын җимеш бакчаларын барыгыз да беләсез... Киләсе дәрестән без анын «Ташбай» исемле әсәрен укый башларбыз. Ул малай узган сугышта батыр булган, кызылармеецларга акларны җинәргә булышлык иткән,—Хөснә апа дүртенче класс балаларына шулай дип сөйләгән иде.

Унөч яшьлек Ташбай мажаралары, чик сакчыларынын дошман көчләр белән

көрәше барыбызга да ошады, әлбәттә. Әсгать Айдар исеме дә мәңгегә күңелгә сеңеп калды. Каргалы белән безнең авылны берләштерүче кешеләрнең берсе буларак та, язучы буларак та. Байтак еллар үткәч кенә Мөхәммәтхарис Айдаров ахунның шушы Иске Белогор авылында Сабан туйлары оештырганлыгын, аңа Каргалы, Оренбург, Бозаулык, Самара тарафларыннан күпсанлы кунаклар җыелганлыгын укып белдем. Мондый вакыйгага багышланган хәбәрләр 1910—1914 еллар аралыгында «Вакыт» газетасында даими рәвештә басыла килгән икән. Менә 1910 елның 29 май санындагы хәбәрдән бер өзек: «Бозаулык өязе Иске Белогор карьясе янында, Айдаров хәзрәт утарында зур бәйге булды. Мөселман вә урыстан ике меңләп кеше җыелган иде. Авыллардан иллеләп имам килде. Ат чабыштыру, көрәш кеби кызыклар белән Сабан туе ясалды. Берничә гәүдәт үгез суелып, халык хозурына аш бирелде...» Хәзер дә әле «хәзрәт бакчасы» исемен йөрткән ул урында кыргыйлашкан алмагач кәүсәләре саклана. Шул сәхрәдә узган Сабан туйларында бәлкем минем бабам да катнашкан, ахун хәзрәтләре догасы белән чын мөселманча суелган ул яшь үгез итен татып карагандыр...

Алда әйтелгәнчә, Каргалы безнең төбәкнең Бозаулык, Иртәк, Иләк, Ток, Самар елгалары буе авыллары өчен үзенә күрә кечерәк бер Мәккә булган. Күрше-тирә авылларның муллалары башлыча шул Каргалы мәктәп-мәдрәсәләрендә укыганнар. Бабамның олы кызының кияве Хәбибулла да Каргалыда мәдрәсә тәмамлап кайткан була. Ләкин ул рәсми рәвештә мәхәллә имамы булып сайланырга өлгерми кала. Илдә зур үзгәрешләр башлана. 1919 елның җәендә Урта Азия тарафына ургылган Кызыл Армия аны да үзе белән ияртеп алып китә. Яу-сугышлар беткәч тә ул шунда кала, Миһербан апабызны да үзе янына алдыра. Илленче елларда аларда кунакта булганда җизнә бабай туган авылы белән бердәй итеп Каргалыны да бик сагынуын искә алган иде.

—Шунда үзләштергән белемемне дә һич онытканым юк. Казакъ, үзбәк авылларында укытканда да көндез хәлфә, кичләрен мулдакә идем. Хәзер дә шулай,—дип мактанып та алган иде Хәбибулла бабай.

Унтугызынчы йөз башы Иске Белогор авылы мулласы Әхсәнне дә Каргалы кешесе дип искә алалар.. Авыл зиратындагы кабер ташында «Биләгур имамы Әхсән»нең 69 яшендә 1824 елда вафат булуы, «24 сәнә» мулла булып торуы бәян ителә. Кабер ташы язулары бик таушалган—алда китерелгән сүзләрне һәм үлгән елын гына бераз чамалап була. Каргалыда туганмы ул, яки шунда укыган гынамы—анысы билгесез. Әмма шунысы хак, Каргалы кешесе саналган. Оренбург ягыннан көнбатыш тарафка юл тотучы укымышлы кешеләр һәрвакыт аларда туктала торган була. (Оренбург белән Самараны тоташтыручы «чуен юлы» фәкать унтугызынчы йөзнең соңгы чирегендә генә салына. Аңа чаклы Самара тарафына баручы мөселманнар Бозаулык буе татар авыллары аша йөри торган булганнар.) Берничә мәртәбә хаҗга барган Каргалы кешесе Рафик бабаның зур сәфәрдән соңгы кайтышында Әхсән мулла өендә вафат булганлыгы мәгълүм. Хаҗины бик зурлап безнең авыл зиратына җирлиләр. Кабере өстенә зур табигый таш куела. Соңрак изге кеше кабере өстенә куелган ул «изге таш» төбендә кунып чыккан кеше савыга икән дигән бер ырым тарала. Сугыштан соңгы елларда да әле ул таш төбендә кунып, савыгып китәргә ниятләүчеләр еш очрый иде. Күпчелеге якын-тирәдәге татар, башкорт авыллары карт-корылары. Култык таягына таянып килүче хәрби киемлеләр дә күренгәлиләр иде. Мосафирларны зират янәшәсендәрәк яшәүче Җомабикә әби каршы алыр һәм авыл башындагы күпергә җиткәнче озатып та куйгалар иде. Файдасы булдымы соң дип сораучы карт-карчыкка мосафирлар еш кына: «Әлегә рухым савыкты, шөт, тәнем дә савыгыр»,—дип җавап биргән. Хаҗга йөреп изге исеме алган Рафик бабаның варислары Каргалыда бүген дә бар. Ерак бабалары каберенә «хаҗ кылучылары» гына хәзер юк инде. Дөнья үзгәрешләренә чаклы алар безнең авылга килгәләп йөргәннәр. Ә изге каберендәге ул «изге таш» әле дә үз урынында, гарәп язулы дистәләгән борынгы кабер ташлар уртасында калкып утыра. Без аны 2006 елда гына фотога төшереп кайттык.

Иске Белогор авылының соңгы рәсми мулласы Габдулла Габидуллин бу вазифаны кырык алты ел чамасы башкара. 1926 елда вафат була. Язулы кабер ташы авыл

зиратында саклана. Аның нәселе дә Каргалы белән даими рәвештә элемтәдә торган. Үзенең тумыш җире—Бозаулык буеның Сөнрән авылы. (Безнең тирә авыллары телендә—Түбән буй Сөнрәне. Бозаулык суы Иске Белогор янәшәсендәге Актау битләвеннән башланып китә.) Сугыш һәм аннан соңгы чорда шагыйрь буларак таныла башлаган Гыйззел Габид тә шул авыл һәм шул токым кешесе. Иске Белогордагы кебек җиде-сигез сыйныфлы (рөшди) мәдрәсәсе булган Сөнрәндә мәгълүм китап рәссамы Байназар Әлмәнев тә беркадәр яшәп ала. Очрашкан, гәпләшкән мәлләрдә без аның белән якташлык тойгыларын да белгертми калмый идек.

Габдулла мулла үз авылларыннан соң Каргалының гали өлешле (югары белем бирүче) мәдрәсәсендә дә укыган булырга тиеш. Балалары, шул исәптән кызы Мәрьям дә Каргалыда укыйлар. Мәрьям әбинең оныгы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Роберт Шәмгунов гаиләсендә «Рәмия мәктәбе» укучыларының күмәк фотосы да бар иде. («Рәмия мәктәбе»н кайвакыт «Рәмия мөслимия» дип тә язалар.) Белгәнебезчә, ул кызлар мәктәбе «Рәмия...»не оештыруда Закир Рәмиев—Дәрдемәнднең хатыны Мәхүбҗамал да актив катнаша, аның тәүге җитәкчесе һәм иганәчесе була.

Бер Ходам, үзең ярлыка...

* * *

1994 елда безне, алдан сөйләшеп куелганча, Каргалы сәфәрендә Мәдинә апа Рәхимкулова озата йөрде. Иң элек юл өстендәге зиратларны карап, йөреп чыктык. Һибәтулла Салихов каберенә куелган кыскача язулы таш элеккечә төп-төз булып, үз урынында басып тора иде. Ә менә Урта зираттагы Ишнияз бине Ширнияз кабереннең эзенә төшә алмадык. Мәдинә апа: «Шушы тирәдә генә иде бит»,—дип берничә мәртәбә кабатласа, шул тирәне ике-өч мәртәбә урап йөреп чыксак та, ул таш күренмәде. Кылган үләне шул хәтле биек һәм куе булып үскән, Мәдинә апа буйлап күрсәткән кечкенә ташны түгел, зурракларын да табып булмый. Ә менә очлы, өлгергән кылган орлыклары, арпа кылчыклары кебек, кадалмаган җирне калдырмадылар.



*Һибәтулла Салиховка куелган кабер ташы*

Зират тарафыннан авыл күренешен һәм кайбер истәлекләрәк, үзенчәлекләрәк кабер ташларын Зөфәр Бәширов фотога төшереп алды. Шуннан соң авыл эченә таба юнәлдек. Сәгыйд Хәялин йортының калдык нигезен дә, «кушманаралы» мәчет, Тукай, Җәлил урамы күренешләрен дә фотода истәлеккә калдырасы килә иде. Әле төп хуҗалары—имамнар карамагына тапшырылмаган берничә иске мәчет күренешен дә, авылның борынгы сәүдә үзәге кибет-келәтләрен дә рәсемгә алдык. Боларның барысы да бит мәшһүр җәмәгать эшлелесе һәм шагыйрь Закир Рәмиев—Дәрдемәнд заманында гөрләп үз вазифаларын үтәп торган җанлы корылмалар булганнар.

Егерменче гасыр башында Каргалыда үзләре сайлаган өлкәдә мәшһүрлеккә ирешкән, яки шуңа ирешү юлына баскан затлар да ишле генә булган. Яңалыкка омтылуы белән шөһрәт казанган Әюп хәзрәт һәм аның Дунай мәхәлләсендәге мәчете һәм мәдрәсәсе алдарак бераз искә алып үтелде инде. Икенче бер мәчет карамагындагы мәдрәсә укытучысы Гомәр Дәүләтьяров исеме исә хәзер сирәк кешегә мәгълүм. Ә бит ул заманында Оренбург төбәгенең атаклы шәхесе булган. Гомәр Габдерахман улы Дәүләтьяров балаларга хисап дәресләрен укыту белән генә чикләми, 1898 елда аның «Мөкаммәл хисаб» («Төгәл хисап») исемле дәреслеге дә басылып таратыла. Мәгәр аны илгә таныткан төп шөгыле астрономиягә карый. Үз төбәгендә ул мөнәҗҗим буларак таныла. Мәшһүр галим Циолковский үрнәгендә Гомәр хәлфә дә үз өй түбәсендә кечерәк астрономик үзәк оештыра. Аның янына йолдызлар күзәтергә төрле тарафтан кешеләр килеп йөри торган була. 1914 елның язында аның Каргалыдагы обсерваториясе белән танышу өчен Казаннан Садрый

Максуди, Оренбургтан Закир Рәмиев, Фатих Кәрими һ.б. киләләр. Күк гөмбәзен күзәтү урынына менүче баскычта Гомәр мөнәҗҗимне уртага алып төшкән фоторәсемнәре сакланган. Дәүләтьяров 1930 елда кулга алына һәм «халык дошманы» буларак юк ителә. М. Рәхимкулова Гомәр хәлфәнең төп гаебе Совет хакимияте урнашкач мулла чапанын киюдә дип белә. Зур үзгәрешләр чорында мәхәллә халкы аны мулла итеп сайлап куйган була.

Каргалы данын еракларга тараткан, Дәрдемәнд һәм аның чордашларына замандаш булган драматург Габдерәүф Хәкимбай улы Ниязбаевны хәзер фәкать театр тарихы галимнәре генә белә булыр. Ул 1881 елда Каргалыда туа, 1920 елда Эстәрлетамак шәһәрендә вафат була. Соңгы эш урыны—Башкортстан мәгариф комиссариаты инспекторы. Г. Ниязбаев Каргалы мәдрәсәсенең рөшди өлешен тәмамлаганнан соң, Казанда Укытучылар мәктәбендә белем ала. Узган гасыр башында шул мәктәптә укыганда беренче мәртәбә сәхнәгә аяк баса. Шәриктәшләре Гаяз Исхакый, Ильясбәк Кудашев, Гафур Коләхмәтев, Шакир Мөхәммәдъяров, Шәриф Сүнчәләйләр белән бергә татарча беренче спектакльләрне куюда катнаша. Рус классик драма әсәрләрен тәрҗемә итүдә көч сынап карый. Аның 1906 елның мартында кайбер пьесаларны татар сәхнәсендә куярга рөхсәт сорап Казан губернаторы исеменә язган ике хаты мәгълүм. Шул хатларында ул Н. Гогольнең «Өйләнү», «Ревизор» комедияләрен, татар драматургларының «Кызганыч бала», «Өч хатын белән тормыш», «Оят, яки күз яше» һ.б. пьесаларын сәхнәләштерергә рөхсәт бирелүен үтенә. Һәм берничә пьесаны, шул исәптән «Өйләнү»не куярга рөхсәт ала. Ул заманда мондый адым ясарга сирәк кеше җөрьәт иткән. Соңрак ул үз туган төбәгендә һәм Урта Азия уку йортларында балалар укыта. Театр белгечләре аның биш драма әсәре язганлыгын әйтәләр. Шулардан ике әсәре «Сәйяр» труппасы тарафыннан, берсе Оренбург татар драма театры тарафыннан сәхнәләштерелгән. «Сәйяр»дә Габдулла Кариев җитәкчелегендә куелган пьесалары «Беренче таң» белән «Борадәран Галимевләр» (автор кушкан исеме «Көчлеләр һәм көчсезләр»). Оренбургта уйналган пьесасы «Кара көннәр» дип аталган. Бу соңгы пьесаның Башкорт театры тарафыннан сәхнәләштерелгән булуы да ихтимал.

Закир Рәмиев-Дәрдемәндкә чордаш иң яшь каләм иясе Зәйнәп Сәгыйдә дә Каргалыда, 1897 елда туган. Хәлиулла хәзрәт кызы. Зәйнәп биредә кызлар мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә уку дәверендә үк халык авыз иҗаты үрнәкләрен туплый башлый. Берничә дәфтәргә халык җырларын, бәет-мөнәҗәтләрне язып ала. 1914 елдан Зәйнәп Оренбургта яши, педагогик курсларда укый, татар матбугатына мәкаләләр, шигырьләр язып тора. Шагыйрәнең берничә шигыре һәм поэмасы Рәмиев байлар исәбенә чыгып килүче «Вакыт» газетасы белән «Шура» журналында басылалар. Зәйнәп Сәгыйдәнең 1915 елда «Шура»да чыккан «Бикчәнтәй бабай дастаны» (икенче атамасы—«Пугачевка багышлы Каргалы дастаны») исемле поэмасы күпләрдә кызыксыну уята. Зәйнәп Сәгыйдә әсәрләре белән шагыйрь һәм нашир Дәрдемәнд тә таныш булгандыр, аларны үз иткәндер дип өметләнәсе килә. Дәрдемәнднең үз карамагындагы газета белән журналда басылган күпчелек шигъри әсәрләрне нәшер ителгәнче үк күздән кичергәнлеге турында берничә истәлектә әйтелә.

* * *

Җәйге кояшның соңгы нурлары Сакмар елгасы белән Урал бергә кушылган тарафтан кыйгачлап, җир ягалап сузыла башлаганда без, борынгы Каргалы шәһәре белән хушлашып, кайтыр юлга чыктык.

*1994—2006.*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# И

**ИЛЬЯС** (Ильясов) Рахман (Габдрахман) Вәкил улы (15.3.1908, Зөя өязе Карамасар а.—23.8.1943), язучы. 1920 елларда Төньяк Кавказда нефть промыселларында эшли. 1931—32 елда Казанда Татар коммунистик ун-тында укый (Казан), 1933 тән газеталар редакцияләрендә, Татарстан радиокомитетында, Язучылар берлегендә, Главлитта эшли. Әсәрләрендә төп игътибарын нефтьчеләр һәм тау кешеләре тормышына юнәлтә: «Кем гаепле?» (1930), «Шәрифҗамал» (1932), «Таулар арасында» (1935), «Чыныгу» (1933) һ.б. «Танышлар» (1939), «Фонтан» (1940) исемле пьесалар авторы. 1941 дә үз теләге б-н фронтка китә, Харьков тирәсендә барган сугышта һәлак була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**ИЛЬЯСИ** Габдрахман Мөхәммәтәмин улы (1856, Казан—1895, шунда ук), драматург, археограф. «Касыймия» мәдрәсәсендә укый. Рус теле һәм әдәбияты дәресләре ала. Конторщик, хисапчы булып эшли. К.Насыйри кул астында төгәл фәннәрнең нигезен өйрәнә, йолдызларны күзәтә. Аның б—н бергә татар авылларына чыгып фольклор әсәрләре, язма чыганаклар җыя. Татар тарихи кулъязмаларын өйрәнеп, алар турында Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә чыгышлар ясый. 1855 елдан бу җәмгыятьнең әгъзасы булып тора. 1887дә үз кул астында татар телендә г-та чыгаруга рөхсәт сорап Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Матбугат эшләре буенча баш идарәгә мөрәҗәгать итә. Рөхсәт бирелми кала.

И.— татар әдәбияты тарихында беренчеләрдән булып хатын-кыз мәсьәләсен яктырткан автор. Аның «Бичара кыз»ы (1887)—татар матбугатында беренче булып басылган пьеса. Пьесада чор өчен актуаль булган шәхес иреге, хатын-кызларның ирләр б-н бертигез хокукка ия булу, татарларны укыту мәсьәләләре куела. Әсәрнең төп героинясын—укымышлы Маһитапны—залим, карун атасы бай малае исерек Жантимергә кияүгә бирмәкче була. Маһитапның күңеленә тәрбияле, укымышлы Жанбай һуш килә. Пьесада яналыкка каршы чыгучыларның тискәре типлары да бар.

Әсәр жанлы, халык сөйләменә якын тел б-н язылган, персонажлар сөйләмендә диалект сүзләре дә очрый. Аерым кимчелекләргә (композициясенең артык гадилеге, образларның гел бертөрле булуы, хәрәкәт житмәү) ия булса да, пьеса куелган мәсьәләләрнең актуальлеге б-н укучылар арасында кызыксыну уята. Бу әсәргә ияреп Ф.Халиди «Рәдде бичара кыз» (1888) драмасын яза. И.нең «Яшь кыз вә хатынларга һәдия» (1887) исемле насыйхәт-публицистик китабы гаиләдә балалар тәрбияләү мәсьәләсенә багышлана. Бу китапның кереш сүзендә автор хатын-кызларга багышланган тагын да күләмлерәк китапны басмага әзерләве турында яза. Ләкин ул китапның язмышы билгесез.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. К., 1983.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ИЛЬЯСОВ** Жәүдәт Хәсән улы (16.2.1929, Башкортстан АССРның Йәрмәкәй р-ны Исламбахты а.—19.6.1982, Ташкент), язучы. Рус телендә яза. 1931 елдан Ташкентта яши. 1953 тән «Комсомолец Узбекистана», «Физкультурник Узбекистана», «Ташкентская правда» г-таларында эшли, «Звезда Востока» ж-налында поэзия бүлеге мөхәррире була. Беренче шигырьләре һәм хикәяләре 1949 елда Ташкентта басылып чыга. И.ның барлык китаплары Ташкентта басыла. Язучының иҗат кыйбласын тарихның борылыш моментларында халыклар язмышы б-н кызыксыну билгели. Аның геройлары—гаделлек, ирек һәм бәйсезлек өчен көрәшүчеләр, аларның прототиплары булып аерым очракларда реаль тарихи шәхесләр тора. «Ачу сукмагы» («Тропа гнева», 1956) исемле беренче тарихи повесте массагетларның Урта Азиягә басып кергән фарсыларга каршы көрәшен чагылдыра. «Согдиана» (1959) романы Александр Македонскийның Урта Азиягә походын тасвирлый. «Тимгелле үлем» («Пятнистая смерть», 1964) романы да тарихи тематика б-н бәйле.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

Анын сюжетына «Томирис» балеты языла (У.Мусаев муз., О.Узаков либр.) һәм ул Кыргыз опера һәм балет акад. т-рында (Фрунзе, 1982) һәм А.Нәвои исем. Үзбәк Зур опера һәм балет т-рында (Ташкент, 1984) куела. 1965 тә И.ның (А.Ташкентаева б-н берлектә, 1963) сценарие буенча «Канатта йөрүче» («Канатоходец») исемле нәфис фильм төшерелә (реж. Р.Батыров). «Алтын пот» («Золотой истукан», 1973) повестендә автор дин, тормыш мәгънәсе, язмыш, яхшылык б-н явызлыкнын мәңгелек килешә алмаслык конфликты турында фикер йөртә. 1979 да урта гасырлар галиме һәм шагыйре Гомәр Хәйямгә багышланачак трилогиянең беренче китабы—«Елан әфсенләүче» («Заклинатель змей») басылып чыга. Трилогиянең «Тынлык саклау манарасы» («Башня молчания») исемле икенче китабы язылып бетми кала. Автор вафатыннан соң басылган «Анахита үче» («Месть Анахиты», 1984) повестендә гаскәр башлыгы Марк Красснын Парфиягә походы (безнең эрага кадәр 52 ел), рим легионынын җинелүе һәм һәлакәткә дучар булуы тасвирлана. И. рус теленә гарәп, корея, үзбәк, таҗик, башкорт, каракалпакъ язучылары һәм шагыйрьләре (М.Сумадах, Г.Голәм, Д.Угая, К.Даян, Ә.Мохтар, Ж.Мөхетдин, Миртимер, С.Әмин һ.б.) әсәрләрен тәрҗемә итә. И.ның әсәрләре үзбәк, татар, словак телләренә тәрҗемә ителә.

Әсәр.: Заклинатель змей. Башня молчания. Таш., 1986.

Әд.: Писатели Советского Узбекистана: Биобиблиогр. справ. Таш., 1977; Яшен К. Творческое вдохновение—на службу народу // Звезда Востока. 1981. №1.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ИМАЖИНИЗМ** (ингл. image—образ), әдәби агым; 20 йөз башы инглиз һәм америка поэзиясендә барлыкка килә (Э.Паунд, Э.Лоуэлл, Ф.Форд, Т.Хьюм һ.б.). Фәлсәфи нигезе булып А.Бергсонның интуитивизм теориясе һәм тормыш фәлсәфәсе тора. Т.Хьюм И.ның эстетик принципларын тәкъдим итә: метафоралар кулланулы көчәйтү шигырьне «образлар каталогына» әверелдерү, тәэсирләр-хисләрнең әһәмияте арту, алымнар сайлауда иреклелек.

Россиядә И. Октябрь рев-циясеннән соңгы елларда рус авангардының (бигрәк тә футуризмның) эзләнүләре нәтиҗәсендә барлыкка килә. Россиядәге И. төп эстетик принциплары б-н инглиз И.на охшаш була, аның асылын һәм традицияләрен үстерә. В.Г.Шершеневич, С.А.Есенин, А.Б.Мариенгоф һ.б. кергән бер төркем имажинист шагыйрьләр (1918 елда төзелә) түбәндәге концепцияне яклап чыгалар: шәхес матур һәм фаҗигале дөньяның чынбарлыгын образлар аша таный, күрә. Имажинистлар иҗаты үзәгендә—зур шәһәрдә югалып калган һәм ялгызлыкка дучар булган шәхес. Беренче планга янәшә куела алмый торган әйберләрне, күренешләрне, атамаларны чагыштыру юлы б—н, сүзнең гадәти мәгънәсен бозу ярдәмендә туган образ чыга.

Татар әдәбиятында И. чын мәгънәсендә мөстәкыйль әдәби агым булып оешып җитми һәм 1920 елларның бер күренеше генә булып кала. 1925 елда К.Нәҗми үзен символист-имажинист шагыйрь дип белдерә һәм төп темасы «үлеп баручы иске тормыш» булган «Өермәләр» җыентыгын чыгара. Аерым әсәрләрендә сукбайлык, яна тормыш төзү мотивлары чагылыш таба (мәс., заманаҗың рухын бәяләгән «Тормыш төбендә» исемле шигырендә «канда юган ертык күнел» образы пәйда була). К.Нәҗминең имажинистик образлары (мәс., «Иске көннәр канлы эзләргә басып йөгерделәр», «Мин күрәм / һәрбер йөрәктә шүрләгән куян эзен», «Ертык күнел каны бетеп шиңде», «Кыйналган эт кебек еллар елап шыңшыдылар», «Төн канаты белән җирне сөртеп, / Салкын буран очкын иләде») яңалыгы, «кече образларның мөстәкыйль көче» б—н таң калдыралар.

Ул еллар матбугаты битләрендә аерым яшь шагыйрьләренең К.Нәҗмигә ияреп язган шигырьләре басыла. Ләкин И. б-н мавыгу озакка бармый: 1924 нең 31 августында чыккан «Правда» г-тасында С.А.Есенин һәм И.В.Грузинов үз төркемнәренең таралуы турында ачык хат б-н чыгалар. Алар артыннан К.Нәҗми дә И.ның татар әдәбиятында «вакытлыча туктатып тору»ы турында үзенең шаян «Манифестын» бастыра.

Әд.: Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. М., 2001; Нигъмәти Г. Әдәбият мәйданында. М., 1925; Сәгъди Г. Символизм турында. М., 1932.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ИМАМОВ** Вахит Шәех улы (18.3.1954, Актаныш р-ны Иске Байсар ав. туа), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1982). 1982 елдан Яр Чаллы шәһәрендә башта урта мәктәп укытучысы, сонрак КамАЗда мастер булып эшли. 1991 дән «КамАЗ» нәшриятынын баш мөхәррире. 1997 дән ТР Язучылар берлегенең Яр Чаллы бүлеге җитәкчесе. И. әдәбиятка «Ир канаты» (1988), «Нәзер» (1991) исемле повестьлар һәм хикәяләре белән килеп керде һәм татар халкы тарихына багышланган «Сәет Батыр» повесте (1994), «Утлы дала» романы (2002) һәм «Татарларның Ватан сугышы» (1993), «Запрятанная история татар» (1994) очерклар, «Казан дастаны» (2005; рус теленә тәрҗемәдә «Казанская

крепость», 2005) җыентыклары белән танылды. Алар туган җиргә мәхәббәт хисләре, комсызлар һәм хыянәтчеләрне кискен гаепләү белән тулы. Иҗатында тарихи темалар белән беррәттән заман проблемаларын яктырткан әсәрләре да бар. «Тозлы яра» романы (2004) белән И. тоталитар җәмгыятьнен чын йөзен татар авылы призмасы аша ачып бирә. «Япун татары» романында (2004) Ватанын ташлап китәргә мәҗбүр булганнар—эмигрантлар язмышын сурәтләп, халкыбызның киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итә. «Өмет» (1992), «Нәзер» (1993) повестьлары буенча телефильмнар төшерелде.

Əд.: Ахунов Г. Һәркемнен үз кулында // Казан утлары. 1987.№5; Вәлиев М. Тукай яшен узганда // Казан утлары. 1989. №6.

**ИМАНКОЛЫЙ** Мөхәммәд–Садыйк, *кара: Мөхәммәдсадыйк Иманколый*

**ИМПРЕССИОНИЗМ** (франц. impression—тәэсир), әдәби агым. И. тарафдарлары чынбарлыкны үзгәрүчән мизгелләрендә табигый рәвештә гәүдәләндерергә, үзләренең тәэсирләрен чагылдырырга омтылалар. И.ның сәнгати концепциясе: дөнья матурлыгына соклана белүче, нечкә зәвыклы, лирик хисчән, тәэсирләнүчән шәхесне хасил итү.

Яңа сәнгати агым беренче тапкыр үзен сынлы сәнгатьтә таныта. И.ның атамасы да Клод Моненың «Impression. Sunrise» («Тәэсирләнү. Кояш чыкканда») картинасы исеменнән килә. И. рухында О.Ренуар, Э.Дега, А.Сислей, Ван Гог, П.Гоген, А.Матисс, П.Сезанн, К.Писсарро һ.б. иҗат итә. Россиядә И. агымына К.А.Коровинны, И.Э.Грабарьны һ.б. кертәләр. И. сыннар ясау сәнгатендә дә (О.Роден, М.Россо, П.П.Трубецкой һ.б.), музыкада да (К.Дебюсси, М.Равель, А.Н.Скрябин һ.б.) чагылыш таба.

Француз шагыйре Ш.Бодлер шигырьләренә үзенчәлекле музыкаль аһәңлелек, хисси тыгызланган янгыраш һәм тон биреп, И. принципларын лирикага алып керә. Француз шагыйрьләре арасында бу агым кысаларында П.Верлен һәм А.Рембо бигрәк тә уңышлы иҗат итә. Проза өлкәсендә И. Ги де Мопассан, К.Гамсун, Б.Келлерман, Гуго фон Гофмансталь, О.Уайльд, А.Саймонс, И.Ф.Анненский, Б.К.Зайцев һ.б. иҗатларында беркадәр чагыла.

20 йөз башы татар әдәбиятында И.ның аерым алымнары (пейзаж күренешләрен фотографиядәгечә» тергезү, сурәт һәм халәт алмашынуны сүзләр агымына тасвирлау, музыкаль яңгыраш бирү) Дәрдемәнднен ике-өч-дүртьюллык шигырьләрендә гәүдәләнә. Ф.Әмирханның («Хәят», «Хәкарәт саналган мәхәббәт»), Ш.Камалның («Буранда», «Акчарлаклар», «Курай тавышы») проза әсәрләрендә И. ны романтизм б-н, И.ны реализм б-н «синтезлаштыру» омтылышы күзәтелә.

1915 елдан соң татар әдәбиятында чын мәгънәсендә импрессионистик әсәрләр язылa. Г.Исхакый «Бер манзара» исемле хикәясендә таң ату мизгелләренен алышынуын, беренче тапкыр эш урынына барган яшь мулланың нечкә күнел кичерешләрен, күчешләрен ул кичерешләргә тиң булган табигать аһәнен тасвирлый. Ф.Әмирхан «Яз исереклегендә» хикәясендә уянып килгән табигать күренешләреннән алган тәэсирләрне күрсәтә, шул вакыттагы яшь кешенең күнел тойгыларының «тәэсир лирикасы»на әверелүен чагылдыра. «Беренче ашкыну» хикәясендә гашыйк шәкертнен бер көне тасвирлана. Ф.Вәлиев «Көймәдә» исемле хикәясендә беренче саф мәхәббәтнен, гашыйкларның очрашу-күрешү мизгелләре гүзәллеген сурәтли. Хикәядә лирик сагыш, импрессионистик «утәкүренмәлелек» б-н сугарылган табигать сурәтләре урын ала.

Импрессионистик әсәрләрдә тирә-юнь хисләр аша кабул ителә, кешенең күнеле, кәефе-халәте, көндәлек ситуацияләр, ниндидер бер мистик яктылык каймасына чолгап алына, ләкин ачык, изге матурлык артында иртәгесе көннен фаҗигасе сиземләнә. Геройларның кичерешләре матур һәм кайгылы. 20 йөз башы татар прозаикларының тормышка үзенчәлекле карашы һәм эстетик каршылыклар шунын б-н билгеләнә.

Сынлы сәнгатьтә И.ның аерым сыйфатлары Н.И.Фешин, П.П.Беньков, П.А.Радимов картиналарында, сыннар ясау сәнгатендә В.С.Богатырёв сыннарында чагылыш таба. 20 йөз сәнгатендә табигатьне сурәтләү (пленэр), этюд эстетикасы алымнары Б.Урманче, Г.Рахманкулова, Н.Д.Кузнецов, А.А.Аникеенко, Р.Нигъмәтуллина иҗатларында күренә.

Əд.: Теория литературы. Т.4. Литературный процесс. М., 2001; Ренессанс в татарской литературе нач. XX века и импрессионистические приёмы в творчестве Шарифа Камала // Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. К., 2002; Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ИНТЕРМЕДИЯ** (лат.intermedius—урталыкта торучы), драма спектакле яки опера актлары арасында башкарыла торган зур булмаган күренеш (гадәттә көлкеле). 15 йөздә мистерия составына кергән тормыш-көнкүреш һәм музыкаль өзекләр формасында барлыкка килә. Татар драматургиясе әсәрләрендә

И. агитация-сатира төсмерен дә ала. Г.Камалның агитпьесаларында И. персонажлары булып Ажак б-н Кужак, Корфетдин б-н Торфетдин, Хатип б-н Латыйп тора. Ф.Бурнаш («Таң атканда», «Әҗәл», «Колчак–Деникин зарлары»), Һ.Такташ («Авыл кызлары», «Гармунчылар») пьесаларына И.не кертәләр. Хәзерге татар драматургиясендә И. кулланылмый диярлек.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**ИРЕКЛЕ ШИГЫРЬ** (франц. vers libre—верлибр)—төп ритмик берәмлек тәшкил итүче төрле озынлыкта килүче юлларның чиратлашуына корылган шигырь яки үзенчәлекле ритмик система. Димәк, әлеге шигырьдә башка шигырь төзелешләрендә төп роль уйнаучы иҗекләрнең басымлы-басымсыз булып килүе дә, һәм аларның саны да ритмик нигез итеп алынмый. Шулай ук иректе озынлыктагы юллар даими зурлыктагы строфаларга да берләшми. Хәтта рифмаларның булуы да мәҗбүри түгел. Ритмны оештыручы һәм саклап баручы төп чара монда нәкъ менә төрле ритмик-интонацион чаралар (янәшә яки эчке рифмалар, композицион яки юлара ялгау, вакыт компенсациясе, тәнгәл турак-цезуралар һ.б.) ярдәмендә берберенә ялганып, тезелеп баручы шигырь юллары, ягъни ритмик-интонацион яктан үзгәреп, уйнаклап торучы синтаксик берәмлекләр—синтагмалар, гыйбарәләр.

Иректе шигырьне беренчеләрдән булып Бельгиядә Э. Верхарн, Төркиядә Н.Хикмәт, Россиядә А.Блок, В.Брюсов, татар поэзиясендә С.Рәмиев куллана.

Әлеге шигырь үрнәкләрен янә Һ.Такташ, Г.Кутуй, М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Ш.Анак, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, М.Әгъләм, Зөлфәт һ.б. иҗатында өлешчә яки күпләп очратырга мөмкин.
*М.Х.Бакиров.*

**ИРОНИЯ** (греч. eironeia—хәйлә, мыскыллау), шаян кинаяː тискәре, мәсхәрәле, кимсетүле мөнәсәбәтне ясалма рәвештә уңай бәяләү. Бу бәяләүнең тискәре, мыскыллы мәгънәсе ситуациянең үзеннән, сүзнең контекстыннан яки интонациясеннән беленә. Әдәбиятта И. стилистик алым, троп булып файдаланыла. Аерым очракларда артык үтемле, көчле И. сарказмга якыная һәм гротеск, пародия, парадокс чаралары б-н бирелә. Татар әдәбиятында И. һәм сарказмга бай иҗат—Г.Тукай иҗаты. И.ның төрле форма һәм төсмерләре аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында, «Кечкенә музыкант», «Буран», «Егет илә кыз» шигырьләрендә очрый. Үзләренең юмористик шигырьләрендә И.дән М.Җәлил, С.Баттал, Ә.Ерикәй, Ш.Галиев һ.б. татар шагыйрьләре дә файдалана.
*В.Х.Ганиев.*

**ИСКУЖИН** Зыя Газим улы (1910, Уфа губ. Сабир вол. Мәксүт а.—1936), шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе. Оренбург татар пед. техникумын, Казан пед. ин-тын тәмамлый. М.Гафури, Ш.Бабич, Һ.Такташ, М.Әмир һ.б. иҗатына багышланган мәкаләләр авторы.

**ИСЛАМОВ** Рәмил Фәнәви улы (14.9.1958, Башкортстан АССРның Балтач р-ны Госман а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2002). Башкорт ун-тын тәмамлый (1987). 1990 елдан ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли (2002 дән әдәбият белеме бүлеге мөдире, 2007 дән директор урынбасары). Хезмәтләре урта гасырлар төрки, төркитатар әдәбиятына карый.

Хезм.: Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни башланышлар. К., 1998; Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә Шәрифнең «Шаһнамә»се. К., 2001.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Рәҗәп һәм Яңа Рәҗәп авыллары

Спас районында Иске Рәҗәп һәм Яңа Рәҗәп авыллары бар. Иске Рәҗәп авылы район үзәге Болгар шәһәреннән—77, ә Яңа Рәҗәп 70 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бу тирәдә бабаларыбызның данлыклы Болгар һәм Шәмсуар шәһәрләре шаулатып яшәгән. Районда алым саен борынгы бабаларыбызга барып тоташа торган истәлекләр, рухи ядкәрләр очрый. Рәҗәп авылы да гаҗәп тарихи һәм борынгы. Иске Рәҗәп авылы зиратында Һ. В. Йосыпов XVI йозгә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары тапкан. Д . А. Корсаков жыентыгында (XVIII йөз) Иске Рәҗәп һәм Яңа Рәҗәп авыллары искә алына. Чәчәкле, Яңа Бәрән (Чәчәкле суы буена урнашкан) авылында 105 ясаклы, 8 керәшен татары көн иткән. Иске Бәрән авылында (Бәрән суы буенда) 416 ясаклы, 4 керәшен татары яшәгән А. Артемьев китабында (1866) күрсәтелгәнчә, Яңа Бәрән авылында 106 хужалыкта 369 ир-ат һәм 389 хатын-кыз көн иткән. Авылда бер мәчет эшләгән. Иске Бәрән авылындагы 401 хужалыкта 1232 ир-ат һәм 1327 хатын-кыз исәпләнгән, 3 мәчет эшләгән. 1869 елнын 14 июнь датасы белән Иске Рәҗәп авылы бер тарихи чыганакта жир белән бәйләнешле рәвештә таратылган имеш-мимешләр нигезендә телгә алына. 1898 елгы хезмәттә Иске Бәрән һәм Яна Бәрән авыллары искә алына һәм аларда татарлар көн итә дип күрсәтелә. К. П. Берстель мәгълүматларына караганда, Иске Бәрән авылында барлыгы 3841 татар кешесе яшәгән.

Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәрендә Иске Рәҗәп авылы турында түбәндәгеләрне яза. «Спас өязе Иске Рәҗәп авылы кешеләренең басу, печәнлек һәм урман җирләрен, шулай ук күршедәге башка авылларнын чикләрен билгеләп язылган һәм хәзинә мөһере белән расланган ышаныч язуларында һәм шул авылның имамнарыннан булган мелла Зәйнелгабидин бине Габделкәрим исемле шәхеснең тәрҗемәсендә мондый юллар күренде: «Тарих 7203 ел декабрьнең унөченче көне илән указ олуг. Газыйм падишаһ хәзрәте—олуг кенәз Петр Алексеевич барча олуг һәм кечек, ак падишаһ, Россия йортын үзе тотучы, үзе биләүче, указ куәте белән Казан өязенең Рәҗәп авылы татарлары югарыда язылган җирләрне сукалау һәм печәнен чабу өчен укадиләр[1] илән биләргә олуг падишаһ хәзрәтенең бердән ясак белән тармакка, ягъни түләмәккә, бу замандагы анлатуны Казанга түләргә яздым».

Рәҗәп авылы оешу турында Татарстанның Спас кантоны Рәҗәп авылында Борһан Кыям улыннан 1928 елда Сәид Вахитов язып алган легенда әһәмиятле чыганак булып исәпләнә.

«Рәҗәп авылы—моннан биш йөз еллар алда корылган бер авыл. Анын беренче килеп утырган кешесе Рәҗәп атлы, Шәһри Болгарның зур кешесе булган. Ул, үзенең агай-энесе белән Шәһри Болгардан күчеп килеп, безнең Рәҗәп авылын нигезләгән.

[1] Укадиләр – угодьелар – файдалана торган җир биләмәләре.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6 нчы санында.*

Рәҗәп баба килгәндә, безнең бу тирә кап-кара калын урман булган. Бу урманда һәртөрле ерткычлар, аю-бүреләр яшәгән, болан сыерлары көтү-көтү булып йөргәннәр. Ә урман агачларында чамасыз күп бал корты илләре булган. Җәй көннәрендә балны әнә шушы кыргый чолыклардан алганнар. Аннары аны Шәһри Болгар базарына илтеп сата торган булганнар.

Иске Рәҗәп авылы янында Ташбилге яисә Калалар өсте дигән урын бар. Халык сөйләвенә караганда, Ташбилгедә һәм Иске зиратта изге шәхесләр күп күмелгән. Авыл аксакаллары ташу ташый торган Шуширмә дигән ермакны искә алалар һәм шушы чурайдан, ягъни су ташуы юлыннан Рәҗәп бабай килгән дип әйтәләр. Су башы газизләре чишмәсен, Балыкчы суы, Кырык бер тармак, Алтылы күпер, Шәмсуар газизләрен әби-бабалар догаларыннан калдырмыйлар. Капран чишмәсе исемле чыганак янында игътибарлы булу кирәк. Кирәк-кирәкмәскә кулыңны юсаң, кулың һәм бөтен гәүдәң авырта башлый икән. Тал төбе чишмәсенең үз хасияте бар: суына сокланып юынсаң, битең авырта, аягыңны юсаң, аксыйсың икән.

Рәҗәп бабай чишмәсе турында шушындый легенда-ривайәт тә бар. Рәҗәп бабай Шәһри Болгардан үзенең нәсел-ырулары белән килеп, хәзерге Рәҗәп авылының көнчыгыш ягына, авылдан дүрт чакрым чамасы читкә, ул чакта урман булган бер урынга тукталган икән.

Ул сау-сәламәт килеп җитүенә бик сөенә, Ходага шөкер сәҗдәсе кылмакчы булып, тәһарәт алырга су эзли башлый. Аңа Хозыр галәйһиссәлам килеп, сәлам биргән:

—Инде синең туктый торган урының шушы,—дип әйткән. Шуннан соң Рәҗәп бабай, Ходайга ялварып, шул җирдән чишмә чыгаруын сораган, ди. Хода, аның теләген кабул итеп, чишмә чыгарган. Чишмә суы, көмеш кебек ялтырап, кыйбла ягына таба ага башлаган. Рәҗәп бабай шуннан, беренче мәртәбә тәһарәт алып, намаз укып, Ходага шөкер сәҗдәсе кылган, ди. Менә шуның өчен бу чишмә Рәҗәп баба чишмәсе дип, чишмәдән хасил булган елга да Рәҗәп елгасы дип атала икән.

Моннан башка авылда тагын Пәриле куак, Иштуган, Әбҗәлил, Хуҗи чишмәләре бар.

Авыл халкы чишмәләрне чистартып тора. Бу борын-борыннан килә торган игелекле гадәт.

Иске Рәҗәп басуларында Урта юл, Имәнкискә, Имәнкуак күлләре җәелеп ята.

Авыл аркылы Инеш һәм Байтирмән елгалары ага. Авылдан якын гына Майна суы Иделгә ашыга. Аны Майна башы дип атыйлар. Иске Рәҗәп авылы Олы һәм Кече Майна елгаларының башланган урынына утырган.

Элек Инеш һәм Байтирмән елгалары бик тирән, киң һәм матур булганнар. Елгалар тирәсендә таллар үскән, су тегермәннәре көне-төне эшләгән. Бу тегермәннәрдә авыл халкы гына түгел, ә күршедәге урыс авылларыннан да килеп он тарттырганнар. Рәҗәп тегермәннәренең даны күп еллар буена сакланган. Суларында балык күп үрчегән, еланнар һәм кошлар гомер кичергәннәр. Елгаларда, халык сөйләве буенча, кечерәк пароходлар да йөзгән. Шулай бер пароход ни сәбәптәндер елгада баткан. Ул алтын-көмеш тәнкәләр төяп барган. Моннан 100 еллар элек авыл уртасыннан аккан Инеш ярларында көмеш тәңкәләр табыла. Бу тәңкәләр Шәмсуар шәһәрендә сугылган әзгәри акчалар була. Корабның баткан урыны Капраннан (тау инеше) ерак булмаган.

Хәзер елгаларның тирәнлеге чыпчык тубыгына кадәр житә. Елга тирәләренә тирес түгү очраклары күзәтелә. Елга-инешләр тирәсенә соңгы елларда тал үсентеләре күп үсеп чыккан. Елга-сулар чисталыгын саклау авыл халкы намусында кала.

Авыл тирә-ягында таулар юк, зур булмаган калкулыклар урнашкан.

Авылның көнбатыш өлешендә ике калкулык бар. Аларны халык Алып чабата каккан урыннар исеме белән йөртә. Аның берсе Майна суын чыккач, икенчесе—Пан юлы өстендә.

Авылның көнбатыш һәм көнчыгыш өлеше урман белән әйләндереп алынган. Урманнарда усак, имән, өрәнге, каен, чикләвек куаклары үсә. Урман кырыйлары җиләкләргә һәм гөмбәләргә бик бай. Җәнлекләрдән поши, кабан дуңгызы, кыр кәҗәләре, боланнар очрый.

Моннан 50-60 еллар элек авылның көньяк-көнбатыш өлеше зур әрәмәләр белән капланган булган. Хәзер ул әрәмәләр беткән, бары сазда үсә торганнары гына сакланып калган. Ул әрәмәләрдә бүре, төлке оялары очрый. Көньяк ачыклык өлешендәге «Чиялек» дип аталган урында 300—400 гектар чамасы җирдә торфлык урнашкан. Бу торф җәй буена янып ята.

Революциягә кадәр урманнар бик нык тикшерелеп торылган. Мал-туар кермәсен өчен тирә-ягы чокыр белән әйләндереп алынган. Ул чокырларның эзләре әле дә булса саклана. Хәзер урманнар нык киселә, утыртылуы артык күп түгел.

Авылда берничә күпер исеме бар: Алтылы күпер, Сары саз, Майна, Нәлет һәм Буалы елга. Бу күперләр авыл тирә-юне белән танышып йөргәндә, авылны уратып алу тәэсире калдыралар.

Алтылы күпер дип урман янындагы тарихи урынны атыйлар. Элек, бәлки, анда күпер булгандыр, хәзер күпер юк, елга яисә инеш тә акмый.

Халык сөйләве буенча, күпер янында ниндидер зур сугыш барган һәм бу сугышта алты туган вафат булган. Анда берничә кабер урыны бар, алар чардуган белән тотып алынган. Халык бу каберләрнең чардуганнарын төзәтеп карап тора.

Авыл тирә-юненә урнашкан Калалар өсте дигән атама зур игътибарга ия. Бу урыннарны халык Болгар чоры белән бәйли. Калалар өсте—шул заманда берәр кала урыны булган булса кирәк. Хәзерге көндә 4 калалар өсте билгеле.

1) Әлморза юлында кала. Әлморза авыл исеме, анда татарлар яши. Иске Рәҗәптән 15-18 чакрым ераклыкта.

2) Нәлет юлында кала. Нәлет—авыл исеме, анда руслар һәм мордвалар яши. Иске Рәҗәптән 5 чакрым ераклыкта.

3) Мулла тавы, яисә Әйләнмәдә урнашкан. Авылдан ерак түгел.

4) Шуширмәдә урнашкан, авылдан якын гына.

Бу урыннарда әле хәзерге көнгә кадәр казылган чокыр эзләре күренеп тора. Чокыр эзе калалар өсте урынын әйләндереп алган. Чокырдан башка берничди корылмалар сакланмаган.

Югарыда әйтелгән чор белән бәйләнешле атама—Ташбилге. Ул авыл уртасына урнашкан, аны халык Ташбилге зираты дип тә йөртә. Хәзерге көндә бу урынны халык изге дип саный. Бу урында начар сүзләр әйтергә ярамый, «изгеләр тота» дип исәпләнә. Монда 6 кабер ташы сакланган. Ташларда исемнәр теркәлгән, берсендә «Хәсән ибне...» сүзләрен укып була.

Көнбатыштан авылны Дунгыз атавы һәм Иштуган чокыры, уң яктан Дунгыз атавы чокыры, көньяктан Буалы елга чокыры әйләндереп алган.

Халык Иштуган чокырыннан озак еллар дәвамында печән чапкан. Куаклыкларында бурсык, кыр тавыклары оялары әле дә бар. Дунгыз атавы чокырында төрле агачлар, мәтрүшкәләр, аю камыры, үги ана яфраклары, бака яфраклары h.б. бик күп үсемлекләр үсә.

Авыл янындагы Габбас ышнасы, Бәрәнге төбәге ышнасы, Миңлевәли умарталыгы дип йөртелгән урыннарны куаклык баскан.

Авыл халкының элек кәсеп-һөнәрләре шактый булган. Алар арба ясаганнар, дегет кайнатканнар, дуга, чана табаннары бөккәннәр. Халык үзенең һөнәрчелеге белән дан тоткан.

Авылда элек-электән базар эшләгән. Ул базарда халык үзе житештергән әйберләрне саткан. Күрше авыллардан да бу базарга бик теләп килә торган булганнар.

Күренекле галим Шиһап Мәрҗани Иске Рәҗәп авылына килгәч, Габделваһап муллага туктый. Мулланың улы Казанда Ш.Мәрҗанидә укыган. Габделваһап абзый белән ул Шәмсуар шәһәре хәрабәләрен карарга бара.

1970 елларда авылда 700—800 хуҗалык саналган, аларда 3000 гә якын кеше яшәгән. Хәзерге көндә йортлар саны 150 гә якын, яшьләр шәһәргә китү ягын карый.

Авылда урта мәктәп эшли. Мәктәптәге укытучылар тулысы белән авыл кешеләре. Хәзерге көндә аның дәрәҗәсен элекке хәленә кайтару өчен тырышып эшләү кирәк. Ул ике бинадан тора, берсе таштан, икенчесе нарат агачыннан салынган. Мәктәптә тарих музее урнашкан.

Авылда тагын мәдәният йорты, балалар бакчасы, медпункт, 2 кибет, кунаклар өчен кунакханә, китапханә эшли.

Юлларның барысына да асфальт салынган, юл күтәртелгән.

Авылда ике катлы, озын һәм матур манаралы таш мәчет салынган.

Халык зиратны карап, чистартып һәм тәрбияләп тора.

Соңгы елларда авыл зураюга, үсүгә таба йөз тота. Зур тарихи традициясе булган бу авылның мәдрәсәсе булуын өмет итеп калабыз.

***

Яна Рәҗәп авылын Иске Рәҗәптән килгән кешеләр нигезләгән. Авылны икенче төрле Чәчәкле дип тә йөртәләр. Хәзер Чәчәкле атамасы рәсми рәвештә дә кулланыла.

Авыл янargументтан Балыкчы һәм Чәчәкле суы агып үтә. Алар Өтәк (Утка) суына тоташалар. Авылда Байлар коесы, Урам башы коесы, Аҗиклар коесы атамалары алган коелар бар. Моннан башка тагын халык телендә Аю күле, Ногман тирмәне арты күле, Акма куагы күле, Чәчәкле күле атамалары әйләнештә йөри.

Авылда урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, медпункт, элемтә үзәге һәм кибет бар.

Авылда мәчет гөрләтеп эшли.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән.

Авылдагы ялгыз карт-карчыклар һәрдаим игътибар үзәгендә. Аларга ярдәм итеп торалар.

Авыл халкы зиратны карап һәм тәрбияләп тора.

Авыл халкы уңган һәм тырыш, тормышлары матур һәм нык. Алар киләчәккә ышаныч белән карыйлар.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

## Электрон почта да төпсез түгел

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

Альфред
Халиков

# БОЛГАР–ТАТАР ЧЫГЫШЛЫ 500 РУС ФАМИЛИЯСЕ*

**БАЗАРОВЛАР**. XIV йөз ахырыннан дворяннар. 1568 елда Ярославльдә Тимер Базаров (исем-фамилиясе төрки) теркәлгән (Веселовский 1974, 19). Базар көнне туган кешеләргә шундый кушамат тагыла (Баскаков 1979, 30).

**БАЛАКИРЕВЛАР.** Борынгы дворян нәселе. Балакиревлар Мамай хан улы Мансур Киятның төркиләрдән торган гаскәре Глинскийлар белән бергә XIV йөзнең ахырында Литвада искә алыналар (В., D.1986, 22), аннары XVI-XVII йөзләрдә кенәз Ив. Ив. Балакирь үз жирләре белән Каширада, Коломнада, һәм Арзамаста теркәлгән ( Веселовский 1974, 22). 1579 елда Проня Балакирев Иван IV гә хезмәткә алына (Веселовский 1969, 100). Соңрак—Нижний Новгород һәм Рязань төбәкләренә тупланган борынгы дворяннар нәселе. Танылган композитор М. А. Балакирев шушы нәселдән.

**БАСКАКОВЛАР.** 1598 елдан дворяннар. Смоленск, Калуга, Тула губерналарында биләмәләре булган. Килеп чыгуларына карата төрле фикерләр бар: 1. XIII йөз урталарында Владимирның башлыгы булган Амраган (Әмир хан) баскактан яки Амиргатадан ( Амир—Әмир Гата) (*әмир* титулына караганда, болгар булуы ихтимал—ОГДР , XII 48); 2. Татар Ибраһим баскактан (БК II, 284); 3. XV–XVI йөзләрдәге төрле йомышлылардан, Русьтагы баскакларның нәселләреннән—мәсәлән, Албыч, Будай, Кудаш, Тутай баскаклар һ.б. (Веселовский 1974, 27). Соңыннан—хәрбиләр, галимнәр, мәсәлән, Н. А. Баскаков (РБС II, 248).

**БАТУРИННАР**. XV йөз башында Урдадан кенәз Федор Ольгович Рязанскийга күченгән Батур морзадан. Чукынганда Мефодий исемен алган. Туганнары Романовларда боярлар хезмәтен башкарган. Леонтьев, Петрово-Соловолар белән туганлыкта (ОГДР IV, 30). Фамилия төрки-болгар *батыр/батур* сүзеннән ясалган (Баскаков 1979, 13-14). Соңыннан—галимнәр, хәрбиләр, мәгърифәтчеләр *(ЭС[1], 1987, 115).*

**БАХМЕТЬЕВЛАР** (БАХМЕТОВЛАР). Ир кардәшләре Касыйм белән Якуп XV йөздә Бөек кенәз Василий Васильевич Темныйга хезмәткә киткән Аслам Бахметтан (чукындырылгач, Иеремей исемен алган) башлана (ОГДР II, 58). «Бәрхет китабы»нда (БК II, 258) Аслам Бахметның кенәз Мещерский (к.) белән туганлыгы күрсәтелгән. Ослам, Аслам төрки-болгар *арслан* сүзеннән, Бахмет төрки-мөселман *Мөхәммәд* яки төрки *Бай Әхмәттән* ясалган (Баскаков 1979, 100-101). Ихтимал, болгар-бортас (мишәрләрнең бабалары) мохитыннандыр. Соңыннан—галимнәр, революционерлар, аларның берсе Н. Г. Чернышевскийның дусты (ЭС[1] 1987, 115).

**БЕРДЯЕВЛАР**. 1598 елдан дворяннар, Смоленск һәм Переяславль тирәләрендә жирләре булган (ОГДР Y, 59; Веселовский 1974, 36). Фамилияләре төрки *бирде*

[1] ЭС – Энциклопедический словарь. М.,1987.

* *Шул исемдәге хезмәттән өзекләр. Дәвамы. Башы 2009 елның 5нче санында.*

«бүләк ителгән» сүзеннән ясалган (Баскаков, 1979, 177). Соныннан—галимнәр, философлар (ЭС 1987, 130).

**БУЛГАКОВЛАР** (беренчеләре). XIV йөз ахырында Мамайның улы Мансур Кият белән Литвага күченүчеләрдән (В., D. 1986, 22). 1408 елда аларның бер өлеше Свидригайло яраннары белән русларга хезмәткә күченәләр, Новгород һәм Мәскәү шәһәрләре тирәсеннән җирләр алалар (ОГДР I, 2-3). XV йөздә боярлар. 1481 елда Новгород шәһәренең башлыгы булганлыгы билгеле (Веселовский 1969, 30-34). Беренчеләренең фамилияләре, башкаларыныкы кебек үк, «горур кеше» мәгънәсен белдерүче төрки-татар *«булгак»* сүзеннән ясалган (Баскаков 1979, 49-50).

**БУЛГАКОВЛАР** (икенчеләре). XV йөз башында уллары Голица (к. Голицыннар) һәм Курака (к. Куракиннар) (ОГДР II, 120) белән Ольг Рязанскийга хезмәткә чыккан Иван Иванович Шай-Булгак, хан нәселеннән. XV-XVI йөзләрдә инде бояр дәрәҗәсе, авыллар бирелә, шул исәптән Мәскәү тирәсендә дә (1457 елгы язма) (Веселовский 1960, 224). 1566-68 елларда боярлар Петр белән Григорий Андреевич Булгаковлар Казанда гаскәр башлыклары булып хезмәт иткәннәр, Казан тирәсендә биләмәләре, шул исәптән Колмәмәт h.б., булган (ПКК[2], 22, 48-50).

**БУЛГАКОВЛАР** (өченчеләре). XV йөз башында Урдадан Рязань кенәзе Федор Васильевичка хезмәткә күчкән Матвей Булгаковтан, ул абыйсы Денисий белән аңа хезмәт итә (ОГДР IX, 89; Зимин[3] 1988, 267, 300).

Шулай итеп, чыгышлары төрле, әмма төрки булган (Веселовский 1974, 53) Булгаковлардан билгеле язучылар, галимнәр, хәрби хезмәткәрләр, фәлсәфәчеләр, митрополитлар да чыккан (РБС, III, 457-474; ЭС 1987, 177).

**БУЛГАРИННАР**. 1596 елдан дворяннар. Гадәттә Казан тирәсеннән чыккан башка кешеләр кебек, Кострома тирәсендә утарлары булган. Биредә үк Новоторжок өязендә Болгар волосте урнашкан була (Веселовский 1974, 44). Мондый фамилияле кешеләр (мәсәлән, Фаддей Булгарин—XIX гасырның беренче яртысы язучысы) Польша татарлары арасында да булган (РБС III, 476).

**БУНИННАР**. Бабасы Урдадан китеп, Рязань кенәзләренә хезмәткә кергән һәм Ряжск өязеннән җир алган Бунин Прокуда Михайловичтан (1595 елда үлгән) башлана (Веселовский 1974, 260). Башка чыганаклар буенча, 1445 елда Бөек кенәз Василийда хезмәт иткән Рязанлы Бунко исеме телгә алына (Веселовский 1969, 310). Буниннар арасыннан атаклы галимнәр, дәүләт эшлеклеләре, язучылар, шул исәптән Нобель бүләге лауреаты И. А. Бунин, чыккан.

**БУХАРИННАР.** 1564 елдан дворяннар (ОГДР V, 49). XV йөздә телгә алынган Тимофей Григорьевич Бухар-Наумовтан һәм аның нәселе—дьяк Ишук Бухарин (XVI гасыр уртасы) белән оныгы Евтихий Иванович Бухариннан башлана (Савва[4] 1917; Веселовский 1974, 58). Н. А. Баскаков (1979, 175-176) бу нәселнең төркиләрдән икәнлегенә шикләнми. Соңыннан—галимнәр, дәүләт һәм сәясәт эшлеклеләре.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

[2] ПКК—Писцовая книга Казани. Материалы по истории народов СССР, Л., 1932.
[3] Зимин А. А. Формирование боярской аристократии в России во второй половине XV – первой трети XVI века. М., Наука, 1988.
[4] Савва В.И. О посольском приказе в XVI веке. Харьков, 1917.

# КӘЧТҮМ

Кичләрен дискотека дигән нәрсәгә барганда оныгымның дусишләре бездә тукталып чыгалар. Шулчак күнелем яктырып китә, йортыбыз эченә яшьлек үзе кергәндәй була. Барсы да: «Исәнсаулыкмы, бабыкай»,—дип кул биреп күрешәләр, йөзләрендә мөлаем елмаю, шөкер, итагатьле егетләр.

Үткән яшьлегем белән чагыштырып, аларны күзәтеп утырырга яратам мин. Киенүләре үк үзгә: әнә бит барсы да диярлек безнең буынга ят исемле джинсы дигән чалбардан, түшләре ачык жиңсез күлмәктән. Муеннарында үзләре «цепочка» диеп йөртә торган ялтыравыклы чылбыр. Әнә шул нәрсәне һич кенә дә күтәрми бит күнел. Түзмәдем, бер тапкыр шактый катгый итеп: «Муеннарыгызга «тавык тәпие» асып йөрисезме әллә, юньсезләр?»—дип ычкындырдым. Егетләр башта каушап калдылар, бераздан кинәт зиһеннәре ачылып, берсе икенчесен бүләбүлә: «Син, бабыкай, бигрәк инде, муенга тәре асып йөрергә безне кем диеп белдең»,—дип, миңа үпкә белдерделәр. Минем һаман да ышанып житмәгәнемне күреп, муеннарыннан чылбырларын салып, каршыма килеп бастылар да: «Менә, кара, «цепочкаларыбызда» бернинди гөнаһ та юк»,—диделәр.

—Шулай да муенга чылбыр асып йөрү безнең милләт яшьләрен бер дә бизи торган эш түгел,—дидем мин.

—Заман, бабыкай! Мода!—диде оныгым.—Без уйлап тапкан нәрсә түгел.

—Алай жиңел генә мода колына әйләнергә ярамый. Киенүнең дә үз культурасы бар. Мин менә сезне шул дискотека дигән нәрсәгезгә матур кәчтүм, ак якалы күлмәк кигезеп, галстук тагып чыгарыр идем.

—...Кәчтүм?!

Яшьләр елмаешып бер-берсенә карашып алдылар. Берничәсе жилкәсен дә сикертеп куйды. Шаулашып алгач:

—Син нәрсә, бабыкай?!

—Яшьләр киямени аны хәзер ...

—Бәлки берәр тантанага, яисә кәләшең белән язылышырга барганда кисәң инде...—диештеләр. Аннан көлешә-көлешә чыгып та киттеләр. Минем уйларым исә кәчтүм белән бәйле бер вакыйгага барып тоташты.

Кырык өченең май ае азаклары. Район үзәге нефтебазасыннан колхозыбызда жир сөрүче МТС тракторларына ягулык ташыйм. Үземә беркетелгән Маруха исемле тимеркүк бия белән һәр ике көннең берендә иртә таңнан юлга кузгалабыз. Нигә ике көннең берендә дигән сорау куйсагыз, жавабы болай: чөнки без район үзәгенә көннең икенче яртысында гына барып житәбез. Тимер юл станциясы артындагы нефтебазадан мичкәбезгә ягулык тутырып чыкканчы кич житә, колхоз фатирында кунып калырга туры килә.

Мине һәр атна башында биредә Хәбибрахман исемле малай көтеп ала. Малай дип әйтүем кимсетү булырдыр кебек, чөнки ул миннән бер яшькә өлкәнрәк, инде уналтысын тутырып, егетлеккә кереп бара. Үткән,

чая яшүсмер, шәһәрдә туып-үскәч, русчаны да су кебек эчә. Шуның өстенә зиһенле, төскә-биткә дә ярыйсы, тумыштан ук кара көдрә чәче килешле булып каш өстенә төшеп тора. Хәбибрахман сату-алу белән эш итә. Ул минем олауга утырып авылыбызга кадәр кайта да, аннан «уф алла» арбасын тартып Минзәлә ягына, ниндидер Матвеевка дигән рус авылына китеп бара. Ул авылда «самосад» дигән тәмәке чәчеп үстерәләр икән. Тәмәкеләрен бик теләп саталар икән. Шулайдыр, чөнки ике-өч көн саен арбасына капчыгы белән тәмәке төяп кайтмас иде Хәбибрахман. Авылда инде ул капчык минем олауга күчә. Район үзәгеннән поезд белән Ижауга китә Хәбибрахман. Аннан инде, билгеле, шәһәр базарына. Базарга тәмәкене капчыгы белән алып чыгып булмый, спекулянт дип бик тиз эләктереп алулары мөмкин. Шуңа күрә тәмәкесен азлап-азлап кына алып чыгып сата. Әйтүенчә, товары кулына да тими икән. Чөнки дәүләт кибетләрендә тәмәке киштәләре шыр буш. Тартучыларның бөтен өмете Хәбибрахман кебек тәмәке «монополистларында», шәһәр базарында «самосадны» тартып карап сайлап алырга була. Күбесенә Хәбибрахманның тәмәкесе ошый икән, «ах, крепкий» дия-дия, суырган саен йөткереп аның тәмәкесен алалар икән. Хәбибрахман татар кешесенә тәмәке сатуның зур гөнаһ булуын да аңлый үзе, әмма нишләсен, авыру әнисен, чәчби сенелкәше белән өч яшен тутырып килүче энекәшен туйдырырга кирәк. Аларның бердәнбер таянычы—Хәбибрахман. Юл газаплары бик авыр булса да, тәмәке сатудан кесәгә гаиләне яшәтерлек сәмән кереп тора икән.

Ул көнне дә Хәбибрахман белән иртә таңнан авылга кайту юлына кузгалдык. Арбада ягулык тутырылган өч центнерлы мичкә. Йөгебез авыр булгач, күбрәк җәяүләп атлыйбыз. Утыру юл бик тигез урыннарда, яисә тау төшкәндә генә. Авылга көн кичкә авышкач кына кайтып җиттек. Хәбибрахман башка көннәрдәге кебек арбадан төшкәч үк Минзәлә ягына китеп бармады, иртәгә иртән кузгалырмын дип куна калды.

Атымны тугарып, төнге ат көтүенә кушып җибәреп кайткач, чәй эчеп алдык та, клубка чыгарга җыендык. Авылның май ае кичләре аеруча матур була бит. Ул арада күктә көмеш сыман нурларын сибеп ай калыкты, тирә-якны сихри яктылык биләп алды. Авыл башындагы урман ягыннан өзеп-өзеп тартар кычкыра, су буендагы таллыкта күнелне каядыр ашкындырып сандугачлар сайрый. Клуб алдындагы яшьләр җыела торган мәйданчыктан тальянга кушылып җыр тавышы ишетелеп тора. Җаннарның каядыр ашкынган мәле! Юынып, юл тузаннарыннан кагынып алгач, без дә шул яшьләр янына китеп бардык.

Клуб алды гөр килә.

Яшьләр чабаталарыннан тузан өермәсе чыгарып тирләп-пешеп «чүпләм» биюе биюләр. Уенга чыкканнар арасында миңа таныш булмаган кызлар да бар. Шәһәрчә киенгән ике кыз, «чүпләм»гә кермичә, эскәмиядә утыралар. Кулларында кульяулык, шул яулык белән вакыт-вакыт борыннарын каплыйлар, янәсе тын юлына тузан кертмиләр. Кызыксынуым артты, яннарына якынрак барып утырдым, борыныма хушбуй исе килеп бәрелде. Янәшәмдәге егеттән шыпырт кына: «Кемнәр болар?»—дип сорадым. «Шәһәр кызлары»,—диде Рафис. Аннары, миннән дә шыпыртрак итеп:—«Ырымбур шәлләре, бәйләгән фуфайка кебек нәрсә сатып йөрүчеләр»,—дип тә өстәде. Тагын күз ташлап алдым. Бигрәк чибәрләр шул! Болар инде сиек-миек бәрәңге шулпасы эчеп арыкланган, колхоз басуында эшләп тузанга керләнгән авыл кызлары түгел! Яшьрәгеннән күземне ала алмыйм, иреннәре чия төсле кызыл, пудра яккангамы, аеруча чибәр күренә. Кырыема килеп утырган

Хәбибрахманның колагына: «Бу күгәрченнәрнең әнә теге яшьрәген озата барам әле»,—дип пышылдадым.

—Ярар, мин өлкәнрәгенә иярермен,—диде Хәбибрахман.

Уеннар бетте, таралыша башладылар. Теге кызыйлар да авылныкылар белән култыклашып кайтырга чыктылар. Хәбибрахман белән күз кысышып алдык та, без дә кузгалдык, артларыннан куып життек тә, «асыл кошларны» авыл кызларының култыкларыннан тартып алырга керештек. Мин, күзем төшкән «фәрештәмне» йомшак кына терсәгеннән әләктереп:—»Рөхсәт итегез озатып куярга»,—дидем. Ул башта сискәнеп, аптырап калгандай итте, аннан кинәт кычкырып ук жибәрде:

—... Кемне?

—... Сине ... то ес ... сезне!

—Синме?

—... Мин!

Кыз үтергеч бер караш белән аягымдагы кирзадан тегелгән сандалиемнан башлап кояшта унып беткән кепкама кадәр күз йөртеп чыкты да, көлеп жибәрде:

—Синең белән урам буйлап култыклашып кайтыйммы? Әллә крышаң киттеме? Як-ягыңа төкерен! Егет называется!

—Нигә, мина ни булган? ...

—Булган да шылган. Башта өстенә юньлерәк костюм алып ки! Аннан кызларга тагылырсың!

Шулай диде дә, кызлар артыннан йөгерде. Аларны куып житкәч, минем турыда нәрсәдер әйткәне, урам янгыратып көлгәне ишетелде.

Мин баскан урынымда багана кебек катып калдым. Бит очларым уттай кызышты, телем аңкавыма ябышты. Гарьләнүдән үземне кая куярга белмәдем. «Чибәр күңел аздырыр, алтын юлдан яздырыр»,—дип әйтә торган иде минем бабыкай. Белмим, нәрсә булыр иде, тик шунда яныма Хәбибрахман килеп житте.

—Мин дә иярмәдем тегенәр, һәй, рәтле кызлар түгел лә алар,—диде ул.—Синеке ни кыланган булды бит әле, ул таш курчак әйткәнне мин дә ишетеп тордым...

—Үзем гаепле,—дидем мин.—Нигә ияреренгә кирәк булган? Вәт дурак?!

—Ярар, шул кадәр бетеренмә! Ә кәчтүмгә килгәндә, алабыз без аны сиңа.

—Кәчтүм? Минамы? Әллә саташасың инде.

—Саташмыйм. Менә дигәнен алабыз!

—...Ничек? Нәрсә түләп?

—Ул ягын миңа калдыр ...

—Урынсыз шаяртканны яратмыйм.

—Яратмаганыңны беләм, холкың шундый синен. Әмма әйткән сүз—аткан ук. Кәчтүм алабыз сиңа! И всё!

—Кирәкми. Өстемдәге эти кәчтүме дә киярлек әле. Янасы сугыш беткәч булыр...

Хәбибрахман, кәчтүмнен ышкылып жөйләре тарала башлаган терсәк турларын тоткалап:

—Кызлар янына киеп чыгарлыгы калмаган шул монын, дускаем,—диде.—Озын сүзнең кыскасы, яна кәчтүм кирәк!

Бер үҗәтләнсә үҗәтләнә инде ул Хәбибрахман. Мин, кәчтүм турында артык сөйләшергә теләмичә, читкә борылдым. Ул исә уң кулын иплэп кенә жилкәмә салып мине үзенә таба борды:

—Тыңла әле! Беренчедән, син минем чын дустым. Икенчедән, син дуслыкның кадерен белә торган егет! Үзенә кыенлык килгәндә дә мине

ярдәменнән калдырганың юк. «Кунак ашы—кара каршы»,—диләр. Хәзер минем чират. Болай итәбез: мин иртән Минзәлә ягына китеп барам, ике көннән әйләнеп кайтырмын. Кайткач, без синең белән Красный Яр авылына барып (бездән өч чакрымдагы урыс авылы бу) бәрәнге сатып алырбыз.

—... Шуннан?—дидем мин, кызыксына баруымны яшерә алмыйча.

—Шуннанмы? ... Бәрәңгене Ижауга алып китәрбез, аны «Сенной» базарында «тәгәрәткәч», толчокка керербез, анда инде, дускаем, кәчтүмнең җаның теләгәнен алырга була.

Хәбибрахман шундый итеп сөйләде ки, ул эшнең барып чыгарына инде мин дә ышана башладым. Сүзендә торды, ике көннән тәмәкеле арбасын сөйрәп кайтып җитте. Минем дә нефтебазадан кайтып кына кергән вакыт иде. Ягулык тутырган мичкәне тракторчылар вагоны янына төшереп, яңа буш мичкә салып өйгә кайттым да, Хәбибрахман белән Красный Ярга киттек.

Красный Ярның кояшка каршы урнашкан бер яклы урамына керү белән урамда очраган урыслар безгә бәрәнге сатучының йортын күрсәттеләр. Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китим: сугыш елларында бу авыл халкы ачлык-ялангачлык күрмәде. Ничектер кечкенә колхозлар җинелрәк яшәделәр ул чакта.

Теге йортка кергәч, Хәбибрахман, бик оста сатулашып, үз акчасына өч чиләк бәрәнге сатып алды. Мин гаҗәпләнеп:

—Шушы өч чиләк бәрәнге кәчтүм сатып алырга җитәр дип уйлыйсыңмы?—дип сорадым.

—Борчылма. Җитәчәк,—диде ул җитди генә.

Икенче көнне башка көннәрдән дә иртәрәк кузгалып, Хәбибрахманның тәмәкесе кырыена бәрәнгебезне дә салып, китеп бардык. Нефтебазадан ягулык алып чыккач, атыбызны колхоз фатирында калдырып, поезд белән Ижауга киттек.

Поездан төшү белән Хәбибрахманнарга ашыктык. Хәтта чәй дә эчеп тормадык, тәмәкене аларда калдырып, капчыктагы бәрәңгене алмашлап җилкәбезгә күтәреп, «Сенной» базарына менеп киттек. «Сенной» дигән урынны беренче күрүем, базарның бөтен тарафы гөр килеп тора икән. Хәбибрахман мине бәрәнгем янында калдырды да, каяндыр үлчәү күтәреп килде. Елмаеп, «Бәхетең бар икән, дустым. Сатуда бәрәнге күренми»,—диде. Аннан «Кому картошка!»—дип кычкырып җибәрде. Шуны гына көткәннәр диярсең, халык төркеме җыелып та өлгерде. Сату башланды. Халыкта акча юк, бәрәнгене килолап кына алалар. Чын сатучы икән, Хәбибрахманның кулы уйнап кына тора, үлчәүдәге бәрәнге чүт кенә авыррак булса, кулындагы пычагы белән кисеп ала. Алма сата диярсең. Аның өчен әллә ничек миңа оят булып китте. Түзмәдем: «Хәбибрахман! Шул кадәр вакланма инде»,—дип ычкындырдым. Ул исә миңа усал итеп карап алды да, пышылдап: «Кысылма! Баскан урыныңда тик кенә тор!»,—диде. Шулай кирәктер, күрәсең, сату-алу эшен белмим шул мин. Белгәнем ат та дилбегә. Тын гына күзәтеп басып торам. Шәһәр халкы нык бетәшкән: йөзләрендә төс юк, күгелҗемләнеп эчкә баткан күзләр, җыерчык сарган битләр. Бигрәк авыр иде шул ул сугыш еллары.

Бәрәңгебез сәгать эчендә сатылып та бетте. Эче акча белән шыгрым тулган брезент букчабызны күтәреп, кием-салым сата торган «толчок» дигән урынга кердек. Ниләр генә юк икән ул «толчок» дигәннәрендә. Рәт белән тезелеп киткән сатучылар: күлмәк, чалбар, кәчтүм кебек товарларын кулларында күтәреп торалар. Үзебезгә ошаганын эзли торгач, ниһаять, урта яшьләрдәге, боек кына басып торган апа янына килеп туктадык. Апабызның кулында карасу зәңгәр төстәге кәчтүм. Рөхсәт сорап пинҗәген

киеп карадым,—үземә үлчәп теккәннәр диярсең! Кинәт күнелем ачылып, рәхәт булып китте!

Хәбибрахман, чалбарын билем турына куеп, озынлыгын чамалады да, бик канәгать булып елмаеп җибәрде һәм «Без бу кәчтүмне алабыз!»—диде.

Кәчтүм сатучыбыз үзебезнең татар милләтеннән булып чыкты, авыз эченнән «Бисмиллаһ» әйтеп, куллары белән инбашымнан сыйпап, аркамнан кагып сөйде. Мин аның күзендә яшь бөртекләре күреп сискәнеп киттем. Моның сәбәбен анларга тырышып кабат апага текәлдем. Ул исә, минем эчке халәтемне сизеп: «Син, улым, минем күз яшемә игътибар итмә, мин болай гына ...»—диде. Аның тавышы калтыранды, үзе һаман, миннән күзен ала алмыйча: «Балакаем, бигрәк ике тамчы су кебек ошагансын син минем улыма»,—диде. Мин ашыгып сорадым:

—Ул улыгыз кайда соң, апа? Исәнме?

—Юк шул... Исән түгел шул минем бәгырькәем,—диде апа өзгәләнеп.—Бер ай элек кенә авыр яраларыннан госпитальдә вафат булуы турында хәбәр алдык.—Мин бер өстемдәге кәчтүмгә, бер бичара апага карап нишләргә дә белмичә басып торганнан соң, кәчтүмне кире үзенә суздым:—Апа, җаным,—дидем мин.—Ала алмыйм мин сезнең бу кәчтүмегезне. Кадерләп саклагыз аны. Сатмагыз!

—Игелекле бала икәнсең, рәхмәт, улым,—диде апа, бите буйлап аккан күз яшен кулындагы яулыгы белән сөртә-сөртә.—Бер дә сатмас идем дә, сабыйларым ач шул. Әтиләре фронтта, йортымда бүтән сатар нәрсәм юк.—Ул ялварулы караш белән кәчтүмне кире сузды.

—Мә, ал, улым! Рәхәтен күр! Куанычлы киемең булып өстеңдә тузсын!

Апабызның сүзләренә Хәбибрахман да тәэсирләнеп, күнеле йомшады, хәтта сатулашып та тормады, шунда ук брезент сумкасыннан апабыз сораган акчаны чыгарып бирде.

Инде бераз алгарак китеп, шунысын да әйтим: бу кәчтүмне бик яраттым мин, сугыш елларындагы яшьлегем шуны киеп үтте. Аулак өйләргә, кичке уеннарга чыкканда кигән саен шул апакайның изге теләкләре исемә төшә иде.

Теге, күңелем кимсетелгән вакыйгадан соң бер ай чамасы вакыт узгач, ул кызлар белән янә очрашырга насыйп булды.

Хәбибрахманның Минзәлә ягына китеп барган көне иде, кичке уенга ялгызым гына чыктым. Өстемдә ак күлмәгемнең якасы кайтарылган шул кәчтүм. Башымда «пассажирлардан» әз-мәз кергән акчага сатып алган ярыйсы гына кепка. Аякта ак майга кара корым кушып ясалган крем белән ялтыраткан ботинка. Шуның өстенә бу арада гәүдәм дә калгып киткән кебек! Кыскасы, өстемдәге киемем дә ярыйсы, үзем дә ничава!

Уеннан тын алырга туктаган иптәшләрем белән кызык-мызык сөйләшеп утырабыз. Шул вакыт көтелмәгән хәл булды, теге таныш «курчаклар» кырыебыздан үтеп киттеләр дә, безгә каршы яктагы эскәмиягә килеп кунакладылар. Хәзергә алар ягыннан да, безнең яктан да сүз кату юк әле, астыртын гына күзәтешү бара. Теге «үз чибәркәем» белән кинәт күз карашларыбыз очрашты, мин аның йөзендә гаҗәпләнү әсәре күреп алдым. Менә ул елмайды да, миңа сәлам биргән кебек, башын селкеп куйды. Мин аның сәламенә дә, елмаюына да игътибар итмәскә тырыштым. Күрәм, битарафлыгым аның кызыксынуын көчәйтте генә. Күпмедер вакыттан сабырлыгы, мин-минлеге сынды бит моның. Кырыемдагы иптәшләрем урыннарыннан торып уенга чыккач, яныма килеп утырды. Күз бит ул, күпме генә карамаска тырышма, барыбер төшә. Тагын да чибәрләнеп киткән бу. Кызарткан иреннәре пешкән чия

төсле мыймылдап тора. Күзе дә зәңгәр төймә кебек зәп-зәңгәр икән. Көдрәләткән чәче маңгаена төшеп йөзенә тагын да чибәрлек өстәп тора. Пудра, хушбуй исе җиңелчә генә башны әйләндерә.

—Беләсеңме,—диде ул, сылана төшеп.—Сине күргәч, мин нинди хәлдә калдым? Карыйм, улмы соң бу ... мин әйтәм ... вообще ... син хәзер танырлык та түгел. Настоящий кавалер!

Мин дәшмим. Ә ул төчеләнүен дәвам итте.—Күрәм, теге вакыт өчен үпкә саклыйсың миңа. Дөресме?

Мин җавапсыз утыра бирәм.

—Беләсезме,—диде ул,—«сез»гә күчеп, менә бүген озатып куюыгызга мин каршы түгел. Пожалуйста!

Икеләнә калдым. Әллә чыннан да озатыргамы?! Бигрәк чибәр бит, җитмәсә, «пожалуйста» дип тә тора әнә. Ләкин кинәт башымда икенче бер уй калкып чыкты. «Озатыргамы? Шул кадәр кимсетелгәннән соңмы?»...

—Гаҗәп,—дидем мин,—Сез бит әле кайчан гына ...

—Кирәкми. Әйдә, онытыйк аны.

—Онытырга? Туктагыз әле, аңламыйм мин сезне, ничек бүген шулай үзгәрәсе иттегез икән ...

—Чөнки сез интересный егет булгансыз хәзер. Өстегездә замечательный костюм! Вообще уважать итмичә мөмкин түгел!

— Кирәкми,—дидем мин, аның артык кыланчыклыгын күтәрә алмыйча.

— Вообще сез мине аңлап җитмисез кебек ...

—Барсы да аңлашыла. Сез мине түгел, кәчтүмемне уважать итәсез икән бит.

—Ну и что?!—Аның йөзе болыт баскандай караңгыланып китте, чибәрлеге дә юып алган кебек юкка чыкты.—Значит, теләмисез мине озатырга?

—Теләмим. Тәкъдимегезгә рәхмәт. Хушыгыз!—Мин урынымнан торып иптәшләрем янына китеп бардым.

**Габдулла ГАЛИЕВ**

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# ТАШТАБАН

ХИКӘЯТ

Бар иде ди Казан каласында бер Таштабан. Төзелештә нәрсәгә тотынса, шуны чәчәк төсле итеп ясап бирә. Кулларыннан гөлләр тама, табаныннан чаткы чыгара. Бар нәрсәсе бөтен егетнең, тик кесәсендәге акчасын гына җил очырып бетерә икән.

Шул егетне Гөлфәри атлы тегүче кыз күзәтеп йөргән. Саз йорт бакчасында кичке уенда биегәндә кыз егеткә йөгән салган, синнән башка тормыш юк миңа, язылышыйк, әйдә, дигән. Никахсыз килеш бер кая да бармыйм, дип котылган Таштабан.

Кыш җиткән. Кыз егетне әти-әнисе янына авылга чакырган. Таштабан, колхоз базарына барып, култык астыннан гына чыгарып сатучыдан өр-яңа бүрек алган. Ах, әнисенең ботинкасы! Бүрек бит ямаулы икән. Шул бүрек белән киңәшкәч: «Мина дигән яр шулдыр инде»,—дигән дә Гөлфәригә ияргән.

Азгын җил Гөлфәриләр морҗасында флейта көйләгән. Күршедәге Рәбияләргә Бакырдан кунакка кайткан Сәет скрипкада уйнаган, моңлы борынгы җырлардан арыгач, шаян такмакка күчкән.

Скрипкамның биле сынса,
Калай белән яматам.
Үзем матур булмасам да
Матур кызлар яратам.

Гөлфәри белән Таштабанның туе шул булган. Бергә яшәп киткәч, планнары зурдан инде боларның. Таштабан чемодан төбендәге машина йөртүче таныклыгын кулына алып әйләндергәләгән. Машина сатып алырбыз. Җәйләрен Арзамас, Дивеевко аша үтеп сезнең авылга кунакка йөрербез, дип Гөлфәринең күңелен юаткан. Тик машинага дигән акча гына авырлык белән, тиенләп кенә табылган. Фатир инде шәп анысы, аны Таштабанга төзелештә эшләгән өчен, бушлай биргәннәр. Җиде яшьлек кызлары яна фатирга күчкәч, «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген», дип очынган.

Ходайның бирмеш көне гомер тиз үтә. Кызлары мәктәпне бетереп кияүгә чыккан, үзе балалар үстерә башлаган. Гөлфәри белән Таштабан һаман машинага дип акча җыя икән. Төзүче белән тегүчегә аны тамызып кына түләгәннәр.

Бер көнне болар боткага дип ярты кадак май сатып алган. Ашарга утырганнар. Ә ботка тамакны ерта, коры икән.

—Моның мае кая соң?—дигән ир.

—И-и, Таштабан, туя белмәдең һаман. Баярук авызыма бер йомшак нәрсә тиде. Шул булгандыр май,—дигән хатын. Ул Таштабанны ике көнгә бер генә ашарга тәки өйрәтә алмаган.

—Аптырама, хатын. Яшәрбез,—дигән ир.—Илдә чыпчык та үлми. Эштән соң ул, икенче камыт киеп, бакчага йөгергән. Бакча гаиләне

туйганчы ашаткан, арткан җиләк-җимешне Таштабан базарда саткан. Акчалары ике арзан машиналык җыелган. Тик машинаны гына бер каян ала алмаганнар, сатучысы булмаган.

Хәерчегә җил гел каршы. Егерме бер чакрымлы машина юлын унбергә калдырып, Таштабан бакчадан Казанга җәяү җилдергән арада дөньялар бозылып киткән. Гаиләнең машинага дип җыйган акчасы банкта зәңгәр төтенгә әйләнгән.

—Әйттем бит процент бәласен. Безгә килешми ул,—дигән Таштабан.—Ярар, нәрсә булсын безгә, каткан тезгә.

Бер дә исе китмичә, ул тагын бер бакча юнәткән. Берсендә алма үстерә хәзер, икенчесендә шайтан алмасы—бәрәңге. Бакчадан бакчага йөгерү Таштабанга берни түгел. Тик менә бәрәңгене сату—әҗәл. Кафтау арты кешеләре Кукмара бәрәңгесен базарга китереп сатканда Таштабанныкы чикләвек хәтле генә булып күренгән. Алучысы юк икән.

Тик дөнья барыбер матур, тормыш дәвам иткән. Бакчада үскән нигъмәтләр белән авызы балланган Гөлфәри дә яшелчәче булып киткән. Яшел суганны базарда Гөлфәри сата инде хәзер. Җәйнең матур көннәрендә ул чәчәкләргә, суганнарга су сипкән, кошлар сайравын хәйран калып тыңларга яраткан. Көзгә хәтле бакчадан кайтмас идем, дип сөйләнә башлаган.

Аны тыңлап торсаң, Гөлфәридән дә шәп бакчачы юк инде. Эшкә унган шул үзе. Таштабан ясаган түтәлләрне түтәл дип тә белми, үзенчә ясап куя. Өйрәнә инде бу, дип Таштабан бер сүз дә дәшмәгән. Беркөнне, Таштабан чәчкән кишер түтәлен бозып, суган утырткан бу. Тишелеп чыкканны көтә бит инде хәзер. Суганнар һаман яшәрми.

—Нишләп үсми бу суган?—дип Таштабанны аптыраткан. Икәүләшеп түтәлне караганнар.

—И-и, авылда үскән морза кызы! Суганнарны тамырларын күккә каратып күмгәнсең бит!—дип көлгән Таштабан.

Чын бакчачы булып җиткәнче Гөлфәри күрсәткән галәмәтләр бер генә булмагандыр әле. Бакча бөтенесен үзенә сыйдырган, ул Гөлфәридән дә, Таштабаннан да унганрак булып чыккан. Болар малтабар булып житешкәндә генә төзелештә эш булмый башлаган, яртышар ел тик торганнар. Таштабанга җитәкче: «Иртәгә эшкә бөтенләй чыкмассың инде»,—дигән.

Мондый авыр сүзне Таштабан бер дә ишетәсе килмәгән. Тагын ун ел төзелештә эшләсә, күпме гаиләне фатирлы итәр иде ул. Казанда, Мәскәүдә, Ташкентта, Әстерханда, Төмәндә, Спитакта—тагын әллә кайларда санап бетергесез биналар, торак йортлар салган осталар бит алар. Хәзер генә ул Казан төзелешләрен үзбәк, төрек, таҗик, кыргыз, уйгур, әзәрбайҗан, әрмән, грузин кешеләре баскан.

Эшсез ничек торсын Таштабан? Аны дуслары төзелеш сакларга чакырган. Сакта Таштабан торганда төнге Казан тынып калган. Мулланур Вахитов һәйкәле янындагы бакчада сандугачларның өзелеп сайравы аны әсир иткән. Бүтән объектларны саклаганда да кошлар оркестры Таштабан җанына ял биргән.

Кремль янындагы Авыл хуҗалыгы министрлыгы бинасы төзелешендә кошлар сайравын тыңларга вакыты да булмаган аның. Метро төзелешендәге кебек, пенсионер көндәшләр гвардиясе үз эшен эшләгән. Кыскартканнар аны. Янәсе, мондый төзелешләрне таза, яшь пәһлеваннар сакларга тиеш.

Кыскартырга дигәндә оста шул түрәләр. Белми алар Таштабанның машина сатып алырга хыялланганын. Аның табаны таш төсле дә бит, ботинкасы чыдамый, аны төзәтергә дә акча кирәк. Тешләре таза анысы, сызламый. Гөлфәринекен яматырга тагын акча сораганнар.

Шундый уйлар белән йокларга яткач, Таштабан төш күргән. Имеш,

анардан имтихан алалар. Берсе: «Кем ул Шотаберган?—дип сорый. Алишер Новаины, Эйнштейнны, Кулибинны сорасалар ни була? Әбугалисинаны, Сәиф Сараины да ишеткәне бар. Шотаберган дигән әллә немец, әллә яһүд кешесен күргәне дә юк ичмаса. Аптырап беткән төшендә. Йоклап торгач, сәер бу төш ни булыр икән?—дип юрарга керешкән. И, зиһенсез икән шул Таштабан. Шотаберган дигәннәре бернинди дә чит ил кешесе түгел ләбаса. Ул бит метро төзелешендә эшләүче үз кешебез Шота! Әле Таштабан метро төзелешен саклаганда, шул прораб, тиен дә түләтмичә, аңа бер КамАЗ ком биргән. Шул комны тирес урынына Таштабан бакчага сибеп чыкса, тагын күпме җиләк-җимеш үсәр. Беркем түгел, калган ураза төсле, шул ком анардан имтихан ала икән. Ярты гасыр элек бу тирәдәге комны Таштабаннар бригадасы төзүчеләре хәзерге «Проспект» сәүдә үзәге турысыннан ит комбинатына таба су үткәргеч сузганда үз кулларыннан үткәргән булган. Төшне юрагач, Таштабан радионың колагын борган. Диктор Абхазия белән Осетиядә Россиянең грузиннарга каршы сугышканын сөйләп ята икән.

Вәт сиңа төш! Утыз ел бергә эшләп йөргән төзелеш остасы Таштабанга Хабаровтан, йә бүтән берәүдән төшендә ник бер хәбәр килеп ирешсен. Ә грузин прорабының игелеге нәкъ сәгатендә изгелек булып төшкә кергән. Хәерлегә генә була күрсен мондый төшләр. Гөлфәри дә көн саен уфтана. «Әй Алла, әгәр син булсаң, сугышларны булдырма. Бакчада өебез дә искергән, зур калаларга бәла килсә, кая барырбыз?» дип кайгырта башлаган.

—И-и, Гөлфәри, Гөлфәри, син Ходайга артың белән борылгансың бит. Шикләнмичә, чын күңелеңнән сора син. Әле шунда да Ходай кемгә ярдәм итәргә, кемгә итмәскә икәнен үзе белер,—ди икән Таштабан.

Болар машинага дигән акчаны пыяла банкыда жиргә күмеп саклый бит хәзер. Көннәрдән бер көнне шуны санарга утырганнар. Саныйлар, саныйлар, өч тәгәрмәчлек кенә чыга.

—Кая киткән безнең бер тәгәрмәч?—дигән Таштабан.

—Үзең бит: «Безнең бабайлар Төмән ягыннан булган», дисең. Шунда тәгәрәде акчаның дүртенче өлеше.

—Нишләп тәгәрәсен?—дип гаҗәпләнгән Таштабан.

—Шулай инде. Минем энем Себердә икәнне беләсең бит. Марҗасы аны тагын куып чыгарган. Дүрт апасы булган килеш берДәнбер энебез бомж булып йөрсенме? Җибәрдек инде үзе сораган хәтле акчаны дүрт кыз туганы бергә җыеп.

—Туган авылыгызда Адилә улы Равил берүзе хуҗа булып яшәп ята дисең түгелме? Кайтса ни була шунда? Буш өйләр никадәр анда. Ике буйдак, өйләнеп тә җибәрсә, дүртәү булырлар иде.

—Өйләнде ди! Әйбәт кеше, яшь чакта өйләнә булыр иде инде алар,—дип әйткән Гөлфәри.

—Белмим, Гөлфәри, минем дә башым катты әле монда. Әллә энеңне, әллә авылыгызны кызганырга шунда.

Ир белән хатын киңәш-табыш итешкәч, калган акчага иске «Жигули» сатып алырга булганнар. Канатлы ат төсле, очып китәргә әзер торган Чибәркәйне «Пегас» автосалоныннан эзләп тапканнар. Шунда әйләнгәләп йөргәннәрен күрсәгез, сез дә Гөлфәри төсле бәхетле минутлар кичерер идегез. Таштабан шатлыкны да, хәсрәтне дә эченә сыйдыра белә әле. Гөлфәри бөтенләй әсәрләнгән. Ул ат муенын сыйпагандай, ялтырап торган «Жиделе»нең тимерләренә кулларын тидереп-тидереп алган. Утырып киткәч, бөтенләй кош тоткан төсле булган Гөлфәри.

—Син, Гөлфәри, сабыр ит бераз! Соңрак үзеңне дә йөртергә өйрәтербез,—дип ир хатынын кисәтеп куйган.

Алар шулай ике яклап баручы бишәр рәтле машиналар ташкынына кушылган.

Ярты ел машиналары тел-теш тидертмәгән. Аннары... Чыгымчы аттан да уздырган. Йә кинәт кенә сүнеп, кабат кабынмыйча аптыраткан. Йә төчкерә, пошкыра да бөтенләй бармый икән. Яннан Таштабан, арттан Гөлфәри тәртә-тәртә берсендә машинаны кәчкә кабызганнар, бүтән утырмабыз инде мона дип саклау урынына китереп куйганнар. Бакчага барырга кирәккәч, тагын, тагын шулай азапланганнар. Тәмам туйдырган бу хәл. Автосервиска ремонтка бирергә сөйләшеп караганнар. Сатып алганда түләгән хәтле акча сораганнар. Каян килсен хәзер андый акча боларга. Кабат автосалонга илтсәләр, анда да егерме меңгә генә җибәреп булса инде моны, дигәнне ишеткәч, калдырмаганнар. Гомер буе җыйган акча җәл бит боларга. Танышбелеш машина «духторларына» да күрсәткәннәр. Аз-маз көйләштереп, атна-ун көн йөрерлек итәләр икән дә бит, шуннан озакка чыдамый.

Беркөнне Таштабанның башына тәвәккәл уй килгән. Туган ягындагы риваятькә кушылып туган әлеге уй. Бер тапкыр Зариф исемле кеше аты белән Мунчала буасы тавыннан менеп бара икән. Таунык уртасына житкәч, моның аты чыгымчылаган. Әйтерлек зур йөге дә юк үзенең, тартмый. «Ах, син шулаймы әле?» дигән дә, Зариф, арбасындагы мылтыгын алып, үз атын атып үтергән. Таштабанда ул замандагылар кызулыгы юк инде. Шулай да машинасын кызганып тормас ул. Машинаны караштыргалаган да, соңгы тапкыр кабызып, Яманкол чокыры янына алып киткән. Ул чокыр тирән, куркыныч, күпләр аны әйләнеп уза икән.

Килеп житкәч сикереп төшәргә дә, кабызган килеш машинаны шунда мәтәлдерергә ниятләгән ул. Егерме метрлап ара калгач, машинасын сүндермичә генә туктаткан. Төшеп чонгылны барып караган. Куркыныч хәл булмаслыгына ышангач, машина тартмасындагы «кирәге чыкканда ярап куяр» дип салган акчаны себереп алган. Зур эш башкарган шикелле, шул тимер акчаларны ул рәхәтләнеп санаган. Төп-төгәл алтмыш җиде сум икән. Бу акчаның бүген үк кирәге чыгачак, дигән ул. Машина сатып алганчы әле, ул табаны шартлаган саен бакчада җир маена чылаткан йон оекбаш киеп йөри торган булган. Машина сатып алгач, «Монардан җир исе килә», дип оекбашны Гөлфәри чүплеккә чыгарып аткан. Инде менә машинаның да исе килмәс.

Ә җир маеннан башка яшәп булмый. Табаннарны бүген үк майларга кирәк, җир мае сатып алырга бу тимер акчалар ярап куяр, дигән.

Таштабан, әле генә санаган акчаларны кесәсенә салып куйган да, машинасын чонгылга якынайткан. Егерме метрлап ара тиз үтелгән. Менә «Жиделе» тонык тавыш чыгарып түбәнгә очкан.

Аннары Таштабан тар сукмактан эре-эре атлап олы юлга таба китеп барган.

**Рәис ИДРИСОВ**

# КАЛАМБУРЛАР

Менә сезгә, **каләм бурлары,**
Татар теле **каламбурлары.**

Көн буе теңкәгә **апа тия:**
“Каян синдә мондый **апатия?**”

Әллә синдә **ар акылы:**
Һәр эшең дә **аракылы?**

Әзерләсә **аш аучы**
Булыр микән **ашаучы?**

Әгәр кушса **бакалавр**
Ашар микән **бака лавр?**

Сорадым **балакайдан:**
“Бәләкәй **бала кайдан?**”

Кемгә кирәк **батырлык,**
Суга кереп **батырлык?**

—Нинди кеше була **битсез?**
—Нигә сорыйсыз, ул **бит сез!**

Сезнең эше **динсезгә**
Нигә кирәк **дин сезгә?**

Әгәр басса **кан даланы,**
Туйдырырмы **кандаланы?**

Чирләре булгач **сансыз**
Әтиең калган **сансыз,**
Ник кыланасың, **сансыз!**

Ә нигә килмәдең **соң?**
—Килергә дәрестән **соң**
Булган иде инде **соң.**

Ник җыясың **юкагач?**
—Бүтән төрле **юк агач.**

Сыерымның сөте **ак,**
Чиләгем тулганчы **ак.**

Ишекләре **ап-ачык,**
Шыпырт кына, **апа, чык.**

Монда җыелган ир-**ат,**
Мылтыгыңнан туры **ат,**
Җиңүчегә бүләк—**ат.**

Сыер сатып **ат алма,**
Эшкуар дип **аталма.**

Китермәгез аның **ачуын,**
Ә көтегез ишек **ачуын.**

Кереп ян капка **аша**
Кура җиләге **аша.**

Агызсаң да **бал Ыкка**
Ул җим булмый **балыкка.**

Башта яз суырып **бармактан,**
Факт дип мөхәрриргә **бар, мактан.**

Син бит **бас,**
Монда **бас.**

Череп баткан **басма,**
Уртасына **басма.**

Әйткән булсаң **баштарак,**
Күрер иде **баш тарак.**

Инде җиткәнсең **буйга,**
Бу агачны куй **буйга,**
Аркылы түгел, **буйга.**

Бу икмәгең **искергән,**
Күтәргән һәм **ис кергән.**

Үзең дә ал **йөкләмә,**
Миңа гына **йөкләмә.**

Сызсаң шырпы **кабына**
Шырпыга ут **кабына.**

Менә **кара,**
Төсе **кара,**
Язып **кара.**

Уң якка **кара: бодай,**
Сул якта—**карабодай.**

Җир асты дип җиде **кат**
Сиңа әйттем ничә **кат,**
Ышанмасаң, дөмек, **кат.**

**Әдһәм ШӘЙХРАМОВ**
*Башкортстан, Бакалы.*

## КЕМ БАШЫНА БУ СӨМСЕЗ ТАШ?..

### Әмир иле

**Планетам минем гаҗәп, сәер,**
**Аяз көннәр анда, һава тын.**
**Әмир иле дигән континентта**
**Моникасын сөя Клинтон.**
*2000 ел, 12 февраль.*

### Бар бер шәхси тәнкыйтьчем...

**Шәхси секретарем да юк,**
**Юк минем шәхси итчем.**
**Аллага шөкер, Союзда**
**Бар бер шәхси тәнкыйтьчем!**
*1980 ел.*

### Җеннәрне адаштырып

**Йөрим Казан урамында**
**Җеннәрне адаштырып.**
**Намуссыз зат китап язган**
**Галимнән урлаштырып.**
*2000, 20 гыйнвар.*

### Сейф эчендә...

**Сейф эчендә яшим мин,**
**Тышта—ишек, эчтә—ишек,**
**Яшәсәм дә сейфта мин,**
**Ике кесәм дә тишек.**
*2001 ел, 27 декабрь.*

### Шигырь яза ул...

**Шигырь яза ул янәсе...**
**Чабата үрә бер ир.**
**Исем беткәнме дөньяда?!**
**Ят исем кушкан әнкәсе,**
**Имезлеге кайда икән?**
**Кайда икән мәммәсе?**
**Шигырьгә боты җитмәгәч,**
**Пасквиль яза һәммәсе.**
*1980 ел.*

## Кем?

**Айну белмәс... Зәхмәтле ул!**
**Ачыклау да моны ансат.**
**Такмак язып өлфәтле ул...**
**Язганнары—суперфосфат.**
*1985, 21 октябрь.*

## Камилләр...

**Шырпы чүбедәй кадалчык**
**Калкып торган камыллар.**
**Асылын белми, болгана**
**«Идел»ләрдә Камилләр.**
*1985 ел, 24 октябрь.*

## Пародист

**Гүзәл шигырь күреп калса,**
**Борынына кергә ис.**
**Шагыйрь җанын талап яши**
**Мародердай пародист.**
*1985, 9 март.*

## «Чиксез» бәхет

**Татарның Бәхете чиксез,**
**Шат ул! Күкләр иңри.**
**Җитми икән бер икона—**
**Әллә нинди «матери».**
*2004 ел, 15 декабрь.*

## Күптән...

**Сәер кеше**
**Инде**
**Мин күптән.**
**Үз капкама**
**Үзем**
**Туп кертәм.**
*2005 ел, 19 апрель.*

**Әмир МӘХМҮДОВ**

*Шигырьләр Ә. Мәхмүдовның «Әмир иле» китабыннан алынды. Казан—2007 ел. «Идел-Пресс» нәшрияты.*

## Әмирҗан Моталлаповка 75 яшь



Актаныш төбәгендә яшәп иҗат итүче язучы Әмирҗан Моталлапов исеме әдәбият сөючеләргә көндәлек матбугатта басылган күпсанлы очерклары, хикәя-повестьлары аша яхшы таныш. Аның әсәрләрендәге геройлар—язучының якташлары, балачак дуслары. Алар аша без актанышлыларның җыелма образларын күрәбез, телләрен, фикерләү һәм яшәү рәвешләре белән танышабыз.

Әмирҗан Закирҗан улы Моталлапов 1934 елның 23 июнендә Актаныш районы Мерәс авылында туа. 1946 елны авыл мәктәбенең дүрт классын тәмамлагач, Теләкәй җидееллык мәктәбендә укый, 1950-53 елларда Актаныш урта мәктәбендә белем ала. Мәктәпне тәмамлагач, бер ел Чат җидееллык мәктәбендә балалар укыта, шуннан армиягә алына.

Армиядән кайткач, Актаныш район Советы башкарма комитетына гомуми бүлек мөдире булып урнаша. Яшьтән каләм тибрәткән егет 1957 елда районның «Колхоз ударнигы» газетасына эшкә күчә. Шул ук елны районда оешкан «Әдәби түгәрәк»кә йөри, хикәя, очерклар яза, әсәрләре республика матбугатында басыла башлый. 1965 елда читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый.

1962 елда Минзәлә районына кушылган Актаныш 1964 елны кабат аерыла һәм вакытлыча ябылып торган газета 1965 елда янадан ачыла. Ә. Моталлапов та газетадагы эшчәнлеген дәвам итә: әдәби хезмәткәр, хатлар бүлеге мөдире, җаваплы сәркәтип, редактор урынбасары вазифаларын башкара. 1989 елда аны типография директоры итеп билгелиләр. Шул елларда басмаханә китаплар да нәшер итә башлый, районда яшәп иҗат итүче каләм әһелләренең дистәдән артык китабы дөнья күрә. Матбугат өлкәсендәге тырыш хезмәте өчен Ә. Моталлапов 1991 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә лаек була.

Ә. Моталлапов проза, публицистика өлкәсендә иҗат итә, шигъри әсәрләр авторы буларак та билгеле. Аның әсәрләре район, республика газета-журналларында даими басыла, аерым җыентыклар булып чыгып тора. Арадан берсе—«Без—Актанышныкылар» (2002) китабы күренекле якташлары белән таныштырды. Соңгы елларда язучының «Яшьлегем кайтавазы» (2004), «Юлларда үткән еллар» (2005), «Авылда давыл» (2007), «Чын кеше» (2008) исемле китаплары дөнья күрде. Әсәрләрендә күбесенчә авыл тормышы, аның үткәне, бүгенгесе, проблемалары хакында сүз бара. Аларда шулай ук кеше язмышлары, аның кичерешләре, мәхәббәт хәлләре калку итеп күрсәтелә. Ә. Моталлапов балалар өчен дә иҗат итә. Ул нәниләргә багышланган берничә китап авторы: «Мин жебек түгел» (2004), «Бал сатучы төлке» (2006), һ.б.

Ә. Моталлапов 2000 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Кыям Миңлебаевның тууына 80 ел

Язучы һәм тәрҗемәче Кыям Миңлебаев (Кыяметдин Сәләхетдин улы Миңлебаев) Татарстанның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында дөньяга килә. Унбер яшендә ул әти-әнисе белән Казан янәшәсендәге Дәрвишләр (Дербышка) бистәсенә күченә, биредә җидееллыкны һәм Кабан күле буендагы 12нче татар мәктәбен тәмамлый. Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң ике ел Сарман урта мәктәбендә урыс теле укыта.

1955 елның көзендә янәдән Казанга кайтып, Татарстан китап нәшриятына эшкә урнаша, кырык елга якын биредә төрле вазифалар башкара.

К. Миңлебаев—иҗади сәләтен тәрҗемә жанрына багышлаган гаять тәҗрибәле вә һөнәрмәнд тәрҗемәчеләребезнең берсе. Гомумән, ул бөтен җиһанга киң таралган утыздан артык әсәр—китапны туган телебез аша милләтебезгә тәкъдим иткән кеше. Мәсәлән, П. Цвирканың «Сандугач», Н. Носовның «Белмәмеш мажаралары», Л. Толстойның «Балачак», «Үсмерчак», «Егетчак», В. Шишковның «Хәсрәт дәрьясы», А. Толстойның «Инженер Гаринның гиперболоиды», «Аэлита», «Михнәтле заман», Г. Маркесның «Ялгызлык», Ж. Амадуның «Габриэланың гыйшкы», Э. Войничның «Кигәвен» һәм дә башка мәшһүр әсәрләрне татарча ул яңгыратты.

К. Миңлебаев озак еллар дәвамында КДУда укыта, фәнни-әдәби түгәрәкләр алып бара, Татарстан Язучылар берлеге каршында тәрҗемәчеләр остаханәсенә җитәкчелек итә. Аның тәрҗемә теориясенә һәм практикасына кагылышлы мәкаләләре, рецензияләре, сынлы сәнгатькә багышланган язмалары да матбугатта даими дөнья күрә. Сынлы сәнгать белән нык кызыксынуы, бөегебез Бакый Урманче иҗатына мөкиббәнлеге нәтиҗәсе буларак, язучы «Бакый» романын иҗат итә. Аннары исә әдипнең «Акыллы атын мактар» исемле роман-хатирәсе дөнья күрде.

Әдип 2005 елда вафат булды. Ул РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1969 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.



*Казанда Шигырь бәйрәме уздырыла башлауның беренче еллары. Ул чорда бәйрәм шәһәр үзәгендәге Тукай һәйкәле янында (Кабан күле буе) үтә иде. Шигъри митингтан соң җыелган әдәбият-сәнгать әһелләренең бөтенесе диярлек хәзер гүр ияләре инде... Таныш йөзләр, газиз исемнәр... Алгы рәттә утыручылар—бүгенге көн укучылары өчен аз билгеле шәхесләр–Мәхмүт Бөдәйле һәм Илгиз Кәлимуллин. 1964 ел.*



*Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин (1934-94). Ул озак еллар "Казан утлары" журналында тәнкыйть бүлеге мөдире булып эшләде.*



*Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин (1942-94).*



*Яшьләре әле 50гә дә тулмаган зур әдипләр. Сулдан уңга: Хәсән Сарьян (1930-78), Әхсән Баян (1927), Әнвәр Давыдов (1919-1968). 1967 елгы фото.*



*Прозаик Фатыйх Хөсни (1908-96) һәм драматург Юныс Әминев (1921-82) язучыларның Тукай клубында үткән җыелышыннан соң. 1979 ел.*

## Алексей Остудин



Остудин Алексей Игоревич 1962 елны Казан шәһәрендә туган. Мәктәп елларында укыганда ук (ул шәһәрнең 131 мәктәбен тәмамлаган) шигырьләр язу белән шөгыльләнә. Тормышында төрле-төрле эшләрдә көч түгәргә туры килсә дә, ул әдәбияттан аерылмый, шигъриятне язмышы дип танып яши. Үз вакытында А. Остудин Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтына укырга керә, әмма күп тә үтми аңа бу уку йорты белән саубуллашырга туры килә. 1985 елда Казан университетының филология факультетына укырга кереп, аны 1990 елда тәмамлый. Соңрак Мәскәүнең Югары әдәби курсларында укып, тәнкыйтьчеләр бүлеген тәмамлый. Шул елларда Алексей Остудинның «Шалаш в раю» (Мәскәү, «Мол. гвардия» нәшр), «Весеннее счастье» (Казан, Тат. кит. нәшр.), «Улица Грина» (Мәскәү, «Москов. раб.» нәшр.) исемле китаплары басылып чыга. Күләмнәре белән әллә ни зур булмасалар да, алар яшь шагыйрьне шигърият дөньясында танытырлык дәрәҗәдә булалар.

Кыргый базар мөнәсәбәтләре тормышка көннән көн тирәнрәк кергән 90 нчы елларда инициативалы һәм җегәрле яшь егеткә шигъръяттән беркадәр ерагаеп алырга туры килә. Ул үз эш-бизнесын булдыра: «Норма» дигән шәхси нәшрият оештыра. Төзелеш эшләре өчен төрле белешмәләр бастыра, реклама-информация юнәлешендә газета чыгара... Әмма әдәбият барыбер күңел түрендә кала бирә, иҗат ялкыны сүрелми. Соңгы 4-5 ел эчендә аның яңа китаплары («Бой с тенью», «Рецепт невесомости», «Проза жизни») Харьков, Киев, Санкт-Петербург шәһәрләрендә дөнья күрде.

Алексей Остудин эшчәнлегенең тагын бер ягын әйтү кирәк: ул үз инициативасы белән, үз хисабына Казанда еш кына төбәкара һәм халыкара шигырь фестивальләре оештыра, Казан укучыларын төрле шәһәрләрдә яшәүче кызыклы һәм талантлы шагыйрьләр белән таныштыра, аралаштыра. Шуңа күрә, әдәбият сөючеләр арасында Остудин шәхесенең дәрәҗәсе шактый югары.

2009 елның 20 мартында, Кабул итү коллегиясенең карары нигезендә, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе Остудин Алексей Игоревичны Татарстан язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—Рөстәм Сабиров, Евгений Сухов, Лилия Газизова) әгъза итеп кабул итте.

## Наил Ишмөхәммәтов



Ишмөхәммәтов Наил Радик улы 1964 елны Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск шәһәрендә туган. 1987 елда Магнитогорскиның Г. Носов исемендәге тау-металлургия институтын тәмамлап, аннан инженер-электрик белгечлеге алып чыга. Байтак еллар металлургия комбинатының тимер кайнату цехында эшли. 1994 елны гаиләсе белән Казанга күченеп килә. Соңгы унбиш ел эчендә үз белгечлеге буенча төрле оешмаларда эшли. 2001 елдан бирле «Идел-Пресс» полиграфия комбинатында инженер-электронщик вазифасын башкарып килә.

Наил Ишмөхәммәтов әсәрләре чагыштырмача соңрак—2003-04 елларда күренә башлады. Әдәби дөньяга соңрак килсә дә, ул нык иҗади тизләнеш алды: берничә ел эчендә күп эшләр башкарды. «Октябрь», «Дружба народов», «Казанский альманах», «Идел», «Казань» журналларында актив басылды; төрле конкурс-ярышларда җиңеп чыкты... Күрәсең, эчке әдәби әзерлеге, потенциаль мөмкинлеге яшьтән үк булган.

Бүгенге көндә Наил Ишмөхәммәтов беренче чиратта тәрҗемәче буларак билгеле. Татарстан Язучылар берлегенә кабул иткәндә каләмдәшләре Н. Ишмөхәммәтов иҗатының шушы ягына игътибар иттеләр дә инде. Тәкъдимнамә язучыларның берсе—Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин болай яза: «Наил Ишмөхәммәтов—әйбәт тәрҗемәче. Ул рус телен дә, татар телен дә камил белә. Күп кенә шагыйрьләрнең, язучыларның шигырьләрен, хикәяләрен тәрҗемә итеп русча чыга торган газета-журналларда, альманахларда бастырды. Минеч өчен иң кыйммәтлесе шул: ул бернинди подстрочникларсыз тәрҗемә итә. Гаиләдә чын татар тәрбиясе алган, халкыбызның гореф-гадәтләрен күңеленә сеңдергән Наил Ишмөхәммәтовка минем ышанычым зур». Үзләренең тәкъдимнамәләрендә шундый ук фикерләрне Зиннур Мансуров, Фәнзаман Батталлар да белдергән.

Ишмөхәммәтов Наил Радик улы 2009 елның мартында Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## ЯЗ. ШИГЪРИЯТ. ТУКАЙ

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышланган күптөрле чаралар, апрель ахырында үзенең иң югары ноктасына күтәрелеп, республикабызда халыкара дәрәҗәдәге зур бәйрәмгә әверелде.

Шагыйрьнең туган көнендә—26 апрель иртәсендә башкалабыз үзәгендәге Г. Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу мәрәсиме булды. Анда Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, халык депутатлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

***

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янындагы мәйданда үткәрелгән Шигърият бәйрәме быел масштаблылыгы белән үзенчәлекле булды: анда Шанхай хезмәттәшлек оешмасы әгъзалары һәм күзәтүчеләре саналган дәүләтләрнең VI мәдәният министрлары киңәшмәсендә катнашучылар да бар иде. Гомумән, халык быел аеруча күп җыелды. Хөрмәтле кунаклар, иҗат әһелләре белән берлектә, Г. Тукай һәйкәленә чәчәк салдылар.

—Габдулла Тукай бүген дә татар мәдәниятенең символы булып кала,—диде Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева тамашачылар алдында ясаган чыгышында.—Шагыйрь дөньяга килгән көнне Туган тел бәйрәме үткәрелү дә бик табигый. Ә Шигырь бәйрәменә елдан-ел яңа бизәкләр өстәлә тора. Бүген рәсми рәвештә Габдулла Тукай сайты ачылды. «Үзебез» яшьләр хәрәкәте үткәреп килә торган «Мин татарча сөйләшәм» акциясе дә күркәм традициягә әйләнде. Телне музейга куеп саклап булмый, аның яшәеше, бүгенге көне һәм киләчәге һәр кешенең үзеннән тора.

Шигърият бәйрәмендә катнашучыларны Россия мәдәният министры А. Авдеев сәламләде. «Габдулла Тукайны төрки халыклар гына түгел, бөтен дөнья яхшы белә,—диде ул.—Тукай—Россия Федерациясендәге барлык халыклар мәдәниятенең асыл ташы. Аның иҗаты аша татар халкы барлык кыйтгаларда танылды. Тукай татар теле өчен эталон булырлык әсәрләр, күпмилләтле Россиянең бик күп буыннары өйрәнерлек зур иҗат мирасы калдырды».

Аннары Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева Президентыбыз М. Шәймиевнең 2009 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турындагы Указын игълан итте, яңа лауреатларга иҗат уңышлары һәм саулык-сәламәтлек теләде. Шуннан соң быелгы лауреатлар: шагыйрь З. Мансуров һәм Камал театры артисты Р. Төхвәтуллин, иҗатларының югары дәрәҗәдә бәяләнүе өчен, җәмагатьчелеккә, республика җитәкчелегенә ихлас рәхмәт сүзләрен белдерделәр, ә Качалов театры артисты С. Романова исә Г. Тукайның русчага тәрҗемә ителгән шигырен укыды.

Аннан соң, гадәттәгечә, Г. Тукай мөнбәреннән бер-бер артлы шагыйрьләргә сүз бирелде. Шигърият бәйрәмендә Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Миннуллин, Р. Вәлиев, Р. Гаташ, Л. Шагыйрьҗан, А. Хәлим, И. Гыйләҗев.Ә. Рәшит, Г. Морат, Р. Зәйдулла, И. Иксанова, Л. Газизова, А. Остудин, Р. Аймәт, Л. Шәех, Л. Гыйбадуллина, Р. Сәлах, Э. Һадиева, Й. Миннуллина, Р. Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Шигърият сөючеләр Алтай Республикасы Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Б. Бедюров һәм Саха (Якутия) Республикасының халык язучысы Н. Лугинов сәламләвен алкышлап кабул итте. Бәйрәмдә танылган җырчылар башкаруында Г. Тукай шигырьләренә җырлар, халык көйләре башкарылды, артистлар һәм балалар тарафыннан шагыйрь әсәрләренә нигезләнгән җырлы-биюле тамашалар күрсәтелде.

Шул ук көнне Камал театры бинасы янында, башкалабызның Бауман урамында Г. Тукайның туган көненә һәм Туган тел бәйрәменә багышланган төрле чаралар үткәрелде.

***

Менә унбиш ел инде апрель аенда Балтач районында да Шигърият бәйрәме оештырыла. Быелгы тантанада Язучылар

берлеге рәисе урынбасары В. Нуриев, әдәбият галиме, Тукай җәмгыяте рәисе Х. Миннегулов, шагыйрьләр З. Мансуров, Г. Мөхәммәтшин, Р. Зәкуан, Л. Янсуар, Х. Бәдигый, Й. Миннуллина, Р. Сәлах катнашты. Алар иң әүвәл Г. Тукайның Сасна Пүчинкәсе зиратында җирләнгән газиз әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберенә чәчәкләр салдылар, Җәлил хәзрәт Фазлыев аның рухына дога багышлады. Аннары Субаш авылы мәдәният сараенда Г. Тукайның «Туган тел» шигыре язылуга 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Балтач районы күләмендә үткәрелгән күптөрле балалар иҗат конкурсларына йомгак ясалды, җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

***

Һәрвакыттагыча, Арча районы бөек якташының туган көненә аеруча хәстәрле рәвештә әзерләнгән. Бәйрәмгә чакырылган кунаклар башта Арча педагогика көллиятендә эшләп килүче Әлифба музеенда булдылар.

Арча үзәгендәге мәйданда үткәрелгән Шигърият бәйрәмендә катнашучыларны муниципаль район башлыгы А. Нәзиров сәламләде. Аннары Казаннан килгән каләм әһелләре—Язучылар берлеге рәисе шагыйрь И. Ибраһимов, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә шул көннәрдә генә лаек булган шагыйрь З. Мансуров, драматург Т. Миңнуллин, шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, Р. Вәлиев, Р. Миңнуллин, Алтай Республикасы Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Б. Бедюров, Саха (Якутия) Республикасының халык язучысы Н. Лугинов, «Мәгариф» нәшрияты директоры М. Вәлиев, язучы В. Нуриев, яшь шагыйрь Р. Мөхәммәтшин, Г. Тукайның дүртенче буын туганы, журналист Р. Гыйлемханов һ. б.лар чыгыш ясады. Бәйрәм мәйданында яңгыраган сәламләү сүзләре һәм шигырьләр җыр, музыка, бию, театрлаштырылган тамашалар белән аралашып барды. Тантана ахырында Арча үзәгендәге әдип-якташлар аллеясендә Г. Камал һәйкәле ачылды. Шуннан соң бәйрәм Г. Тукайның Яңа Кырлай авылында урнашкан музейда дәвам итте. Кунаклар комплекс янәшәсендә истәлеккә яшь чыршылар да утыртты. Каләм әһелләрен Арча муниципаль районы башлыгы А. Нәзиров озатып йөрде.

***

Шигърият һәм Туган тел бәйрәмнәре кысаларында республикабызның Тукай районында да бөек шагыйребезгә багышланган чаралар үткәрелде. Очрашуларда язучылар Т. Миңнуллин, Н. Гыйматдинова, В. Имамов, һ. б.лар катнашты.

***

Габдулла Тукайның тууына 123 ел тулу уңаеннан, Истанбулда күргәзмә оештырылды. Анда бөек шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы белән бәйле фотографияләр, аның китаплары, истәлекләре урын алды. Күргәзмәне «Тукай» мәдәният һәм мәгърифәт Үзәге рәисе Кюршат Алтай ачып җибәрде. Үз чыгышында ул татар милләте өчен Габдулла Тукайның рухи маяк, берләштерүче символ булуын искәртте. Үзәкнең матбугат һәм яшьләр комитеты җитәкчесе, журналист Рушания Алтай исә Тукайның якташы, күренекле язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең шагыйрь турында язган мәкаләсеннән өзекләр белән таныштырды.

Төркия татарлары арасында танылган шәхес, күренекле җәмәгать эшлеклесе, дипломат Синан Утрау үз чыгышында Тукай иҗатының актуальлеген әйтеп, аны рус шагыйре Александр Пушкин белән тиңләде. «Кыска гомерендә бары тик 7-8 ел гына иҗат итүенә карамастан, Габдулла Тукай Пушкин кебек күп һәм саллы әсәрләр язып калдырган. Кызганыч, Пушкинны таныган кебек, Тукаебызны дөнья әдәбияты әле танып бетерми. Безгә Тукайны дөнья халыкларына күбрәк танытырга кирәк»,—диде ул.

***

Бу көннәрдә республикабыз шәһәр һәм районнары, шулай ук милләттәшләребез күпләп яши торган башка төбәкләр, әнә шул рәвешле, бөек Тукай рухы, Туган телебез рухы белән яшәде.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

### ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ ТУЛУНЫ БӘЙРӘМ ИТҮ ТУРЫНДА

Бөек татар шагыйре, яңа татар әдәбиятына һәм хәзерге татар теленә нигез салучыларның берсе булган Габдулла Тукайның илебез һәм дөнья әдәбиятына гаять зур өлеш кертүен исәпкә алып, шулай ук 2011 елда аның тууына 125 ел тулуны билгеләп үтү йөзеннән, карар бирәм:

1. 2011 елның апрелендә Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар уздырырга.
2. Татарстан Республикасы Министр-

лар Кабинетына өч ай вакыт эчендә:

Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру җәһәтеннән, бөек татар шагыйренең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле объектларны ремонтлау, реконструкцияләү, төзекләндерү, музей экспозицияләрен төзү, әсәрләрен һәм аның турындагы әдәбиятны бастырып чыгаруны күздә тоткан республика планын, тиешле чараларның җаваплы башкаручыларын, үтәү срокларын, аларны финанслауның күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына:

тиешле муниципаль берәмлекләрдә Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган тантаналы чаралар әзерләү һәм уздыруны оештыруны тәэмин итәргә;

Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру буенча төп чараларның республика планын гамәлгә ашыруда актив катнашырга.

4. Республика оешмаларына, җәмәгать берләшмәләренә, иҗат берлекләренә, башка кызыксынган органнарга һәм оешмаларга Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган чараларны әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. «Татмедиа» ачык акционерлар җәмгыятенә, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлар җәмгыятенә, республика һәм җирле гаммәви мәгълүмат чараларына Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуны бәйрәм итүгә әзерлекне һәм аны уздыруны киң яктыртуны оештырырга.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты**
**М. Ш. ШӘЙМИЕВ.**

*Казан, Кремль, 2009 ел, 22 апрель.*

## АЙТМАТОВНЫ ОЛЫЛАУ

Г. Камал театры бинасында Шанхай хезмәттәшлек оешмасы илләре мәдәният министрлары очрашуы кысаларында зур бер чара—дөньякүләм мәшһүр язучы Чыңгыз Айтматов истәлегенә багышланган иҗат зыялылары очрашуы булып узды.

Кичә романтик рухта—язучының туган иле—серле Кыргызстан тауларын хәтерләткән күренешләрдән башланып китте. Таулар белән уратып алынган шушы илдә туып-үскән, әтисе ягыннан кыргыз, әнисе ягыннан татар булган Чыңгыз Айтматов Татарстанга күп тапкырлар килде. Ә менә язучының соңгы елларда Казанга сәфәрләре ТР Президенты М. Шәймиевнең Ч. Айтматовка аеруча җылы игътибары белән дә бәйле була.

Премьер-министр урынбасары-мәдәният министры З. Вәлиева да үз чыгышында Шанхай хезмәттәшлек оешмасы илләре мәдәният министрлары очрашуы кысаларында Чыңгыз Айтматов истәлегенә багышланган кичә уздыруның зур мәртәбә булуын искәртте. «Әдип Европа илләрендәге һәм бергәлекләрендәге хәлнең торышын аеруча киң күзаллап һәм тирәнтен тоемлап яшәде, иҗатында аларга каршылыклар, аңлашылмаучылыкларны бетерү турында еш мөрәҗәгать итте»,—диде ул.

Республикада язучының нәсел-нәсәбе белән бәйле урыннар барлана, алар истәлекле урынга әверелә. Ч. Айтматовның нәсел тамырлары барып тоташкан Балтач районы Борбаш авылында ана һәйкәлбюст кую планлаштырыла. Язучының бабасы Хәмзә абзый белән бәйле Кукмара районы Мәчкәрә авылында бу нәселгә кагылышлы тарихи урыннар аеруча күп. Кукмараның 1 нче татар гимназиясенә Ч. Айтматов исемен бирү дә күздә тотыла. Казанда уза торган халыкара «Алтын мөнбәр» кинофестивалендә бер көн Чыңгыз Айтматов истәлегенә багышланган.

Россия мәдәният министры А. Авдеев Ч. Айтматовның гаҗәеп дәрәҗәдә талантлы булуын һәм аның әсәрләрен дөньяның барлык почмакларында да яратып укуларын, аңа ышануларын әйтте. «Кыргыз атадан, татар анадан таулар арасындагы бер кечкенә авылда туган кеше дөньяның әхлакый кыйммәтләрен югары күтәргән бөек әсәрләр һәм табигатьне философларча анлап, өйрәнеп, безгә ничек эшләргә тиешлегебезне әйткән»,—диде ул.

Кичәдә шулай ук Кыргызстан мәдәният һәм мәгълүмат министры С. Раев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь И. Ибраһимов, Алтай Республикасы Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Б. Бедюров, Саха Якутия Республикасы халык язучысы Н. Лугинов, РФ Көнчыгышны өйрәнү институты директоры Рыбаков һ. б. чыгыш ясады.

Искә алу кичәсендә Чыңгыз Айтматовның якыннары—хатыны Мәрьям Урматова, сеңлесе Роза, улы Илдар да бар иде.

## ТАТАРСТАНГА ДАН КИТЕРГӘН ҖИҢҮ

2 май көнне Татарстанда тагын бер чемпион пәйда булды: «Зенит-Казан» Мәскәү өлкәсенең «Искра» командасын җинеп, волейбол буенча Россия чемпионатында алтын медаль яулады. «Баскет-холл»да узган хәлиткеч уенда якташларыбызны җиңүгә рухландырып торган җанатарлар арасында Президент Минтимер Шәймиев тә бар иде. Җиңүчеләр алтын медальләрне дә республикабыз җитәкчесе кулыннан кабул итеп алды.

—Татарстан спортының алтын адымнары дәвам итә,—диде Президент, чемпионнарны котлап.—«Рубин»—Россия чемпионы, «Ак Барс»—Гагарин кубогы иясе, инде «Зенит» та илнең иң көчле командасы булды. Бу—бик кадерле җиңү. Чөнки соңгы елларда Россия волейболында җиңүләр җинел генә бирелми. Бездә—алтын егетләр! 9 еллык тарихында команда беренче лигадан Чемпионнар лигасында җиңүгә кадәр юл үтте. Бүген исә икенче мәртәбә Россия чемпионы булды. Рәхмәт Татарстан даның үстерүчеләргә!

## УНИКАЛЬ КҮРГӘЗМӘ

Мәгълүм булганча, апрельнең соңгы атнасында башкалабызда Шанхай хезмәттәшлек оешмасының VI кинәшмәсе булып узды. 27-28 апрельдә «Хәзинә» милли галереясендә Шанхай хезмәттәшлек оешмасына кергән илләрнең рәсем һәм декоратив-гамәли сәнгать күргәзмәсе эшләде. Монда Кытай, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казакъстан, Таҗикстан, Россия, Татарстан рәссамнарының һәм остакулларының 495 эшен күрергә мөмкин иде.

Күргәзмәне ачу тантанасында кинәшмә кунаклары—төрле илләрнең мәдәният министрлары катнашты. Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева үз чыгышында күргәзмәнең уникальлеген, мөһимлеген искәртте.

Галереядә урын алган сәнгать әсәрләре милли тамырларга тоташуы белән игътибарны җәлеп итте. Бирелә һәр халыкның бары үзенә генә хас үзенчәлекләрен күрергә мөмкин»,—диде Россия мәдәният министры Александр Авдеев.

Әлеге күргәзмәдә рус остакулларының сырган юрганнарын, таҗикларның бизәкләп тукыган келәмнәрен, Кытай рәссамнарының нәзакәтле бизәкләр белән чуарланган рәсемнәрен, иксез-чиксез казакъ далаларының киңлеген, иркенлеген тоярга мөмкинлек биргән сынлы сәнгать әсәрләрен күреп хозурланырга мөмкин иде.

Кызганыч, күргәзмә нибары берничә көн генә дәвам итте.

## ЙОЛДЫЗЛАРГА ЯКТЫ ЮЛ

Менә тугызынчы ел инде «Пирамида» мәдәни-күңел ачу сәхнәсендә яңа «йолдызлар» кабына. 16 февральдән 27 апрельгә хәтле Президент М. Ш. Шәймиев карамагында «Созвездие—Йолдызлык» фестивале республика төбәкләрендә узды. Аның оештыручылары: Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм күрсәтү фонды, муниципаль берәмлекләр советы, Мәдәният, Мәгариф һәм Фән министрлыклары, «Татарстан—Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе.

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Зилә Сөнгатуллина рәислегендәге жюри төбәкләрдә 2224 чыгыш карады. Фестивальнең йомгаклау концертында 26 районнан 700дән артык бала үз сәләтен күрсәтте. Фестивальдә талантлар саны елдан-ел артуы күзәтелә. Моңлы тавышлар, кызыклы биюләр, оста алып баручылар пәйда булуы сөендерә. Моңа кадәр «Созвездие—Йолдызлык»ның лауреаты булган 18 егет һәм кыз бүген Мәскәүдәге дәрәҗәле сәнгать уку йортларында белем ала. Бу юлы да аларның чыгышын Россия мәдәният министры Алексей Авдеев, уку йортлары педагоглары һәм Шанхай хезмәттәшлек оешмасы вәкилләре, Азия илләренең мәдәният министрлары да карады. Премьер министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева әлеге фестивальне, Азия илләреннән балалар чакырып, халыкара дәрәҗәдә үткәрергә мөмкин булуын да әйтеп узды.

Фестивальнең иң зур бүләге Гран-прины Зәйдән Айдар Сөләйманов яулады. Аңа 70 мең сум күләмендә стипендия тапшырылды. Хореография буенча Гран-прига Яшел Үзәннең «Орфей» бию коллективы ия булды. Аларның студиясенә 80 мең сум бирелде. Беренче урыннарны алган балаларга да стипендияләр шактый зур—40ар мең сумга җитә. Бөтен катнашучыларга да Айрат Хәйруллинның хәйрия фондыннан кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

## ЕЛ КИТАБЫ

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе Мәдәният министрлыгы белән берлектә һәр елны үткәрелә торган «Ел китабы» конкурсына йомгак ясады.

Конкурста 129 әсәр катнашып, шуларның 43е чәчмә әсәр, 41е тезмә әсәр, 23е балалар әдәбияты, 22се рус телендә чыккан матур әдәбият иде.

Чәчмә әсәрләр буенча 1нче урын Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете», 2нче урын Альберт Хәсәновның «Җәнбәт җәвере», 3нче урын Рәфкать Кәраминең «Олы юл да сикәлтәле» әсәрләренә бирелде.

Чәчмә әсәрләр буенча 1нче урынны Зөлфәтнең «Ходай сулышы», 2нче урынны Флёра Гыйззәтуллинаның «Башкаемда дөнья исәпләре», 3нче урынны Мөхәммәт Мирзаның «Тере су» әсәре алды.

Балалар әдәбияты буенча 1нче урын «Журнал укучы жираф», 2нче урын Бикә Рәхимованың «Җайдак малай», 3нче урын Нәкыйп Каштановның «Кучтәнәч» әсәрләренә бирелде.

Рус телендә чыккан матур әдәбият буенча 1нче урынга Разил Вәлиевнең «Строки жизни», 2нче урынга Борис Вайнерның «Ниндзя из Самураевки», 3нче урынга Равил Бохараевның «Золотые ступени» һәм «Устами татарского народа» китаплары чыкты.

## «ҖИСЕМ» ҮЗЕН КҮРСӘТӘ БАШЛАДЫ

26 апрельдә Татар дәүләт гуманитар педагогика университетында «Җисем» кинофестиваленә йомгак ясалды.

Быел кинофестивальдә 100гә якын фильм катнашты. Бу—узган елгы белән чагыштырганда 70 эшкә күбрәк. Күренекле кинорежиссерлар Рамил Төхфәтуллин, Салават Юзеев, Идмас Үтәгәнов, сценарист Айсылу Хафизова, рәссам Булат Гыйльмановтан торган жюрига яшь киночыларның эшен бәяләү бик җиңел булмагандыр. Җиңүчеләрне яшь үзенчәлегенә бүлеп, 7 номинациядә билгеләделәр. Байбулат Батуллинның (Казан) «Җәйнең беренче кар»ы кыска метражлы нәфис фильм номинациясендә җиңде. Ләйсән Кәбированың (Питрәч) «Мин—лидер» фильмы иң яхшы юмористик фильм дип табылды. «Иң яхшы анимация фильмы» дигән исемне Казан егете Рамил Абдуллинның «Тартмагыз!» дигән мультфильмы алды. Апас районы Каратун мәктәбе төшергән «Аукцион» фильмында (Алмаз Гыймадиев әсәре буенча) иң яхшы актерлар төркеме уйнаган дип табылды. Иң яхшы оператор эше, сценарист, режиссура номинацияләренең дә җиңүчеләре бар иде. Алар Казаннан Ильяс Камалов, Зөлфия Зөбәирова, Минзәлә районыннан Айназ Гайниева. Студентлар иҗаты да шундый ук номинацияләр буенча аерым бәяләнде. Ә инде Гран-прига Казан яшьләре Илшат Рәхимов, Гөлнара Әхмәтова, Равис Хөснетдинов төшергән «Хөкем» («Күк канцеляриясе») дигән фильм лаек булды.

Болай булса, кем белә, безнең сәләтле яшьләребез мәшһүр «Оскар» бүләкләрен дә яуларлар әле.

## ХӘЕРЛӘРЕ БЕЛӘН ҮССЕННӘР

«Илһамлы каләм» әдәби әсәрләр конкурсына йомгак ясалды. Иң уңышлы дип табылган әсәре өчен Гран-прины Теләче районы Югары Кибәхуҗа урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы Гөлнар Минекаева алды. «Иң яхшы шигъри әсәр», «Иң яхшы чәчмә әсәр», «Иң яхшы драма әсәре», «Иң яхшы публицистик әсәр», «Иҗади зәвык һәм сәнгатьлелек», «Сюжет һәм хикәяләү үзенчәлекләре», «Авторның үз стилен чагылдырган әсәр», «Композицион осталык» номинацияләрендә тагын 17 җиңүче билгеле булды. Җиңүчеләрнең әсәрләреннән туплап чыгарылачак җыентыкка кереш сүзне республика Президенты үзе язарга вәгъдә иткән.

Әлеге конкурс узган елның 25 декабрендә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм ТР Язучылар берлеге тарафыннан республика күләмендә 9-11 нче сыйныф укучылары арасында игълан ителгән иде. Аның I турына 175 укучыдан эш килгән, ә II турга шуларның 89ы узган.

«Конкурсны булдыру, беренче чиратта, татар укучылары арасында сәләтлеләрне барлау, тәрбияләү һәм үстерүгә бәйле. Аның төп максатлары укучыларда иҗади һөнәрләргә карата кызыксыну уяту, татар халкының телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклап калу һәм үстерү, гуманитар юнәлештә сәләтле яшьләрне эзләү һәм алар белән эшләү, ТДГПУда белем алу мөмкинлеге бирүдән гыйбарәт»,—диләр аны оештыручылар.

## ЯЗУЧЫЛАР БДИга КАРШЫ

Россия язучыларының апрель аенда узган съездында каләм осталары рус теле һәм әдәбиятыннан БДИ (бердәм дәүләт имтиханы) тапшыруны элеккечә инша (сочинение) язу белән алмаштыруны сорап Россия федерациясе Хөкүмәтенә махсус резолюция юллады. Рус теле буенча, шиксез бер фикергә килерләр, ә менә Россиядәге күпсанлы милли телләр белән нишләргә?

## ХАҖГА КОМИТЕТ ӘЗЕРЛӘЯЧӘК

Татарстанда Хаж эшләре буенча комитет төзеләчәк. Бу хакта Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте хәбәр итә. Хәзерге вакытта оешманың документлары әзерләнә инде. Хаж комитеты Дин эшләре идарәсе каршында булыр дип фаразлана. «Иделхаж» төбәкара үзегенең директорлар советы рәисе Рөстәм Гатауллин сүзләренә караганда, яна оешма таможня хезмәте, Сәламәтлек саклау министрлыгы белән хезмәттәшлек итеп, изге сәфәргә кагылышлы мәсьәләләрне тикшерәчәк.

## КАРДӘШЛӘРНЕҢ ТУГАН ТЕЛ КӨНЕ

25 апрель—чуваш мәгърифәтчесе, беренче әлифба төзүчесе Иван Яковлевнын туган көне. 1992 елдан башлап Чувашия Республикасынын Югары Советы карары нигезендә әлеге көн Туган тел көне булarak билгеләп үтелә башлады.

22 апрельдә «Ак Барс» яшьләр үзәгендә Туган тел көненә багышланган тантаналы кичә узды. Казанлылар белән чаллылардан тыш, чарада Аксубай, Алексеевск, Әлки, Тәтеш, Югары Ослан, Яшел Үзән, Лаеш, Кайбыч һәм Буа районнары вәкилләре дә катнашты.

Чувашия Республикасы халык артисты Вячеслав Христофоров, «Янра юра» һәм «Сявал» ансамбльләре катнашындагы концерт бик күнелле узды.

## МАЭСТРО РӨСТӘМ АБЯЗОВ

31 марттан 4 апрельгә кадәр республикада II Абязов фестивале узды. Ул виртуоз скрипкачы, танылган дирижер, Татарстанда гына түгел, ә Россия күләмендә дә билгеле Рөстәм Абязовка—50 һәм анын иҗатына 30 ел тулуга багышланган иде.

Фестиваль кысаларындагы чаралар гаять күптөрле булды. КДУнын тарих музеенда Р. Абязовка багышланган «Маэстро Рөстәм Абязов» дигән күргәзмә оештырылды. 1 апрельдә С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында «La Primavera» камера оркестры концерты булды. Шулай ук Рөстәм әфәнденең скрипкада башкарган әсәрләре һәм оркестр тарафыннан 20 ел дәвамында яңгыраган композицияләре урын алган компакт-дисклар тәкъдим итү чарасы да уңышлы узды.

II Р. Абязов фестивален ТР дәүләт симфоник оркестры концерты йомгаклады. Бу көнне оркестр белән Рөстәм Абязов үзе идарә итте.

## АРТИСТКА ХӨРМӘТ

28 апрельдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык артисты Асия Галиевага 80 яшь тулу унаеннан иҗат кичәсе үтте. Үзенең 60 ел гомерен сәхнәгә багышлаган актерны Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова тәбрикләде һәм ана хөкүмәт бүләге—«Фидакарь хезмәт өчен» медале тапшырды. Юбилярны Театр әһелләре берлеге рәисе Ринат Тажетдинов, үзе эшләгән театр коллективы, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, консерватория укытучылары, үзе укыган 98 нче мәктәп педагоглары котлады. Соныннан тамашачы хозурына заманында Асия Галиева Гөлҗамал булып уйнаган «Гөлҗамал» спектакле тәкъдим ителде.

## ФОТОЛАРДА—ТАНЫШ ЙӨЗЛӘР

Милли музейда фотограф Шамил Абдюшевнын «Казан папарацие» дип исемләнгән фотокүргәзмәсе ачылды. Экспозициядә Татарстанның танылган сәясәтчеләре, спортчылары, тренерлары, гомумән, танылган шәхесләрнең фотолары урын алган. Фотограф гайре табигый шартларда кабатланмас мизгелләрне тотып ала белә. Ул ыгы-зыгылы киеренке тормыш казанында кайный. «Шәхес һәм спорт», «Мегаполистагы тормыш», «Объектив ялгышмый»—фотографны кызыксындырган темалар монын белән генә дә чикләнми. Үткән ел «Бәллүр каләм» премиясенә лаек булган фоторепортернын эшләре әледән-әле республика басмаларында, шул исәптән безнең журналда да дөнья күреп килә.

## ТАТАР ИСЕМНӘРЕ БУЕНЧА ҖИТДИ ХЕЗМӘТ

Казан дәүләт университетынын татар филологиясе һәм тарих факультетында Галиуллина Гөлшат Рәис кызы «Лингвокультурологик аспектта татар антропонимы» дигән темага докторлык диссертациясе яклады. Кеше исемнәренә бәйле булган бу хезмәт күпләр өчен кызык һәм файдалы булырга тиеш.

Шуны истә тотып, галимә Татарстан Республикасы Милли архивындагы метрика кенәгәләреннән, ЗАГС бүлекләрендәге документлардан, вакытлы матбугат сәхифәләреннән, сүзлекләрдән һәм башка чыганаклардан 61 меңнән артык татар антропонимнарын туплаган. Аларны төрки-татар мәдәнияте кысаларында тикшергән. Исемнәрнең килеп чыгышын дингә, ышануларга, гореф-гадәтләргә һәм халкыбызнын мәдәни кыйммәтләренә бәйләп аңлаткан.

Хезмәтнең фәнни җитәкчесе—татар исемнәре буенча атаклы галим—Гомәр Саттаров. Г. Галиуллина үзе дә үткән елдан бирле факультетта «Хәзерге татар теле» кафедрасы мөдире булып эшли.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар мәдәнияте зур югалту кичерде: 2009 елның 22 апрелендә, 88 нче яшендә иң өлкән язучыларыбызның берсе—шагыйрь, прозаик, Бөек Ватан сугышы ветераны **Әдип Малик улы Маликов** вафат булды.

Әдип Маликов 1921 елның 16 августында Башкортстан АССРның хәзерге Яңавыл районы Югары Чат авылында укытучы гаиләсендә дөньяга килә. Пермь шәһәрендәге татар педагогия училищесында укыган чорда Ә. Маликов әдәбият белән ныклап кызыксына башлый һәм үзенең беренче шигырьләрен иҗат итә.

1939 елда училищены тәмамлагач, Әдип Маликовны Пермь өлкәсенең Барда районы Солтанай авылы җидееллык мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр. Шул ук елның көзендә аны Армия сафларына алалар. 1945 елның августында ул разведчиклар отделениесе командиры сыйфатында Көньяк Сахалин утравын япон самурайларыннан азат итү сугышларында катнаша. Бу операциядә үзенә йөкләнгән хәрби бурычны батырларча үтәгәне өчен ул «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Армиядән кайткач, Ә. Маликов Татарстан радиосында әдәби-драматик тапшырулар редакторы булып эшли башлый һәм Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан Мәскәүгә М. Горький исемендәге әдәбият институтына укырга җибәрелә, 1951-60 елларда Әдип Маликов яшьләр газетасының үз хәбәрчесе сыйфатында Минзәлә һәм Әлмәт төбәкләрендә эшли. 1955 елда Татарстан нефтенең үзәгенә әверелгән Әлмәт шәһәрендә әдәби берләшмә оештырып, күп еллар дәвамында аңа җитәкчелек итә. 1963 елда шушы әдәби берләшмә нигезендә Әлмәт язучылар оешмасы барлыкка килә.

Ә. Маликов—бай әдәби мирас калдырган әдип. Ул өч дистәгә якын китап авторы. Аның 50-70 нче елларда иҗат ителгән «Ташчы», «Гайшә апа», «Фәрдәнә», «Салкын Алан» кебек поэмаларында һәм күпсанлы шигырьләрендә замандашларының хезмәт пафосы белән өретелгән тормышчан образлары сурәтләнә. Шушы ук сүзне аның очерклары һәм балалар өчен язган поэма, шигырьләре турында да әйтергә мөмкин. «Без Кояшны юлда каршылыйбыз», «Гашыйклар юлы» кебек проза китаплары һәм, ниһаять, авторның солдат еллары белән бәйле «Яшьлек утравым» исемле повестьистәлеге, соңгы елларда иҗат ителгән «Гомер мизгелләре» исемле документаль повесте һәм башка әсәрләре заманның сәнгатьчә документаль елъязмалары буларак игътибарга лаек.

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен Әдип Маликов «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә, «Почет билгесе» орденына лаек булды.

Әдип Маликов—татар халкының күренекле шагыйрәсе Сажидә Сөләймановаының ире иде. Алар кулга-кул тотынышып, үрнәк гаилә булып яшәделәр.

Талантлы шагыйрь, прозаик Әдип Маликовның якты истәлеге укучылар күңеленә һәрвакыт сакланыр.

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы,**
**Татарстан Республикасы Язучылар берлеге идарәсе.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* *М.Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театры.*

*Дүртенче биттә:* язучы **Зөфәр Дәүләтов**.

# Яңа китаплар




**Шәукәт Галиев.** Сиңа әйтер сүзем бар: шигырьләр, фәлсәфи фикерләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.—367 б. Тиражы—2000 данә.

«Берәү матурлыкны тудырып рәхәт таба, берәү әзеренә соклана. Матурлыкка битарафлар да, аны юкка чыгаручылар да аз түгел. Миңа матурлыкны иҗат итү кызыклы...» Китапның тышына ук язылган бу сүзләр халык шагыйренең иҗади кредосы булып яңгырый. Шагыйрьнең 80 еллык юбилеена атап чыгарылган бу китап сайланма характерда: аңа авторның үзе өчен кадерле әсәрләре тупланган: Заман һәм яшәеш хакында шигырьләр, әдәбият-сәнгать турында уйланулар...

Китапта шактый биобиблиографик белешмә биреләчәк. Кереш сүзне шагыйрь Рафис Корбан язган.




**Һанс Кристиан Андерсен.** Уникс сәяхәтче: әкиятләр. Казан: «Мәгариф» нәшр., 2008.—175 б. Тиражы—1000 данә.

Татар халкының берничә буыны дөнья әдәбияты классикларын үз ана телебездә укып үсте, мәгънәви һәм эстетик тәрбия алды. Элеккеге чорлардагы кебек үк булмаса да, бу хәл хәзер дә дәвам итә. «Мәгариф» нәшриятында «Дөнья классикларын татарча укыйбыз» сериясенең булуы шуны раслый. Һ. К. Андерсенның бу китапка кергән унҗиде әкиятен тәрҗемәче һәм мөхәррир, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Люция Гыйззәтуллина тәрҗемә иткән. Югары полиграфик кимәлдә нәшер ителгән бу китап нәни укучыларыбыз өчен зур бүләк булачак.

Китапның рәссамы—Д. Нәүрузова. Мөхәррире—Л. Гатауллина.



Зөфәр Дәүләтов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)